# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

9
СЕНТЯБРЬ
1974

## Бу санда

Г. АФЗАЛ. Китаплар язмышы. Шигырьләр . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Тау ягы повесте . . . . . . . . 7

М. СӨНДЕКЛЕГӘ 70 ЯШЬ

М. СӨНДЕКЛЕ. Көндәлек дәфтәреннән. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
С. САФУАНОВ. Күңелендә — ике халык моңы . 84
Х. ВАХИТ. Мәхәббәтең чын булса. Пьеса . . . 87

А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 175 ЕЛ

А. ПУШКИН. Шигырьләр . . . . . . . . . 122

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 129
М. ЗАРИПОВ. Тавык кошмы, түгелме! . . . . 133

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

И. БЕЛЯЕВ. Солдат төймәсе . . . . . . . . 143

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Татар типографияләре тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . 166

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Н. ХИСАМОВ. «Кыйссам Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше . . . . . . . . . . . . 175

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ГАЛИЕВ. Гомернең июне . . . . . . . . 183

Ф. САФИУЛЛИНА. Язучының тел осталыгы һәм тәрҗемә . . . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.

Телефоннар: Баш редактор — 3-03-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 28/V-1974 ел, Басарга кул куелды 12/VII-1974 ел, ПФ 04077. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87.000 экз.
Заказ Ю-138. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары». 1974 ел.

## Гамил Афзал

### Китаплар язмышы

Кемнәр күрмәгән
нинди илләрдә
Китаплар чыгару хәстәрен!
Кол Гали уйланган
айлы таңнарда
Болгар ташына куеп дәфтәрен.

Халыклар язмышы —
китаплар язмышы.
Гомерлек афәтләр китереп,
Болгар янды,
Казан янды, —
Китаплар яндылар үкереп.

Имамнар кушканнар —
үтәгән куштаннар,
Шагыйрьнең башын кисхәннәр;
Заманнар үткәннәр,
гасырлар кичкәннәр,
Китаплар исәннәр, исәннәр.
Чыралар яндырып,
мәдрәсә тынганда
Китаплар күчергән хаттатлар.
Авылдан-авылга,
базарда, урамда
Китаплар сатылган, китаплар...

Музейда китаплар,
кадерле урында,
Эндәшми-сөйләшми ятармы,
Мәхәббәт, яхшылык,
гаделлек турында
Мең еллык хыялы татарның!

Былбыл моңы булып
илләрдә йөргәндер
Йосыф һәм Зөләйха шатлыгы,
Ак тастымал булып
өйләргә кергәндер
Таһирлар, Зөһрәләр сафлыгы.

Кайчакта кемгәдер
кадерсез күренеп,
Яттыгыз чормада, тарлыкта,
Кияү бүләк иткән
яулыкка төренеп,
Тордыгыз түрдәге сандыкта.
Чүлләрдә салына,
тауларга сарыла
Халык юлы белән китап юлы;
Әстерхан ягына,
Сахалин ярына
Барып җитте бөек Тукай моңы.

Солдат капчыгында,
кайларда яттың син,
Юлларың, хәвефле, күңелсез;
Төрмәләр астыннан
ватанга кайттың син,
Җиңүче булып, үлемсез.

Уйлылар уйланган,
уйсызлар тик торган,
Язу да күрмәгән әйбәтләп,
Нәп-нәни кулларга
китаплар тоттырган
Фидаи җаннарга мең рәхмәт!

Гөлбостан илләрдә
без бар дип, эз бар дип,
Очыгыз, китаплар, киек казлар кебек,
Сандугач телегез,
һәр кемгә килегез
Бәхетле, якты язлар кебек!

## Гамлет

Сөңгеләр, ачы авазлар, мәкерле серле эңгер.
Тәхеткә менә явызлар, кабергә төшә кемдер.

«Быть или не быть» дисең син шомланып һәр сәхнәдә,
Булмыйдыр утсыз-төтенсез, әйтче, хикмәт нәрсәдә!

Булды, җитте шикләнүләр, әйтче, Гамлет, «быть!» диеп,
Елмаеп-көлеп яшәргә ихтыяр бик нык диеп.

Сук сугалсаң, я кизәнмә, кылма эшнең яртысын,
һәр вакыт хурлык китерә ярты ялган, ярты чын.

●

Картайсам да кайнар җилләр көтәм,
Кайгы илләренә ашыкмыйм.
һәр агачның җилфер-җилфер иткән
Яшел яфрагына гашыйкмын.

Бар начарны, бар яхшыны тоеп,
Көлә-көлә гомер буйладым.
Чәчәк исен иснәп туймадым мин,
Кояш нурын күреп туймадым.

Шатлык дәрьяларын кичәсем бар
Күзем белән сөеп тамчысын,
Барча картлар кебек, эчәсем бар
Хәсрәтнең дә иң-иң ачысын.

## Яшьтәшләр

Яшьләнә күзләр, яшьләнә,
Яшьтәшләр киткән саен.
Уйнап-көлеп яшисе дә,
Уйнап булмый, дускаем.

Ямь тулы еллар исләрдә,
Без әле яшьләр идек;
Гарасат җилләр искәндә
Без инде гаскәр идек.

Аяусыз кысылды тешләр
Яңгырда, буранда да.
Тимердәй торды яшьтәшләр
Тимерләр сынганда да.

Фронтлар артка чиктеләр,
Фронтлар алга барды;
Яшьтәшләр дәрья кичтеләр,
Яшьтәшләр кала алды.

Үлемне җиңде яшьтәшләр
Үлемсез илгә атлап,
Изге җирнең һәр үләнен
Йөрәкләр белән каплап.

Асыл егетләр иделәр,
Усал егетләр иде.
Борчулы хатлар килделәр,
Болгавыр чаклар иде.

Йолдызлы бүрекле алар,
Калдылар хәтерләрдә.
Йолдызлы каберләр дә бар,
Язусыз каберләр дә.

...Әйдә, яралар яңарсын,
Кая, бер төрик әле!
Агарган чәчләр агарсын,
Җимертеп йөрик әле!

Китмәгез әле, яшьтәшләр,
Сафларда сирәк бит без,

Дөньяның данын тотарга
Әле дә кирәк бит без...

Уйлана торган аем бу,
Моңая торган аем;
Яшьләнә күзләр, яшьләнә,
Яшьтәшләр киткән саен.

## Ил кызы

Сара Садыйковага

Ай нурында, су юлында, һай, җырыңда моң тулы,
Талпынасың, көрсенәсең, гөл сибәсең, ил кызы.

Син шаһит тә, син өмет тә, илт бәхеткә, су юлы!
Ак чиләкләр, ак беләкләр, ал йөзеңдә ай нуры.

Талир тәңкәләр сибелгән көмеш чишмәләр чыңы,
Бер күңелдән мең күңелгә моң тараткан кыл тыны.

Җырларыңда, моңнарыңда серле өннәр дулкыны:
Алсу таңнар очкыны да, айлы төннәр тылсымы.

Күккә менә, җиргә иңә, җанга сеңә ил моңы;
И сагышлы иң сылу кыз, кайдан алдың син моны?!

## Бер кыз җырлый

Пароходлар үткән чагында
Бер кыз җырлый Идел ярында,
Көмеш моңы ефәк җилләрдә
Идел өсләрендә тирбәлә,
Дулкыннарга кунып ургыла,
Чәчәкләрне кочып нур була.

Җилбер-җилбер искән җилләргә
Толымнарын чөеп җибәрә,
Бер сихерле көлеп караса,
Дөнья йөзе якты нур була.
Кулларыннан тотып, елмаеп,
Күзләренә баксам ни була!

Җилбер-җилбер ефәк күлмәген
Җилфердәтеп Идел ярында,
Җиләк җыеп йөргән чагында,
Җиләк кебек Идел чибәрен,
Җилфердәтеп ефәк күлмәген,
Кочагыма алсам ни була!

**Әхсән Баянов**

# ТАУ ЯГЫ ПОВЕСТЕ

*Сиңа багышлыйм...*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК



Тау ягы дип атыйлар икән бу якны.

Идел һәм Кама киңлекләреннән карасаң, илаһи бер кала.

Өч архитектор — Кояш, Җил, Су — гаҗәеп сызыклар, рәвеш-кыяфәтләр белән бизәгән бу каланы. Гаҗәеп тә төрле һәм гүзәл төсләр белән.

Ярлар — мәңгелек диварлар. Диварларда — урман һәм куаклар рәвешле язылган сурәтләр. Су буйлата биеклек нәкъ урталай киселгән дә, шунда миллиард еллык тарих — катлы-катлы булып сырланган гасырлар ачылып ята. Урыны-урыны белән киртләч диварлар өчәр почмаклы булып тезелеп калган. Күпме бәрелеп-сугылып узса да, вакыт аларны һич шомарта, түгәрәкли алмаган. Шулай да диварлар киңлектә эвклидча түгел, ә Лобачевский геометриясендәге шикелле — кырлары бер-берсенә тоташмаган өчпочмаклар булып, бәхет һәм кайгыларның, җиңү һәм җиңелүләрнең, мәхәббәт һәм хыянәтләрнең, бер сүз белән әйткәндә, тормышның — үткәннәрнең һәм киләчәкнең чиксезлеген күрсәтеп тора шикелле.

Өч даһи — Су, Җил, Кояш — үзләренең бөек әсәрләренә шундый идеяләр салган, ә кешеләр ул әсәргә бик гади генә Тау ягы дип исем кушканнар.

Идел өстендә ак канатларын киереп күк дулкыннар җилпенәләр. Җилпенәләр дә аксыл теплоходлар күкрәгенә, ярларга ташланалар һәм шунда бәрелеп юкка чыгалар. Алар әнә шулай бер-бер артлы ерактан, зәп-зәңгәр киңлекләр аръягыннан әкрен генә баш калкыталар һәм, зәңгәр канатларын җәеп кагына-кагына, бернидән курыкмыйча, туп-туры мәңгелек ташлы ярларга һәм теплоходлар күкрәгенә ыргыла торалар. Аларның бу тилелегендә әллә нинди тирән мәгънә бардыр кебек.

Ташлы ярларга килеп бас та кулыңны кояшка суз — җылысы сизелми калмас.

Таулар өстенә менеп бас та кулыңны айга суз — бармакларың ай кытыршылыгын сизми калмас.

Килеп бас та йолдызларга суз кулыңны — мәңгелектән килгән балкышлы серләр уч төбеңне кытыклап торыр.

Кояш та, Ай да, йолдызлар да якын икән бу җирләрдә — юкка гына Тау ягы дип атамаганнар икән бу якны.

## Сандугач белән гөлҗимеш

*Бабай әкияте*

Яр буенда — таш авыл.

Таш авылның таулы урамнары буйлап атлаган юлчы егет — солдат киеменнән. Таулы-ташлы урамнар буйлап килде дә ул хәрби комиссариат дигән бер кызыл өйгә керде.

Хәрбиләрчә исәнләшү, күрәсең, авыл җирендәге подполковник өчен тансык иде, күңеле күтәрелеп киткәндәй тоелды аның:

— Я, котлыйм кайтуың белән, иптәш сержант.

Яшь солдат рәхмәт әйткәч, аңа утырырга рөхсәт иттеләр. Кайсы авылга, кем янына кайтканын сорадылар.

Солдат исә, ни дип җавап бирергә дә белмичә, аптырабрак калды. Подполковник, күрәсең, сабыр кеше — көтте. Утырган килеш солдатның документларын карый башлады.

— Бөтенесе тәртиптә. Учетка кер дә — авылыңа кайтып кит. Үзәнбаймы синең авыл?

— Мин анда хатлар язып карадым — җавап бирүче булмады.

Подполковник егетне икенче төрлерәк аңлады бугай.

— Егерме чакрым — солдат кешегә ерунда. Хәерле юл! Давай-давай, тизрәк, үзеңне бик көтәләрдер. Сөенсеннәр,— шулай диде военком.

— Кемнәр?

— Ничек кемнәр? Әтиең, әниең.

— Минем әти үлгән булырга тиеш.

— Алайса, әниең.

— Белмим.

— Ничек белмисең?

— Исемен белмим.

— Оят, начар! Бу ни дигән сүз?

— Авыл Советына кабат-кабат язып карадым, белмиләр. Безнең Үзәнбай түгел, бүтәндер, диләр. Ә минем документларда — шушы район.

Военком уйлана калды. Бераздан гына әлегә кадәр булмаганча йомшак тавыш белән әйтте:

— Син нәрсә, монда тумаганмыни? Мондарак утыр әле, якынрак кил.

— Монда,— дип, солдат өстәл янына күчеп утырды.

— Я? Шулай булгач?..

— Онытканнардыр... Ныклап тикшерергә вакытлары җитми, күрәсең.

— Әниеңнең фамилиясе ничек?

— Белмим.

— Исеме?

— Белмим.

Подполковник ачуланырга да, кызганырга да белмичә, гаҗәпләнеп карап тик торды.

— Бу ни дигән эш, ә? Әниеннең исемен дә белмәгәч...
— Менә шулай инде.
— Ә ул сине күпме еллар эзләгәндер!
— Бик ихтимал.
— Көткәндер.
— Әйе, шул...
— Менә сөенәчәк! Улы үзе кайтып төшкән!
— Менә мин аны ничек табарга икәнен белмим шул әле.
— Ә атаң? Анысы кем?
— Эх, белсәм икән.
— Соң... фамилиягез бардыр инде...
— Шул фамилия белән язып карадым — җавап килмәде.
— Менә сиңа, ә! Тугашев, Тугашев... Тикшереп карыйк әле.

Военком телефон трубкасын алды да Үзәнбай авылын сорады.

Озак тынлык.

— Кайттың, ә кемгә икәнен белмисең, ә? Җайсызрак килеп чыкты шул, җайсызрак. Ә хәзер тырышып карыйк. Хәзер... Алло! Үзәнбаймы? Кем бу? Авыл Советы секретаре? Бик шәп! Менә нәрсә, сеңелем, сезнең авылда туган бер егет армиядән кайтты. Әти-әнисенең кем икәнен белми. Исеме Тәбрик, фамилиясе Тугашев. Беләсезме дөньяда шундый кеше барын? Юк? Менә, белергә тиеш сез аны, тиеш! Тугаш бабай? Ул нәрсә ди? Бернинди малаем да, онытым да юк диме? Бердәнбер оныгым була язган иде — ул да вафат, ди? Ничек алай була инде ул? Үз акылындамы соң ул? Шулаймы? Әйе, бар дөньяда шундый кеше һәм ул сезнең авылныкы. Аның фамилиясе һәм исеме бар. Табыгыз.

Подполковник башын аска иебрәк көтеп утырган солдатка таба борылды.

— Менә шулай, бер-ике сәгать йөреп тор. Район үзәге белән таныш. Беренче тапкыр күрәсеңдер бит?

— Шулай булып чыга.

— Ә чемоданың шушында гына калсын — югалмас.

Дөнья чак кына ямансулангандай тоелды.

Тау буендагы таш авылның да йортлары гел таш кына түгел, агач өйләр белән чиратлаша икән. Урамнары да гел такыр гына түгел — сикәлтәләр, күлләвекләр белән чуарланган. Алар аша узганда машиналарга шактый гүелдәргә, төтен чәчәргә туры килә. Аста — Идел, зәңгәр киңлек. Аның да зәңгәрлеге уңа төште...

Әни... Ни төслерәк икән ул? Яшьме, картмы икән? Сугыш вакытында ук иргә чыккан булгач, яшь үк түгелдер инде. Тәбрик туганда, егерме биш яшьләр булса, хәзер, егерме елдан соң, кырык биш яшьтә... Яшь икән әле, яшь!

Кем төслерәк икән?

Раймаг дигән зур гына кибеттән көләч бер хатын чыгып бара. Таныырга теләгәндәй карап та куйды. Әллә шулмы? Әй, ул Үзәнбайда бит әле, нишләп монда килеп чыксын. Ничек? Ник? Нишләп килеп чыкмаска тиеш ди әле ул? Кырык биш яшьлек ана егерме чакрым җиргә нишләп йөри алмасын? Шулай, бик ихтимал аның монда килеп чыгуы. Бәлки менә шул үзедер әле? Ә бәлки тегесе! Юк, анысы артык яшь. Кайсы икән шулай да, кайсысы икән аның анасы?

Поселок белән таныша тор, дигән иде военком. Танышырсың — күңелдә һаман бер уй, бер кеше... Мең кыяфәткә кереп килә дә баса каршыга, уза да китә. Тик елмаюы гына бетми, һаман елмая...

«Китапларда язалар, ана мәхәббәте, диләр. Ничек була икән ул ана мәхәббәте? Ул мине ничек яратыр икән? Ул мине алдына утыртып сөя алмас бит инде хәзер! Ә минем кечкенә бала булып аның алдына утырасым, сөеләсем килә. Ничек яратыр икән үзеннән олы малайны? Кар-

шыларга чыккач, күрешкәч тә бәхетнең, куанычның артык зурлыгыннан үксеп еларга керешерме, әллә шундук кочагына алып иркәли башлармы?»

Ана ничек кенә каршыласа да, Тәбрик дөньядагы иң якын кешесенең аркасыннан сөяр. «Тынычлан, эни, елама», дияр, кулъяулык белән — әллә каян, Берлиннан алып кайткан кулъяулык белән — яшьләрен сөртер... Ана шуннан соң елмаер да тагын улының күкрәгенә башын куяр. Шуннан соң култыклашып өйгә керерләр. Тәбрикнең беренче соравы шул булыр: «Минем әти кем? Ул кайда?»

Ә энисе җавап урынына башын гына исә?

Алайса, Тәбрик: «Ул кайсы фронтта һәлак булды?» дияр. Юк, юк сугышта булган бөтен кеше үлеп бетмәгән ич, кайткандыр әле, исәндер. Әллә... Кем белә, бәлки каты яралы булып, кайткач үлгәндер. Югыйсә, җавап язган булыр иде — Тәбрик язган йөз хатка бер генә булса да җавап килер иде. Ә ана?

Ник энисе язмады икән? Әллә ул да...

Юк, юк мең тапкыр юк — ул исән булырга тиеш. Энисе төннәр буе Тәбриккә этисе хакында сөйләргә тиеш, яуда батырларча һәлак булуы хакында... Үзе хакында да сөйләргә тиеш. Төн буе гына түгел, көннәр буе, еллар буе — бертуктаусыз. Егерме ел вакыт эчендә һәм аңардан элек тә ниләр булган, барысын да, барысын да сөйләргә тиеш ана.

Вакыт калса, Тәбрик үзе дә сөйләр, әлбәттә. Күп түгел, бик аз итеп. Нигә дисәң, бик аз яшәгән бит әле ул дөньяда. Нәрсә генә сөйләсен?

Ну, әйтер инде, Казаннан ерак түгел Займище дигән станция янында ямь-яшел чыршы-нарат урманы эчендә үстем, үзең приютка шунда урнаштыргансың бит, дияр.

«Алай да, эни, кая урнаштырырга кирәклеген белгәнсең — табигатьнең иң матур почмагына — Идел буена. Кайтышлый да карап узылды...»

Тагын нәрсә әйтер Тәбрик?

Анда унынчы классны бетергәч, Юдино тимер юл депосында ике ел сварщик булып эшләдем дияр дә, хәзер армиядән кайтып килешем, дип өстәр. Бик ныклап сораса, нефть институтына керергә җыенуын да әйтми калмас. Ник тәгаен нефтьнекенә? Татарстан шуның белән атаклы булгандыр инде. Бүтән нәрсә әйтә алмас. Сүзе беткәч, үзе сорар: «Эни, ник мине приютка бирдең?» дияр. Хәле авыр булгандыр, әйтеп аңлата алмаслык авыр булгандыр. Югыйсә, үз улын кем инде әллә кая илтеп ташласын. Ана бит ул!

Подполковник килергә кушкан вакытка хәзер минутлар гына калып бара. Поселокны рәтләп карый да алмады Тәбрик, өлгермәде. Ашыга-ашыга тагы капкаларына хәтле кызылга буялган йортка китте.

Тагын военком булмәсе.

Йөрәк дөп-дөп тибә. Моңарчы беркайчан да бу хәтле дулкынланганы юк иде Тәбрикнең... Ишек ачкач... Булмәдә — хатын кыз! Энисе! Энисе! Бүтән кем булсын! Ләкин Тәбрик ни өчендер аның кочагына ташлана алмады. Хатын үзе дә, торып баскач, катты да калды. Военком шулай ук рәтле сүз таба алмыйча, ахрысы:

— Менә шушы егет,— дип кенә куйды.

Йөзендә шатлык әсәре юк. Димәк...

Димәк, Тәбрикнең еллар буе саклап йөргән хыялы, өмете бер секунд эчендә челпәрәмә килде. Ләкин юк, юк, моның белән Тәбрик килешә алмый, моның белән Тәбрик беркайчан килешә дә алмаячак. Әйе, бик тә, бик тә татлы хис белән, кемгәдер «әтием, энием!» дип эндәшү бәхетеннән ул үзен беркайчан да мәхрүм итмәячәк. Әгәр җинелергә нияте булса, менә болай, кузгалырга куркып, күзләрен мең өмет белән тутырып карамас иде ул шушы хатынга.

Хатын үзе дә аның каршысына ук килеп шактый ара сүзсез торгач, егет көч-хәл белән генә күңеленнән ике сүз тартып чыгара алды:

— Сез... минем әниме? — Татарча рәтләп белмәгәнлектән, русча сорады.

— Их, Тәбрик, Тәбрик! Менә нинди булгансың! — диде хатын, егетнең аркасыннан кагып.

— Сез минем әни түгелмени?

Күренеп тора, мин синең әниең түгел диясе килми апаның, бала күңелен рәнҗетүдән курка. Шунлыктан сүз тапмый интегә.

— Мин синең әниең түгел шул, балам, түгел...

Апа тагын нидер әйтмәкче булып та, күзләренә чыккан яшьләрен тыярга тырышып та азаплана. Ник алай икәнен Тәбрик сорый алмый: тагын да катырак сүз ишетермен дип курка. Ә чынында, «әниең юк» дигән сүздән дә катырак сүзнең булуы мөмкинме?

Ярый әле, военком каушамый, ярдәм итә.

— Әмма сез — аның иң якын апасы. Бәлки әнисен алыштыра алырсыз...

— Әйе шул, без аның әнисе белән туганнар кебек идек. Ялгызы калгач, Тугаш бабайны да шуңа күрә үзебезгә алдык...

Апаның каушавын сизеп, подполковник:

— Солдатның бабасы исән, алайса? — дип сорады.

— Исән шул, исән!

— Бу инде начар түгел, егет, ишеттеңме?

— Ишеттем. — Тәбрикнең йөзе чак кына яктырып китте.

— Мине игәчәң дип бел,— диде хатын Тәбриккә текәлеп бераз торгач, кинәт кенә кулын сузды. — Энем, улым, дияргә мөмкин. Исәнме, я, Тәбрик! Сөембикә минем исемем.

— Исәнмесез, Сөембикә апа,— диде Тәбрик тә, чак кына чырае ачылгандай.— Сезнең исем миңа яхшы таныш.

— Менә, бик шәп булды, таныштыгыз,— диде военком.— Матур итеп кунак итегез, сөйләшегез.

— Ярый, алайса, әйдә, Тәбрик.

Тәбрик нишләргә белмичәрәк торгангамы, чемоданны военком үзе күтәреп алып тоттырды.

— Ну, хәерле юл, брат, хуш!..

*
* *

Әнисенең генә түгел, әтисенең дә юклыгын Тәбрик Сөембикә апасының һәм подполковникның күз карашларыннан ук аңлап алган иде. Ләкин... ләкин барыбер ышанасы килмәде. Күңел дигәнең хәтта үчләшә, бәхәсләшә һәм очкын хәтле генә өметне сүндермәс өчен Сөембикә ападан нәрсә булса да сорарга да курка иде. Хәер, кузов тулы кеше, теләсәң дә әллә ни сөйләшә алмас идең.

Машина дыңгыр-дыңгыр каядыр бара һәм кая баруы Тәбрик өчен шулай ук барыбер иде. Авылда аны беркем дә көтми, ул анда беркемне белми, аның анда беркемгә кирәге юк. Бер кешенең, ана дигән кешенең нәрсә икәнен Тәбрик гомер буе белми яшәсә дә, ятимлеген бу хәтле дә йөрәкне чеметә торган ачыклык белән сизгәне юк иде әле. Әнисе юк, әнисез — туган җир юк...

Кешеләр нидер сөйләшә, көлешәләр: хатыннар, ирләр, яшьләр, картлар. Ә Тәбриккә сәер — ни дип көлә торганнардыр. Сүзләрнең күбесен ул аңлап бетерми һәм аңларга да тырышмый. Аңа юньләп татарча өйрәнергә туры килмәде. Әнисе белән сөйләшергә кирәге булса дип, кайтышлый очраган һәр татардан диярлек ким дигәндә ике-өч сүз отып калырга тырышкан Тәбрикнең хәзер, туган тел яңгырашын якыннан тыңларга, аһәңе, музыкасы белән ләззәтләнергә вакыты җиткәч, күңеле

сүрелде. Ят авыллар, инешләр чуарланып, ялтырап кала — аларга илтифат итми Тәбрик.

Бер хәлдә озак барудан җайсызлык тойганга күрә генә, ул, ниһаять, күтәрелеп алга карады.

Ямь-яшел кырлар — игеннәр, игеннәр, игеннәр, бернинди утрау, бернинди кара нәрсә күрмәссең. Авыллар да юк микәнни?

Күпмедер баргач, машина түбән төшә башлагач кына җавап табылды: ике катлы икән бу ил, өстә дә кырлар, аста да басулар, үзәннәр. Үзән буйларында авыллар. Автомашина яшел тау буйлап төшә. Ә ерактa, ике яклап, очы-кырые күренмәгән шундый ук таулар тезмәсе. Анда шулай ук дистәләрчә чакрымнарга җәелгән тигез гүзәллек. Елгалар, басулар, бакчалар, авыллар — барысы да уч төбендәге шикелле.

Тау иле...

Әле күптән түгел Займищеда, аннары Юдинода яшәгәндә Идел аръягында гына шушы таулар башланганын, туган җир башланганын Тәбрик уйлый белмәгән. Идел аръягындагы таулар артында гына кемнәрнең ничек яшәгәнен белергә дә, күрергә дә теләмәгән. Шунда әнием юкмы, әтием юкмы дигән сорау, күпме генә чакрымнар узып, күреп килергә дигән уй ничек башына кермәде икән аның? Сәер, кызганыч һәм шул ук вакытта Тәбрик моның өчен үзен гаепле дип сизми. Үз теләге белән китмәгән бит. Ә кайтуын кайтты менә — үз теләге белән...

Тора-бара, ничектер, үзе өчен бер нәрсәне ачыклады Тәбрик: бүгенге көн никадәр матур һәм мәгънәле, киләчәк көн никадәр якын һәм мавыктыргыч тоелса да, кешегә алар гына җитми, аңа тагын үткән тормыш та кирәк, үзенең каян килеп чыкканын белү дә кирәк икән. Үз дәрәҗәсен тояр өчен, кимсенмәс өчен, ятимлек сизмәс өчен — бүгенге көн генә түгел, тарих та кирәк икән адәм баласына. Ничә яшенә генә җитмәсен, кешегә барыбер ана кирәк. Ул үзенең кем баласы икәнен белергә тиеш! Һәм менә Тәбрик кайтты... Ятимлек белән килешмичә, язмышы белән бәхәскә кереп, туган җир тормышын бөтен тирәнлеге белән белергә, аңларга хыялланып кайтты. Ләкин хәзер, вакыты җиткәч, кайткач, теләге нигәдер какшагандай итте. Кинәт кенә ник шулай булды әле? Ник?

Җайсыз хәл, җайсыз һәм күңелсез. Колакка ят шикелле җыен аңлашылмый торган сүзләр җуылдый. Синең бүгенге көнгә генә түгел, тарихка да хакың бар, ди, ахрысы... Ләкин юкка, юкка кайттың, ди. Бәлки бүтәнчә әйтә торгандыр? Ныклап аңламый шул егет, тел белми.

Хәерле булсын, ул, бөтенесен машинага тапшырып, баягыча кузовка сыенды да, уйларын бүтән якка, бергә хезмәт иткән дусларына күчерде.

«Алар кайда икән? Минем кебек ялгыз түгелләрдер, кайда гына булсалар да...»

*

* *

Ниһаять, машина бер авылның урам уртасына, кечкенә кибет янында тукталды. Алгы почмакка аркасын терәп утырган Сөембикә апа торды да Тәбриккә елмаеп:

— Килеп җиттек,— диде.

Тапталып, актарылып беткән кара урамнан бераз баргач, яшел чирәмле урамга чыктылар. Үләндә оеп утырган казлар торып сигнал бирде: сак булыгыз, ят кеше бар, янәсе. Бәбкәләре артык сәерсенми генә: «Булса соң, безнең ни эшебез бар анда?» дигән сыман пипелдәштеләр.

Тәбрик казларны чамалап кына аңлый. Аларны гына түгел, кешеләрне дә. Капка төбе саен диярлек кем дә булса аларга сүз кушып кала. Кунак хакында сорашалардыр, мөгаен. Кайсысы тәрәзәдән карап кала... Тәбрик, үзен зоопарктан чыккан аю тәслерәк хис итсә дә, үртәлми — ничектер бу хәл кызык тоела аңа.

Сөембикә апасы башка йортлар төсле үк бер өй янына җиткәч туктады да бәләкәй капканы ачты:
— Шушы инде безнең өй, Тәбрик, пожалысты.
Ишегалдында тавыклар кыткылдап каршылады. Алар да гаҗәпләнә, алар да ятсына:
— Кытыйк-кыт-кыт!..
Аннары күзгә ташланган нәрсә шул булды: урамдагы яшел чирәм белән һич ярашмаган сап-сары болдыр, баскыч алды. Аяк басарга да куркырсың. Итекләрне салырга туры килде һәм Сөембикә апасы аңа шунда ук нәгышле башмак чыгарып бирде:
— Бабай үзе дә кими саклый торган әйберсе. Кадерле кунакка гына...
— Рәхмәт.
— Кара, татарча да беләсең икән бит?
— Бик аз, ике-өч сүз.
— Ничава, өйрәнерсең әле.
Шул арада өйалды ишеге ачылып, аннан уналты-унҗиде яшьлек бер кыз бала елмаеп чыкты:
— Кайттыгызмы, әни?
Аның белән бергә өйалдына чыккан тәмле аш исе, ничектер, күңелгә үк бөркелгәндәй тоелды.
Кыз Гөләндәм атлы икән. Танышкач та өйгә чакырды. Шунда егет үзенә бөтенләй ят тоелган, әмма бәхетле икәне сизелеп торган дөньяга аяк атлавын, узган тормышка — әнисе дәверенә килеп керүен һәм аны монда барыбер табачагын күңеле белән сизде.
Авыл өе.
Сул якта челтәрләр капланган ак мендәрле караваг, аңда — мич белән кушылып киткән бүлмә. Каршыда — өстәл. Сурәтләр — бер карасаң таныш кебек, бер карасаң — әллә ничек, чит илгә килеп чыккан кебек. Чит-ят җирләрне күрер өчен адәм балалары махсус сәяхәтләргә китә. Һич югында (бабасын күрү бәхетен әйтеп тә тормастан), дөнья белән танышлыгы артыр.
— Бабай кайда соң?
— Хәзер кайтып җитә,— дип, кыз чатнатып русча әйтте дә рамдагы сурәтләр каршына якын ук килеп: — Монда синең әниең дә бар, тапсаң — үзеңә! — дип елмайды.
Әллә егет моңаеп калмасын дип юри шаярта, әллә фаҗигане аңлап җиткерми бу бала. Тәбрик аңа ышанырга да, ышанмаска да белми аптырап калганга, кызның чаялыгына капма-каршы буларак, Сөембикә апасы кайгылырак төстә әйтә куйды:
— Синең әниең шунда, балам.
— Кайда? — Әйе, могҗиза көтүе юкка түгел аның! Тәбрик шуңа ышанып түргә узды. Тик кыз тагын рамга таба баш изәгәч, чырае тагын җимерелде. — Ә... рәсемдә...
— Тапсаң — үзеңә.
Кызның яхшы ниятенә, егеткә борчылырга ирек бирмәскә тырышуына инде чынлап ышанган Тәбрик барыбер аңа иярел елмая алмады. Кыз таләп иткән шаянлыкны бөтенләй читкә какмаса да, кыяфәте җитди булып кала бирде:
— Мин үземә ошаганын сайлыйм, алайса, иң яхшысын.
— Ал, ал!
Хатын-кыз рәсемнәре ике рамда да күп иде. Ләкин ул беренче рамда үзенә тәмам охшаганны тапмады да икенче рамга текәлде. Һәм менә... аның әнисе! Ап-ак челтәр шәл ураган яшь-яшь хатын. Шәл астыннан чем-кара чәчләре күпереп тора. Уйчан күзләр, моңсу күзләр мең төрле мәгънә һәм хис сирпеп карый. Тере шикелле. Чак кына түгәрәк, чак кына озынчарак ягымлы йөз һәм ул таныш йөз! Тып-тын өй эчен шул ягымлы төс җылыта икән! Менә хәзер кузгалыр да рамнан чыгып улын кочар!..

Ләкин ул ни өчендер кузгалмый. «Әнием, чыга алмыйсың шул кара рам эченнән, син анда — мәңгелек тоткын...»

Келт-келт иткән сәгать тавышы йөрәкләрнең тынгысыз тибешен саный. Санап кына да калмый, кайгыны кадак итеп йөрәккә кага. Хәтта Гөләндәмнең сабый күзләреннән дә әллә нинди тирән моң сирпелә иде бу минутларда. Шуны сиздермәс өчен һаман шаярырга тырышкан була үзе.

— Син аны ничек таныдың?

Егетнең тиз генә җавап бирмәсен сизеп, Сөембикә апасы үзе аңлатырга тиеш тапты:

— Төскә үзе дә нәкъ әнисе бит.

— Юк, минем әнием чибәр...

— Син аңа охшагансың, суйган да каплаган! — Бу юлы инде кыз чын күңелдән шатланды.

— Сез аны миңа бүләк итмәссезме?

— Шулай килештек ич, син аны отып алдың, — диде Гөләндәм. Һәм, ни әйтер дигәндәй, әнисенә карады. — Бу рәсеме бераү генә инде дә... Әйе бит?

— Бераү генә булса да... Ул аңа тиеш.

Рамны куптарып тиз генә урындыкка куйгач, Сөембикә җәһәт кенә карточканы алды да Тәбриккә сузды һәм онытыла язган фикерен очлап куйды:

— Ана — иң башта баланыкы ул.

Тәбрик рәсемне кулына тоткач, Гөләндәм таш сын булып тын калды һәм, шуңа күрә диярсең, баягыдан күп мәртәбә әрнешлерәк тынлык урнашты. Якында гына, үз кулында гына, тере шикелле карап торган әнисенә текәлеп, бала бернинди сүз дә аңлата алмаслык кичерешкә талды...

Рәсемдәге сөйкемлелек, матурлык кайчандыр тере булган... Кемнәр беләндер (ай, бәхетле кешеләр!) сөйләшкән ул, бәхәсләшкән, яраткан...

Аның исеме — Көлемсәр.

*
* *

Шушы урамнарда, шушы тауларда, яланнарда, инеш буйларында йөргән ул. Шушы сулар, чишмә чылтыраулары шикелле, шушы тирәкләрдә сайраган кошлар җырына кушылып, аның сүзләре ишетелгән, йөрәк моңнары яңгыраган. Ул, дөнья тулы бәхетлеләрнең берсе булып, һаман көлеп, сөеп, сөелеп яшәргә тиешле булган — юкка гына Көлемсәр түгел бит аның исеме. Гөләндәм Тәбриккә бу исемнең мәгънәсен бик шәп аңлатты. Әйе, матур исем, яз кебек, язгы табигать кебек!

Көлемсәр!

Ямь-яшел чирәм өсләрендә ялан тәпи йөгереп йөргән бала чагы, аннары май күге төсле саф, якты яшьлеге — уйнап-көлеп кенә мәхәббәт дөньясына барып чыккан, көлемсәрлеген җуймыйча, бүтән бер кеше язмышы белән кушылган... Көлемсәрлеген җуймыйча гына Фәрхетдин дигән егеткә ябышып чыккан ул. Чын күңелдән, бөтен барлыгын, тормышын, язмышын һичнинди куркусыз бүләк итәрлек булып, чын ярату белән ярата белгән. Ә ике йөгерек инеш бергә кушылдымы, тынгылык, хуш. Инде бүтән тормыш, бүтән язмыш...

Ул тормышны, ул язмышны Тәбрик кабул итә алмый — Тәбрик әнисен бәхетлерәк язмышка лаек дип саный... Тәбрик, беренче чиратта, әнисенең шушы җиргә кабат кайтуын көтә һәм шунсыз, шунсыз...

— Әни, дәү әти кайтып килә!

— Әйе шул, бик шәп булды әле! — диде Сөембикә апа, җайсыз минутларның бетүенә сөенеп.

— Синең дә дәү әтиең ул, Тәбрик абый.

— Чынлапмы?

Алар каршыларга чыкканда бабай ишегалдына кергән иде инде, ул капка төбеннән үк:

— Я, сынук, пришулмы? — дип, ике кулын суза килде.— Бик тә хорошо, бик тә шәп. Әйдә, өйгә керик.

Була бит соңгы чиккә хәтле чиста, саф төс-кыяфәтләрен саклап калган сөйкемле картлар. Тугаш бабай шундый карт икән. Сакалы көрәк сакал диярлек зур да түгел, кәҗә сакал да түгел. Мыегы да мактанчык ир күркеннән ерак, анысы да кешенең эчке бер тыйнаклыгын әйтеп тора. Барыннан да бигрәк, бабай чал булса да, күңел көрлеге, тел җорлыгы белән җәлеп итә торгандыр кешеләрне. Картлык иркәлеге, үзенә аерым хөрмәт таләп итә торган көйсезлеге дә юк шикелле. Бик үк еш очрамый торган җылгыр карт, бәхетле карт. Бер күрүдә менә шушындый хисләр кузгалтты ул. Башындагы күк эшләпәсе, камзул астыннан күренеп торган зәңгәрсу күлмәк итәге һәм җиңнәре, кара галош һәм ак оекбашлары белән, ниһаять, кулындагы таягы белән, рөхсәт сорамый-нитми генә, хәзер җил капкадан кергән кебек, керде дә куйды бабай Тәбрикнең күңел түренә.

Тәбрик белән алар бер күрүдә яратыштылар.

*

* *

Әле генә кузгалган булуларына карамастан, бергәләп тагын чәй эчтеләр. Чәй янында бабайның беренче соравы шул булды:

— Бөтенләйгә кайттыңмы, улым?

— Шулай дип уйлаган идем дә... Ничек булып чыгар инде.

— Авылыбыз ошамас дип куркасыңмы?

— Берничек тә әйтә алмыйм әле, бабай.

— Шулай димсең? Алай...

Карт тотлыкканын сиздермәс өчен генә чынаяк тәлинкәсенә чәй өстәде дә, ике куллап күтәреп, шуны чөмерергә керешкән булды — бик тә сусаган, янәсе. Соңыннан гына шактый еректан әйләнеп төште:

— Басулардан урап кайттым әле. Аллаһы теләсә, уңышлар менә дигән. Шушы хозурлыкны ташлап, типсә тимер өзәрлек кайсыбер җилкуар, авыр дигән булып, җиңел тормыш эзләп, калага элдерә. Адәм рисвайлары. Синең, улым, комбай-трактор йөртерлек өнәрең бармы соң дигәндәй?..

— Армиядә шофер идем. Юдинода тимер ябыштыручы булып эшләдем — сварщик булып.

— Бигрәк шәп. Авылда самый дәрәҗәдә машина телен белгән кеше. Тимер белән дә дус булгач, егет асылы инде, аллага шөкер икән.

— Тик мин нефть институтына җыенам әле.

— Тора-бара нифете дә табылыр, алла теләсә. Җиребезнең төбенә хәтле төшеп, әллә нинди серләр айкап чыгарырсың әле. Ай, безнең җир, белә китсәң, әлләниләр бардыр анда.

— Шуны беләсем килеп кайттым да.

— Ә нифеткә чаклы аннан да гаҗәбрәк әйберләрне күреп шаккатарсың да яратырсың бу якны. Бүгенге тормыш үзе ни тора?! Андагы сабан туйлары, чабыр[1] бәйрәмнәре...

Сабан туй дигәннәрен хәзер бөтен дөнья белә. Ә менә чабырны Тәбрик беренче кат ишетә. Тәбрик кенә түгел, Гөләндәм булып Гөләндәм белмәгәч инде, нинди атаклы бәйрәмдер.

— Чабыр дисеңме? Анысы ни соң, бабай?

Мондый сорауны көтмәгән карт каушагандай итте:

— Чабыр тауларын күргәнегез юкмыни?

---

[1] Чабыр — җыен.

— Тауларын бар, ә чабыры кайда соң? — дип төпчендә кыз.
— Булыр, алла теләсә, чабыры да булыр. Үзем янадан оештырам, менә күрерсез. Хәзер бигрәк тә шәп — нәкъ вакыты, атна-ун көннән...
— Сабан туймы? — дип бүлдерде Тәбрик.
— Сабан туе әле генә узды шул, соңга калгансың бит әзрәк кенә.
Шуннан соң карт бик дәртләнеп җыенның, тау ягы теле белән әйтсәк, чабырның нәрсә икәнен тәфсилләп аңлатырга кереште. Борын-борыннан килгән кабилә-ыруг кешеләренең очрашу бәйрәме икән. Дуслык, танышлык ныгыту, төрле уеннар, кәмит-таганнар, җигүле һәм җигүсез юрга атлар белән түгәрәк әйләндерүләр, сәүдә итү, шулай ук башка килгән һәм килмәгән бүтән кызыклар, бүтән кыланмышлар. Бөтенесенең мәгънәсе — туганлык һәм дуслык, шуны яшь буынга мирас итеп тапшыра килү.
Дүртәүләп тәнозын сөйләшеп яттылар. Тау ягы хакында, Тәбрикнең әнисе турында...
— Ә чабырны барыбер күрсәтәм мин сиңа. Хәзер йокла, балам, юл кешесе, арыгансың...

*

* *

Иртәгесен Тәбрик үзен бөтенләй икенче кеше сыман тоеп уянды. Күңеленә гомеренең шушы гаҗәеп бер кыска мизгелендә ургылып тулган, дәверләр аша җыелып килгән хәлләр һәм вакыйгалар, хәзергә аңлашылып та җитмәгән, әмма җавапны барыбер табарга туры киләчәк сораулар авырлыгыннан башы нелдә. Шулай да вакытны әрәм итмәскә карар кылды — иртәнге сәгать алты тулгач та, түр почмактагы чыбылдык белән уратып алынган бүлемен калдырып, чемоданыннан гантельләр алды да ишегалдына чыкты. Ә тышта яп-якты көн икән. Бу юлы тавыклар да ятсынмады бугай, янга ук килеп карадылар. Җим сорамакчылар, ахрысы. Алар тирәсендә, утардагы иң зур хуҗа — кызыл әтәч үзенең бөтен әтәчлеген күрсәткән кыяфәт белән әйләнгәләп йөри — тыныч һәм горур. Тик Тәбрик гантельләрне күтәрә, уйната башлауга, тревога куптарды юньсез. Тавыкбикәләр исә башта кайсы кая качышса да, соңыннан, ул-бу күренмәгәч, тагы чыктылар һәм җырлаша башладылар.
Шул вакыт Тәбрик Займищеда чакта ук көлеп карый торган бер әкәмәт күрде. Әтәч иптәш ниндидер орлык тапкан да тавыкбикәләрен чакыра:
— Кет, кет, кет, кет...
Билгеле инде, шул кадәр чын күңелдән чакыргач, тавыклар көтүе белән җыелып та килде, көтүе белән хур да булды — әтәч-хулиган орлыкны үзе кабып та йотты. Мескен тавыклар, үпкәләргә кирәген дә аңламыйча, үз шөгыльләренә таралыштылар.
— Кытыйк, кыт-кыт... кытыйк.
Урамнан узып барган хатын-кызлар да шул тавыклар шикелле шат. Барысы да диярлек Тәбрик белән исәнләшә:
— Исәнме, Тәбрик, сау кайттыңмы? — диләр.
«Исәнмесез»,— дип елмаеп кына куя Тәбрик. Нигә дисәң, өстәргә бүтән сүз белми. Тагын әллә ниләр сораштырмак, сөйләндермәк булсалар да, иңбашларын гына җыера. Тегеләр дә русча рәтле сүз таба алмагач:
— Хараша, хараша, пришул, — дип кенә куялар да үзләренчә нидер сөйләнә-сөйләнә китеп баралар.
Шулай, ничек сөйләшәсең телсез кеше белән. Үзенең телсез икәнен бервакытта да күз алдына китереп караганы юк иде әле Тәбрикнең — авыр икән, гаҗәп авыр икән бу! Үз иленә кайтуы экваторга барып чыккан кебек. Ярый әле, Тугаш бабай кайтып керде. Таң белән торып, каядыр барып та килгән икән. Яшь чагында шахталарда йөргәнгәме, русча шактый аңлатып сөйли.

— Тордыңмы, улым?
— Тордым, бабай.
— Дөрес эшләгәнсең. Бәхетне аны иртән иртүк өләшәләр. Соңга калсаң, өлешсез калуыңны көт тә тор. Шуңа күрә кояш белән бергә торып чыга крестьян басуга.
— Солдат та шулай.
— Солдат белән крестьян бәхете — авыр бәхет ул, авыр.
— Җиңел булса, аның бәхет икәнлеге беленми, диләр бит.
— Дөрес. Җиңел яшәүчеләр дә юк түгел, югыйсә.
— Бразилиядә увирапуру дигән кош бар икән, бабай.
— Кайда, кайда дидең, улым?
— Бразилиядә.
— Анысы ни тагы, кайсы төштә — германнан арымы?
— Ары! Америкада, океан артында.
— Ә! Америка! Ерак икән! — Бабай, әкият тыңларга әзерләнеп, болдыр баскычына утырды.— Шуннан, нинди хикмәтле кош инде ул?
— Менә шул кош, бабай, елына ун гына тапкыр — анда да бишәр генә минут сайрый икән. Аның шул сайравын ишетсәң, гомереңбуе бәхетле кешегә әйләнәсең, имеш!
— Ансат икән, ансат, алай...
— Сайраган чагын туры китерү кыен ди шул.
— Барыбер ансат. Иблис сүзе бу, улым. Бәхет, ничек әйтсәң дә, җирдә ул, шуннан актарып чыгарсаң гына синеке була. Ни өчен дип әйт.
— Ни өчен, бабай?
— Вәт, болай. Фәрештәләр нурдан яратылган. Шуңа күрә аларның урыны күктә. Пәриләр төтеннән... Шуңа күрә аларның тәне юк, теләсә кайда кубарылып йөриләр — ватансыз, ягъни хыянәтчеләр кебек. Иблис — уттан яратылган — урыны тәмугта, наканис. Барыбер кабачак ул анда. Ә адәм балчыктан яратылган, шушы җирнең үзеннән. Шуңа күрә аның бәхете дә шушында. Ул җирдән, үзе туган җирдән аерылмаска тиеш, җире ни күрсә, ул да шуны күрергә тиеш. Адәм баласына бүтән язмыш белән яшәү гөнаһ — иблислек. Аннары бул мәңгелек тәмуг кисәве.
— Кызык сөйлисең син, бабай.
— Мин сөйләмим аны, шушы туфрак, балчык сөйли — мин бит шул балчык инде.
— Дөрестер ул, бабай. Галәмгә чыгып та кеше үзенең торагын тикшерә, Җирне өйрәнә бит. Минем дә менә читтә йөргәндә туган җирне, сезне күрәсем килде — бәлки шунда үземне анлармын дип йөрдем...
— Шулай ул. Әнә үзебезнең тәкъдир башын белү өчен дә җирне казыйлар шәһри Болгарда...
— Анда барып килергә мөмкин булырмы икән?
— Нишләп булмасын, булыр. Менә син, әллә нинди кош дидең, ничек исеме?
— Увирапуру!
— Уера пыру... Син аның артыннан кума, яме, балам. Үз кояшыңны бел. Безнең үз кошыбыз бар, әйтергә яраса.
— Нинди кош?
— Сандугач.
— Ә!
— Кошыбыз — сандугач, чәчәгебез — гөлҗимеш. Гөлҗимешнең матурлыгына гашыйк булып, сокланып, сандугач шашып-шашып сайрый... Артык соклануыннан өнсез кала, телдән яза. Ел саен шулай, ипидер, валлаһи.
Аның матур сүзләрен раслап, шап-шап кагынып, ихата уртасында әтәч кычкырды. Елмаймыйча булдыра алмады Тәбрик.
— Әтәч тә безнекеме?
— Безнеке. Җир кешесенә вакытны әрәм итмәскә кушып кычкыра.

— Хәзер инде сәгать кубәйгәч, әтәчнең кирәге ул чаклы түгелдер.
— Сәгать икенче чут ул.
— Атом сәгате өч йөз ел эчендә бер генә секундка ялгыша ди.
— Әтәчкә житми барыбер. Әтәч бит ул бөтенләй бүтән чут — вакытны гына түгел, крестьянның хәлен, язмышын да күрсәтеп тора ул әтәч. Мәгънәле яшәргә, бәхетле яшәргә кушып тора. Утарында әтәч кычкырмаган кеше крестьян түгел инде ул, ачәрвах, булдыксыз адәм. Юк, әтәчсез дөнья — дөнья түгел ул. Әтәч — маладис. Кара син аның тәпиләрен, ә, кыяфәтләрен! Баһадир, прәме Алып батыр! Чүтеки әтәчсез булмый, улым, һәркемнең утарында әтәч йөрергә тиеш.
— Сандугач, гөлҗимеш, әтәч...
— Әйе, шундый җыр да бар... Ничек әле...
— Белмим.
— Ә син аны бел! Неприменно бел.
— Ярый, бабай, өйрәтерсең.
— Моңарчы өйрәтә алмагач... белмим шул, белмим. Бик зур гаепле без синең каршыда, балам.
Яшь солдат гаҗәпсенеп карагач, карт тагы сүзгә кереште:
— Алып бабаң — Тау ягының беренче хуҗасы. Ул да игенче булган, җирдән яралган. Бер заман, җир тырмалап йөргәндә, моның чабаталарына туфрак тула икән дә, ул аны чишә дә бушата, чишә дә бушата икән. Һәр чабатага җыелган туфрак тау булып кала икән. Безнең тау ягы шулай барлыкка килгән.
— Кызык әкият. Ә чыны...
— Әллә ышанмыйсың инде, балам...— Кәефе кырылып, бабай шактый ара уйланып торды да Тәбрикнең кулларына карады:
— Болары нинди гер?
— Гер түгел, гантельләр.
— Анысы ни дигән сүз?
— Менә, зарядка ясыйм шулар белән. Карап тор, бабай.— Һәм Тәбрик кулында гантельләрне биетә, әйләндерә башлады: иелеп тә, тураеп та — төрлечә.
Бабай тагын күңеле күтәрелеп көлемсерәде дә болдыр баскычына утырды. Тәбрик уенныннан тукталгач кына:
— Ничә килограмм бу гер? — дип сорады.
— Гер түгел, гантель.
— Әйе, беләм, шул... гер... ничә килолы дидең?
— Ике килолы.
— Әйбәт икән.
— Башта кечкенәдән башладым.
— Чуже безнең зәрядке шәбрәк, улым. Әйдә әле, тот әле менә бу агачны...
Тәбрик юан гына бүрәнәне кулбашына күтәреп, кая куярга белми торгач, бабай бармагы белән күрсәтте:
— Юк, алай түгел, әнә теге станокка сал. Күрәсеңме? Илтә тор шунда. Мин пычкы алып чыгыйм да, икәүләп, кисеп-ярып куярбыз. Шуннан да шәп зәрядке булмас.

*
* *

Карт крестьян Тугаш белән яшь солдат Тәбрик утын кисә. Бабайның тыны кысыла башласа, ял итә, гәпләшәләр.
Утын сыра кайнату өчен кирәк икән, һәр чабырның төп эчемлеге — шул, имеш. Һәр кадерле кунак сые — өй сырасы... Бабай бүген кояш белән торып, колхоз председателе янына баргач, сыра идеясен колхоз

башлыгы бик мактаган, әмма чабыр мәсьәләсендә партком белән сөйләшергә кушкан, секретарь исә: «Кунагыбыз ничаклы гына кадерле булса да, онытылып беткән бәйрәмнәрне яңарта алмабыз», дигән. Сезнеке җитмәсә, Тугаш бабагыз бар бит әле! Тугаш бабалары бердәнбер оныгына әнә шул онытылган матурлыкларга хәтле терелтеп күрсәтергә җыена, һич тә кыенлык туды дип чигенергә җыенмый. Якын-тирә авылларга йөреп, авыл җитәкчеләрен күреп сөйләшергә, кирәксә, район башлыкларының иң кәттәләренә үк барып җитәргә, оныгына барыбер авылның һәм узган, һәм хәзерге ямьнәрен күрсәтеп чыгарга сүз биреп кайткан. Булдыра алсаң, кара, дигәннәр... Оныты исә, чабырның нәрсә икәнен белмәс борын аның барып чыкмасын сизә диярсең, һаман бүтән нәрсә белән кызыксына:

— Мин туганда син кайда иден, бабай?

— Авылда идем, трутармидән кайттымые инде.

— Нишләп син мине приютка җибәрттең, үз яныңа гына алмадың?

— Алар миннән син туганны яшерделәр бит, белгән булсам!

— Ә нишләп Займищега кунакка килми иден?

— Башта синең анда икәнне яшерделәр. Соңыннан вафат диделәр. Фәрхетдин, үги атаң, үзе шулай кайтып әйтте. Әниең шул кайгыдан гына дигәндәй харап булды.

— Ул да ышандымы минем үлгәнлеккә?

— Ышандык инде, балам, барыбыз да ышандык.

— Ә менә минем ышанасым килми.

— Фәрхетдинне әйтәм, үзе дә үлде теге вакытта, сине дә үтерде. Безнең беркатлылык аркасында, безнең наданлык, гамьсезлек аркасында үтерә алган ул сине — ышандык без ана, тәки ышанылган... Кем икәнлеге тагын бер кабат ачылды. Их, бала, бала, гафу итә алырсыңмы икән инде син безне.

Онытының ни әйтерен көтмәстән, бабай юан бүрәнәгә күчеп утырды да, сакал-мыегын сыйпап уйлана торгач, күзләрен йома төшеп, борынгы бер көйне көйләп җибәрде.

Ал җимеш лә, гөлҗимеш лә
Сандугачка сөенеч.
Сандугачкай гөлне сөя,
Син дә сөяргә тиеш.
Сандугач, гөлҗимеш...

Сандугачкай гөлгә гашыйк,
Гашыйклыгы — җырында.
Сөйли кошкай ак бәхеткәй,
Пакь бәхеткәй турында.
Сандугач, гөлҗимеш...

Хушланудан, сокланудан
Сандугач телсез кала.
Сөеклесе илдән киткәч,
Гөлҗимеш таҗын сала.
Сандугач, гөлҗимеш...

Баланың җырны аңлап бетермәгәнен сизсә дә, Тугаш карт: «Я ничек?» дигән булып, солдатка карады.

— Әкият бик матур да... тик аңа ышанып та бетеп булмый бит, бабай.— Тагын нидер өстәмәкче иде, тыйлыгып калды.

— Әйдә, тагын бераз селкенеп алыйк, булмаса,— диде бабасы туган җир шигъриятенә онытын ышандыра алмау әчелеген басар өчен генә.

Аның җырын дәвам иткәндәй, әтәч кычкырды:

— Ки-ке-ри-и-и-кү-ү-к!

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Төн.

Төн ашыга таңга.

Төн ашыга очрашуга.

Таң кочагына ташлана төн. Ташлана да шунда юкка да чыга, эреп бетә, әйтерсең олы бәхете һәм мәхәббәте хакына корбан итә гомерен.

Караңгылык кочагыннан тынлык та качып йөгерә һәм Тау ягы дигән серле калага шаулап тагын яктылык керә. Кояш нурларыннан тукып ясалган чатырын җәеп, алсу-зәңгәр күлмәген киеп, көн килә Идел киңлекләренә.

Тагын көн килә.

## Яшь имән таныймы икән?

Туган җир һәр яңа көнгә истәлекләр сөйли. Аңа гына түгел, ишетсәң, сиңа да сөйли — чынын да, әкиятен дә. Күп хәлдә ул аны безнең бабайга әверелеп сөйли. Кайсына ышанырга, кайсына ышанмаска икәнен үзең бел, үзең бир бәяне, сиңа андый хокукны табигать үзе биргән, үз җирең киңәшә синең белән.

Көндез табигать серләре бик үк ачык ишетелми. Көн ул кешегә ләззәттән, хыялдан бигрәк, хезмәт өчен бирелгән. Җир һәм туфрак көндез эш авазлары белән бәхетле. Болары да изге тавышлар. Ә кичләрен, шул изге тавышлар тынгач, ишетелер-ишетелмәс кенә яфрак шыбырдый, чишмә чылтырый. Елганың да үз моңы бар. Менә шулар инде туган җир авазы булып ишетелә — сөя белсәң, тыңлый белсәң.

Сөяме, юкмы, Тәбрик әле ачык кына үзе дә белми. Ләкин тыңлый, ишетә ул.

Табигать аңа әнисе хакында сөйли. Ул хикәятләргә сирәк-мирәк Туташ бабасы, Сөембикә апасы сүзләре кушылып китә. Күкрәк биеклеге булып үскән бәрәңге сабаклары арасына, ике бакчаны аерып торган ызан буендагы түера янына ук баскан да тыңлый Тәбрик. Кайдадыр якында, бик якында менә шушы яшь имән яфраклары шавына кушылып, яшь бала тавышы ишетелә. Тәбрикнең үз тавышы... Тәбрик үз тавышын тыңлый, еллар аша тыңлап, үзен кызгана, тик кызганса да, ярдәм итә алмый.

— Йокла, балам, түз, балакаем...— Моңысы — әнисе тавышы, ул шулай Тәбрикне тынычландырмакчы була. Әмма юк, бала аның саен ярсыныбрак елый, аның саен әрнебрәк үкси һәм... бүгенге Тәбрик, олы Тәбрик, чыныккан солдат, авыртуга чыдый алмыйча, колакларын каплый. Хатирәләр тимер кием шикелле аның бөтен тәнен чолгап кысалар. Ул аны салып, иркенгә чыкмакчы, селтәп ташламакчы да җиңеллеккә ыргылмакчы була — уйны әнисенең күңеллерәк елларына күчерергә, туган авылының шаулап торган бәхетле чакларын күз алдына китерергә тырыша, ләкин...

...Үләмә буенда кыш та, җәй дә чылтырап чишмә ага. Көлемсәр чишмәдән су ала — суда шәүләсе чайкала... Мөлдерәп су тулган чиләккә әләкми шәүлә — һаман чишмә төбендә кала.

— Синең сурәтең дә минем күңелдә әнә шулай чайкала,— ди каяндыр килеп өлгергән бер егет.

— Абау! Кеше куркытып йөрисең шунда, көшбәтсез.

— Минем әти дә риза, әни дә. Бүген килсәң, бүген ике куллап күтәреп алырга торалар.

— Ә минекеләр белән сөйләшәсе дә юк, барыбер риза түгелләр.

— Каян беләсең?

— Сүзләреннән.
— Ничек?
— Әле биш елсыз ул хакта авыз да ачмыйбыз, диләр. Күрше-тирәгә шундый сүз тараталар.
— Чыгып куйсаң... бернишли алмаслар.
— Шулай да буламы?
— Әй, яратам да бит мин сине, Көлемсәр! СССРда бер бит син! Бер генә!..
— Абау! Үзәнбайдан чыкканың юк — СССР тагы сиңа!
— Нишләп чыкканым булмасын? Караталга барганым бар, Бортаска, Болгаерга!
— Әһә-һә! Ярты илне гизгәнсең икән инде. Үзәнбайдан ары алты чакрым җир киткәнсең икән.
— Бүген мин сине урлыйм. Ни булса — шул.
— Урланган малда бәрәкәт юк, ди безнең эти.
— Син мал түгел, син — сандугач.
— Җитәр, көшбәтсез.
— Чыгасыңмы бүген кич?
— Әллә тагы.
— Чык, шушы төшкә кил, мин сине шушыннан урлап китәрмен — туп-туры үзебезнең өйгә. Булдымы?
— Аннары ни?
— Аннары дип... туй итәргә риза эти. Әни күптән риза. Син ризамы?
— Түгел.
— Чык, яме!
— Көшбәтсез!
Йөгерә-йөгерә мунчага су ташый Көлемсәр — Фәрхетдин сүзләреннән соң ялан тәпиләре тагын да тизрәк ялтырый. Мәхәббәт! Ай бу ялан тәпиле мәхәббәт! Бөтен нәрсәне җиңел генә һәм шәп итеп хәл кыла да куя бит ул!
Фәрхетдин — балта остасы, һөнәре дә шәп, кыяфәте дә ким-хур түгел, халык әйткәндәй, сызылып киткән кара мыек, сөлек төсле егет. Тыйнаклыгы белән дә күңелне җылытып тора — тәүфыйклы ир булыр дип юрыйлар. Шул унтугыз яшьлек тәүфыйклы егет уналты яшьлек Көлемсәргә гашыйк...
Менә инде мунча да өлгерде, көтү дә кайтты. Әнисе сыер савар да этисе белән мунчага китәр, ә Көлемсәр тиз генә сепаратка кереп чыгар да, аннан... Калганын үзе белә инде ул. Дөресрәге, белә дә, белми дә — үзеннән-үзе сер итеп саклый. Сепараттан кайтып, ике-өч минут үтте дигәндә, сандыклар актарып, зур бер төенчек төйни дә Көлемсәр, келәт артындагы әрекмәнлеккә яшерә.
Караңгы төшкәндә мунчадан ак ыштан балакларын җилфердәтә-җилфердәтә этисе һәм аннан озак та тормыйча шундый ук кыяфәттә әнисе чыгып җитә. Көлемсәрнең эш беткән — сөекле эти-әнисен баллы-майлы өстәл, сап-сары самавар гөҗләп көтеп утыра. Шуның өчен әткә белән әнкә, кызны мактый-мактый, сөлгеләрне кулбашына салып кына, тирләрен сөртә-сөртә, чөкердәшеп чәй эчәргә тотыналар — бәхетнең, кызның кадерен белеп кенә.
— Әйдә, кызым, үз кулың белән дә ясап бир әле берне, синең кулдан чәй ишшү дә тәмлерәк була,— ди этисе.
— Әй, эти, тел бистәсе дә инде син.
— Дөресе шул, кызым. Рәхмәт, менә шәп. Үзең ник эчмисең?
— Эчәсе килми, эти. Мин тиз генә бозауны карап керим әле.
— Бозау? Нинди бозау?
— Рәтләп бикләмәдем бугай... Чыгып сыерны иммәсен,— ди Көлемсәр һәм чыгып та тая.
Күпмедер минут үткәч, әби әйтеп куя:

— Нишләп керми ул Көлемсәр?
— Бозау чыгып качканмы әллә? Тукта, карап керим әле?
Чыкса, абзарда бозау мыш-мыш күшәп ятуын беләә. Кыздан гына жилләр искән.
— Карале, карчык, кыз бит юк анда...
— Бозау артыннан киткәндер.
— Киткәндер сиңа бозау артыннан... Әйдә әле, бүген кыланышлары бик мәзәк иде. Нидер сизенгән идем аны.
— Булмасны сөйләмә инде, карт.
— Чыгасыңмы, юкмы, кәнсә-кәнис! Әйдә! — Карт шундый итеп акырды ки, гомерендә бу хәтлене ишетмәгән карчыгы, аякларына тиз-тиз генә киез-каталарын эләктерде дә, ах-ух килеп, карт артыннан йөгерергә кереште. Картның кулында — кай арада алып өлгергәндер — зур имән таяк, каталары өстеннән ябалак канатлары төсле ыштан балаклары лашпырдый.
— Гөнаһ шомлыгы, хәзер мин ул бозауның җанын алам! Эт итеп тукмыйм, юньсезне.— Кемне сүгә торгандыр карт, үзе дә белми.
Белми дисәң дә, дөрес бара бит әнә — түбән тыкрыктан ике кеше җан-фәрманга чаба — кызы һәм...
— Әй, туктагыз! Әй! — Карт кычкырып җибәрүгә, тегеләр кире борылып түбән таба сызмасыннармы. Елга буйлап, яңа салынып беткән өйгә таба.
— Юньсезләр, тәүфыйксызлар!
— Ник алай дисең, карт, туктале, тукта, киңәшик!
— Син киңәшкәнче...— диде дә тыйлыкты карт. Тик барыбер төшенде карчыгы: син сафсата саткан арада ни генә булмас бу дөньяда, дигән сүзе иде бу аның. Һәм йөрәкләрен тота-тота йөгерә бирделәр. Җитмәсә, үч иткәндәй, ыштан һәм чапан канатлары куак һәм әрекмән ботакларына эләгә дә туктата, эләгә дә туктата.
— Әй, җәмәгатьләр, тотыгыз! Кызны урлыйлар! Кызны! Тотыгыз!
Ул салган сөрәнне ишетеп бөтен авыл диярлек урамга чыккан арада, егет белән кыз яңа гына салынган бер өйгә кереп шылдылар. Көлемсәрнең этисе ишекне тартмакчы... Ә ишек эчтән бикле... Инде халык та җыелып алган — акырыш, гауга:
— Җимерергә кирәк ишекне, каерырга кирәк.
— Әйдә, бүрәнә белән, җәмәгать!
— Әйдәгез!
Дөп-дөп иткән тавыш һәм аны туктаткан аваз:
— Сез нәрсә, җәмәгать, җимерер өчен салдырдыммыни мин сезгә бу өйне? Ә?
— Кызны урлаганнар бит.
— Кызлы кеше, кем, син, бар, үз өеңне җимер, яме. Минекен җимермә.
— Нишләп җимерим ди? Ватам гына бит.
— Һа-һа-һа!
— Әй, җәмәгать, ташлагыз бүрәнәне...
— Алайса, ут төртеп кенә яндырыйк, җимермик.
— Үз кызыңны яндырырсыңмы?
Җавап урынына — ык-мык.
Нишләсеннәр, карт телен йоткач, халык таралыша. Карт белән карчык, мескеннәр, мунчадан пешеп чыккан тәннәре калтырый башлаганчы торсалар да, ялынып-ялварып та, куркытып-өркетеп карасалар да, ишек ачылмый.
— Ходай орган нәрсәләр! Егылып үлгерләре. Башыгыз бетсен! Бусагамнан кертмим мин сезне! Гомер буе бикләнеп яши алмассыз. Арт сабакларыгызны укытырмын әле мин сезнең! Нибуч! — Картның соңгы сүзләре шул булды.

Һәм киттеләр.
Ә өй эчендә...
Өй эчендәге Фәрхетдин белән Көлемсәр җинел сулыш алдылар. Ә моннан ярты сәгатьләп элек ишек бик каты дөберди башлагач, Фәрхетдиннең тавышы ничектер калтырый башлап, ничектер үзен-үзе белештермәгәндәй:
— Әллә ачыйкмы? — дип Көлемсәргә сыенган иде.
Көлемсәр шунда гаҗәпләнеп кенә куйды:
— Син нәрсә? Куркасыңмы? Курыксаң, бар, тәрәзәдән ташлан...
— Юк, мин болай гына.
Шулай диде дә тынды егет. Әмма тыштагы тавышларны бик игътибар белән тыңлый иде ул.
Көлемсәр ачуланмады, ләкин егетнең шул кыяфәте, агарынган йөзе әллә ничек: әйтеп бетереп булмый торган шик төслерәк булып хәтергә урнашты. «Әллә ачыйкмы?..» дигән сүзе еллар буе һаман ишетелгәндәй тоела иде аңа.
Ни генә булмасын, бу вакыйга авылда озак еллар буе кызыклы хикәя булып йөрер өчен калды. Барышмый-килешми атна-ун көн уздыргач, ду килеп туй да иттеләр.
Матур яши иде Көлемсәр. Вакыты җиткәч, алма төсле кыз бала, аннан тагы күп тә көттермичә икенчесен алып кайтты. Тагын да бик күп еллар шулай бәхетле яшәр иде, әлеге дә баягы — бөтен дөнья өметен җимергән сугыш булмаса... Фәрхетдине сугышка китте дә, күп тә үтмичә, бөтен дөньяга таныш хат килде: «Сезнең тормыш иптәшегез рядовой Фәрхетдин Гыйльметдинович Закиров Ватан азатлыгы өчен сугышта батырлар үлеме белән һәлак булды».
Ике ятимәне кочаклады да калды Көлемсәр...

*
* *

— Сөембикә апа, ятимәләр дигәнегез минем апалармы инде?
— Апаларың, Тәбрик, синең апаларың.
— Ә хәзер кайда алар?
— Урта Азиягә киттеләр. Ташкент ягына. Чәчелдегез дә беттегез шул, берегез дә калмады. Өегез буш хәзер...
— Ә апалар ник китте?
— Шул инде, җуелган бәхетләрен эзләп.
— Тапканнармы соң?
— Чит җирдә тапкан бәхетне инде аны...
— Кыен яшиләр микән?
— Үз тормышлары, үз балалары анысы.
— Миңа адресларын бирә алмыйсызмы?
— Бирермен. Син дә алар кебек авылыңны ташлап китәрсеңме икәнни?
— Әти ике кыз бала калдырып фронтта батырлар үлеме белән үлгәч, мин ничек тудым соң?
— Их, Тәбрик, дөнья катлаулы шул... Төрлечә сыный кешеләрне тормыш дигәнең.
— Ничек кенә булса да яшермәгез, мин белергә тиеш.
— Анысы шулай инде ул да...

*
* *

Күкрәк биеклеге булып уңган бәрәңге сабаклары арасына кереп, ызан буендагы имәнгә сөялгән Тәбриккә яшь имән шавы белән бергә яшь бала тавышы ишетелә. Ишетелә дә тагын нигәдер тынып тора.

Сөембикә апасы сүзләре төсле булып ераклардан ямансу өннәр килә. Сүзләр — һаман Тәбрикнең әнисе хакында...

Көлемсәр — игенче кызы, басуга мәхәббәте ана сөте белән кергән һәм бөтен гомерен билгән. Гади игенче генә булып калмыйча, Идел буендагы Тәмте авылына барып, «Зональный училище» бетергән һәм туган авылына агротехник булып кайткан.

Белем үзе шәп нәрсә, ләкин аның файдасыз байлыкка, күз көегенә әйләнүе дә бик җиңел икән. Агротехника кушканча эшләр өчен, көч кирәк — тракторлар кирәк. Трактор булмаса, һич югында — атлар кирәк. Атларның иң яхшылары, егетләр төсле үк, фронтка китkәч, яки дошман табаныннан әле генә котылган бүтән җирләргә ярдәмгә җибәрелеп, авыл атсыз-көнсез диярлек калгач, төссез-хәлсез атлар арбачаналарны сугышка бара алмаган карт-коры, бала-чага белән бергәләп тартканда да көчкә-көчкә генә сөйри башлагач, агротехника онытылды. Басуда сабан өстерәгәндә буразнага башларын төртеп атлар җан бирәләр... Дөньяның шушы хәтле дә киң, шушы хәтле дә матур икәнен беренче һәм соңгы кабат шунда гына күреп кала торганнардыр алар. Атлар үлгәндә генә күккә карыйлар...

Хәлсез ат белән нәфис хатын-кыз авылны көчкә өстерәп бара. Бу чакларда Көлемсәр булып Көлемсәр дә сирәк елмая.

Басуга тубал тотып картлар белән бергә ул да чыга һәм иген чәчә. Атлый да сибә, атлый да сибә. Көннәр буе.

Бер көнне басуга яшь бер кеше килеп тукталды:

— Кем монда Көлемсәр?

— Мин. Ни бар?

Көлемсәр шулай дип сорады да, үзе, җавап белән кызыксынмагандай, тагын бодай бөртекләрен очыра-очыра (анысы да колхозның үзенеке түгел, Каратун пристаненнан барып алдылар — дәүләт бирде) атлавында булды. Сизелер-сизелмәс эзләр генә кала артыннан. Озаклamый — ямь-яшел, яп-яшь сабаклар тишелеп чыккач — ул эзләр күмеләчәк... «Бодайлар! Шаулап үсәрме шулай, әллә чүп-чар астында күмелеп калырмы?»

Ул эзләргә басып әлеге егет атлый икән.

— Сезгә нәрсә кирәк? — диде Көлемсәр, кинәт тукталып.

— Мин — районнан... вәкил. Сезгә ярдәмгә җибәрделәр.

— Алыгыз соң тубал... Әнә тегендә арба янында...

— Миңа икенче төрле эш кушкан иде...

— Ярдәм итәргә дигәч, бүтәнчә мөмкин түгел, бары тик эш белән...

Егет, гажәпләнүеннән туктап, Көлемсәрнең уйчан һәм искиткеч гүзәл кыяфәтенә карап катты да калды. Бүтәнчә сүз кушарга мөмкин түгеллеген чамалагач, үзе дә, арба янына барып, җилкәсенә тубал асты һәм әле генә барлыкка килгән өметләре төсле саф бөртекләрне җилгә каршы чәчә башлады.

Төш җиткәнче шулай эшләделәр.

— Минем исемем — Мирсәет,— диде егет кайтышлый.

— Булса соң? — диде Көлемсәр, көлмичә генә.

Бергәрәк баручы бүтән хатыннар һәм малайлар елмаеп кына куйдылар. Шаярырга кемнең дә хәле юк. Авылга кергәч, кем кайсы якка сүзсез генә таралышты. Көлемсәр дә үз өенә кереп калды. Вәкилгә борылып та карамады.

Ләкин тегесе болар янына көн саен килеп китә торган булып, бер көнне болай диде:

— Сезнең эшегез моның белән генә чикләнергә тиеш түгел.

— Беләм.

— Трактор белән дә чәчәләр бит, теге як басуда. Дөрес чәчәләрме?

— Көн саен булам мин алар янында. Ышанычлы кешеләр.

— Ышан, ләкин тикшер.

— Сез килдегез бит, тикшерегез менә.
— Сезнең белән бергәләп. Әйдә, барып кайтабызмы?

Юк-бар сүз белән авылдан ким дигәндә ике чакрым ераклыктагы тракторчылар будкасына барып життеләр. Жирдән керосин исе аңкып тора. Ике-өч мичкә һәм тегендә-монда нindидер тимер-томыр аунап ята, кеше күренми. Будкага керсәләр, анда да жан иясе юк. Стенага «Сугышчан листок» ябыштырылган. Шуңа карап, вәкил:

— Монысы әйбәт,— диде.— Кем яза?
— Кем булсын инде.
— Үзегез?
— Үзебез! — диде Көлемсәр, үчекләгәндәй тавыш белән.
— Яза да беләсез икән.
— Беләбез.
— Бер генә авылда да сезнең кебек чибәрне күргәнем юк иде,— диде егет.

«Оялмый да». Көлемсәр, бу фикерен запаска калдырып:

— Авылдан-авылга кызлар күзләп йөрибезме? — дип кенә куйды.
— Сез чибәр һәм чәнечкеле... гөлжимеш кебек.
— Чәнечкеле булмасаң, күргән берегез тотып ашарга да күп сорамый бит.
— Әйе шул.
— Әйдә, егет, ышыкта әллә ни сөйли башладың. Жилгә чык.
— Анда салкын.
— Баштагы чүп-чарны туздгытып ташларга шәп була ул суык жил.— Көлемсәр тиз генә чыгып, трактор гүләгән якка таба атлады.

Мирсәет тә калмый, әрсез. Күпмедер баргач, куып житте дә бик озак уйлаганнан соң гына әзер булган нәтиҗә төслерәк итеп шуны әйтте:

— Мин сезне коточкыч нык итеп ярата алыр идем!
— Ә нәрсә комачаулый?
— Көлемсәр, шаяртма. Мин чынлап.
— Кызык егет син.
— Ут белән сәхнәдә генә уйнау күңелле. Ә жирдә...
— Уйнамагыз, кем куша.
— Пожар чыгаруың бар, Көлемсәр.
— Сүндерүчеләр табылыр.
— Кемнәр? Синең бит... Сезнең бит...
— Нәрсә? — диде Көлемсәр һәм үзе дә көтмәгәндә елмаеп егеткә карады.
— Сезнең бит ирегез инде хәтсездән үлгән...— һәм шул сүзе белән бөтенесен харап итте вәкил иптәш. Көлемсәрнең бөтен күләчлеге очты да китте... Авыз ачып бер сүз әйтмәс булды. Тракторчы һәм чәчүчеләр белән сөйләшкәндә дә кырыс иде ул:

— Почмакларыгызда чи калган. Анда нәрсә үстерергә уйлыйсыз?
— Соңыннан әйләнербез,— диде тракторчы хатын.

Мирсәет исә күңеленнән шул хатын белән Көлемсәрне чагыштырды да нәтиҗә ясады: «Көлемсәр артистка кебек үткен һәм чая... укытучы кебек тыйнак һәм акыллы».

— Килгәндә карап мендек — беткән кишәрлектә дә буш почмаклар калган. Әйләнмәгәнсез.

Мирсәеттә яңа фикер: «Ә мин — тикшерергә килгән махсус кеше — күрмәгәнмен...»

— Ярый, әйтербез.
— Карагыз аны, алдый алмассыз.
— Ярый, ярый, алдамабыз.

Трактор гүләп китеп тә барды.

*
* *

Шул көннән соң Көлемсәрне уйламаган сәгате юк Мирсәетнең. Бигрәк тә бер нәрсә котырта аны — ул теләгән темага авыз да ачтырмый Көлемсәр.

— Шулмы бик кирәкле сүзегез? Шуның өчен җибәрделәрме сезне вәкил итеп? — ди.

Бер көнне егет Көлемсәрнең тәрәзәсен төнге сәгать унберләр тирәсендә килеп какты. Тәрәзә пәрдәсе күтәрелеп, Көлемсәр күренде.

— Чык әле ике генә минутка, Көлемсәр. Бик кирәкле эш бар.

— Иртән дә мөмкиндер ич... җиде төн уртасында уятмасагыз.

— Бик ашыгыч, чык әле.

...Яшь хатын белән яшь егет шушы көзге шомлы төндә ни сөйләштеләр икән? Бу инде ике кеше арасында мәңгелеккә кала торган сердер. Аны беркем дә ишетмәгән һәм ишетмәячәк. Моны Тәбриккә беркем дә сөйләми һәм сөйләмәячәк. Күз алдына китерү дә кыен булачак. Дөнья шундый серләр белән тулы... Ул серләр — күктәге йолдызлар санынча, агачлардагы бөреләр санынча, күкрәкләрдә типкән йөрәкләр санынча... Шулай да чама белән төшенү кыен түгел аларны: чамадан тыш күп серләрнең җыенысы бергә мәхәббәт дип атала. Нинди генә сүзләр әйтелсә дә — барысы да мәхәббәткә тоташа. Шулай да беләсе иде — нинди сүзләр сөйләштеләр икән яшь гүзәл хатын белән яшь чибәр егет көзге шомлы төндә?

Моңайдылар микән, көлделәр микән? Ихтимал, көлгәннәрдер. Монысы табигыйрәк, чөнки көлүнең азагы — күз яше...

Шунысы мәгълүм — монысын Сөембикә апа яхшы белә — Көлемсәр белән Мирсәет ул төнне басудан кайтмаганнар... Шул котырган җилле төндә, шыксыз яланда ничек җылы тапканнар диген! Әллә көзне җылытырлык ук мәхәббәт булдымы икән?

*
* *

Җәйге яшел көн, иркә җил, яшь имән.

Шундый матур көн, шундый ягымлы җил, шундый яшь имән Тәбриккә кызганыч бәхет турында сөйлиләр, Сөембикә апа тавышына кушылып сөйлиләр алар.

...Иртән мин чәчүгә менгәндә, Көлемсәр белән Мирсәет орлык төялгән арба янында басып торалар иде. Сөйләшмичә генә. Йөзләрендә беренче карауда ук әллә нинди үзгәреш сизелеп тора... Бигрәк тә Көлемсәрнең оялчан йөзендә. Егеткә күтәрелеп карарга да батырчылык итә алмый, хәтта безгә дә... Гомер буе бергә үскән, бергә яшәгән туганнарыннан да оялгач ни! Ул курка — күңелендәген бүтәннәр сизә дип курка, төнге сүзләрне алар да ишетеп торгандыр дип ояла. Ишетмәгәнен дә белә, ләкин аңа шул чаклы нык билгеле булган нәрсәнең бүтәннәргә фаш булмавын акылы белән сыйдыра алмый... Шул кадәр кызганыч тоелды миңа Көлемсәр бу иртәдә. Кайгысыннан кичерәеп калган һәм шул ук вакытта әйтеп бетергесез бәхетле дә иде ул үзенең ямансу сере белән...

Бүтәннәр берни сизми. Аларда бүтән кайгы, бүтән шөгыль. Бигрәк тә кызларда. Кызлар Мирсәетне үртәп, үзләренең гөнаһсыз шаянлыкларын башкаларга да күчерәләр.

— Егетебезнең әнисе бик усалдыр, ахрысы, кызларга карама, дип әйтеп җибәргәндер.

— Егетмени ул, поломучный бит.

— Безгә килгәч, эре бәрәңге ашаган.
— Егерме кызга — бер егет, эреләнерлек тә шул.
— Әй, егет, торма җебеп.
— Кызлар, болай хәтерен калдырсак, беребезгә дә булмас. Бөтенебезгә дә эләксен, карап кына торыйк.
— Кирәкле кишер яфрагы...
— Лутчы булгәлик.
— Әйдәгез!
— Әйдәгез!
Мирсәет, мескен, көләргә дә белми, еларга да дигәндәй.
— Кызлар, бу нәрсә инде бу? Мин сезнең белән шаярырга килмәдем. Мин...
— Син, син... Ни өчен килдең?
— Чәчәргә безне өйрәтәсе юк, үзең өйрән.
— Әйдә, булгәлибез, әйдә!
— Кызлар, якын килмәгез... нишлисез сез? Ну, житте!
— Җиттеме? Әйдәгез, алайса, чынлап.— Шактый кыю бер кыз егетнең җилкәсеннән эләктереп тарта башлауга, бүтәннәре аяктан ук ектылар да изүләрен ачып корсагына бодай тутыра-тутыра чыр-чу килергә керештеләр.
— Бодайны әрәм итмәгез, бодайны! — дип кычкыра Көлемсәр.
— Җирдән ерак китмәс,— дип, кызлар егетне аунаттылар-аунаттылар да арыгач туктадылар.
— Акыл өләшкәндә кайда калдыгыз сез? — Шул сүзләр белән Мирсәет гимнастерка каешын ычкындырды да, куенындагы бодайны кага-кага, өс-башын рәтләргә әрҗәле арба янына килде.— Тапканнар шаярыр нәрсә.
— Чынлап та шул... Шаярырлык бернәрсә тапмадык.
— Җитәрегез инде, кызлар, уеныгызның чыры юк,— диде, ниһаять, Көлемсәр, үртәлүен яшерә алмыйча.
Әмма кызлар яңадан да озак кына каңгылдашмыйча туктамадылар. Ярты сәгатьләп үткәч кенә тырмачылар атлары янына килеп, чәчүчеләр җилкәләренә тубаллар асып, тагын орлык чәчәргә керештеләр.
— Әй, эт ашагыры мал! — дип җикерде бер чибәр, үгезләренә чыбыркы шартлатып.
— Әйдә, чаптаркай, сынатма,— диде икенчесе һәм сызгырып куйды.
Шул рәвешле таралыштылар да без өчәү генә калдык — Көлемсәр, мин, вәкил. Егет кәефе кырылган Көлемсәргә акланулы кыяфәт белән әйтте:
— Үпкәләмә, Көлемсәр, алар үзләре бит...
— Үпкәләрлек нәрсә юк монда, син аларга тиңрәк...— диде Көлемсәр һаман уйчан кыяфәттә.
Аралары шактый җитдиләшкәнен сизеп, мин дә тиз генә җилкәгә тубал эләктердем дә кызлар янына киттем. Хәлләрен сораштырмакчы идем Көлемсәрнең — бүтән вакытка кала инде, ярый. «Син аларга тиңрәк...» дигән сүзе гомерлеккә кереп калды хәтергә.
Тагынниләр сөйләшкәннәрен ишетмәсәм дә — чамалыйм: бер тирәдә әйләнгәндер әңгәмә. Бер уйласаң, гаҗәбрәк тә шул: егермешәр яшьлек егерме кызның берсен дә сайламыйча, кызлар үз чутларына кертергә башларына да килмәгән, ике балалы, егерме биш яшьлек хатын кешене ярата Мирсәет... Ник алай икән?
Соңыннан бу хакта Көлемсәрдән сораган идем, ул үзе дә гаҗәпләнеп әйтте:
— Йөз егерме кыз да кирәкми, син генә миңа кирәк, дип әйтә. Нәрсә тапкандыр миндә шул хәтле... нәрсә тапкандыр,— диде.

*
* *

Тәбрик кесәсеннән әнисенең рәсемен чыгарды да аңа текәлеп бик озак тын торды. Яшь имән таный микән, әллә онытты микән инде аның әнисен? Ул чакта бит имән әле Тәбрик кебек үк сабый гына, түерә гына булган.

— Чибәр булган икән шул минем әни.

— Чибәр иде, акыллы иде, ягымлы иде. Әллә нинди ямансу бер ягымлылык сирпелеп тора иде аның күзләреннән. Көлгәндә дә бетмидер иде моңсулыгы. Сөйләшкәндә дә ниндидер бик кирәкле бер сүзне әйтми калдырадыр иде шикелле. Көн буе бергә йөреп-сөйләшеп аерыласың да уйлыйсың: күзләре белән нидер эзләде, нидер тапты, нидер әйтергә теләде, әйтә алмады. Нинди сүз икән?

*
* *

Шулай һәр матурлык ниндидер сер белән өртелгән була. Кичке тынлыкта син арыш басулары буйлап әйлән — ниндидер яшертен мәгънә тирән сулыш алып ята шунда... Бакчалар буйлап, урманнар буйлап әйлән — аңлашылып бетмәгән мәгънәләр шаулый анда. Арыш өлгергән басуда, бакча янсә урман тынлыгында кемнәр генә мәхәббәт аңлашмаган, нинди генә кешеләр үзләренең иң эчкәреге өметләрен табигатьнең төс-буяулары белән бизәмәгән... Эшләгән, сөйләшкән, көлгән, яраткан — яшәгән. Хәзер күзгә һичнәрсә күренеп тормаса да, башаклар һаман элеккечә кыштырдый, яфраклар элеккечә шыбырдый...

Үзәк өзгеч моң. Шундый аңлап булмас моң һәр минут, һәр сәгать сизелеп тора иде синең әнкәңнең һәр сүзе, һәр хәрәкәтеннән. Хәрәкәтеннән бигрәк, күзләреннән. Барлык Тау ягы матурлыгы тупланган иде бугай ул күзләрдә. Сөембикә хатын-кыз була торып яраткач ул күзләрне, Мирсәет ничек яратмасын соң?!

Чат ябышты Көлемсәргә егет һәм ычкындырмады: күпмедер вакыттан соң элекке иреннән, Фәрхетдиннән калган ике кызы белән район үзәгенә алдырды. Тик авылда аларның бергә тора башлауларын беркем белми иде — әйтмәделәр, сөйләмәделәр чөнки. Ә Көлемсәрнең, укыган кешенең, районга эшкә күчүе гомумән мәзәк тоелмады.

Элекке ирен яраткандырмы, юкмы, әйтә алмыйм, әмма да Мирсәетне чынлап сөя иде Көлемсәр — әллә нинди фаҗигале ашкыну белән ярата иде. Шулай да тормышка чыгу һич теләгендә юк иде. Шунысы бар: Фәрхетдиннән, әйткәнебезчә, хат-хәбәр инде күптән килми. Батырларча һәлак булды дигән язу гына саклана сандык төбендә... Шулай да — яшьлек хатирәләренә, беренче кавышу, беренче якынлашу матурлыгына кер төшерүдән, күңел сафлыгын, хис изгелеген югалтудан куркыпмы, бер дә теләмичә, аяклары тартмыйча гына китте әнием район үзәгенә. Аяк тартмаган җиргә бармау хәерле. Бергә тора башлап ике-өч ай да узмагандыр, Фәрхетдиннән хат килеп төшмәсенме: исән икән, хәерсез, әсирлектә булган һәм хәзер үзебезнең якка чыгарганнар. Озакламый кайтырмын дип язган.

Ничек ике ут арасында көйгәнен, газап чиккәнен Көлемсәр үзе генә белгәндер. Мондый хәлдә киңәш бирү дә, акыл өйрәтү дә җиңел түгел — мең кабат уйлап, беркемне дә тыңламастан һәм ишетергә дә теләмәстән... үзенчә хәл итте Көлемсәр. Монысы Фәрхетдин кайтып төшкәч булды.

*
* *

Мең үлем кагылудан тупасланган карт солдат күнеле дә бикле өйгә кайтып төшкәч яңадан ачык җәрәхәткә әйләнми калмагандыр. Фәрхетдин хәлен дә күз алдына китерергә кирәк. Кешеләрнең хатыннары киткән, яңадан матур тормыш корып җибәргәннәр. Кавыша алмаганнарының кайберләре һаман өметләрен җуймый көтә. Ә Көлемсәр, изге дип саналган Көлемсәр, уналты яшьтән сөеп чыккан Көлемсәр... Балалыгы белән генә алданды микәнни, чынлап яратмады микәнни? Юк, юк, чынлап ярата иде. Фәрхетдиннең йөрәге моны сизә иде, ләкин ул чакта арада Мирсәет дигән кеше пәйда булмаган иде. Фәрхетдин үлмәсә, аны сөяргә ничек кенә булса да вөҗданына рөхсәт итмәгән булыр иде. Ә үлгәч... Әнә сугыш чорында бер шагыйрь:

Сиңа сер итеп әйтәмен
Якын күргәнгә генә:
Мин үлсәм, башка берәүне
Салырсың йөрәгеңә,—

дип үзе хат язган бит. Ата-бабадан килгән миһырбан үзе шулай куша. Әгәр үлгән булса, Фәрхетдин дә шулай олы җанлы булып калыр иде. Шул чакта чынлап та геройларча һәлак булмавына, язмышына чын күңелдән үпкәли хәзер Фәрхетдин. Исән булмаса, хәерлерәк буласы икән, хәерлерәк буласы!

Ялан хәтле өйдә кичләр һәм төннәр буе ялгыз уйланып ята торгач, акыл дигәнең буталып ук китә шикелле. Акыл бутала, аның белән бергә — бәйләнчек сораулар туа...

Фәрхетдин «үлгәнгә күрә» генә Мирсәет дигән бәндәгә киткән хәләл хатыны Фәрхетдин исәнгә әверелгәч, хатасын яңадан төзәтсә, ни гаеп? Әгәр Көлемсәр кайтмаса, Фәрхетдин дигән бәндә гомер буе сагынып, иң бәхетле көннәрен һәм яшь Көлемсәрен хыялыннан чыгара алмыйча, аның белән бергә яшәячәк. Ә кайтса? Кайтса да ни буласын әйтә алмый Фәрхетдин... Ләкин кайтырга тиеш Көлемсәр, тиеш!

Фәрхетдин килеп керүгә, Көлемсәр баскан төшендә телсез калды. Ят кешедән куркып диярсең, ике кызы, Фәрхетдин хәзер икесен берьюлы күтәреп кочагында очыртып уйнатасы ике сабый, әниләре итәгенә сыенды. Фәрхетдиннең тышкы пөхтәлеге аша ниндидер усаллык, кыргыйлык сизелә иде бугай аның күзләреннән, ялыну катыш зәһәр рәнҗеш бөркелә иде... Күпме тыярга тырышса да, яшерә, тыя алмады ир кеше ул зәһәрлекне...

— Менә мин кайттым, Көлемсәр,— диде.

Ә Көлемсәр аңына килә алмый.

— Мин сине алырга килдем, Көлемсәр.

Тагын да ныграк каушый Көлемсәр, телгә килә алмый.

— Болар — минем кызлар, мин аларны да алырга килдем.

— Юк, юк! — җан ачысы белән кычкырган Көлемсәр балаларны кочакламакчы, ләкин кулында савыт-саба иде.

Фәрхетдин шуларны алып куймакчы булгач, хатын читкә тайпылды. Аннары ата кеше кызларының башларыннан сыйпамакчы иде, балалар нигәдер кычкырып елап ук җибәрделәр.

— Кит, Фәрхетдин, балаларны яратсаң, тизрәк кит!

Шул сүзләрне ишеткәч, Фәрхетдин коелды да төште һәм, җитмәсә, шул вакыт Мирсәет дигәннәре кайтып керде. Бөтенесен аңлады, әлбәттә. Көлемсәрнең кулындагы тәлинкәләрне ник өстәлгә куя алмый интеккәнен күреп, беренче эше итеп, шуларны алды да, әйтерсең бик тыныч кына аш сала башлады.

— Рәхим итегез өстәл янына.

Ләкин аны беркем ишетмәде. Аптырагач, кунагыннан:

— Син Фәрхетдинме? — дип сорады.
— Фәрхетдин булсам, ни әйтер иден?
— Сүзем шул гына, гаепле кеше эзләмә, бик каты ялгышырсың. Үзеңне дә җәзалама, безнең дә бәхетне җимермә — үз өеңдә матур гына итеп яңа тормыш кор.
— Яңа тормышны син кор инде, энекәш, сиңа җайлырак булыр ул. Ә минем хатын һәм балаларда синең дәхелең булмасын.
— Мин сиңа яхшылык белән...
— Миңа синнән бернинди яхшылык кирәкми, булганы бик җиткән. Инде Көлемсәрдән, балаларымнан башка бер ай интектем. Алардан башка беркемне дә үз итә алмаячагым көн кебек ачык.
— Тагын бер ай интегеп кара.
— Акыллы егет икәнсең, рәхмәт, тик мин әйтәм, син үзең интегеп кара. Бәлки син интекмәссең дә... балаларың юк...
— Кем әйтә алай кистереп?
— Нәрсә?
Мирсәет Көлемсәргә карады, шуңа күрә бугай хәләле, ниһаять, үзе телгә килде:
— Фәрхетдин, ачуланма, тынычлан, кит, кичер.
— Мин сине кичердем, кайт кына.
— Мин синнән үтенеп сорыйм, зинһар, кит.
— Алайса, балаларны бирәсез. Бу фатирда үзегез кеше почмагында яшәгәндә, аларга адәмчә яшәү мөмкин түгел монда. Кышка каршы салкын идәндә аунатырга ирек бирмәм, көтмәгез. Киенегез, балалар.
— Соңгы сүзне әйттермә, Фәрхетдин...
— Нәрсә, буеңда юктыр бит?
— Бар.— Бу юлы инде Мирсәет ирләрчә катгый итеп әйтте.
Күпмедер вакытка тагын өнсез калдылар. Ахыр чиктә Фәрхетдин нәрсәнедер хәл иткәндәй тирән итеп сулады да кызлары янына килде.
— Үзәнбайга, үз өебезгә кайтабызмы? Сагынгансыздыр инде.
Куркулары ничектер уза башлаган балалар нидер пышылдый алдылар. Тик сүзләре ачык ишетелмәгәнгә, Фәрхетдин тагын кабатларга мәҗбүр булды:
— Сезне өй сагынган, бакча... Мин сагынам, мин — сезнең этиегез.
Кызларның олырагы, ниһаять, елмайгандай итте. Нидер әйтәсе дә килде бугай. Мөгаен «эти!» дип эндәшәсе килгәндер. Бәлки бүтән сүзләре дә хәтеренә төшкәндер. Шунысы ачык — кыз этисен таныды.
— Сагындыгызмы авылны?
— Сагындык.
— Әйдәгез, алайса, киттек.
— Әни дә кайтсын.
Олыларның күз карашлары кылычлардан да катырак бәрелешеп, чыйкылдашып алуын, әлбәттә, балалар да сизми калмагандыр. Кызларының ягымлы чыраен күргән Фәрхетдиннең баягы кыргыйлыгы жуелып, ул инде акылга сыешлы тәкъдим ясады:
— Сез балаларны әзерли торыгыз — тагын бер атнадан килеп алырмын, ачуланышмыйк,— диде.

*
* *

Беркем берни вәгъдә итмәсә дә, күнелендә көйрәп торган күмер һаман җанын исертеп әрнетсә дә, Фәрхетдин кайгысын җиңәргә тырышты. Әмма... ялгызлык барыннан да усалрак иде, зиһенне гел миңгерәтә торды. Шул нәрсәне ачыклап бетерә алмады Фәрхетдин: бигрәк тә нәрсә җанны талый — ялгызлыкмы, хатыны ташлау оятымы, әллә алырга барып та алып кайта алмау гарьлегеме? Әйе, гарьлек, нииндидер

гарьлек, җиңелү гарьлеге... Шул гарьлеккә үч итү, җиңү нияте белән өйләнергә дә тырышып карамады түгел. Әмма барып чыкмады. Күңелгә ошый язган берәү килешеп беткәч кәҗәләде: «Плендә булган кешене белмәссең, себер җибәрерләр дә, балалар кочаклап кал аннары», дигән булып курыкты мәгънәсезең. Менә сиңа тагын бер төзәлмәс җәрәхәт! Җитмәсә, Фәрхетдин бу мәгънәсез сүз хак булып чыкмас дип тә төгәл әйтә алмый, андый нәрсәдән бер генә кеше — Көлемсәрнең генә курыкмаячагын бөтен йөрәге белән тоя да буш дөньясын өметтән бигрәк хәвеф тутырганын, бу бушлыкны бары тик Көлемсәрнең генә тутыра алачагын бар акылы белән аңлый һәм, хәлəлен өйгә кайтарып булмаячагын төшенгәч, тәмам югалып кала. Әйе, аны бары тик бер генә кеше — Көлемсәр генә коткара алачак. Ул гына, бары тик ул гына! Һәм бер көнне Фәрхетдин курку, каушау дигән нәрсәләрне җиңәргә тырышып, үз сүзен итәргә дигән теләк һәм ярсыну белән, авылдагы иң шәп атны һәм тарантас сорап алды, дугасына хәтта җиз кыңгырау да такты; күрше-тирәгә: яңа хатын алырга барам, дигән булып, тагын Көлемсәрне һәм балаларын алырга китте.

Юл буе нәрсә уйлаганын сорасаң, үзе дә әйтә алмас иде. Мие дә, күңеле дә, дугадагы ялгыз кыңгырау да бер генә мәгънә белән чыңладылар: «Көлемсәр, Көлемсәр, Көлемсәр...»

Яшьлектә Фәрхетдин кызны урлап кына — җәяүләп кенә алып кайтты һәм, бер карасаң, оят-гарьлек шуннан ук башланган да шушы дәрәҗәгә җитеп үскән хәзер. Ходай язгандыр... Ләкин яшьлек кимчелеген төзәтеп, кыңгырау чыңлата-чыңлата, хатынны барча авылларга күрсәтеп алып кайтырга шул ук ходай куша! Һәм хатын моңа лаек! Артыгы белән! Күп кызлардан әле дә гүзәл, әле дә сөйкемле бит ул!

Хатыны һәм балалары вакытлыча торган ят өйгә килеп терәлгәч, нәрсәнедер уйлап җиткермәгәнен тойды, ләкин тәгаен нәрсә икәнлеген күз алдына китерә алмыйча, беравык капкага сөялеп торды. Ярый әле, ишегалдыннан кызлары күреп аның янына килергә батырчылык иттеләр. Капканы ачкач хәтта бу якка чыктылар, әтиләре кочаклагач, бик тыныч кына басып тордылар.

— Я, кайтабызмы?

Кече кызы күзләрен челт-челт йомгаласа, олысы беркөндәгедән дә кыюрак итеп әйтте:

— Әни кайтса, кайтабыз.

— Әниегез дә кайта, алла бирсә кайта. Килегез әле, утырыгыз әле шушы тарантаска. Әниегез белән без хәзер чыгып җитәрбез.

Ата кеше шул сүзләр белән балаларын тарантаска күтәреп утыртты да тиз генә өйгә кереп китте.

Көлемсәр гадәттәгечә казан тирәсендә булаша иде булса кирәк. Фәрхетдин дә ни чаклы гына ярсып керсә дә, беркөнге кебек үк, сабый шикелле, ишек төбендә катты да калды. Монда инде вакыт дигән нәрсә үзенең көчен җуйды. Нәкъ сабый сыман елап та җибәрер шикелле иде ир кеше. Кыяфәтенә, торышына карап, кызганудың ахыр чигенә җиткән хатыны, ниһаять, үзе сүз башларга тиеш тапты:

— Тагын киләсе иттеңмени, Фәрхетдин?

— Балалар тарантаста инде, сине көтәләр...

— Җүләрләнмә, Фәрхетдин! — Ялварулы бу сүзләрдән шулай ук ниндидер якынлык ишетелә иде. Шул хис Фәрхетдингә җан кертте һәм Көлемсәрне урлаган чагы ап-ачык булып хәтеренә килде дә шул чактагы кебек үк әллә нинди сусаулы бер сөенеч белән елмаеп куйды. Әйе, вакытны тәмам бутады Фәрхетдин: аның алдында — гүзәл кыз Көлемсәр, ә ул яшь чибәр егет кызны урларга түгел, бу юлы законлы рәвештә алырга килгән, ул законлы мәхәббәткә, законлы бәхеткә хаклы! Хаклы кеше хакын белеп ялвара:

— Сине урлап киткән төшләрне күрсәм, йөрәк жу итә... Һәр жирдә — син, күзләрең, тавышың... Үтермә, Көлемсәр, кайт. Жирсегән ат шикелле егылып үләм мин, әгәр кайтмасаң.— Һәм тагы башы авыраеп түбән иелде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Көлемсәр мич янындагы эскәмиягә утырды да тын калды. Аның ни кичергәнен хәзер Фәрхетдин бик яхшы тоя, ләкин... нинди карарга киләчәген белмичә газаплана. Нәрсә әйтер? Нәрсә? Ниһаять, бер сүз әйтергә тиештер бит инде? Күпме утырырга мөмкин?

— Үтермә, Көлемсәр!..

Ә Көлемсәр иренә шашкандай карап торды-торды да алъяпкычы белән битен каплады. Битен каплады да үксергә тотынды.

— Син үзең, үзең мине үтерергә килгәнсең!

— Көлемсәр, жаным, бәгърем, үлмик, икебез дә үлмик. Әйдә, кайт өенә, өең көтә, авылың, болының, кырларың, юлларың... яшьлегең...— Егет чакта әйтә алмаганны картайгач жан әчесе менә шулай кычкырырга мәжбүр итте. Күңелендә жыелып сакланган сүзләре аңа буйсынмыйча теленнән ычкындылар.

Сүзләренә үзе дә ияреэргә теләгәндәй, бер секундта сикереп торды да хатынының иңеннән кочаклап, аны юатырга, күз яшьләрен сөртергә кереште. Һәм шул вакыт, капка төбеннән кычкырып, аңа кызлары ярдәмгә килде:

— На, бахбай, на!

— Әйдә киттек үзебезнең өебезгә!

— На-а!

Кыңгырау чыңы — яшьлектәге кебек, нәкъ яшьлектә утырып кайтырга тиеш булган пар атлар кебек... Ямь-яшел болыннар, ябышып чыккан чакта кереп бикләнгән өр-яңа өйдә беренче үбешү...

Ай, чит кеше өе булып чыкты шул аларның тормышлары кушылган урын. Әллә шуның өчен хәерсез булып чыкты микән аларның язмышлары?

— Киен, Көлемсәр, тизрәк.

— Мирсәеттән качыпмы? — Мәгънәсен аңладымы-юкмы, ләкин ишетте Фәрхетдин бу сүзләрне.

Әйе, бу аның жиңүе иде, жиңүе һәм бәладән котылуы, бәхетсезлектән әйбәт көннәргә юл табуы иде — аңа хәзер бер генә нәрсә — жан олылыгы гына кирәк, хатынының бөтен ялгышларын гафу итәргә, чын күңелдән гафу итәргә генә кирәк, һәм, күз тимәсен, Фәрхетдин шул зурлыкка, шул чынлыкка әзер бугай... Шундый чын миһырбан белән әйтелгән беренче сүзе шулдыр:

— Мирсәеттән качып? Алайса, көтик.

Бүтән сүзләр артык иде. Ничектер бугазны буып торган әлмәк өзелде... ләкин эшнең ни белән бетәсен икесе дә ачык белми әле. Тәрлесен күтәргә мөмкин... Соңгы сүзне, әйтерсең, Мирсәет алып кайтырга тиеш. Ярый әле, вакыт дигән нәрсә оста табип — яраларны сыйпап уза тора — югыйсә, бу ир белән хатын тәмуг дигәннән дә мең мәртәбә каһәрлерәк шушы хәлдән ничек чыгарлар иде икән? Ә менә вакыт коткарды — Мирсәетне, ниһаять, кайтарды. Мирсәет, билгеле инде, кергәндә үк хәлне аңлаган һәм чырайдан язган иде. Ләкин ул Фәрхетдин дә, Көлемсәр дә көткәнгә караганда юашрак кыланды. Әйтерсең, сүз өчен генә әйтүе:

— Көлемсәр, нишләвең? — диде.

Моннан ары булганны күз алдына китерү кыен түгел: башта — сүзсезлек, аннан соң Көлемсәр күзләреннән ихтыярсыз тәгәрәгән күз яшьләре, аннан соң күз яшьләреннән ачырак сүзләре:

— Без күрәсен әллә кем күрмәс, Мирсәет, тәкъдир шундыйдыр, ачуланма.— Китәм димәде, ләкин аңлашылды...

— Беркая китмисең! — Чынлап җибәрәсе килми бит!
Шуны аңласа да, Көлемсәр кузгалды:
— Мин балаларымның урын-җирен алам инде...
Бүтән бер сүз әйтмичә, урыныннан купмыйча катты да калды Мирсәет. Көлемсәр шуны гына аңлап бетермәде — артык сызланудан шулай аптырап калдымы ул, әллә, киресенчә, инде баладан котылырга риза булуданмы... Монысын әйтү мөмкин түгел, ә менә дурт кешелек гаилә, кыңгырау чыңлата-чыңлата, тыныч бәхетләр иленә кайтуына ышанып, сәфәр китте.

*
* *

Бу көннәрдә үзенеңниләр уйлаганын һәм кичергәнен беркемгә дә сөйләмичә, Көлемсәр һаман кабатлар иде: «Тәкъдир шундыйдыр инде, без күрәсен бүтәннәр күрмәс».
Башта матур гына яшәп тә киткәннәр иде кебек, әмма бер көнне чырайдан тәмам язган иде Көлемсәр.
— Ул-бу юктыр бит? — дип сорадым мин.
— Бар шул, Сөембикә апа, бар,— диде Көлемсәр.
— Ни бар?
— Фәрхетдин... туачак сабыйны күпсенә, юк итәргә куша.
— Белгән иде дисең түгелме соң?
— Белсә дә... юк итәргә куша. Нишлим икән?
— Белмим шул, Көлемсәр. Уйлашырга, киңәшергә кирәк инде.
— Әйт турысын гына, юатма: беттем бит мин, беттем!
— Көлемсәр! Алай ярамый, тынычлан, борчылма, җае килеп чыгар, менә күрерсең. Барысы да рәтләнер. Җан биргәнгә юнен дә бирер. Җитәр, елама.
Елама дип киңәш бирү ансат ул кешегә. Минем дә киңәшем файдасыз: һаман елый Көлемсәр, көн-төн елый. Ярдәм итәр идем, булдыра алмыйм. Кешеләргә дә әйтә алмыйбыз — сер... Күкрәк түрендә йөрәк тибеше инде сизелеп торган, күпмедер вакыттан соң дөньяга килүе ихтимал булган бала — артык...
Күрше-тирә авылларда йөреп кайткач, бер көнне кич белән кердем дә Көлемсәргә болай дидем:
— Иртәгә кичкә килә инде... ышанычлы кеше.
— Кит аннан, Сөембикә! — Бу сүзне, кинәт әйтелгәнгәме, сөеңүтөслерәк ишеттем мин.
— Әйе, бик булган акушерка... Вәгъдә бирде, сөйләнмәскә дә, эшләргә дә.
— Мин алай булдыра алмыйм, Сөембикә.
— Ничек?
— Күрәләтә... Кеше үтерү.
— Куйчәле! Синнән генә калганмы!
— Калмаса да.
— Җүләрләнмә, Көлемсәр. Бу бит инде — бердәнбер чара. Тагын нишләргә мөмкин?
— Нишләргә дә мөмкин түгел.
— Шулай булгач?
— Мин алай да булдыра алмыйм. Мин аның гомерен үзем чикли алмыйм, лутчы минеке чикләнсен. Аныкы түгел. Ул яшәргә тиеш.
Ул бу сүзләрне шул кадәр өзгәләнеп әйтте ки, аптырадым да калдым мин.
— Белмим инде, җаным. Мин баладан котылу җаен тапкан кебек булдымые. Ярдәм итмәкче булдымые.

— Сиңа бик зур рәхмәт инде, Сөембикә, рәхмәт. Әмма да булмый, ачуланма.
— Тапкансың сүз! Син үзең ачуланма.
— Рәхмәт... Ни язган — шул булыр. Без күрәсен кеше күрмәс.
Бүтән бер сүз дә әйтә алмадым — әйтеп бетергесез катгыйлеге белән телсез калдырды мине Көлемсәр. Көннәр буе, айлар буе аптырап иза чиктем. Дөресен генә әйтсәм, бу сүзләре белән ул минем күңелдә әллә нинди соклану, горурлану кебек хисләр уятты. «Ул яшәргә тиеш, мин яшәмәсәм дә, ул яшәргә тиеш!» Болар — һәр ана тарафыннан әйтелә торган таныш сүзләр бугай. Үзем дә шулай дияр идем. Тик... Көлемсәр кызганыч. Ни булыр икән?..
Аннары ни булганын Сөембикә апасы сөйли алмый — ә бүтән кем дә белми. Шулай да Тәбрик ишетә...

*
* *

Балакай!
Дөнья сине кул чабып, тәбрикләп каршыламады. Тудың, ләкин кешеләр арасында синең үз урының юк. Нишлисең... Әмма син үзеңнең кеше икәнлегеңне күрсәт — үз урыныңны даулап ал. Чын егетләр мәйданга шулай гына килә. Ата-баба сүзләре бу, яратып әйтелә торган. Сүзләр генә түгел, сиңа калган иң олы мирас һәм васыять тә шулдыр, бала, уйлап кара һәм үзең хәл ит...

*
* *

Син тугач, Фәрхетдин атна буе өйгә кайтмады. Ник икәне, нәрсә уйлап йөргәне кайткач ук аяк тибеп кычкыруыннан аңлашылды:
— Себерке, күрәсе булмыйм balаңны, теләсәң кая куй! Икенче кайтуыма күземә күренсә, кара аны...
Ана кеше үз колагына үзе ышанмады.
— Юкны сөйләп тормачы, үзең риза булып алып кайттың лабаса!
— Аны табарга кем мәҗбүр итте сине? Кем үтенеп сорады? Аны дөньяга китермәгәннән кем җәфа чигәр иде дисең?
— Мин аны тудырмаска вәгъдә биреп кайтмадым монда, Фәрхетдин, хәтерлисеңдер, үзең бүтәнчәрәк сөйли идең, шуңа күрә генә кайттым, сиңа ышанып, балалар хакына, узган көннәр хакына дип кенә. Үзең дә бик яхшы хәтерлисең син боларны.
— Ә мин нинди ант бирдем? Бирмәдем бер нинди ант та!
Менә шулай үзгәрде дә куйды Фәрхетдин үзе дә, өйдәге тормыш та. Ник болай дип сорасаң, мәгънәсен Фәрхетдин үзе дә әйтә алмаган булыр иде, билгеле. Яшермик, гаебен артык зурайтмыйк — ул үзе дә матур һәм тату тормышка сусаган, әмма бүтәнчә булдыра алмый иде. Аның бөтен тырышлыгы, бөтен нияте гел яхшыда, ләкин үзе дә теләмәстән гел яманлык кыла... Шундый бәләкәй кеше булып калуында ул үзе гаепле, түгелме, ниһаять?!
— Мин белмәдем болай авыр буласын, алдагысын чамалый алмаганмын. Аң бул, урап кайтуыма тавышы ишетелсә, үзеңә дә, балаңа да көн күрмә, ишетсен колагың!
Үги әти акырынып туйгач, тагын атна-ун көн олагып йөрде. Күрше авылларга өй эшләп йөрү гадәте шуннан башланды...
Кайтып керсә, баланы харап итәр дип, Көлемсәр сабыйны бәләкәй арбага салып бакчага, менә шушы яшь имән төбенә чыгара иде...

Балакаем! Иөрәк җимешем! Нинди хәлгә куйдым бит мин сине! Рәнҗи дә белмисең, кулыма килеп торасың, елмайгандай итеп карыйсың, ниндидер авазлар чыгарасың. Таныпсың, әнкәң килгән, янәсе! Ана! Нинди ана мин! Әле рәнҗи белмәсәң дә, бераздан, аң керә башлагач, тиешлесен әйтерсең син миңа. Әйтерсең... Ә мин, исән булсам, түзәрмен, әниеңнең битенә төкерсәң дә... түзәрмен. Шулай тиеш тә булыр. Балам! Балакаем! Ярый әле, елак түгелсең. Чүпрәкләреңне алыштырганда да, ялгызың гына калгач та бик еламыйсың. Туганда ук аңлы малай булып тудың бит — күршеләр колагына чалынмаска да бик шәп, Фәрхетдин ишетмәскә дә... Ялгыш килә генә күрмәсен инде. Өй тирәсен әйләнмичә калмас, шул чакта тавышыңны чыгара күрмә. Кара аны, белдеңме? Туера белән бәрәңге сабаклары арасында тыныч кына ят. Йөрәк җимешем минем, я, озак тормам, тагын килермен.

Өйдә чәй өлгергән, самавар шәп ат кебек ярсып пошкырып утыра. Атларның чыңнары да, кыңгырау чыңлатканнары да безне ерак алып китә алмады инде... Алып китә алмады...

Сүзсез генә өстәлгә чәйнек-чынаяклар һәм самавар китереп куям. «Менә шулай — яңадан башланган тормыш тагын сүтелә...»

Көн үтте, кич житте — төнгә баланы йокларга алып керим дигәндә, Фәрхетдин кайтып керде. Бер сүз әйтми, ләкин колагыма әллә нинди коточкыч сүзләре ишетелә, ә шуларның да барысын җиңеп — Тәбрик тавышы... Әйе, исемен мин өмет белән Тәбрик дип кушсам да, дөнья аны тәбрикләп каршы алмады.

Ниһаять, йоклап китте Фәрхетдин. Ә мин — балам янына. Төн буе ике арада йөреп уздырдым. Инде менә тәүлек тә үтте, икенче көн караңгылык белән күмелде. Икенче көн, өченче, дүртенче...

Ник кайттың шул җанвар янына дип Сөембикә кабат-кабат үзәгемне өзә. Нишли ала идем соң — Мирсәет белән бервакыт барыбер аерылышырга туры киләчәк иде. Бүген чынлап яратса да, иртәгә үкенәчәге көн кебек ачык, ике балалы хатынга егет башымны корбан иттем дип аһ орачагы, кешеләрдән кимсенәчәге хәзер үк сизелә башлаган иде бит. Аны чынлап та озак бәйләп тоту әхлакка хилаф эш булмас идемени? Юк, мин андый корбанга мохтаҗ түгел, минем аркада кемнеңдер кимсенүе минем өчен үлемнән дә яманрак. Фәрхетдин дә бик кызганыч иде. Мин кайтмасам, чынлап та харап булачак, теләсә кайда иясез мал шикелле әҗәл эзләп йөриячәк кеше иде. Балаларымның үги ата белән яшәүләренә караганда, бер генә тапкыр чын күңелдән «әти!» дип эндәшүләрен артыграк күрмәсәм, бәлки кайтырга тиз генә ризалашмаган да булыр идем.

Тик мин бер генә нәрсәдә ялгыштым. Мирсәетнең суына башлавын сизсәм дә, болай ук тиз читләшәсе башыма килмәгән иде. Нинди хәлдә калуым белән кызыксынып кына да карамады, яңадан үзенә чакырсын димим, һич югы, сүзе белән, сүзсез генә булса да, бары тик миһербанлы күзләре белән карап кына торса да, ярдәм итәргә димим, хәлемне генә белергә тырышса да, бик житкән иде. Ничек түзә, ничек түзә ала кеше! Ялгыштым шул, ялгыштым...

Җәйге көннең гадәте шул — яңгырсыз булмый, бигрәк тә июль яңгыры куәтле. Көн буе җилләде-җилләде дә, караңгы төшә башлаганда, чиләкләп диярлек коярга керешге. Өй эчендә идек, тәрәзәләр шакылдап ябылды. Яшен яшьнәп, коточкыч чытырдау белән, күк гөмбәзе — шундый зур пыяла челпәрәмә килеп, кырылып төште. Калганын хәтерләмим диярлек, тик томан аша гына күргән һәм ишеткәндәй тоям. Мин чырылдап кычкырып җибәргәч, өйдәгеләр берни аңламыйча каттылар да калдылар. «Ни булды да ни булды?»

Һушыма килсәм — караватта ятам. Уянгач, йөрәк авыртуы тагын да ныграк көчәйде дә үземне-үзем белештермәстән үксергә керештем. Күпме үксегәндермен, бервакыт ишегалдыннан тавыш ишетелде... Тәбрик тавышы!.. Ул да үкси, ул да өзгәләнә. Балакаем! Нишләп монда бик якында соң әле синең тавышың? Әллә миңа гына шулай тоеламы? Әллә мин акылдан язаммы?

Юк, бәхетсезлегемә каршы, акылымда икәнмен. Әнә ишек ачылды да кулына Тәбрикне тоткан Сөембикә күренде:

— Баланың гаебе юк, ул интегергә тиешле түгел,— диде дә кемгәдер ачуланып — әлбәттә, әлбәттә, миңа инде! — ачыргаланып кычкыргач, баланы кулыма тоттырды.

Алдым баламны. Ул тыпырчынып тәнемә орынгач, бөтен гәүдәмә ниндидер илаһи тынычлык йөгерде. Кочакладым баламны. Торып бастым да жансыз кеше шикелле нәкъ өйнең уртасында каттым да калдым. Нишләргә кирәген аңларлык хәлдә түгелмен. Юк, чак кына ялгышам, шушылай баламны тоткан хәлдә, беркемнән курыкмыйча, горур торырга кирәген тоям. Дүрт яклап дүрт кеше миңа карап шаккаткан — күзләрендә курку, каушау, аптырау, аңларга тырышу гаҗизлеге. Дүрт кеше берьюлы телсез, өнсез калды. Ә минем кинәт телем ачылды, горурлыгым кайтты:

— Бу минем балам! — дидем. Әйтерсең каршымдагы гаҗиз күзләр миннән нәкъ менә шул хакта сорыйлар.— Бу — минем балам!

Әйтерсең аны миннән тартып алмакчылар...

## Сөембикә тавышы:

Кич әниең белән шул хәлдә аерылыштык. Без чыгып киткәнче, тораташ сыман, тамчы да кузгалмады. Иртәнчәк, көтү куганда очраштык ие — бөтенләй икенче кешегә әверелгән. Йөзе шикәр төсле ап-ак, күзләре тып-тыныч, әйтерсең аңа җирдә берни дә кирәкми, әйтерсең бөтен нәрсә житеш... Әйтерсең берни дә булмаган, бернинди фаҗига дә юк. Аның шундый да куркыныч тынычлыгын күргәч, йөрәгем жу итеп китте.

— Хәлең ничек, Көлемсәр?
— Әйбәт алай.
— Нәрсә ди Фәрхетдин?
— Нәрсә дисен инде...
— Балага... ачуланамы?
— Сорама да инде син аны...
— Котырамы?
— Котыра шул. Әйтмәгән сүзе калмады.
— Нәрсә ди?
— Телем бармый әйтергә. Ярый инде.
— Көлемсәр!..

Борылып ишегалдына керәм дигән жиреннән капканы ачкан хәлдә тукталып калды әниең. Тик бер сүз дә эндәшмәде, баягы ямансу күзләрен мөлдерәтеп карады гына.

— Бәйләнә торган булса, берәр җаен табарга кирәк, Көлемсәр.

— Хәзер җай кирәкми, Сөембикә апа, бернинди дә җай кирәкми.— һәм, җавап көтмичә, кереп тә китте.

Көненә өч кереп, хәлен көненә өч тапкыр сорашам. Җавап бирә бирүен дә, тик һаман күңеле бик төшенке иде.

— Баламны тартып алырлар төсле тоелган иде. Ә ул беркемгә дә кирәкми икән.

— Алай димә, Көлемсәр, беребездән дә артык түгел ул безнең.

— Илендә артык булмаса да, өендә артык, дигәндәй...

Шушы вакыт дөбер-шатыр Фәрхетдин кайтып керде. Бер уйласаң гаҗәп тә — өендә шушы хәтле усал, холыксыз адәм сугышта бик үк батырлык күрсәтә алмаган диләр. Күзләрендәге зәһәрне күрсәң — гүяки бөтен дөнья агуын эченә җыйган.

— Себеркеләр! — диде ул безгә карарга да җирәнгән кыяфәт белән.— Күнелләме?

Ике сүзеннән бер мәгънә чыгара алмыйча, башыбызга суккандай өнсез калдык. Ә ул тәрәзә башыннан әллә ни эзләп тапты да чыгып барышлый тагын да явызрак итеп үкерде:

— Кәнтәйләр!

Инде минем чыдар әмәл калмады: сикереп тә тордым, барып та төкердем битенә лач итеп.

— Җан көеге, адәм гарьлеге! Ир булып йөрисең тагын, хатыннар хәтле дә ми юк үзеңдә. Миңгерәү, ангыра, булдыксыз! Тфү!..

Тиз генә эскәмия күтәреп алды да бу миңа кизәнде:

— Чыгып сыз хәзер үк өемнән, ну!..

Көлемсәр чарылдап кычкырып җибәрде:

— Ай, Сөембикә апа! Җаным!..

Ә Фәрхетдин эскәмияне түшәмгә терәп торкан хәлдә:

— Карт себерке! Син кавыштырган ул этләрне, син! Син, карт эт! — дип үкерде.

Бәхеткә каршы, өстәлдә тәлинкә бар икән — ал да тондыр шуның белән моның җирәнгеч битенә — коелды төште тәлинкә дуңгыз битеннән челпәрәмә килеп. Түшәмгә терәлгән эскәмиясе дә дөбердәп идәнгә төште. Хатыннардан мондыйны ук күреп өйрәнмәгәнгә, үзе дә каккан казыктай сураеп калды. Хәлнең ничек бетәрен Көлемсәр генә аңларлык булып чыкты.

— Ай, Сөембикә апа, чыгып кач, кач! — дип кычкырды ул ачыргаланып.

Мин курыкмыйм. Куркудан узган чөнки.

— Качармын мин аңа! — Бу сүзләр инде Фәрхетдин миңа бәргәли, суккалый башлагач һәм үзем дә аның белән бугазлаша башлагач әйтелде.— Качармын мин аңа, юньсезгә, черек җанга!.. Ай, үтерә, үтерә! — Үзем шулай акырам, үзем тегенең аягына ябышам.

Тарткалаша торгач, минем күлмәк умырылып чыкты. Шуның ачуыннан аның гимнастерка якасыннан эләктереп тарткан идем, анысы да ертылды. Тагын бераз тарткалашкач, җайсыз килеп, тезләремә чүктем. Ул минем өскә ауды да икебез дә идәнгә егылдык. Шул килеш тә куллары белән бугазыма үк ябышмакчы идеме, белмим — тик баш бармагы авызыма эләкте дә бик җай килде — тиз генә тартып алырга һәм өстемнән сикереп торырга мәҗбүр булды бәдбәхет... Бармагыннан кан ага...

— Хатыннар белән генә сугышмасаң шул, ант бозган әшәке, булдыксыз җан! Үзең ялынып, зар елап алып кайттың бит! — Һәм сикереп торып тагын өстенә ташланмакчы идем, кинәт ирләрчә кискен итеп җикерде бу:

— Җитте! Җитте сиңа!..

Мин, чынлап та, ирләр тавышы ишеткәч туктадым. Ул да, акылга килгәндәй, бая үзе күтәргән эскәмияне аякларына бастырып утырды:

— Мин гаепле, сез түгел... булды.

Чынлап әйттеме, юкмы — белерлек түгел иде. Сүзсез калдык. Бәлки өй тынычланыр да иде. Бала үкси икән. Көлемсәр аны күкрәгенә кысып тирбәтә:

— Я, балакаем, курыкма, берни дә юк. Менә тукталдылар инде — акылга килделәр. Җитәр, йөрәк җимешем, булды, бетте.

— Битеңне юып кер,— дидем мин Фәрхетдингә һәм ул шулай ук

ана боерыгын тыңлаган малай төсле зарсыз гына чыгып та китте: маңгаеннан бөтен бите буйлап кан агып төшкән иде юньсезнең.

Фәрхетдин торып киткән эскәмиянең икенче башынарак утырып, бераз сулу алгач һәм ярсынуым басыла төшкәч, Көлемсәр караватына утырдым.

— Сине дә кыйнадымы?

— Кыйнады шул, Сөембикә апа, бик каты кыйнады.

— Бит-күзеңдә болай күренми.

— Бөтен тәнем... кара янмаган җирем юк.

— Бәдбәхет! — Бераз сүзсез утыргач, тагын әйтми булдыра алмадым. — Шул катыншадан кыйнатып тормасаң!

— Мин алай сугыша белмим шул. Сине кыйный алмады.

— Үзеннән яман сугышырга кирәк андый ир белән. Шунда бернишли алмый ул. Икенче юлы беләрәк төшә.

— Миннән буламы инде.

— Йомшак шул син, Көлемсәр, йомшак.

— Анадан шулай тугач...

— Ә син кыйнатма, ишетсен колагың. Котыра башласа, йөгер дә кер миңа.

— Ярый, Сөембикә апа, шулай эшләрмен.

— Ял ит, борчылма.

Ул шулай ятып калды.

Өй янындагы койма баганасына кагып куелган асылма комганда һаман юынып тора иде Фәрхетдин. Эндәшүемә дә борылып карамады — җәрәхәтен күрсәтергә оялды булса кирәк. Ләкин әйтәсен барыбер әйттем мин аңа:

— Чәнти бармагың белән дә чиртәсе булма Көлемсәргә, колагыңа киртеп куй. Башың ике булса гына кагыл.

— Янама, яме.

— Кереп җаныңны алып чыгармын, ишетсен колагың!

— Бик кадерле булса, ал да чык күршеңне — баласы белән бергә. Сыйдыр.

— Син юкта бик әйбәт тордылар, юклыгың сизелмәде. Бик теләсәң, чык та олак.

— Үз өемнән кумакчы буласыңмы?

— Тәбрик өе ул.

— Тәбрик? Үзе салгач аныкы булыр.

— Анасының өе — аныкы. Өй төпчекнеке була.

— Бирем мин сезгә өй, тоттырырмын.

— Карарбыз, кем ни тоттырыр!..

Чыктым.

Икенче көнне көтү куганы күренмәгәч (Фәрхетдин үзе куды сыерсарыкны), Көлемсәр янына йөгерә-атлый кердем. Һаман ятып тора. Күрәм, тагы да хәлсезләнгән.

— Тагы кыйнадымы?

— Юк та...

— Шуннан?

— Болай талый... эт кебек ырлап тик тора. Көн-төн. Һич тынгы юк.

— Хатын белән шулай яшәп булыр ди микән?

— Бу өйдә каласың килсә, балаңны теләсәң кая куй, ди. Көнгә егерме тапкыр карганып әйтә, мин торган өйдә бу балага урын юк, ди, эзе дә булмас, ди.

— Китмә, беркая китмә.

— Болай да яшәп булмый ич.

— Җай табарга кирәк.

— Белмим шул инде, берни уйламый баш.

Кинэт башка бер уй керде минем:
— Үз этисенә илтсәк баланы?
— Ялгыз ир ничек бала карасын соң?
— Алайса, Көлемсәр, приютка бирик.
— Баланымы?
— Кемне булсын бүтән...
— Белмим шул. Алай да түзә алмамын, саргаеп үләрмен.
Мондый уй аның да башына килгән булса кирәк, ләкин кабул итә алмаган, күрәсең.
— Вакытлыча биреп торыйк, Көлемсәр, бу ерткыч бераз тынычлангач, яңадан барып алырбыз.
— Әллә инде... Ничек дип тә әйтә алмыйм инде. Аталы-аналы баланы алмаслар да.
— Алырлар, сельсоветта Рабига эшли ич...
— Бернәрсә дә әйтә алмыйм, Сөембикә апа. Үзең кинәш ит инде, җаным. Миннән булмый.
— Ярый, син карышма гына, бөтенесен рәтләрбез. Көймә, түз.
— Тырышып карармын, Сөембикә апа. Болай да көн юк шул.
— Мин тагын керермен, Рабига белән сөйләшкәч.
Ә Рабига каршы килмәде — хәлне белеп тора бит. Юнәтеп бирде тиешле язуларын. Шул рәвешле, атасы-анасы үлгән бала булып, дөньяга чыгып киттең. Казаннан ары Займище дигән бер станса бар икән. Шул тирәдәге урман арасына үз кулым белән илтеп тапшырдым. Әнием чиреннән терелә алмыйча, синең янга бара алмыйча да калды. Кире алып кайтыгыз, дип бик ялынгач, Фәрхетдин киткән иде — сине вафат икән дип кайтып әйтте. Бу чакта Тугаш бабаң да синең барлыкны белгән иде инде, Фәрхетдингә ышанмыйча, үзе дә барып килде, тик аңа да шул ук сүзне әйткәннәр.
— Их, улым, улым, мин бит анда сине Закиров дигән фамилия белән сораштым, әнием исә минем исем белән яздырган икән,— Тугашов дип. Закиров дигән бала чынлап та үлгән булгандыр инде. Мирсәет фамилиясендәге бала бөтенләй юк иде. Аллага шөкер, әйе, шунысына да шөкер итик — исәнсең ич!

*
* *

Тәбрикнең уе һәм карашы һаман бәрәңге җирендә иде. Күпмедер онытылып торгач, Сөембикә апасыннан:
— Бәрәңге ул чакта да әйбәт үскән идеме? — дип сорады.
— Бәрәңге ни — үсә инде ул, балам. Хәзерге төсле үк иде.
— Мин шушы җирдә яттыммы инде?
— Нәкъ менә шушы төштә. Дүрт тәгәрмәчле кечкенә арбада. Арбаның өстен келәюнке белән каплаган идек.
— Кайда хәзер ул арба?
— Таралып беткәндер инде, шул заманнан бирле ни, ничек торсын.
— Төнлә дә шушында куна идемме?
— Шушында шул, балакай, яңгыр яуганда да...
— Нишләп курыкмадым икән? — Солдат елмаеп куйды. Аннан күрмәкче — Сөембикә апасы да.
— И балакаем! Шушы хәтле зур булырсың дип күз алдыма да килмидер идең.— һәм ул Тәбрикнең аркасыннан сөеп куйды.— Әнием исән булса, әй, шатланыр иде! Үлмәс тә иде, аннан бәхетле кеше дә булмас иде, чит кешеләр кулында исән калмас дип синең кайгыңнан гына чирләде дә, син вафат икән дигәч, шул хәсрәттән генә үлде дә бит ул.

Бакча аша үзып, аннары таллыклар аралап ике-өч адым киткәч, текә яр — Үләмә елгасы.

Баскыч буйлап төшсәң, аста — елга уртасына таба ике як ярдан да икешәр калын тактадан басма сузылган. Нәкъ уртада, пар такталар очрашкан иң тирән төштә, баганалар калкып тора. Ә югарыдан сине таллар күмә...

Йөрәгеңдә матурлык дигән изге тойгы йөрткән бер генә кеше дә бу төштән җинел генә уза алмыйдыр. Менә шундый елга ул кечкенә Үләмә!

Су өстендә кавышкан таллары — яшел чатыр, әйтерсең су һәм яфраклар телендә генә сөйләргә мөмкин булган бик тә, бик тә кадерле серне ят күзләрдән саклар өчен шулай куе булып үскән алар. Су агымына тез тиңентен кергән япь-яшь үләннәр моны беләләр, башлары каралып өлгермәгән җикәннәр моны беләләр. Тыныч су чылдыравына кушылып, әллә кемнәрнең бала чаклары, беренче гөнаһсыз талпынулары, ихтимал, кемнәрнеңдер мәңге яшь бәхетләре, сагышлары, фаҗигалары хакында пышылдыйлардыр.

Кемнәр утырды икән моңарчы бу басмага аякларын салындырып. Сикерешкән балыклар, тал астыннан, су буйлата шуып кына барган үрдәкләр һәм казларны күзәтеп кемнәр утырды икән?

Үләмә!

Менә нинди гүзәл һәм серле бу Үләмә! Камышлар һәм таллар, зирек һәм өянкеләр әллә нинди хәбәрләр ишетеп, шуларны беркемгә дә сөйләмәскә вәгъдәләр биреп, шул серләре белән чак кына кыланчыкланып көлешәләр дә кайчакларда. Елтыр күзле җәнлек шикелле кача-кача ага тар инеш. Юк, җәнлек шикелле түгел, чая кыз төсле бугай ул. Шаянлыгы, чаялыгы белән алдый. Алдый да әйтеп аңлата алмаслык тын һәм төпсез сагышка китереп чумдыра...

Тәрәзәдән карасаң — ят тормыш...

— Минем әти белән сөйләшәсем килә.

Сөембикә апасы җанланып куйды:

— Әйе шул, бик дөрес. Мин аңа хәбәр җибәргән идем инде. Казанда икән — терлек илтә киткәннәр. Ике-өч көннән кайтасы диләр. Килер ул, килми калмас, эчендә җаны булса.

— Фәрхетдин абый белән дә сөйләшер идем.

— Анысына да хәбәр иттек. Кыртапада гына. Кемгәдер өй эшли.

Шактый уйланып торгач, Тәбрик кинәт:

— Ә өйне карап буламы? — дип сорады.

— Әйдә, барып карыйк. Бикле тора ул. Тыштан гына карамасак.

— Тыштан булса да.

Ындыр сукмагы буйлап, каралты ягына килделәр. Өр-яңа такталардан коелган койма, тап-таза бүрәнәләрдән салынган каралты-кура. Әйләнә-тирәдә җан иясе барлыгы сизелми — тып-тын. Сукмакларны чирәм баскан. Өйдә, бөтен ягы белән китерелеп салынган таза йорт эчендә, шулай ук җан әсәре юк. Нидәндер куркып, ниндидер песи генә чормага чатырдап менеп китте. Хуҗасыз яшәп, кыргыйга әйләнгән бугай. Ә өй эчендә тәрәзә яңакларындагы челтәрләр генә нәрсәдер сөйли башлар кебек — ана турында, гомернең башлануы турында.

— Матур өй. Чын архитектор бизәкләре. Кем эшләгән моны?

— Фәрхетдин үзе. Кулыннан килә анысы — яманларлык түгел. Борын-борын заманда ата-баба салган кебек итеп өйне ул гына сала белә.

— Бердәнбер кеше...— диде Тәбрик, сүзенә нинди дә булса мәгънә салмыйча гына.

Тик Сөембикә апа үзенчә аңлады:

— Бердәнбер... Шундый сәер кеше инде ул — үзе оста, үзе явыз.

— Мин шушы өйдә тудыммы?

— Шушы өйдә.

— Ә ул яңа бит. Бер дә искерми торган итеп тә сала беләме әллә?

— Сипләп салды ул аны, шушы төштә, нәкъ элекке төсле итеп.

Тәбрик тәрәзәдән карады:

— Әни караваты кайсы?

— Сул як почмакта... энә... шул инде. Шул ук караваг. Рәтләп җыелмаган гына тик.

— Анда кем йоклый хәзер?

— Фәрхетдин.

— Ничек йоклый ала икән ул бу караватта?

— Әйтә алмыйм ансын. Бер дә әйтә алмыйм.

— Аңлашылмый шул, Сөембикә апа.

— Без синең әниең белән (күршеләр генә түгел) туганнар кебек тә якын идек. Шуның хикмәтедер инде, әтисе Тугаш бабай ялгыз калгач, аны үзебезгә алдык. Кызының өенә бабасын Фәрхетдин якын да китермәде.

Тәбрик өй эченнән күзен озак, бик озак аера алмый торды. Апасы ашыктырмады — барысын да сизә бит. «Нишләп елап җибәрми әле?» дип, Тәбрикне җәлләп өзгәләнде. Ә Тәбрик күзләрендә авыр, ләкин тыныч моң.

Тәбрик, тәрәзә яныннан киткәч, үлән баскан ишегалды буйлап йөренде дә тагын сорады:

— Ник явыз икән ул кеше?

— Белмим шул.

— Аңлашылмый. Миңа аны күреп сөйләшергә кирәк. Еракмы моннан Кыртапа?

— Җиде-сигез чакрым.

— Якын икән.

Шулай диде дә ул капка ягына атлады.

Урамга чыккач, Сөембикә апасы аның кителеннән нәрсәдер йолкып алды:

— Тигәнәк ябышкан,— диде ул. Кешесез бакчаның шул инде ул.— һәм чүпне читкә ташлады.

— Мин сезнең өскә күтәрелгән эскәмияне күрмәдем,— диде Тәбрик, елмаерга тырышып,— урындыклар гына тора.

— Таралгандыр инде. Әллә кайчан таралгандыр безгә күтәрелгән урындыклар.

Шуннан соң икесе дә елмаешып, кайтыр якка киттеләр. Әйтерсең хатирәләр аз вакытка гына кунак булып килгән дә инде бу тормышка, бүгенге көнгә күләгә булып төшәргә теләмичә, каядыр еракка киткән. Әйтерсең җирдә бары тик бәхет һәм шатлыклы уйларга гына урын калган.

— Тәбрик абый, картлар кебек гел үткәннәр белән яшәмәгез әле. Караталда бүген кино була, барыйк әле шунда бергәләп. Менә дигән чибәр кызлар анда, менә дигән уңган егетләр — танышырсың, дуслар табарсың... Канатланып биерсең, җырларсың. Барыйк әле бүген Караталга.

— Әйдә соң... Китик, Гөләндәм.

Кино, танцы, җырлар, биюләр, шаян сүзләр һәм мут күзләр — яман хисне куып, күңелләрне күккә күтәрә.

Көн килдеме, кем дә булса аны чәйгә, ашка чакыра. Кыстатырга, бармый калырга ярамый икән — йола, армиядән кайткан кешене чиратлашып бөтен авыл кунак итәргә тиеш! Әле авылда күпме өй! Көн саен өч керсәң дә — бер ай кирәк!

Шагыйрь әйткәндәй, дөнья матур, дөнья киң. Ә шулай да, ә шулай да... Һәр яңа көн туды исә, чалт аяз күктә сарык тиресе хәтле генә бер болыт кояш турысына тап килә дә бөтен Тау ягын күләгәли.

Килә ява, килә ява,
Иңләште бер болыт.

...Тәбрикнең кайту һәм чакыру хәбәрен алгач та, Фәрхетдин дә, Мирсәет тә ашыгыч рәвештә килеп житәрләр дигән өмет акланмады. Бер көн көттеләр, ике көн, өч көн көттеләр — юк, күренмәделәр. Ә Тәбрикнең күрәсе килә — туган әтисен табу ышанычыннан бигрәк, ничектер, аларны күргәч, әнисен дә табар төсле тоела. Күптән вафат әнисенең күпмедер өлеше генә булса да шул кешеләр янында яшәп ятадыр кебек һәм аны сорап алырга мөмкиндер шикелле. Алай гына да түгел, сораганны да көтмәстән үзләре бүләк итәрләр төсле... Ләкин менә күренмиләр, Тәбриккә әнисен кайтарып бирәселәре килми, күрәсең. Тик ул аны барыбер алачак. Нигә дисәң, беренче чиратта, ана — баланыкы...

Бишенче көнне Мирсәетнең Казаннан кайтканлыгы һәм Фәрхетдиннең һаман да Кыртапада икәнлеге билгеле булгач, Тәбрик, уйлап та тормастан, Кыртапага үзе барып кайтырга карар кылды. «Ә әти, билгеле, үзе киләчәк!»

Юл башын гына булса да күрсәтим дип, Тугаш карт аны озата барды. Төп максатының күрше авылларга чабыр буласын хәбәр итү икәнен ул ни өчендер белгертеп тормады.

— Әйдә, балам, турырак юлдан чыгарыйм әле үзеңне. Урау булса да юл яхшы, дигәннәр диюен дә. Юл да туры булса, ишшү дә шәбрәк, ишшү дә мәслихәтрәк. Әйдә, улым, дөнья күрсәтеп кайтарыйм әле.

Ямь-яшел киң урам буйлап бераз киткәч, икенче урам манарасыз мәчет яныннан уза икән. Мәчет буендагы кое тирәсендә хатын-кыз җыелышкан да нәрсәдәндер зарланышып тора иде.

— Нишләп аптырашта калдыгыз болай?

— Менә, суыбызның тәме китте. Әллә нишләде. Төбен чистартып булмасмы дип җыелдык не.

— Соң, кем рөхсәт бирми?

— Суын чыгарып бетердек инде дә, хәзер төбенә төшәргә йөрәк җитми.

— Хатын-кыз эшеме инде бу? Ирләрегез төшсен.

— Әйтмәдек шул әле.

Озак уйлап тормастан, Тәбрик кое чыгырындагы чылбырны карарга кереште:

— Чылбыры нык күренә болай... Агачы тотар микән? — Аның ниятен хатыннарга бабай төшендергән арада, кителен салып ыргытты да, чиләкле чылбырны каты гына эләктереп, кое бурасына менеп тә утырды. — Акыртын гына әйләндерсеннәр.

Бабай аның сүзләрен хатыннарга:

— Крути тихунька,— дип тәрҗемә итте.

Кулы белән ишарә ясагангамы, болаймы, русча диярлек әйтелсә дә, аңладылар тагы.

Әкренләп, чыгырны көйле генә әйләндерә башладылар. Ә биш-ун минуттан кое төбеннән Тәбрик тавышы ишетелде:

— Алыгыз чиләкне.

Ләм тулы чиләкне тартып чыгарсалар — анда коточкыч нәмәрсә...

— Ай, ни бу! Ай! — диештеләр хатыннар чыр-чу килеп.— Нинди су эчкәнбез! Ай!

— Түгегез чиләкне!

Чиләктә — ниндидер үләксә, әллә мәче, әллә куян...

Кое төбеннән тагы боерык:

— Анысын соңыннан тикшерерсез, тагын төшерегез бауны.
— Ай-һай! Кем ташлады икән? Үзе төшмәгәндер инде кҮрәләтә.
— Вәт юньсезләр, бауны төшерегез!

Бабай юкка җикеренде, билгеле, тиз арада бөтенесе рәтләнде. Алтыҗиде чиләк ләм чыгарылгач, егет инде якты җир өстендә иде. Хатыннар коега су җыелгач, тагын бер йөз чиләк су чыгарырга вәгъдә биреп, егеткә мең рәхмәтләр укып калдылар. Өч-дүрт адым атлагач, бабай аларга үз йомышын әйтте:

— Киләсе җомга көнне Бәки чабыры — җыйнаулашып чыгыгыз, яме, оныта күрмәгез.

Карт Ямәки авылына хәтле озата килде дә, бу авыл кешеләрен дә чабырга чакыргач, кире Үзәнбайга борылды.

— Кыртапа кешеләренә чабыр буласын әйтергә онытма, улым, — диде Тәбриккә.

— Онытмам, бабай.

Солдат кул болгады да нык адымнар белән ары китте.

*
* *

Кыртапа тау астына урнашкан икән. Төньяктан искән иң әче җилләр тими үтәдер бу өйләргә...

Урамда очраган һәр кеше иң якын танышына эндәшкән кебек исәнләшеп үтә. Тик аларны Тәбрик аңлап кына бетерми. Бер карчык туктальп ук әллә ниләр сөйләп торды-торды да, соңыннан Тәбрик: «Бик матур сүзләр әйттегез бугай, кызганыч, аңлый алмадым»,— дигән иде, әби кул селтәде дә тагын нидер сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Аңлап бетермәвеннән беразкәефсезләнеп баргач, яшьрәк бер ирне туктатып, Фәрхетдин абзый эшли торган өйнең (йорт хуҗасының исемен аңа Сөембикә апасы әйткән иде) кайда икәнлеген сорады да аннары уңгарак борылды. Тау тагын да әчкәрәк уелып кергән төштә яңа өй — шунда таба китте.

Капка шар ачык, ләкин ишегалдында җан әсәре күренми. Өр-яңа стеналар чыршы бүрәнәләрдән салынган. «Тау ягында чыршы урманнары күренми, каян алалар икән?»

Кинәт бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте Тәбрикнең — өй эчендә кемдер шакылдый. Фәрхетдинме? Паспортта атасының исеме урынында торган кеше кем, нинди икән? Әти диярлекме, әллә... Ничек сүз башлап, ничек сөйләшерләр? Кеше белән танышу, сөйләшүнең мондый ук кыен, җайсыз чагын беренче тапкыр тоя Тәбрик. Ни өчен килүе кинәт баштан ук чыкты. Ник соң әле? Ата булыр кешесен эзләпме, әллә әнисенең кем икәнен сорашыр өчен генәме? Юк, аның өчен генә түгел бугай. Ә ни өчен? Бәлки кире китәргәдер? Юк шул, нихәтле ерак җирләр кайтып, нихәтле җирләр килеп, күрми китү әллә ничек сәер тоелыр...

Ярый әле, шул вакыт, кеше килүен сизепме, үз йомышы беләнме, өйдән нечкә генә, озын гына бер егет чыкты. Ә менә аның өчен чит кешегә башлап эндәшү ишек ачып чыгу кебек үк гади нәрсә икән. Күзгә чалынуга, аптырап тормады, елмаеп ук җибәрде:

— О, солдат! Отпускагамы, кайчан кайттың? — Әйтерсең алар күптән таныш, фамилиясе, исеме генә түгел, бөтен тормыш юлы билгеле, алай гына да түгел — якын иптәш.

Тәбрик тә, авыз ачып калмыйча, егетнең фартлы гадилеген бик тиз эләктереп алды:

— Отпускага түгел, парень, бөтенләйгә дип тә әйтә алмыйм.

— Машина җитми шул шоферларга. Менә миңа да юк. Машина кәтә торгач, балтачы булып китәм инде.

— Ул да һөнәр.

— Әйтәсе дә юк. Әйдә кер, сине дә өйрәтәм.
Ялындырмады Тәбрик — керде. Керде дә, өйдә бүтән кеше юклыгын күргәч, кемне эзләп килүен әйтте.
— Ә! Фәрхетдин абзый! Хәзер килә, кибеткә аракыга гына китте. Эт тышка чыкканчы кайтып житә, борын төбендә генә безнең кибет. Ул килгәнче шушыны гына кисеп атыйк әле,— дип, әлеге егет җиде-сигез кат итеп тезелгән такта өстенә пычкыны куйды.— Әйдә тарт.
Күпмедер кискәч, Тәбрик гаебе беләндер инде, такталар пычкыны кыса да башлады. Аларны алгарак шуыштырып, яңадан кисәргә керештеләр. Хәл җыярга тукталган арада, яңа танышы Тәбриккә комплиментлар яудырырга тотынды:
— Кыяфәтең стиляга төсле булса да, кулыңнан эш килә икән.
— Ничек стиляга?
— Ну, шәһәрчә дип әйтимме соң, алайса. Минем кебек түгел син, һич охшамаган.
— Алла сакласын,— дип шаярткан булды Тәбрик.
Ләкин әлеге егет, үзенә бирелгән беренче бәяне дөрес аңлап, иреннәрен кыса төште:
— Начар шул мин, сөйләшә белмәгәнрәкләрнең иңи шүрлегенә дә менеп төшә беләм.
— Молодец!..
Ә егет уйлап та тормастан:
— Ә менә синнән булмый андый нәрсәләр. Әллә каян күренеп тора, бернинди егетлек юк синдә. Тәрбияле бала син,— дип мыскылларга кереште.
Тәбрик исә, бәхәсләшүнең артык икәнен сизеп, шаяртуында булды:
— Ә син үзең? Берәрсен кыйнаганың бармы?
Егет моңа горур кыяфәт белән:
— Берне түгел, өчне! — дип куйды.
— Өчне! Берүзең!
— Егет кеше шундый булырга тиеш.
— Батырлыгың өчен мактыйм. Нинди кешеләр иде соң алар?
— Ничек нинди кешеләр?
— Син кыйнаган кешеләрне әйтәм.
— Кем дип. Шул инде, өч карчык. Тәмләп чәй эчеп утыралар иде, мин сиңа әйтим, самавар янында сайрашып. Ләчтит сатып ягъни.
— Сезнең өйдәме?
— Түгел шул. Мин үз өебез дип, күршеләргә кайтып кергәнмен. Салган баш бит, үзең беләсең. Мин аларны бездә утыралар дип торам. Куа башлагач, берсе мич артына сыпырды, икенчесе — өстәл астына, өченчесе карават астына мүкәйләде. Башта өстәл астындагысын өстерәп чыгардым. Аннан кире карават астындагысын. Мич артындагысы үзе чыгып сызды. Шуннан соң иркенләп караватта аяк сузып йоклап киткәнмен.
Тәбрикнең күңел чынлап күтәрелде:
— Тәмле булгандыр йокы!
— Тәмен кем белсен, уянгач күңелсез булды.
— Кеше караватында йокы туйдыру кызык тоелмадымыни?
Егет авыр итеп көрсенде дә хикәясен очларга тырышты:
— Туймады шул йокы, туймады. Күрше Гарәфи, дус кеше бит инде, ботымнан сөйрәп төшергән дә урамга чыгарып ыргыткан.
Шулай сөйләшкән арада, капка як тәрәзәдән ниндидер сакал-мыек баскан бер кеше карады. Тәбрик тәрәзә ягына карап утырганлыктан, аны бик тиз күреп алды һәм секунд эчендә башына бернинди рөхсәтсез сәер уй килде: «Дезертир!» Икенче секундта күз карашлары ук очрашты да, ят кеше, ни өчендер, тиз генә юкка чыкты. «Фәрхетдин абый!» — Өченче секундта күңелдән ялт итеп шул уй үтеп, Тәбрик эштән туктады.

Куллары бер хәрәкәтсез калды — хәтта уй да тукталгандай тоелды. Мenә кызык! Каян килә шушы хәтле каушау? Әллә курку укмы? Кемнән? Ник? Менә ул ишекне ачар, керер...

Егет Тәбрикне хәл җыярга туктаган дип белде, ахрысы. Танылып өлгергән беркатлылыгы белән тагы боерды:

— Тарт әйдә, аз калды инде.

— Фәрхетдин абый кайтты,— диде Тәбрик тәмам күңелсезләнгән кыяфәт белән. Гүяки бу очрашу аның өчен көтелмәгән хәл, гүяки ул аны үзе эзләп килмәгән...

— Кайда соң ул?

— Ишеккә таба китте.

Көттеләр, көттеләр — ишек ачылмады, аяк тавышлары да ишетелмәде. Аптырагач, ишегалдыннан егет үзе карап керде:

— Юк бер кеше дә.

— Кергән иде инде.

— Шулай тоелган гынадыр.

— Менә инде, үз күзләрем белән күрдем.

Шулай тәгаен әйтсә дә, Тәбрикнең күңелендә тагы аңлаешсыз фаразлар бутала башлады: «Әллә чынлап та күзгә генә күрендеме? Ким дигәндә бер-ике атна кырылмаган сакал-мыек, нидәндер курыккан ялтыр күзләр... Нидән курка бу күзләр? Ә бит моңарчы бу кешене усал адәм дип сөйләделәр! Нинди усаллык һәм нинди куркаклык? Әллә мин үзем генә уйлап чыгардыммы? Әллә ул усаллык белән куркаклык дөньяда юкмы? Ах, булмаса! Әгәр булмаса, ихтимал, әйе, бик ихтимал, минем әни дә исән яшәр, мин дә болай һич кирәксез кеше артыннан йөрмәгән булыр идем».

— Бүтән кеше булгандыр ул, керер иде.

— Әйтүе кыен.

Көттеләр, көттеләр — тагын юк. Ахырда егет, тиргәнеп:

— Аракыны качып эчмәсен тагы, паразит,— дип, пычкыны ыргытты.

— Шундыйрак кешеме?

— Белеп бетермәссең кешене. Менә, паразит, качты, яртыны алып шылды. Үзәнбайга ук киткәндер әле. Куа киттекме?

— Бар, син үзең генә караштырып кил. Үзәнбай ерак бит, анда ук качмагандыр әле.

— Карт бүре... тотсам җиде тиресен салдырам мин аның,— дип сүгенә-сүгенә чыгып та китте егет.

Идәндә — такталардан ясалган сурәтләр, бу якларда бары тик Фәрхетдин генә ясый белгән тәрәзә яңаклары. Ничек усаллыкта даны чыккан кеше шундый матур бизәкләр ясый белә икән? Пушкинның даһилык һәм явызлык — килешми торган нәрсәләр диюе ялгышмы икән әллә? Өйдән өйгә, авылдан авылга йөрсәң күрәсең — көлеп, елмаеп тора тәрәзәләр... Күбесен шул кеше ясаган. Ә үзе... Ә үзе ник әле беренче караштa ук куркак тоелды? Аңламассың, һични аңлый алмассың.

Шулай, өйне генә кара: аның эчендә көндез дә кояш иде, хәзер дә, көн кечкә таба авышкач та кояш... Кечке кояш булса да, аның да шушылай елмаеп торуы хәерлерәк бит. Буш өй эче яктылык белән тулгач, ямьсез дә тоелмый — җылылык, яктылык җәен дә кадерле... Менә монда беркем дә юк — йомычкалар аунап ята, сагыз исе аңкып торган бүлмә такталары кемнәргәдер рәхәт һәм тыныч бәхет вәгъдә итә. Ләкин хәзергә монда бушлык, җансызлык... Шул җансызлыкта көннәр буе эшли торган кеше — Фәрхетдин абзый. Кая качты соң әле ул?

Уйларны сискәндереп, баягы егет дөбердәп керде: кош тоткан диярсең. Кулында — ачылмаган ярты.

— Эчмәгән, карт алай ук юньсез булып чыкмады.

— Молодец.

Тәбрик бу сүзенең кемгә төбәп әйтелгәнен үзе дә әйтә алмас иде. Шул сүзнең кирәксез икәнен абайлап, сорап куйды:

— Кайда соң ул?

— Теге тыкрыкта, бүрәнә өстендә утыра.

— Монда килмимени?

— Киләсе килми. Эчә торыгыз ди. Үз өлешен калдырырга кушты. Әйдә, өч борынга әйбәт кенә була ул.

— Юк, мин аның янына барам әле,— дип, Тәбрик ишек бавын тотты.

— Что-то аның сине күрәсе килми бугай, шулайрак тоелды.

— Ә мин, болай булгач, аны барыбер күрми китмим.— Тәбрик каршы як тыкрыкка таба ашыкты.

Борылгач та бүрәнә өстендә баягы «дезертир» күзгә чалынды. Әйе, бар ул кеше, уйлап чыгарылган гына түгел, һәм куркаклыгы да хак: Тәбрик күренүгә (ашыгып түгел түгелен), кузгалды да тагын читкә атлады бу адәм.

— Абый!..

Тәбрикнең кискен тавышыннан шып туктады бу кеше. Сүзсез генә көтә калды. Барып җиткәч,— ни гаҗәп? — Тәбрик үзе дә каушап куйды: аңа ниндидер усал, явыз кәяфәтле, карчыга борынлы ямьсез бер адәм карап тора иде. Башында — уңып төсен җуйган кепка, өстендә соңгы елларда сирәк күренә торган сырма бушлат, ә аякларында — балтыры кайтарылган киез итекләр... Июль аенда, җәйге чиләдә киез итек кигән, җәйге кара туфракта! Тәбрикнең шуннан сәерсенгәнен сизде бугай:

— Шулай җайлырак,— дип куйды агай, беренче сүзе шул булды.

«Ничек шушы кешене минем әни ярата алды икән?»

Абзый яшь солдатның үз аякларыннан һаман күз ала алмавын күреп, җикереп диярлек:

— Исе китте! һы... Раматиз минем аякта. Болай да боз кебек. Эссе чиләдә дә җылынмый менә,— диде.

«Аякта гынамы икән боз?» — Шулай уйласа да, Тәбрик бүтәнчә әйтте.

— Җәй көне... бик үк табигый түгел шул.

— Җәй көне. Нәрсәсе бар аның? Киез итек күргәнең юкмы?..

— Бар барын...

Гаҗәп, нинди юк-бар сүз сөйләшә башладылар! Гүяки сигез чакрым араны Тәбрик шуның өчен килгән. Гүяки аларның иң мөһим сүзләре күптән сөйләшенгән. Бигрәк тә шунысы мәзәк: алар бер-берсен бер күрүдә танадылар һәм кемнең кем булуы хакында сорашуның кирәге дә чыкмады. Ничек танышырмын, ничек сүз башлармын дип, килешли юл буе борчылган иде Тәбрик.

Шулай ук сүзсез килешеп, яңа салынган өйгә таба борылдылар. Әкрен-әкрен генә атлаганда да Фәрхетдин гаҗәп дәрәҗәдә сак баса иде аякларын. Солдат һаман сәерсенеп карагангамы, тагын акланган-дай әйтте:

— Раматиз... плиндә йөргән чаклар истәлеге.

— Бик үк күңелле истәлек түгел шул.

— Сезнең кебек җир селкетеп йөри идем мин дә.

— Сугыштан кайткач та шулай йөргәнсез түгелме соң? — диде Тәбрик, сүзләренә тиешле мәгънә салып.

Моңа каршы абзый, «пүчтәк әйбер» дигәндәй, кул селтәде:

— Юк шул, булмады, энем, булмады.

Шул сүзләр белән мөнәсәбәтләр дә ачыкланды — «абзый», «энем»...

Өйдә теге егет шешәдән үз өлешен эчеп куйган, күңеле тиешле баскычка күтәрелгән иде инде. Боларны күтәреп алгандай каршылады һәм, һай-һайлап, ике стаканга бүлеп аракы салды:

— Мәгез әле... Чәкешегез әле.

Әмма «чәкешеп китүдән» курыккандай, икесенең берсе дә чәкешергә җөрьәт итмәде, ипи каптылар.
— Иң яхшы закуска — ипи,— диде егет.
— Әфлисун булмаганда,— дип елмаерга тырышты Тәбрик.
— Ипине рәнҗетмәгез,— диде агалары.
Шуннан соң утырдашлары нәрсә уйлагандыр, Тәбрикнең фикер һаман Фәрхетдин тирәсендә бөтерелә иде: «Үзе усал, үзе ямьсез, үзе бик үк мәгънәсезгә дә охшамаган».
Балтачы егетнең ни уйлавы ул тәкъдим кerткәч аңлашылды:
— Солдат кешене борчу кыен да инде. Ну шулай да...
— Борчы, рәхим ит.
— Безнең кесәдә пока ашлык сугалар, иптәш. Син бер өчлекне кызганма инде, мин барып килим.
Юлга дигән күпмедер акчасы бар иде Тәбрикнең — бер дә кызганмыйча чыгарды өчлекне. «Хәзерге минутта егетнең китүе хәерлерәк».
Тынлык, бушлык. Идәндәге йомычкалар, бүрәнә кисәкләре, пычкы чүбе дә өйне тутырып түгел, бушлыкны, җансызлыкны арттырып ята. Хәтта Фәрхетдин абзый үзе дә... киез итек эчендәге ревматизмлы аяклары да әллә нинди өшеткеч салкын тарата кебек. Гомер буе өй салып, бөтен гомерен диярлек шушылай буш өйдә үткәргәндер ул. Буш өй, буш җан, буш гомер... Мөгаен, хәзер ул бушлыктан котылырга тырышмый да, киресенчә, күнегелгән шушы хәленнән аермагайлары дип курка торгандыр әле... Ник шулай тоела икән? Ник икәнен хәзергә әйтү кыен, тик бүтәнчә уйларга мөмкин дә түгел.
— Кайда минем әни? — Уйламаган, көтмәгән җирдән, Тәбрик теленнән шундый кискен сорау бәрелә-сугыла чыкты.— Кая куйдың син аны?
Җавап көтү артык дәрәҗәдә беркатлылылык икәнен аермачык белгән хәлдә, Тәбрик көтте. Тегесе, билгеле, мәсхәрәле бер төстә елмайды гына.
— Бөтенләйгә кайттыңмы?.. Армиядәнме? — дип сорады.
— Бөтенләйгә. Армиядән.
Фәрхетдин иелеп калын гына йомычка алды да шуны вак-вак кисәкләргә аерырга кереште.
— Сиңа торыр урын кирәк инде хәзер, ә?
— Башта эшкә урнашырга кирәк.
— Эше табылыр анысы. Кияр муены булса, камыт әзер. Ә менә торыр җир дисәң, анысын теләсә кайда әзерләп куймаганнар.
— Ул хакта уйлаганым юк...
Саф дөреслекне абзый кабул күрмәде:
— Бардыр анысы, уйламыйча гына булмас.
— Чынлап әйтәм.
— Алайса, ник килдең монда?
— Мин инде әйттем.
Агай соңгы сүзләренең мәгънәсенә бик төшенмәгәнгә, Тәбрик җавап ишетмәде. Фәрхетдин, йомычканы ваклап бетергәч, нәрсәнедер хәл иткән сыман, кискен итеп әйтте:
— Әмма ләкин минем идәнгә синең аяклар басмаячак. Мин моны әниеңә карганып әйттем.
— Ничек? Кайда?
— Минем өйдә. Минем идәндә.
— Аңламыйм.
Абзый тагын астыртын гына елмаеп, фикерен чынлап та ачыкларга чамалады булса кирәк.
— Тугашларга кайткансың ич?
— Кайтсам соң?
— Аларның өйләре кысан. Ә кыз бар, менә дигән. Ярәшеп җибәрерләр дә... Өйсез кая китәрсез?

Ачуланырга кирәк иде дә, Сөембикә апаның кызы Гөләндәм искә төшеп, Тәбрик тыелып калды.

— Фәрхетдин абзый (беренче тапкыр исеме белән эндәште ул аңа), минем ул хакта сөйләшергә ниятем юк.

— Керереңнән алда чыгарыңны уйла дигәндәй, үз әтиеңнең, Мирсәетне әйтәм... аның да ишле гаилә — син сыярлык түгел...

Бу сүзләрнең никадәр каты һәм мәгънәсез икәнен аңлап әйтә микән бу кеше, әллә юк микән? Әллә ул янында торган, әле киләчәге берничек тә ачыкланмаган кешенең беркемгә дә кирәк түгеллеген йөзгә бәреп әйтә алырлык ук явыз кешеме? Тәбрик чынлап та дөньяда беркая да сыймый торган артык кешеме?

Аның үзен шушындый да кызганыч кеше итеп беркайчан да тойганы юк иде әле. Ләкин менә артык ул, һаман артык икән! Бу кадәр дә кимсенү, бу чаклы да кимсетелү була ала икән дөньяда?! Әйе, Тәбрик моны башына да китерә алмый яшәгән! Шушы авылга, туган анасының тормыш юлдашы янына килмәгән булса, ишетмәгән, сизмәгән, һич югы, бу чаклы ук ачы итеп аңламаган булыр иде. Аңламаганнан гына хәл яхшырмыйдыр, шулай да бүгенгедән чак кына булса да бәхетлерәк булыр иде. Ә бүген ул ялгыз, кызганыч, бәхетсез булып, олы, ләкин мәгънәсез һәм салкын дөньяда берүзе басып тора...

Дөньяның якасыннан эләктереп, селкеп ташлыйсы иде дә, дөнья хәйләкәр: үзе күзгә күренмичә генә каршыга Фәрхетдин абзыйларын гына китереп бастыра. Ә Фәрхетдин болай да мескен, ничек якалашасың аның белән?

— Ярый, сез мине әни өенә кертмәдегез, ди. Ә бит әле минем үз әтием исән. Гаилә ишле дип, ул үз баласын куармыни?

— Әйтәм бит — анда синсез дә житеп арткан. Сигез бала, хатыны, үзе...

Тәбрик Фәрхетдиннән бигрәк үзен үчекләргә кереште:

— Алайса, җирле власть ярдәме белән үз өемә кайтып керергә туры килә инде.

Тегесе моны ишетүгә очкылык тоткандагыдай бер ымлык кына чыгарды да тотлыгып калды. Үзе башлаган сүзнең болайга ук борыласын әйтерсең көтмәгән. Шулай да куркуы аңа фикерләрен тиз җыярга ярдәм итте:

— Ничек үз өең? Анысы кайда?

— Ну, әни өе.

Тәбрик үз усаллыгыннан үзе көлеп җибәрергә әзер. Шулай да тагын агайга сынаулы җитди караш ташлады. «Ә чынлап та әни йорты бит! Ник анда мин артык булырга тиеш?»

Фәрхетдин абыйсы үртәлеп урыныннан торды да, ни өчен икәнен үзе дә белмәстән, әле генә үзе утырган бүкәнне тибеп аударды һәм ул тәгәрәгән арада сүзен әйтә куйды:

— Синең әниеңнең өе инде юк! Юк!..

— Нишләп? Кая киткән?

— Юк менә, юк булгач. Ул минеке! Минем өй!

Шундый да мәгънәсезлеккә, шундый да вакчыллыкка бара ала икән ир кеше! Кылт итеп Тугаш бабай хәтергә килде дә ирләр, халыклар, Алып шикелле олы кешеләр язмышы хакындагы сүзләр ерак һәм күңел ирешмәс матур хыял төсле булып кына калды.

«Синең белән дә шаяртыбрак сөйләштем бүген, бабакай, гафу ит, начарны күрмичә, яхшының кадере юк икән. Гафу ит, бабакай, синең кебек ил турында түгел, өй хакында кычкырышабыз. Ул хәзер әнием истәлеген рәнҗеткәнгә күрә, әнием өчен — гаделлек хакына гына бәхәсләшәм мин».

— Алайга китсә, син минем әни өендә яшисең, ә моңа синең хакың юк.

— Бар хакым! Фронтка киткәндә кем аңа йорт калдырып китте? Синме? Минме? Мин. Ә кайткач?...

— Кайткач, ул сине өйгә үк кертмәскә тиеш булган.

— Мирсәет дигән себеркегә китәргә тиеш булган ул, шулаймы?!

Бу минутта ни булганны Тәбрик төшенмәде. Берничә минуттан соң Фәрхетдиннең акыруыннан, ухылдавыннан гына исенә килеп, аңлап алды: мескеннең якасыннан эләктереп, күтәреп бастырган икән:

— Кем ул себерке? Ә? Кем? Минем әнине пычратмакчы буласыңмы шакшы телең белән? Кабатла жаның ике булса. Кабатла!

Агай сүзсез генә тайпылып күлмәк изүләрен рәтләгән арада, Тәбрик инде өй эче караңгыланган икәнен абайлады. Күпме гомер утырылган! Ә рәтле бер сүз сөйләшенмәде. Гаеп, мөгаен, аңарда да, Тәбриктә дә бардыр. Ике кеше кычкырышса, аның икесе дә гаепле... Дөрес, Тәбрик тә гаепле... рәтләп сөйләшә белмәде, жай тапмады.

— Утыр әле, Фәрхетдин абый, — диде ул, бая утырган бүкәнне күрсәтеп, — олы кеше бул әле, я.

— Ярый... синең кебек эзмәвергә карт кеше белән сугышу, әйтик, шулай ук егетлек түгелдер ул.

— Шуны белеп тор: әнисе хакында кемгә генә әшәке сүз әйтсәң дә — баладан юньле жавап көтмә. Мондый ук әшәкелекне бүтән кешегә эшләмәскә киңәш итәм мин сиңа. Ярый әле, исән калдың, шунсына рәхмәт әйт.

— Рәхмәт...

Агай моны үчекләшеп әйттеме, юкмы, шулай да Тәбрик инде ярыйсы ук суына төшкән һәм олы яшьтәге кешенең якасыннан алганы өчен үзе дә уңайсызлана башлаган иде. Шуңа күрә, тегесе баягы бүкәненә утыргач, Тәбрик аның каршысына басты да елмаерга тырышып диярлек сорады:

— Я, шуннан, тагы нәрсә?

— Нәрсә булсын? Дөресен әйтәм мин — минем өй — үземнеке.

— Сез һаман шул хакта.

— Сугышка чаклы да мин аны хәләл тиремне түгеп салдым. Сугыштан кайткач та байтак материал һәм көч китте. Ә синең үз атаң бар, ул кайгыртырга тиеш.

— Ярый, булды, бетте. Мин сезне юри котыртып кына бәхәсләшмәкче идем. Сезнең өй миңа кирәк түгел, теләсәң нишлә, теләсәң нишләт.

— Сиңа ни кирәк соң?

— Әнине табып бир — шул гына!

Фәрхетдин, тагы житдигә китүе ихтимал булган сүз сөрешеннән котылыр өчен ике кулы белән дә күзләрен каплап озак кына утыргач, үзалдына сөйләнергә кереште:

— Син хәйләкәр, әлбәттә, хәйләкәр. Әниеңнең минем кесәдә генә түгеллеген беләсең.

— Шуны да беләсем бик килде: я, әйтеп бир — теге чакта ник кабул итмәдең мине? Баланың ни гаебе бар иде?

— Аңлатып була торган эш түгел монысы.

— Мин аңларга тырышырмын.

— Синең дә яшь бар хәзер. Күп тә узмас, өйләнерсең. Балаларың булыр. Әйтик, сине кая да булса жибәрделәр ди берничә елга. Кайтуыңа, хатының каяндыр бала табып куйсын.

Тәбрик урыныннан сикереп торды, ләкин берни әйтә алмады.

— Ир юкта бала табу... ничек соң, синеңчә? — дип сорады Фәрхетдин хаклыгына нык ышанган һәм кискен бер тавыш белән.

Жавап урынына ниндидер тупас сүз ташлыйсы килсә дә, Тәбрик тыелып калды — агай сөйләүдән туктар да, нәрсәнедер, бик кирәкле

бер әйберне ишетә алмый калырмын дип курыкты һәм, чак кына урнаштырып йөргәч, Фәрхетдиннең җилкәсенә иелде:

— Син — үлгән кеше... Әни кулында хат булган... Ул документны бит беркая да куя алмыйсың.

— Анысы да дөрес...

— Шулай булгач, аңа үпкәләргә, үтергәнче кыйнарга ни хакың бар иде? Әнине бозык дип сүгәргә нинди вәхшилек, нинди явыз кара йөрәк таптың син?! Каян алдың аны? — Фәрхетдин уйланыбрак калганга, егет тагын өстәде: — Әгәр дә чак кына үзен бурычлы итеп исәпләмичә, синең белән араны өзгән булса, үзең минеке дип күкрәк каккан өенә сине кертмәгән булса, ул исән дә калган булыр иде, синең кабахәт сүзләреңне дә ишетмәгән булыр иде. Һәм мин аңа хәзер дә әни дип эндәшә алган булыр идем. Мине әнисез калдыручы — син...

— Ә мине ялгыз калдыручы кем?

— Кеше синең өчен яраткан кешесеннән аерылган, кабат синең белән торырга риза булган, ә син... Ничек дип әйттең аңа рәхмәтеңне?

— Рәхмәт әйтергә онытканмын, гафу ит!

«Кара син аны, ирония белән дә телләшә ала!»

— Ә син аны ник гафу итмәдең?

— Хатының син юкта бала алып кайтыр да, син аны гафу итәрсең, сиңа да җитәр әле ул көн.

Бу сүзләрне ул әйтерсең нindидер ерак киләчәкне күреп әйтә... Тәбриккә түгел, бөтенләй читкә карый... Һәм тагын башын тотып капкараңгы идәнгә текәлә.

— Ярый, Фәрхетдин абый... Хәзер син миңа сөйлә генә, алайса. Әни хакында, мине приютка илткәч ниләр булганын. Ул ничек хис итте үзен? Бик нык кайгырдымы?

— Кайгыру дисең...— Шулай дигәч, Фәрхетдин тотлыгып калды.

— Утыр, Фәрхетдин абый, ашыкмый гына сөйлә.

— Кайгыру дисең син. Кайгы гына булса иде дә ул!.. Син киткәч, ул урыныннан тормады... Мин аны үпкәләп, миңа үч итеп ята дип торам. Атна буе эндәшмәдек. Кызлар гына килә янына — аш китерәләр, чәй... Шуннан гаҗәп: балалар минем белән сөйләшмиләр — әйтерсең мин аларны да рәнҗеткән. Әниләрен җирләгәч тә икесе берьюлы читкә, Үзбәкстанга киттеләр. Хатлары ике-өч елга бер генә килә... Шулай... Әйе... Әниең... Атна-ун көн авыргач, өй чормасыннан төшеп килә бу. Көлемсәрне әйтәм, кулында бала төсле итеп төргән чүпрәк-чапрак. Авыруыннан саташканы әллә каян күренеп тора. Бәләкәй чакта кыз бала курчак белән уйный бит — нәкъ шулай. Мине күрүе булды, чарылдап кычкыруы булды: «Кит, кит, күземә күренмә, син яшергәнсең, барыбер таптым баламны, таптым, минем балам, минем балам, минем балам!» — ди. Мин шаккатып калган арада — мәче дә тиз сикерә алмас алай! — сикереп тә төште баскычтан, миңа килеп ташланды да сук-калый, тырнаша, прәме күзне чукып чыгармакчы. Бер кулында әлеге төенчеге бар. Ярый. Тиз генә тайдым да бикләп алдым ишекне. Күршетирә җыелып, дилбегә белән бәйләп, караватына яткырдык. Икенче көнне Камскига больниска озаттык. Ай ярым дигәндә кайтты — тынычланган, билгеле. Шулай да йөзендә елмаю әсәре күренмәде — көннәнкөн ныграк үз-үзенә бикләнә барды, бизгәк тоткандагыдай саргайды да тагын каты авырый башлады. Кыш буе ятты. Язга чыккач...

Өй әче караңгы, өй әче тын.

Караңгы өйдә, тын өйдә, буш өйдә алардан башка өченче зат — карачкы төсле шом... Кайдадыр ишек артында сагалап тора бугай... Әллә шул карачкы үзе сөйли, әллә инде аның сүзләрен Фәрхетдин кабатлый. Шактый озак өнсезлектән соң колак төбендә тагын сәер тавышлар ишетелә.

— Көннәр буе, төннәр буе уйлана, бәхәсләшә, сөйләшә торгач, нинди генә уйлар баштан кичмәгән, нинди генә сүзләр, вәгъдәләр ишетелмәгән дисең. Кичерәм дип күпме антлар бирелмәгән дисең! Юк, жиде төн уртасында хәтергә килеп, төшкә кереп, куркып торасың да тагын газаплана башлыйсың. Алай тиз генә түгел, ә гомер буе да, мәңгегә дә килешә торган җинаять түгеллеген аңлыйсың. Үзенне харап итәргә йөз кабат ант итәсең... Ләкин булмый, мин андыйга сәләтле түгел, ходай андый көч бирмәгән миңа. Үзем бүтәнчә булдыра алмагач, я, мин гаепleme? Әйт, гаепleme мин? Әйт, гаепleme мин?

— Барып алмаска кирәк иде, ә барып алгач, торып булмаганын аңлагач, чыгып китәргә иде.

— Мин ансыз яши алмый идем... Мин аны үзем мең кабат кичергән, үз-үземә аны җәберләмәскә мең дә ике кабат сүз биргән, ә үзем... үзем теләгәннең гел киресен эшлим.

— Сугышта да син батырларча үләргә ниятләгәнсең дә, тагын киресенчә килеп чыккан — әсир эләккәнсең.

— Бер төрле телим, икенче төрле эшлим — гомер буе шулай...

Фәрхетдиннең тормыш төбендәге кешеләргә генә хас ямьсезлегенә, кызганычлыгына карап, егетнең күңелендә әллә нинди авыр хис кузгалды. Шушы кеше турында: «Сугышта батырларча һәлак булды», дип язу килгән бит. Юк, агай, бик үк батырларча үлмәгәнсең шул...

— Минем әнине син көчсезлегең аркасында, куркаклыгың аркасында харап иткәнсең, ә үзең исән калгансың... — дип нәтиҗә ясады Тәбрик.

Һәм аның бу кискенлеге дә агайны гаҗәпләндерерлек түгел иде.

— Нинди аерма? Ул үлде дә котылды, ә миңа җәзасы калды — күпме гомер таланып узды. Хәзер дә шул ук хәл. Әллә син миңа җиңел дисеңме? Рәхәт чигеп яши дип беләсеңме син мине? Япа-ялгыз бер өйдә — өйдә генә түгел, бөтен дөньяда япа-ялгыз — рәхәт яши дисеңме?

— Әнинең хәле бик авырайгач, аның үтенечен тыңлап, мине алып кайтырга, изге ният белән Займищега баргансың да, үзең мине үлгән дип кайтып ялганлагансың. Тагын бер куркакларча ясалган хыянәтең ачылды.

— Ә мин кемне гаеплим? Кемне тиргәргә миңа? Кемнең якасыннан алырга? Ярый, син килдең дә мине бугаздан алдың. Ә мин кемнән таләп итим мыскылланган бәхетемне? Кемнән? Кем мине ялгыз калдырды?

Бая күпме сүз сөйләнеп, болай ук көчле яңгыраганын ишетмәгән иде Тәбрик. Бөтенләй диярлек яңгырамаган икән баягы сүзләр! Ә болары... Буш өй әйтерсең ул сүзләрне мәңге оныттырмас өчен кабат-кабат кычкыра иде...

— Кемне гаепләргә тиеш мин? Я, әйт! Кемне?!

Караңгы өй, буш өй эче шул вакыт Фәрхетдин абзый үксүе белән тулды. Тәбрик аны тынычландырырмын да Үзәнбайга кайтып китәрмен дип кенә торганда, әйтерсең бая карачкы дигән нәрсә ишекне ачты да күптән түгел генә чыгып киткән плотник егет кыяфәтендә өйгә килеп керде һәм эшне үзеннән дә тупасрак мәгънәсезлек белән пычратып ташлады. Исерек сүземе? Юк, алай гына түгел шул. Яхшылык белән, янәсе, тынычландырырга теләп, янәсе, тирә-юньдә таралган яманатны, ана хакында таралган әшәке сүзне чыгарды да селкеде исерек егет:

— Һаман кычкырышасызмы? Сез нәрсә ул хәтле — әллә нинди бер зиначы хатын өчен...

— Кабахәт!

Тәбрик шулай дип кенә акыра алды. Егет, аның тораташтай катып калуын сизеп, җәһәт кенә ишектән чыгып сызды. Өй баягыдан да шомлырак һәм йөрәк өзгечрәк бушлык белән тынып калды.

Күпмедер вакыт узгач исенә килсә, Тәбрик инде авылны узган һәм басу юлы буйлап атлый икән.

Башында мең төрле уй чуалганга күрә, берсенең дә очына чыгарлык түгел. Кемнәрдер очрап, аңа нәрсәдер әйттеләр дә бугай. Беркемнең йөзен күрерлек, сүзләрен аңларлык түгел. Башын иеп атлый да атлый егет. Инде Черныш дигән авылга ук җителгән икән.

Тау башыннан чишмә ага.

Тәбрик чишмә янында туктап, улак башына утырды. Улак башына утырды да исәпсез күп уйлары эчендә берүзе калды.

Бертуктаусыз чылтырап чишмә ага. Чишмә суларына кушылып, минутлар ага. Әллә чишмәдән, әллә шушы кечтә генә ачылган хәлләрдән йөрәккә ниндидер өшеткеч һәм чиркандыргыч тамчылар сибелә. Тамчылар төнге күккә сибелеп, аннан тагы җиргә тама тора, туңа тора — кышын караңгы тау куышларында, язын-көзен өй түбәләрендә асылынып күктән җиргә кадалырга торган боз сөңгеләр төсле укмаша. Чак кына үрел дә ал. Ал да синең йөрәкне бу хәтле дә каты җәрәхәтләгән адәмнең үз йөрәгенә када. Кемгә? Кем йөрәгенә тиешле? — Күз алдына йөзен сакал баскан дезертир килеп баса, сакаллы, ертык шинельле... Кыяфәте, төсе белән — Фәрхетдин. Фәрхетдин, өч адым алга! Шулай, бу погоннар сиңа хәрам — аларны Тәбрик «смирно» торган иптәшләре каршында йолкып ала. Нигә дисәң, сугышка керү белән, син, Фәрхетдин, чебеш җаныңны саклар өчен җай табып, әсирлеккә шылгансың, илеңне яклап бер генә ядрәне дә тиешле җиргә атмагансың. Үзебезгә каршы да атмагансың, билгеле, тик бу аклану түгел, илгә яу килгәндә атмый калу — үзе җинаять. Сугышның азагына кадәр фашист алпавытына батрак булып бил бөккәнсең һәм сарык-дуңгыз арасында тыныч кына яшәгәнсең дә, сугыш беткәндә, бүтән ил кешеләре сине безгә бүшлай биргәннәр. Солдат хисе, көрәшче хисе синдә беркайчан да булмаган һәм хәзер дә юк. Яшь солдат кайтканын һәм сине көткәнен белгәч, чакырылгач, әнисе хакына булмаса, солдат шинеленә ихтирам йөзеннән генә дә кайтып килер идең. Юк синдә андый ихтирам, булмаган. Бу шулай. Булачак солдатның әнисен кыйнап, куркытып, акырып, үлем чигенә җиткергәнсең һәм... әйе, әйе, үтерүчеләрнең берсе булып әверелгәнсең. Ил гомерен дәвам итәсе ананы үтерү — илгә хыянәт! Хыянәт!..

Тәбрик — улак башында... һәм... яныннан гына чишмә ага.

Тәбрик бу вакытта бөтен дөньяда берүзе. Шундый шыксыз, шундый күңелсез! Түзә алмасаң, үксе дә җибәр. Әмма җан шул чаклы өшегән — елый алу үзе бер бәхет булыр иде. Аның өчен әнә җил елый, чишмә яшь түгә, яфраклар, урманнар аһ итә — бөтен җир ыңгыраша. Тәбрик тыныч.

Тыныч. Ләкин ялгызлык куркыныч кебек. Шушы хәтле киң җирдә, шушы хәтле олы дөньяда Тәбрик бөтен нәрсәдән аерылган — үткәннән дә, бүгенгедән дә һәм, ахрысы, киләчәктән дә...

Шулай да, кайда соң әле зур тормыш? Кайда соң ил тормышы, заман тормышы? Һәм ник шушы хәтле тын? Тукта, еракта́н, офыктан ниндидер моңлы аваз килә түгелме? Самолет тавышы. Самолет! Әнә утлары да җемелди башлады. Килә, якынлаша, гүелди, гөрли, җырлый самолет! Димәк, кайдадыр тормыш бар, димәк, аңа кушылырга мөмкин, бүген булмаса, иртәгә, иртәгә булмаса, соңрак. Ләкин ул анда барыбер барып җитәчәк, анасын үтергән бу тынлыкта калмаячак, калмаячак!

Күңелдә туган ышаныч тагын тынычлыкка тоташа. Күпмедер вакыттан соң караса, матур тынычлык ай булып улакта йөзә икән! Ай! Шундый ак, шундый пакь!

Монсулыктан арыгандай, Тәбрик чак кына читкә китеп, йомшак чирәмгә ята, һәм айлы төндә чишмә чылтыравы аралаш әнисенең үксегән тавышын ишетә башлый. Елаумы бу, җырлаумы? Табигать сере... Мондый вакытта тамашачының булмавы хәерле...

Әнисе арыганчы үкси-үкси дә чишмә чыңын гына калдырып каядыр китеп югала. Җир өстендә чишмә җыры, ай нуры, йолдызлар җемелдәве генә кала. Мәңгелек якты, мәңгелек матурлык... Чиксез ераклык... Чиксезлек үзенең зирәк тынлыгын күңелгә йолдызлар җемелдәве рәвешендә сирпи.

Шул нурлар белән коенып күпмедер яткач, кеше, йөрәгендә ниндидер көч туганын тоеп, янадан чишмә янына килә.

Сап-салкын төнге чишмәдә кулларын, битләрен юа. Чишмә суыдай сафлык белән әнисен, әтисен, алардан соңрак бөтен дөньяны ук юасы килә.

«Алар бу чишмәне күрмәделәр, белмәделәр микәнни? Ник юынмадылар икән? Ә хәзер соң микән инде?»

Тезләнеп шул салкын суны — җиде кат җир ташын тишеп чыккан зирәк көчне — тешләрен чатната-чатната эчкәч, тәмам хәл алгач, аек акыл белән Тәбрик шуны ачыклады: күңелдә бүген туган тыныч нәфрәт күпмедер микъдарда барыбер калды, юылып бетмәде... Һәм шул хис белән ул ары китте, тау башына таба атлады. Биегрәк күтәрелгән саен төнге үзәнлеккә, андагы авылларга ешрак борылып карый торган булды. Күтәрелгән саен күз алдында айлы киңлек һаман зурая, киңәя барды. Шушы илаһи киңлектә табигатьнең үзенә хас зирәклек белән яшә дә яшә генә бит инде! Яшә дә яшә генә! Әнием минем, нәрсә комачаулады сиңа? Нәрсә?! Кешеләр, сез ни өчен берегезнең тормышын берегез харап итәсез? Ә бит бу киңлекләрдә урын һәркемгә җитәрлек — чын мәхәббәткә, бәхеткә, яшәүгә дә...

«Кешеләр, ник сез йолдызлардан үрнәк алмыйсыз? Йолдызлар әнә бер-берсенә һич тә комачау итмәстән, чиксез иркенлектә балкыйлар да балкыйлар, мәңге, мәңге. Бу көмеш үзәннәр галәм шикелле үк иркен ләбаса! Иркен ләбаса! Җирдә яшибез дисәгез, җир киң, күккә күтәрелергә дисәгез, тауларыгыз тезмә-тезмә. Күтәрелегез, менегез — үзегезгә кирәк йолдызны сайлагыз да тотыгыз кулыгызга — менә шушылай үрелегез дә тотыгыз — минем кебек! Йолдызлар бит һәркемгә җитә, һәркемгә!»

Тәбрик кулларын сузды, үзе сайлаган йолдызны тотты да күзләренә якынрак китереп йодрыгын ачты. Йодрыгын ачса, уч төбендә нишләптер йолдыз юк. Йолдыз аннан ни өчендер качкан иде... Ах, хәйләкәр, ах, хәйләкәр йолдыз! Ә Тәбрик бит сине барыбер тотар, барыбер тотмыйча калмас!

Тау буйлап бара торгач, егет, Ямәки юлын чамалап, түбән төште. Тынлыгы, монсулыгы белән күңелгә кергән кечкенә авыл урамы буйлап атлады... Бая Тугаш бабай белән узган урамнар шул арада истәлеккә дә әверелгән. Ай-яй тын, ай-яй ямансу да соң көмеш үзәндә югалып яткан авыл!

Әнә сиртмәле кое... Ул да истәлек, ерак заманнардан калган истәлек шикелле. Төбенә карасаң, ул заманнарны күреп тә була торгандыр. Чү, анда, кое төбендә нәрсә җемелди? Йолдызлар түгелме соң? Шулай шул, йолдызлар! Аларны ничек алып чыгарга да тотып карарга? Әллә монысының да төбенә төшәргәме?

Егет тагын алга атлады.

Ямәкине узгач күп тә үтмичә...

Чү, нәрсә бу? Шагыйрь әйткәндәй, качкынмы, җенме? Бу заманда качкын да, җен дә калмады, кешеләр генә калды. Ә шулай да... бу нинди җиңел шәүлә? Төн кошымы, пәри күбәләгеме? Әллә Тәбрикнең күптән түгел генә кулына тотып караган йолдызы җиргә төшкәнме?

Әйе, шул, шул үзе — тик ул хәзер кыз кыяфәтендә, чибәр, җинел, бәхетле кыз!

— Гөләндәм, син бит бу?

— Әйе, Тәбрик абый, мин бу.

Егет, тиз генә йөгереп килеп, Гөләндәм сеңелесен кочаклап алуын сизми дә калды. Кыз исә сөенеченнән Тәбрик абыйсының кулын тотты да, аның янында таган әйләнгән шикелле бөтерелә башлады. Таган шикелле, Җир тирәсендә, Кояш тирәсендәге Җир, Җир тирәсендә әйләнгән Ай шикелле...

— Төнлә нишләп йөрисең син, Гөләндәм?

— Сине каршылап. Сине көттем. Озакладың ич... Без инде куркып беттек.

— Ә төнлә болай берүзең йөрергә курыкмадыңмы?

— Курыкса ни!

Аңлады Тәбрик: Гөләндәм аның өчен беренче батырлыгын эшләгән, аның өчен куркуын җиңгән. Менә сиңа бала! Менә сиңа унҗиде яшьлек кыз бала! Ул инде күзгә күренә, әллә нинди рәхәт, саф уйлар һәм тойгылар кузгата алырлык икән. Фәрхетдин абзый юкка гына әйтмәгән икән. Кешегә матурлыкны да бармак белән төртеп күрсәтергә кирәк шул, югыйсә, күрми ул аны, танымый, аңламый. Ә аңласаң, матурлык ачышка әверелә, бәхеткә һәм...

Ярый әле, фикер агышын тыеп кала алды егет, югыйсә, бәхет белән бергә йөри торган атаклы һәм изге сүз телгә килә язды бит...

Ләкин ни генә дисәң дә, Гөләндәм бар, ул янда, Тау ягының барлык матурлыгын бергә җыйган тылсымлы көч аның белән бара һәм бер сүз әйтмичә генә, туган җирне, авылны яратырга үгетли — нәкъ Тугаш бабай сүзләре шикелле.

Йөгерә-атлап, Үзәнбайга ук якынлаштылар. Ул да Ямәки төсле үк сибелеп-таралып ята. Уянмас та кебек — йоклый.

Икесе дә ирексездән туктап калдылар: Тәбрикнең туган йортына җителгән икән.

Туган йорт...

Ә менә хәзер шушы өйдә, энисе, апалары белән бергә, Тәбрикнең дә йоклап ятуы бик ихтимал иде бит?! Язмыш бер бармагын гына селкегән дә гомерләрне бүтән якка борган. Ай, бу язмыш дигәннәре! Тылсымлы да, ягымлы да, усал да!

Фәрхетдин бәлки дөрес курка, бәлки шушы шыксыз караңгы йорт эчендә Тәбрикне Гөләндәм шикелле ягымлы киләчәге көтә торгандыр?

Ләкин тәрәзәдән карасалар, анда — һаман да җан өшеткеч бушлык... Тыела алмасаң, кычкыр да җибәр. Юк, болай ярамый, тизрәк Сөембикә апа янына, Тугаш бабай янына кайтырга кирәк.

Тук-тук-тук.

— Кем бар?

— Без бу, бабакай!

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Җирне һәм күкне яшенле яңгырлар кабат-кабат юып тагын үтә күренмәле зәңгәрлек белән бизәп китте. Уң яктагы таулар тезмәсе — җанлы сәхнә, аерым агачларына хәтле күргәзмәгә сайлап куелгандай бериш. Алар, ерак урманнар хакында уйланып, чак кына ямансу балкышлар сирпеп, күңелне каядыр дәшә, җилкендерәләр. Тезмәнең иң биек төшләре баһадирлар күкрәге төсле мәһабәт, җир тетрәсә дә селкенмәс шикелле.

Шушы яшел таулар тезмәсенә күтәрелеп, каршы якка күз салсаң, сөзәк җирләр артындагы тәбәнәк калкулыклар тагын әкертен-әкертен биеккә табан үрләп баралар.

Ә урталыкта — сусыз диңгез, алтын үзән. Ул күкнең үзе шикелле үк еракка-еракка җәелгән дә алгы якта — күз күреме җитмәс җирләрдә — офыклар белән тоташкан. Киңлек-иркенлек рәхәте, чиксезлек ләззәте, биеклек бәхете — бөтенесе бергә. Шул иркенлек, шул чиксезлеккә чык та:

— Эһ-һе-һей! — дип елларга, заманнарга кычкыр.

Һәм тыңла.



## Көянтәңне ал да...

— Гөләндәм, безгә сыра коярга ким дигәндә ун чиләк су кирәк.

— Кайчан?

— Хәзер үк, балакаем, көянтәңне ал да кит коега.

— Кичә төбенә мин төшеп чыккан коегамы инде ул, дәү әти?

— Изге чишмә ерак бит, Тәбрик, коега барырга туры килә инде.

— Ә бу коедан... бабай, үзең беләсең, алмыйк әле.

— Ә! Менә ни өчен соңгы көннәрдә рәтләп чәй эчмисең икән! Ул хәтле шикләнмә, мәче төшкән коедан йөз егерме чиләк су алып түксәң, китап аны хәләл исәпли, балам.

— Барыбер, бабакай, әйдә, чишмәдән үзем алып кайтыйм әле, ә?

Нишләсен, Тугаш карт Тәбрик оныгының нечкә күңелен рәнҗетмәс өчен тракторчылардан мичкәле арба сорарга мәҗбүр. Суны көянтә-чиләксез генә ташырга туры килде.

Бәки дигән авылга таба ике чакрым чамасы җир үткәч, тау итәгендә чылтырап чишмә агып ята. Бабай кабат-кабат аңлатканча, тавы — изгеләр тавы, ә суы — изгеләр чишмәсе. Түбәннән ургылып торган агымны тап уртада калдырып, колач җитмәслек бетон торба куйганнар да су нәкъ йөрәк шикелле... бертуктаусыз талпына һәм аның шул талпынышы аермачык күренеп тора. Чишмә төбенә бераз карап торганнан соң, Тәбрик кулларын-битләрен юмакчы булып иелгән иде, бабасы рөхсәт итмәде — изге суны корбан түләмичә эчәргә ярамый икән. Моннан ун-унбиш адым үрдәге коры чишмәгә күпме дә булса көмеш яки бакыр акча салырга, әгәр алары булмаса, шушы тере чишмәгә бер генә булса да чәч бөртегеңне бүләк итәргә, агызып җибәрергә тиешсең. Кесәсендә Казан трамваеннан калган шактый гына бакырлары бар иде, Тәбрик шуларны сусыз чишмәгә салып килде дә инде хокуклы рәвештә кулларын ялгаштан агып торган су салкынына куйды. Рәхәтләнеп кулларын-битләрен, хәтта чәчләрен дә юды һәм мондый рәхәтлек өчен бер уч бакыр гына түгел, күбрәк тә кызганыч түгел иде.

Шактый озак хозурлангач, ун-егерме адым түбәнтен нииндидер корылмалар барын күреп, шунда таба китте. Барса, ни күрсен — скважина, насос станциясе... Җентекләп тикшерде — бөтен нәрсә үз урынында, моннан бер ел гына элек Тәбрикләр үз частьларына су китертер өчен төзегән чишмә шикелле үк. Бер генә нәрсә җитешми — мотор гына юк. Тәбрик шатлыгыннан кычкырып ук җибәрде:

— Бабай, кил әле дим, кил әле !

Бабасы килде килүен, әмма оныгының шатлыгын уртаклашырга ният сиздермәде. Оныгы түзмичә яңадан сорарга мәҗбүр:

— Бабай, шушы хәтле байлыгыгыз була торып, нишләп яман су эчәсез сез, ә? Үзегез әйткәндәй, изге чишмәдән баш тартасыз?

Бабасы кул гына селтәде:

— Сөйләмә инде, балам, син аны, сөйләмә.

— Тукта әле, бабай, рәтләбрәк аңлат әле.

Әгәр ышанырга мөмкин дип санасаң, чишмәнең шактый искергән яңа тарихы да бар икән. Әйткәнебезчә, шушындый олы байлыгы була торып, Үзәнбай ничәмә йөз еллар буе эчәр суга тилмерә. Коедан чыккан мәче һәм тавыклар гадәти хәлгә әверелгән инде. Әгәр күрше авыл егете берәр кызны үзенә карата алмыйча, үч алырга кирәк тапса, коега кош-кортны тере килеш тә ташлап китүе ихтимал. Мондый хәлләргә күнегеп беткән авыл ул хәтле күтәрелеп тә бәрелми. Ләкин менә Тәбриккә бик тә, бик тә яман тәэсир итте бу, һәм авыл халкы аңа әллә ничек кызганыч тоелды, ничектер күңелендә аларга ярдәм итәргә тырышу теләге кузгалды.

Менә чишмә, скважина, насос станциясе... төзелгән килеш онытылган. Каян килә мондый тилелек?

— Төрлечә кыландырып карадылар, барып чыкмады. Авыл артыннан узган Үләмәдә болганчык су ага. Терлекләргә ярый инде — шуннан алалар, ә кешеләргә юк шул, юк, — диде бабасы.

— Күпме кеше көянтә белән әллә кайлардан су ташый.

— Сиртмәле коелар, чылбырлы коелар — матур, әмма да суга гел саран булдылар.

«Авылга саф чишмә суы бирсәң, аннан да олы бүләк буласы түгел икән. Кешеләрнең көн саен чакырып кунак итүләренә ярашлы менә дигән бүләк булыр иде бу. Ләкин инде Тәбрикне көтмәгәннәр, үзләре корып куйганнар. Ни өчендер файдаланмыйлар гына. Сәбәбен бабасы бик җиңел аңлатты:

— Менә җиргә кадалган шушы торбалардан су килми.
— Нишләп?
— Белүче юк.
— Мәче ташлаганнардыр әле.
— Син, балам, көлмә инде безнең бәладән.
— Чынлап әйтәм, су килергә тиеш моннан.
— Әллә нинди галимнәр килеп тә баш кына чайкап киттеләр.
— Әйдә әле, председательгә алып бар әле мине, сөйләшик әле.

— Барырбыз анысы, тик сүз белән генә су чыгара алмассың. Ул хәтле түземсезләнмә — өч ел буе тик яткан торбалар тыныч кына тагын шул хәтле ята бирерләр. Тузып юкка да чыгарлар.

Мичкәгә су тутырдылар да мөмкин кадәр тизрәк авылга ашыктылар. Бәхетсезлеккә каршы, идарә йортында хисапчылардан башка беркем дә юк иде. Уракка төшәр алдыннан кәнсәләрдә бик утырмаска тырышалар, имеш. Иртәгә кояш белән торып килергә булдылар.

Ә бабалы-оныклы өйгә кайтуларына Сөембикә белән Гөләндәм инде суны кайнатып та чыгарганнар иде һәм Тугаш бабасы абзарның эчке як түбәсеннән ике зур гына көлтә алып төшкәч (яшь арыш саламын махсус җыеп куялар икән), шуны Тәбриккә балта белән вак кына итеп кискәләргә-турарга кушты. Кискәләгәч исә ул башакка әверелде. Башакны Гөләндәм белән Сөембикә апа кайнар суда бик каты пешекләп мич буенда тезелеп торган чүлмәкләргә салдылар да бер капчык он кертеп аны да шул чүлмәкләргә тутырдылар, аны боламык сыман итеп болгаттылар һәм шуннан соң, чүлмәкләр өстенә табалар каплап, һава йөрмәсен дип, камыр белән сылап та куйдылар. Иң ахырдан, мичтә кисәүләр янып беткәч, утлы күмерләрне учакка тарттылар, анда әлеге чүлмәкләрне тезеп утырттылар. Морҗаның төтен юлы ябылып, мич авызы да каплап һәм сылап куелды. Шулай да ярты сәгать үткәнче үк өйдә чыдап булмаслык эссе иде инде. Тәбрик урынны болдырга

җәеп ятты һәм анда аңа кояш белән бергә тору бигрәк тә җайлы булып чыкты. Чәй-фәләнне көтмичә, бабасын ияртеп, идарә йортына китте.

Ындыр табагы кебек такыр утарда ыгы-зыгы башланган һәм келәт төсле бер корылма алдында бер төркем кеше нәрсә хакындадыр шактый каты бәхәсләшеп торалар иде. Тәбрик аларның аерым сүзләрен ишетсә дә, бәхәснең асылына төшенә алмады. Төркем уртасында — председатель. Башына «Ялта» дип язылган ак кепка, өстенә ковбой күлмәге кигән ул абзыйның кыяфәте шактый кызык — гәүдәсенә караганда тәпиләре кыска икәнлеге бер күрүдә күзгә ташланды. Тәгәрәп кенә дигәндәй килеп, Тугаш карт белән, аннары Тәбрик белән үзе башлап исәнләште. Әлеге төркем дә аның артыннан иярми калмады, билгеле, тагын урап алдылар.

— Я, солдат, яллар ничек уза? Кайтканыңны ишетсәм дә, чакырырга ашыкмадым, үпкәләмә, шәплəп ял ит. Үзең башлап килгәнсең икән, бигрәк тә шәп, тик ятасың килмидер. Әмма да, дөресен әйтим, хәзергә автомашина юк, яңа трактор да күренми. Икесен ремонтлап карыйм дисәң, рәхим ит.

— Мин башка йомыш белән килгән идем, иптәш председатель.

— Ул безнең су станциясен хутка җибәрмәкче иде, Корбан улым, — дип ярдәм итәргә ашыкты бабасы.

Егет авызыннан ишетсә, житдигә алмас дип курка иде ул. Ләкин карт үзе әйтсә дә, әллә ни исе китмәде председательнең.

— Җибәрегез соң, кем мишәйтли сезгә? — диде председатель.

— Миңа ике автокран кирәк булачак! — Егет аның шаяруын кабул итмәде, билгеле.

— Аннары?

— Торбаларыгыз бардыр, житәрлектер инде.

Кунакны рәнжетмәс өчен генә абзый чынын әйтте:

— Яртысы инде җиргә үк кумелгән, ә яртысын табасы бар.

— Кыенмы табу?

— Әй, энем, энем, монда инде фән кандидатлары килеп теш сындырып китте. Ә сезнең нинди образование?

— Урта мәктәп.

— Менә минем югары мәктәп. Барыбер берни дә чыкмый.

— Сез зоотехник.

— Ярый, лутчы син шәплəп ял ит. Соңыннан тракторга утырырсың.

— Аңысы өчен рәхмәт.

Онытынның кәефе кителгәнен вакытлы чамалап, Тугаш карт ярдәмгә килмәсә, председатель сүзне беткәнгә санап китеп үк бармакчы иде, ярый әле, аны туктата алды.

— Тагын ни әйтер идең, бабай? — диде председатель аңа.

— Син, Корбан энем, акыллырак бул әле. Бер олыны тыңла, бер кечене, дигән халык. Һаман сусыз интектерергәмени ниятең?

— Ну, уйлыйбыз, эзлибез тиешле белгечләрне.

— Тиешле кеше шушы бала түгелме икән?

— Эше шундый кыен булгач, мин нишли алам?

— Эшләмә, ышанып кара солдат кешегә, китерт кранны дөбердәтеп. Сиңа ни тора. Теге чакта дөбердәдегез бит. Яшник-яшник аракы түгеп, ярты литр су ала алмадыгыз.

— Ә синең егет чыгара алса суны, аннан да җәлләмәс идек аракыны.

— Мин аракы өмет итмим, иптәш председатель, эш хакы да кирәкми. Минем теләкләр бүтән. Бары тик сезне җәлләп.

Шушы вакыт төркем телгә килеп председательне үгетли башлагач, ниһаять, тегесе йомшара төште:

— Ә син ул эшнең рәтен каян беләсен соң? — дип елмайды да, ачуланма дигәндәй, егетнең аркасыннан кочаклап куйды.

— Армиядә. Үзебезнең торган җиргә шушындый ук чишмә керткән идек.

Шушы сүзләрне ишеткәч, председатель йөзендәге шаянлык кинәт сүнде. Ныклап сөйләшергә кирәк икән алайса дип, Тәбрикне һәм Тугаш картны үзенең эш бүлмәсенә чакырды. Бүлмәдә итәгать белән:

— Кайтканыңа ни чаклы, иркенләп бер сөйләшкән дә юк, — дигән булды.

Сөйләшә торгач, чишмә тарихына яңа мәгълүматлар өстәде.

Авылда элек дүрт йөз дә сиксән өй булып, хәзер ике йөзгә калган, имеш. Кайбер патриотизмы аксый торган адәмнәр чишмәле авылларга, ванналы-кранлы бүлмәләре булган калаларга сыпыртырга тырыша икән. Бигрәк тә яшьрәкләр. Иң җайсызы шул — председатель аларга үпкәли алмый, нигә дисәң, ничә ел инде — сусызлык...

Кытлыктан котылмак өчен председатель абзаң Казанга, авыл хуҗалыгы институтына барып су китертергә ярдәм сорагач, андагы иптәшләр ике куллап риза булганнар да сәләтле дигән бер аспирантка кандидатлык эше итеп шушы чишмәне тапшырганнар. Аспирант килгәч, шундый сөйләшү булган:

— Су күтәргеч манара куясызмы? — дип кызыксынган акча ягын белә торган председатель.

— Юк. Андый коточкыч расход нигә сезгә?

— Кирәк түгел шул.

— Аска кечкенә бак куярбыз да суны шул бак туктаусыз озата торыр.

— Алайса, эшкә тотыныйк, иптәш аспирант,— дигән председатель, акча аз кирәк булачагына бик тә куанып. Хәзер исә саранлык аркасында харап булдым дип, вөҗданы белән бәхәсләшеп интегә икән Корбан абзабыз.

Аспирантның дәртләндергеч сүзләре бүгенгедәй колак төбендә чыңлый аның: «Скважина, скважина кирәк сезгә. Моңарчы сез һәм без белгән насослар суны буралы коелардан алса, безнеке скважинадан алачак. Яңалык бу. Мондый станция хәзергә бөтен илдә берәү генә, ә Татарстанда бөтенләй юк. Бу үзе бер фәнни ачыш булачак...»

Дөрес, ачышы булган, ә менә суы...

Көнне-төнне белмичә тырышсалар да, эш төгәлләнде дигәндә, аспирант егет, бүтән вакыт калмады, калганын үзегез дә башкарып чыга алырсыз дип, каласына сызган. Ә җитәкче булмагач, ачышы ярты юлда кабат ябылган да калган — һәм менә бишенче ел дигәндә дә су юк, ә аспирант үзе диссертацияне шәп яклаган, имеш.

— Соң инде, җитәкләргә дә алып килергә иде кабат үзен.

— Алып килмәгән кайда! Карады. Теоретик исәпләр барысы да дөрес, эшләнүе дә шәп, су килергә тиеш дип, тагын китте дә барды. Бу юлы ярты куюның да файдасы булмады.

— Минемчә дә бөтен нәрсә дөрес монда.

— Ә нишләп су юк соң?

— Мәче салганнар... Берәр кызыгыз күрше авылның берәр усал егетенә кияүгә чыкмаганга үч алганнар.

— Ә чынлап әйтсәк?

— Мин чынлап әйтәм.

Председательнең утырган җиреннән кәгазьләрен актарган, телефоннан әллә кемнәр белән сөйләшкән булуыннан егетнең ихтирамсызлыгына хәтере калган сыман бер нәрсә сизелеп тора иде.

— Онытың шаярта гына бит безне, ягъни — мыскыл итә...

— Бернинди мыскыл юк, күтәрергә ике кран китертегез. Әгәр барып чыкмаса, эшли башлагач, бәясен үзем түләрмен. Кран китертү бәясен әйтәм. Курыкмагыз...

Шуннан соң председатель бәхәс куертмады.

— Курыкмаска тырышыйк. Алайса, минем газикка утыр да РТСка элдер, энем. Безнең исемнән сөйләш, таныклыкны хәзер язып бирерләр.
— Ә бер чакрымлык торбаны каян аласыз?
— Суны чыгара алсаң, калганы өчен кайгырма — бетте.

*
* *

Билгеле инде, бөтенесе дә Тәбрик теләгәнчә шома гына барып чыкмады. Беренче көйсезлек таныклыкта иде: анда Маркс исемендәге әртил әгъзасы Тугашев Тәбрик Фәрхетдинович дип язганнар иде. Үзләренең әртил әгъзаларын беренче рәнҗетүләре иде бу. Ләкин егет бүтән монда юл куймаячак — этисенең исемен паспортта ук Мирсәетович дип үзгәртәчәк. Ләкин әлеге кәгазьнең тылсымы әллә ни сизелмәде диярлек. Үзенең тиздән китәчәген, авылның тагын бер-ике гасырга сусыз калачагын төшендергәч кенә бер кран вәгъдә иттеләр — анысы да өч көннән соң гына булачак. Килешмичә кая барасың. Дөресен әйтсәк, ул хәтле ашыгыр җир дә юк — Тәбрикне әле авылдан кумыйлар, киресенчә, аны көн саен кунакка чакырып торалар әле. Кичен бабасы да ашыгу, сабырсызлану — ходайга каршы эш, дигәч, егет тәмам тынычланды. Хәтта запаска бирелгән бу өч көн хәерлегә дә булып чыгар, шул арада аның этисе килер (инде аның Казаннан кайткан дигән хәбәре бар) һәм иркенләп сөйләшерләр, аңлашырлар, киләчәккә планнар корырлар.

Ләкин алай уйлап кую дөрес булып чыкмады. Әтисен дүрт күз белән дигәндәй көтсә дә, кадерле кешесе ни өчендер күренмәде. Икенче көнне Тәбрик, ниһаять, түзә алмыйча, иртә таңнан торып Келәнче авылына үзе китте.

Барышлый теге чишмәдән тагын тешләре чатнаганчы су эчкәч, тәне генә түгел, җаны да сафланып киткән кебек булды, шул дәрт, шул канат белән Келәнчегә барып җиткәнче ару-талу дигән нәрсәне бөртек тә тоймады.

Келәнчедә әрәмле, әрекмәнле ташландык ихаталар бөтенләй диярлек күренми. Агач-куаклар ышыгындагы өйләр яп-якты тәрәзәләре белән елмаеп торалар. Һәр өйдән ныклык, тазалык-иминлек, күңел көрлеге сизелә. Тугаш бабайның бу авылны күргәне бар микән? Ул күрергә теләгәнчә яшидер монда халык...

Тукта әле, нигә Тәбрик гел бабасы хакында уйлый соң әле? Ул бит этисе янына, туган этисе янына килә!

Җәйге аяз иртә Келәнчене искиткеч бер ямь белән бизәгән. Авыл башыннан көтү чыгып бара.

Әтисенең өен сорашып белде дә аннары бер капканы ачты. Ишегалдында кырык биш-илле яшьләр чамасындагы берәү ат җигеп ята иде. «Эти!» дип уйлап алды Тәбрик һәм кинәт тагын каушап калды. Каршысына һаулап кечерәк бер ак эт килеп чыкмаса, шактый кыен хәлгә каласы иде. Ат җигүче кеше эт өргән тавышка тиз генә борылды да:
— Бобик, ярамый! — дип кычкырды.

Ләкин, Тәбриккә ныклап илтифат итмәстән, һаман ат җигүендә булды. Әйтерсең улы аның өчен бөтенләй әһәмиятсез бер кеше иде. Нишлисең, Тәбрик үзе этисе янына килеп, аңа карап тора башлады. Тегесе салмак хәрәкәтләр белән дилбегәне рәтләп ат өстенә куйгач кына эндәшергә тиеш тапты.

— Хәерле иртә, егет кеше.— Тавышында һаман шул илтифатсызлык иде.

Тәбрик бу сүзләрне яхшылап аңламаса да, мәгънәсен кабатлап сорамады һәм русча үзе эндәште:
— Сез Мирсәет исемле кешеме?
— Әйе. Соң?..

— Мин — Тәбрик...

— Тәбрик? — Ир кешенең шунда гына ваемсызлыгы юкка чыкты. Шулай да, ни өчендер, каушаптыр, әлбәттә, сорап куйды: — Нинди Тәбрик?

— Менә шушындый... — Тәбрик бу юлы үзе тыныч булырга тырышты һәм, тегесе телсез калгач: — Көлемсәр улы... — диде.

Атлы арбаны Мирсәет бер сәбәпсезгә ким дигәндә өч тапкыр әйләнып чыккандыр. Шактый йөренгәч, мөгаен, ник икәнен үзе дә белмәстән, арбасына утырды да Тәбриккә карады. Фәрхетдиннеке кебек үк, моның да күзләреннән беренче күренгән нәрсә курку иде... Сүзсезләктән аптыраган Тәбрик үзе сүз башлады:

— Сезгә... Сөембикә апа хәбәре килеп җитмәдемени?

— Ә... Хәбәр... Синең кайту хакында... житте, житте анысы...

— Нәрсә... Син, алайса, мине улың итеп санамыйсынмыни?

Җавап урынына ата кеше утырган җиреннән кузгалып кына куйды.

Тәбрик, беркатлылыгы белән, моны каушаудан гына дип исәпләсә, хәзер аны әтисе кочаклап алыр, беркайчан ишетмәгән кадерле, ягымлы сүзне әйтер, «Улым!» дияр, узган кайгылар, кичерешләр, шикләнүләр барысы берьюлы төтен шикелле юкка чыгар дип көтсә дә, ата кеше алай итмәде. Ә улы: «Әллә борылып китеп барырга микән?» дигән уен көч-хәл белән җиңеп, кыенлык белән булса да әйтте:

— Мин сезнең белән сөйләшергә теләр идем.

— Шулаймы? Ярый...— Һәм ата кеше, капкадан кергән бер хатынны күргәч, тагын тотлыкты.

Хатын татарча ике-өч сүз генә әйтте дә өйгә кереп китте. Шуннан соң гына Мирсәет Тәбриккә таба борылды. «Хәзер әйтәчәк, улым, диячәк!»

Юк, егетнең өмете тагын акланмады, бернинди атаусыз-исемсез генә тәкъдим итте ата кеше:

— Мин хәзер шушы ат белән заготскотка китәм. Син дә утырмыйсыңмы?

— Мин анда нишләрмен соң?

— Сөйләшербез. Авылдан чыккач...

Нишләсен, авылдан чыкмыйча гына сөйләшү мөмкин булмагач, ризалашырга туры килде. Атлы арбага беренче утыруы булганга, анда бару Тәбриккә шактый кызыклы тоелды.

Арба кылтыр-кылтыр килгәнгә, ахрысы, атасы сүзгә керешмичә бара. Авылны чыгып шактый киткәч, атны чирәмле җиргә чыгарып туктатты да улы ягына күчеп утырды. Әмма икесе дә башларын игән килеш, сүзсезлектән гаҗиз булып, шактый вакыт телгә килә алмадылар.

— Ярый, яхшы — син дә бар икән дөньяда.

— Әйе шул, бар... — «Әти» димәкче иде, әйтә алмады, кыенсынды...

Кара син, үз атаңа «әти» дияргә кыенсыну ни дигән сүз инде ул? Ник болай? Әнә бит, әтисенең дә баядан бирле «улым» дигәне юк. Никадәр кадерле сүз икәнен башына да китерми шикелле. Хәлне аңламыйдыр ул. Кемдер әйткән, сусауның нәрсә икәнен чүлдә булмаган кеше аңламый дигән. Дөрестер бу. Аңласа, болай эшләмәс иде. Аңа нәрсә, сигез баласы сигез яктан «әти» дип теңкәсенә тия, сигезенә көн саен сиксән сигез тапкыр «улым», «балам» ди торгандыр, ә бу улына... Бу улы бөтенесеннән дә начаррак микәнни?

— Менә нинди егет булгансың... Кем уйлаган!..

Тәбрик бу сүзләрнең бернинди эчтәлексез, сүз юктан гына әйтелгәнен сизеп, аларны игътибарсыз калдырды. Ул көткән сүз бүтән шул, бүтән...

— Эшли башламагансың әле?

— Башланыр инде...— Тагын чак кына «әти» дип ычкындырмады Тәбрик.

Гажәп түгел, ул беренче күрешүдә үк шул сүз белән этисенең коча-гына асылынмакчы иде бит. Барып чыкмады. Бөтенләй икенче төрле булып чыкты, бөтенләй. Хәзер дә сүз һич кирәкмәгән, һич теләмәгән юлга кереп китте.

— Зарплата эшкә кергәч үк бирелмәс. Шуңынча яшәрлек акчаң бармы соң?

— Анысы инде...

— Син тартынма, әйт. Мин сиңа бераз юнәтермен.

— Рәхмәт. Мин акча сорарга килмәдем.

«Фәрхетдиннең өй сорап кайткан дип коты очса, монысы акча сорар дип курка...»

Болай ук уйлаганын белмәсә дә, улының сүзендә беркадәр үртәлү сизгән ата шундук сүзен төзәтергә ашыкты:

— Син үпкәләмә... кирәк булса гына дим мин.

— Акча сорарга килмәдем. — Кабатлауда да мәгънә бар!

Ата кеше аптырабрак калды. Урынлы кыенсыну. Аннан ничек котылырга белмичә шактый утырдылар. Күңелдә булган нәрсә чыкмыйча, сизелмичә калмый бит ул — житмәсә, һич үзе теләмәгәндә, эти кеше утка тагын керосин сипте:

— Ну, алайса, эшкә урнашкач, кирәк булса, тартынма, хат яз... түлке хатка «эти» дип язма...

— Эти дип язма?

Кайтарып сорамау мөмкин түгел иде, чөнки әллә каян күренеп тора — акылга сыя торган хәл түгел бу. Атасы хәзер үк хатасын төзәтәчәк, бүтән төрле әйтәчәк!.. Бүтән төрле? Юк шул, ул алай итмәде, баягыдан да ачырак, башка сукканнан да яманрак итеп:

— Әйе, — дип кенә куйды.

Һәм шул сүз инде Тәбрикне бөтенләй тугарып ташлады. Арбадан сикереп төште дә каядыр йөгермәкче булды... тукталып калды. Әдәп өченме? Шулайрак бугай, югыйсә, инде нәрсә көтәргә? Йөгерергә, китәргә, качарга...

Ата кеше исә, улының ни кичергәнен чак кына чамалый да алмыйча, һаман үзенчә акланырга тырышты:

— Дөньяда син барын минем бу хатын белми бит... Ишетсә — бетте... аның законы үзе белән — сигез баланы үземә ташлап китте барды булыр.

— Син... сез... — Тәбрик кызарды, каушады һәм Фәрхетдин абыйсы белән килеп чыккан хәл кабатланудан куркып, үзен көчкә-көчкә кулга алды. «...Ярамый, ярамый, ни генә әйтсә дә, түзәргә, ни генә булса да. Ата! Нинди ата?!»

Атын юл буендагы ялгыз каенга бәйләгәч, эти кеше улы янына канауга утырды:

— Шулай килеп чыкты... Көлемсәр... синең әниең...

— Нәрсә әнием? Минем әниемә ни булган?! Ул гаепмеме? — Тәбрик ишетелер-ишетелмәс кенә шулай дия алды. Әйтерсең бу уйны ул үзе генә уйлый һәм кешегә ишетелүен теләми иде. Дөресрәге, каушавыннан һәм тавышы калтыраудан ул бу сүзләрнең әйтелгәнен бөтенләй тоймады диярлек.

— Ну, соң... ну... син исән икәнне миңа беркем дә әйтмәде бит. Ә тугач, мин сине күрә алмадым — Фәрхетдин кайтты. Шуннан соң...

— Шуннан соңгысы кирәкми! — диде егет.

— Ник?

— Болай... — диде дә тынды Тәбрик, чын сәбәпне әйтә алмады. Дөресе: «Син законсыз туган булып чыктың», дип әйтер дип курыкты ул. Ә мондыйны... кемнең ишетәсе килсен? Өстәвенә күңелдә бүтән фикер.

— Ә сез... йөкле хатынны ник чыгарып җибәрдегез?

— Каян?
— Сез бит бергә яшәгәнсез?
— Әйе, чит-ят кешеләрдә квартирда тордык — район үзәгендә. Үз өебез юк иде.
— Барыбер, ник җибәрдегез? — Атасының чын уен белер өчен ул аның күзләренә туп-туры карады — очрашканнан бирле беренче тапкыр.
— Мин аны кумадым, үзе ташлады мине.
— Ташларга мәҗбүр иткәч.
— Ничек?
— Сез аны киләчәктә матур тора алачагыгызга ышандыра белмәгәнсез. Юк, ялгыш әйтәм, киләчәктә аның белән бергә булуыгызны үзегез үк күз алдына китерә алмагансыз. Дөресме шул?
— Мин ул чакта уполминзагта эшли идем. Гади заготовитель. Яшәү шартлары — билгеле. Көлемсәр «гаилә ишәйсә нишләрбез» дип көненә өч кенә тапкыр кабатламагандыр. Шуңа күрә дә ташлады бугай. Авылда үз өе... Фәрхетдине икенче кабат килгәч, китте. Балаларын да җәлләгәндер инде.
Тәбрик хәлнең болай гади генә булганына ышанырга җыенмый иде, әлбәттә.
— Ник җибәрдең? — дип кабатлады һәм үртәлүен яшерергә теләмичә: — Ник? — дип өстәде.— Әйбәт чакта яраткансыз... ә чынлап киләчәк хакында... — Тәбрик ни өчендер тотлыгып калды. Аңа нәрсәдер аңлашылып бетми иде.
— Көлемсәр һаман әйбәт булып калды.
— Әмма сез никтер соңыннан кимсенә башлагансыз. Миңа менә шунысы аңлашылмый.
Улы аңламаганны этисе төшендереп бирергә тиеш иде һәм ул шулай эшләргә тырышты да:
— Ата-бабадан килгән гадәт инде ул — егет кеше ирдән кайткан хатынга өйләнсә, бу — егетнең кимлеге исәпләнә. Җае килсә-килмәсә дә, аны котыртырга тырышалар.
— Сезне дә котырталар идеме?
Бу сорауга болайрак җавап бирергә тиеш иде атасы: «Өстәвенә, кешенең күңелендә яшь кыз белән тора башлауның ничек икәнен, нинди тойгылар барлыкка китерүен беләсе килү һәм, белә алмагач, дөньяның ниндидер бәхетеннән мәхрүм калу ояты һәм үкенече җәфалый башлый бәндәне — анысы бигрәк тә яман нәрсә икән». Ләкин кайчандыр бәхетне бары тик шушы хис агуласа, бүтән бернинди сәбәп булмаса да, бу хакта беркемгә дә авыз ачып сүз әйтмәс иде Мирсәет. Бигрәк тә үз улына, шул хатыннан туган балага әйтмәс иде. Җитмәсә, шушындый сәер кичерешләр белән бергә Көлемсәргә булган чын ярату, чын якынлык та яши иде бит. Турысын гына әйткәндә, Көлемсәрне яраткан хәтле ул үз гомерендә беркемне дә мавыгып ярата алмады. Ул аны хәзер дә сагына, бигрәк тә хатыны белән үпкәләшкән чакларында. Мондый чакларда Көлемсәр янына китәсе, ә китү мөмкин булмагач, аның кабере кырыена сузылып ятасы һәм шунда мәңгелеккә онытылып каласы килә. Ләкин менә әллә нинди сәер сәбәпләр аркасында шундый да кадерле кешесен ул үз янында саклап кала алмады, алай гына да түгел, тагын шул каһәрле сынау килсә, тагын да сакларга көче җитмәс иде. Менә шундый катлаулы сынау инде ул. Моның нәрсә икәнен белмәгән һәм белергә тиеш тә булмаган бала белән хәзер ахыргача ничек аңлашасың инде?
Уйларының күләгәсе бары тик чыраенда гына бераз чагылганын тойган хәлдә, Мирсәет бик гади генә:
— Мин аны хәзер дә яратам, — дип куйды.
— Куркак мәхәббәтегез белән... яраткан кешегезне... үзегез үтергәнсез, Фәрхетдин белән икәүләп... — Менә сиңа бала! Әллә фикерне

чырайга карап укый ала торган сәләте бар инде бу баланың? Бер нәрсә сөйләмәгән килеш барын да аңлады. Болай булгач, улы гаепле атасын бәлки әле гафу да итәр? Ләкин Тәбрикнең йөзендә әллә нинди, нәфрәткә охшаш ачу сөремләнә иде... Бер секундта шуны күреп, ата кеше улына «Зинһар, бүтән сүз өстәмә!» дигән ялварулы караш кына ташлады... Шуннан соң атасы да, улы да бер-берсен кызгангандай башларын күтәрә алмыйча тын утырдылар. Бүтән юньле сүз ишетмәсенә ышана башлагач, Тәбрик, ниһаять:

— Ярый, мин китим инде, — дияргә мәҗбүр булды.

Ата кеше үзе дә нәрсәнеңдер әле хәл ителмәгәнен сизсә дә, китмә дия алмады һәм ике-өч минуттан соң үзе дә кузгалды:

— Әйдә, заготскотка бергә барыйк та аннан соң мин сине шушы ат белән илтеп куярмын.

— Юк, мин үзем... кеше күрмәсен...

Болай дип ул юри, сынар өчен генә әйткән иде дә, тик атасы шулай тиеш дигәндәй кабул итте:

— Син безнең авылда кем улы икәнлегеңне беркемгә дә әйтмәденме?

— Беркемгә дә әйтмәдем.

— Ярый. — Улы тавышындагы мыскыллауны әллә сизмәде, әллә сизмәгәнгә салышты.

«Үзе әйбәт, үзе куркак! Фәрхетдин шәфкатьсез куркак булса, монысы — нечкә күңелле куркак. Куркаклык! Менә нәрсә үтергән икән минем әнине! Менә нәрсә!» — Шулай дип уйлады Тәбрик һәм ике-өч секундтан башына шундый фикер китерә алуына үкенә куйды: «Үз атасы хакында ничек уйлый ала бит кеше! Яхшымы, яманмы, ул бит — ата. Ә ата-ананы сайлап алмыйлар... Ата? Ә атамы соң ул? Минем атам шушы кешеме? Түгелдер, түгелдер, бөтенләй икенче кешегә ялгыш килгәнмендер... Ата! Әтием! Әтием! Үзенә шул сүзне әйттерергә курыккач, нинди ата инде син?!»

Ата-ананың үз баласын моннан да ныграк рәнҗетүе мөмкин түгеллеген Мирсәет гүя тоймый... Ә Тәбрик тамагына тыгылган әче төеннән арынырга тырышып басып тора. Мәңге онытылмаслык әче сүз эзли. Андые табылмагач, ул да түгел, шуның нәкъ киресен эшлисе, рөхсәт итмәвен онытып, әти дип, атасының муенына асылынасы килә... Ләкин...

— Ачуланма, Тәбрик...

Тәбрик борылды да тагын мыскыллы елмайды һәм:

— Юк, ачуланмыйм, хушыгыз, — дип китеп тә барды.

— Хат яз. Тик әти дип язма, яме?

— Язармын. «Әти» дип...

Ата кеше, көтелмәгән сүзләргә җавап тапмыйча, башын иеп калды. Күтәрелеп караса, улы тау артына китеп күмелгән, тау юлы белән ул күзгә күренмәслек ара үткән иде инде.

*

* *

«Әти дип язма!»

Келәнченең матурлыгын, юлдагы, кырдагы гаҗәеп төсләрнең берсен дә күрмичә, бар көченә йөгерә-йөгерә барды да барды Тәбрик. «Әти дип язма! Әти дип язма!» дигән сүзләр артыннан куып җитеп кадала килде.

Бу сүзнең мәгънәсе шул: кеше сизмәсен, тагын бер улы барын беркем белмәсен... берүк белә күрмәсен... Мескен, ай, мескен!

Китаплардан укыганча, кешеләрдән ишеткәнчә, ата кешеләр уллары белән горурлана, ә бу кеше хурлана! Шулай булып чыга, әйе, хурлана! Югыйсә, үзе исән чагында үз баласын приютка илтергә юл куйган, аналары аның хәлен дә белмәгән һәм белергә дә теләмәгән кеше ничек ата дигән бөек исемне йөртә алсын?! Тәбрик шулай ук хурланырлык баламыни?

Изге чишмәгә җителгән инде. Җан ачысы бераз басылмасмы дип, тагын кулларын-битләрен юды, тешләре чатнаганчы су эчте, ләкин җанны тутырган рәнҗеш кимергә чамаламый иде. Тора-бара хәтта изге чишмә үзе эчне пошыра башлады. Берничә көн элек сокланып караган чишмәгә бүген бакса, монда искитәрлек берни дә юк икән — нәрсә дип табыналардыр бу чокырларга. Бабайлар каберлеге, алар белән очраша торган җир, янәсе. Ата-баба йоласы. Син дә ихтирам итәргә, мәхәббәт белән искә алырга, үзең башланган суга һәм туфракка табынырга тиеш. Ә алар, ул бабайлар, Тәбрикне ихтирам иткәннәр микән соң? Уйладылар микән аның җиргә киләчәге һәм язмышы нинди булачагы турында?! Әллә алар да үз балаларыннан баш тартырлык дәрәҗәдә мәгънәсез булганнармы? Ә ни өчен ихтирам итәргә, ни өчен табынырга тиеш әле Тәбрик аларга? Үзләренең иң кадерле байлыкларын, йөрәк хисләрен түгел, хәтта телләрен, моңнарын да мирас итеп бирә алмаган ата-аналар хакына гыйбадәт кылу мөмкинме? Нәрсә хакына?

Ләкин менә бу чиксез тирән чокырның эче кемнәрнеңдер ихтирамлы, миһербанлы куллары салган акчалар: борынгы болгар көмешләре-алтыннарыннан башлап, бүгенге акчаларга хәтле булган тәңкәләр белән тулы, имеш. Туган туфракка хәер-доганы күпме бирсәң, шул хәтле әйбәт, һәм ул беркайчан да җитеп тә туктамый, дип өйрәтә Тугаш бабасы. Ярый, тагын күпмедер тиеннәр өстәлсен...

Шулай уйлап, кесәсенә тыгылган иде, акчасы юклыгы исенә төште. «Каһәр суккан, онытылган бит, онытылган — теге көнне салган иде бит бар булган вак акчасын. Инде сезгә минем бирерлек бер тиенем дә юк, шул кадәр дәрәҗәгә җитте оныгыгыз, һәм аның тиеннәренә сез лаеклымы, түгелме — анысы да билгесез».

Шул вакыт ерак чокырлардан кемнәрнеңдер ачулы чырайлары күренгәндәй тоелды. «Коеның төбендә — без, коеның төбе һәрвакыт чиста торсын, үзең дә начар уйлар һәм әйберләр төшермә анда».

Ләкин Тәбрикнең баягыдан да усалрак сүзләре юк түгел: «Ә анда инде шактыйдан җыелган алама нәрсәләрне кая куярсыз? Фәрхетдин абыйны, үзенә эти дияргә рөхсәт итә алмаган Мирсәет дигән кешене кая куярсыз? Суга төшкән мәчеләрне күңелгә күчереп саклау фарыз түгелдер ич?»

Җавап итеп әллә Тәбрик, әллә төпсез коедан туган җир үзе эндәшә: «Әгәр халык эчә торган суга начар әйбер төшсә, син аны ничек кенә итсәң дә ал, калдырма, кое чиста булсын, халык эчә торган суны син дә эчми кала алмыйсың — мәңгелектән килә һәм мәңгелеккә агачак бит ул су!»

Ләкин Тәбрик нишли ала? Атасы да, анасы да табылмаган төшне туган җир, туган туфрак дип ничек атый алсын ул? Юк, аның туган җире юк, юк һәм Тәбрик моннан иртәгә үк башка җирләргә китәчәк.

Катгый карарга килеп, әле бер-ике көн элек кенә үзе ялынып дигәндәй төзәтергә рөхсәт алган корыч чишмәгә күз дә салмыйча, бая гына тешләре чатнаганчы эчкән тере чишмәгә караш та ташламыйча, ары китте бала.

*

* *

— Ни булды, улым?

Күзгә күренү белән шул сорауны биргәч, Тәбрикнең кыяфәте һәм хәле әйбәт булмагандыр инде...

Тәбрик башын гына иде, берни дип тә җавап бирмәде. Шуннан соң бабасы, бүтән сорау белән йөдәтмичә, өйгә чакырды — бик вакытын белеп кайткан, мактап кына йөри икән улы, бик әйбәт, бик хуп...

Сөембикә апа белән Гөләндәм дә шундый ук мактау сүзләре һәм гадәттәгечә якты чырай белән каршыласалар да, Тәбрик аларга да ел-

мая алмады. Хәлне төшенгән гаилә кешеләре бары тик кайгыртулы карашлары белән генә ярдәм итә алалар иде.

Өй эссе булганга күрә, кичке аш бакчага чыгарылды. Беренче итеп бабай өстәлгә түгәрәк ипи, аннары зур графин белән чия суы тәсле эчемлек китереп куйды.

— Менә өлгерде, кадерле кунакка коела торган өй сырасы. Касәнең дә шәбен генә сайлап бирим әле.

— Кунак килер дә китәр, безне онытма, — дигән булып шаярта Гөләндәм.

Әмма андый шаянлыктан гына Тәбрикнең кыйналган күңел сызлавы һич тә узарга чамаламый шул.

— Китмибез без, улым, шулай бит? Китмибез. «Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарыбыз, һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарыбыз». Шулай бит, улым?

— Бөтенесе аңлашылды, бабай,— дип, ниһаять, елмаерга мәҗбүр булды Тәбрик.

Аңлашылмый торган мәгънә конкрет эчемлек белән алмашынгач исә тагы да күңеллерәк булыр әле, янәсе.

— Менә шушы бер йомры максыманы бушатып куйсаң, аңлашылмас нәрсә калмас. Ягез әле, миннән үрнәк алыгыз.

Карт эчкәч, бүтәннәр дә ялындырмады һәм тора-бара чынлап та кәеф бераз күтәрелгәндәй тоелды. Башка хәмер куәте менгәндәге кебек түгел, ничектер җиңел һәм рәхәт, сау һәм саф иде бу күтәренкелек. Шуңа күрәдер инде, бабай бая җайсызрак тоелган сорауларын да кузгатырга мөмкин санады:

— Я, нәрсә ди инде «әти» дигән кеше?

— Минем әтием юк,— Тәбрик бу юлы да баягыча елмаерга тырышса да, күзләрендә әйтеп аңлата алмаслык әрнү генә ялтырады. — Миңа инде китәргә кирәк, бабай.

— Китәргә? — Монысы Гөләндәмнең куркып кычкыруы иде.

— Әйе, иртән үк.

Бабалары исә, аптырашта ук калып, бераздан гына телгә килә алды:

— Әнкә рухын рәнҗетү — тәүфыйксызлык. Сиңа гомер биргән җирең — туган анаң...

— Гомер биргән дә... Ул гына җитми икән бит кешегә.

Карт мондый ук борылыш көтмәгән иде, билгеле. Тагын каушады. Бер дә юктан торып басты һәм яңадан утырды. Җилкәләрен кашып интекте.

— Әйе, шул,— диде, ниһаять, зиһенен яңадан җыеп,— без гаепле. Кулдан бала ычкындыру — ата-баба ялгышы. Әмма да бердәнбер көнне син кем дип сорасалар, ни дип җавап бирерсең?

— Сорамаслар дип беләм, бабай.

— Сорарлар, сорамый булмый ул. Һәм юкны сөйләмә дә, беркая җибәрмим мин сине.

— Ачуланма, бабай.

Гөләндәм исә беркатлы — киеренкелекне бетерер өчен төрле кыланышлар белән әле Тәбриккә, әле бабасына күз кыскан була:

— Алып батыр малае, тәүфыйксыз, нишләп алай бабаңны рәнҗетеп, шушы матур җирләрне дә ярата алмыйсың син, ә?

Бабайның кәефе кырылса да, өмете бөтенләй үк өзелми иде әле. «Тормыш кәрт уены кебек, иң читен чакта уен тузы коткара», дип тынычландырырга тырышты ул үзен. — «Уен тузы... нәрсә соң әле ул уен тузы? Бармы соң ул? Бар бугай, бөтенесен үзгәртә торган көчле фикер...»

— Син дә шул, улым... Вәгъдә иткән эшеңнән, халыктан качып китәсеңмени инде... дезертир шикелле?..

Карт крестьян ялгышмады — яшь солдат бу сүздән сискәнеп китте, үз колагына үзе ышанмыйча кабат сорарга мәҗбүр булды:

— Нинди дезертир, нинди халык?

— Менә шушы сырага катнашкан изге суны... ничек тәмле бит, ә? Шуннан да тәмләрәген, кирәгрәген авыл халкына бүләк итәргә вәгъдә бирдең түгелме соң?

Әх, менә ничек! Тәбрик үз хәсрәте аркасында бу хакта бөтенләй оныткан лабаса — үз мәнфәгатьләре белән мавыгып, халык кайгысын оныткан! Кайтканнан бирле үзен кунак итүче, ата-анасы бирә алмаган сый-хөрмәт һәм якынлык, туганлык хисләрен сиздерә, аңлата торучы шушы эчкерсез һәм искитмәле садә кешеләрнең өметләрен алдап, аларны һаман шул шикле коедан су эчәргә калдырып, вөҗдан үзе биргән эш-бурычыннан качмакчы булган ул! Әйе, Тәбрикнең әнисе каршындагы әхлакый бурычларын үтәүдән, үз бәхетләреннән ялан аяк качкан үги һәм туган әтисе кебек үк, Тәбрик тә туган җир алдындагы бурычыннан качып дезертирлык итәргә җыенган. Рәхмәт, бабай. Хәтергә төшердең. Югыйсә, синең онытын да киләчәктә Мирсәет һәм Фәрхетдин атлы кешеләр кебек үк мескен хәлдә калмас идемени?

Бабасына оныгы бу фикерләрнең берсен дә әйтә алмады, билгеле, ләкин кыска гына җавабы да өйдәге өч кешенең чыраен берьюлы яктыртып җибәрде:

— Ярый, бабай, сезне сусыз калдырмам.

— Менә, ичмасам, сүз!

— Сырасы бигрәк тәмле — эчик әле.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

Кичке табигать, кичке утлар, егет белән кыз шикелле, ахрысы, күзгә-күз карашып сөйләшәләр.

Әллә нинди мәгънәләр рәхәт җил шикелле кагылып, күңел дигәнеңне билгесез ераклыкка чакыра. Тын һәм моңсу үзәннәрдә кичке утлар, төнге учаклар гашыйк йөрәкләргә әллә ниләр аңлата — узган көннәр хакында, алардан да бигрәк киләчәк бәхетләр хакында хәбәрләр китерә.

Тауларга мен дә кара — чиксез үзәннәрдә утлар, утлар, утлар. Күктәге йолдызлар санынча! Бу җирләрдән аерылгач, төнге аяз күкләргә, галәмнәргә карарсың да, төнге үзәннәрдәге шушы утлар җемелдәвен күрерсең...

Әллә инде элек диңгез шаулаган монда, әллә язларда Идел җәелеп ташыган — ни булса да барыбер, су урынында хәзер нур агыла. Ага да ага чиксез яктылык — гомер кебек, тормышның үзе шикелле.

Чиксезлек һәм яктылыкларның бөтенесе бергә туган җир дип атала.

Туган җир балага ана күзләре белән карый — үз баласына ягымлы һәм назлы тойгыларын кичке утлар рәвешле итеп сирпи туган җир.

## Сау бул, туган җир!

Акылга сыймаган фараз һәм теоретик исәп. Кайсы әйбәтрәк шуларның? Билгеле инде, исәпсез ерак китә алмыйсың — бөтен ачышларның нигезе исәпкә корылган дисәк — ялгышмабыз. Ләкин ачышлар кайвакыт бөтенләй исәпләмәгән җирдән дә, көтмәгәндә дә килеп чыга.

Аспирант егет күрә алмаганны урта белемле кеше күрә алса... әнә шундый кешелек сыйфаты хакында уйланыр җай бар бугай. Болай ачышлар хакында фикер әйтә алыр кеше хәзергә Үзәнбайда күренмәсә дә, уйламыйча гына дөрес бәяне бирүчеләр булды, әлбәттә.

Әгәр Тәбрик мәче төшкән коены күрмәгән булса, скважина белән дә шундыйрак хәл килеп чыккандыр дип фараз итә алмас иде ул. Һәм менә шаярып кына әйтелгән фикер аспирант егетнең бөтен исәпләрен

бәрде дә екты. Монысы бәлки бераз арттырудыр инде, ләкин хәлне бөтенләй үзгәртеп ташлавы берсүзсез хак. Билгеле, Тәбрик үз сәләтен ачыклау түгел, иҗади психологиянең нәрсә икәнен ишетә дә белми әле. Әмма колхоз председателе, үзе әйтмешли, кара акыл белән ачышка бик дөрес бәя бирде һәм кызыклы тәкъдим ясады... Ярый, монысы соңрак эшләнде, хәзер тәртип беләнрәк сөйләргә тырышыйк.

Вәгъдә ителгән ике кран урынына берәү генә килеп, аның гына көче җитмәс, чыгыр юкмы дип кызыксынгач, анысын авыл машина паркыннан таптылар. Килгән кран һәм табылган чыгыр белән тарттыра торгач, артык карышмыйча гына, скважиналар суырылып та чыкты. Һәм Тәбрик кушканча, кире яклары белән күтәртеп карасалар, скважиналардан шалтыр-шолтыр таш коела башлады... Тәбрик үзе дә сизмәстән шаркылдап көлеп җибәрде:

— Карагыз, иптәш председатель, тартынмагыз. Нәрсә бу? Коега мәче салганнар дип кем әйткән иде сезгә?

— Әмма да бит... болар бит, күзем ялгыш күрмәсә — таш.

— Кешеләр кылган аламалык тора-бара ташка әйләнә ул.

— Минем бөердәге шикелле... Кем эше булыр бу, мондый да явызлыкка кемнең куллары бара алды икән?

— Бәлки явызлашып түгел, шаярып кына эшләгәннәрдер әле. Бәлки әле скважинага таш тутырып балалар уйнагандыр.

— Мәгънәсез шаяру!..

Бераз суккалагач та торбалардагы таш тәмам коелып бетте. Краннар торбаларны икенче башыннан күтәргәч тә председатель зарланудан туктамады:

— Нинди пүчтәк нәмәрсә аркасында ничә ел сусыз интектек.

— Коегызга мәче төшмәгән булса, бәлки бу юлы да башка мондый уй килмәгән булыр иде әле.

— Син кайтмаган булсаң, меңәрләп төшсә дә, безнең баш җитмәс иде моңа.

— Кызганычка каршы, бернинди баш кирәк булмады.

— Әйе, шул, бик кызганыч һәм адәм көлкесе.

Скважиналарны урынына утыртып цементлагач һәм икенче көнне насосныйга мотор да китереп куйгач, гөжләп су да киткәч, председатель бөтенләй телсез калды. Бер мәгънәсезгә буталып озак йөргәч кенә Тәбрик аркасына кулын куйды:

— Кал безнең авылда, колхозның баш инженеры итеп куям мин сине.

— Урта белем белән баш инженер?

— Белем белән генә түгел ул, әллә нинди белемле кешеләрдән дә бернәрсә чыкмый кайчак. Ну, шул аспирант килсә? Юк, бу эшне аңа тапшыра алмас идем мин. Белгән генә түгел, уйлый торган баш кирәк моңа. Аннары килеп, урта белемле кешегә шундый эш бирерлек булгач, ни өчен сусыз интегүебезнең сәбәбен дә төшенгәнсеңдер инде.

— Үземә белем кирәклеген дә төшендем.

— Алайса, сельхоз институтка гариза җибәр, колхоздан стипендия түләп укытырбыз. Ул белем белән син әйткән нефтьтә дә эшләп була, инженер кайда да үз дәрәҗәсен төшерми ул. Ризамы син шуңа?

— Уйларга вакыт бар бит әле.

— Уйла давай, бетте. Мин хәзер торбалар кәсебенә керәм. Хуш хәзергә. Бетте.

Корбан абыебыз, су шатлыгы һәм торба гаме белән канатланып, кыска тәпиләре белән теркелдәп кенә машинага утырды да китеп барды. Тәбрик өйгә кайтып барысын да сөйләгәч, Тугаш бабасы аннан һич ким сөенмәгәндер. Бәлки арттырыбрак та җибәргәндер әле. Председательнең нинди тәкъдим ясаганын белгәч исә, күзләрен үк сөртеп куйды:

— Акыллы кешедән акыллы сүз чыга, бик дөрес, бик тә шәп әйткән.

Торбалардан чыккан ташларга исә бабай икенче төрлерәк бәя бирде:
— Авылны туган күрергә кирәк, балам, яратырга кирәк, аның үз кешесе булып кайгырту кирәк. Теге Аспиран атлы егетне әйтәм. Башсызлыктан түгел ул, һич аннан түгел. Әгәр авылыбызның үз кешесе булса иде ки, ничек итсә итәр, сусыз ташлап китмәс иде. Чит-ят кешенең йөрәге сызламый безнең өчен, вәт менә шуның өчен дә башы житмәгән аның. Ә син безнең үзебезнеке булып чыктың, болай булгач, үз улыбыз. Бөтен авыл хәзер икеләнмичә улым диячәк сиңа.
— Дәү әти, артык мактап та жибәрмә, бер чакрым торба сузасы бар бит әле.
— Анысына калгач булыр инде, алла боерган булса, су чыгару кодрәтенә ия кеше анысын гына эшләр ул.
Икенче көнне үк, кояш нурларын жиңеп дигәндәй, авыл өметләре төсле матур жемелдәп, басу капкасы төбендәрәк электросварка очкыннары чәчри-сибелә башлады. Шул төштә әллә нинди пыялалы башлыкмы, калканмы кигән егетне Тугаш карт үзе чын итеп сөйләргә яраткан Алып батырның нәкъ үзе бу дип, күренгән бер кешегә горуранә сөйли торды. Торбага торба ялгана, көнгә көн тоташа торгач, Тугаш бабай күрсәтергә вәгъдә иткән бәйрәм дә сиздермичә генә килеп житте. Тугаш карт шулай кадерле оныгы өчен хәтта кулдан килмәгәнен дә эшләмәкче. Тәбрик өчен жанын бирергә әзер торган шушы кешене — дәү әтисен ташлап китү жиңел булмас, билгеле. Ләкин эти дигән нәрсә... ул булмагач, күңел монда барыбер тулы булмаячак. Үзлегеннән нәтижә килеп чыга: торбаларны тәмам тоташтырып бетергәч тә Тәбрик китәчәк. Китәчәк һәм, ихтимал, бүтән бер дә кайтмаячак.

*

* *

Ә бүген Тугаш бабай бәйрәме.
Алдан сөйләшенгәнчә, атлы-арбалы бер агай дөбердәп килеп тә житте. Арбадагы ямь-яшел печән өстенә сыра мичкәләрен жайлап урнаштыргач, иң алга Гөләндәм белән Сөембикәне утыртып, уен-көлке белән шаулашып, китеп тә бардылар. Барысыннан да бигрәк Гөләндәм шат, барысыннан да бигрәк ул киенгән, ул бизәнгән.
— Эх, кызым, маладис, прәме минем карчыкның кыз чагы, суйган да каплаган. Нәкъ инде менә айдан төшкән кебек!
— Чабыр булгач, чабыр булсын инде, дидем. Синең карчыкка да бик ошыйсым килде. Кулга дисбе генә таба алмадым әле.
— Шаяртма бик, минем карчыкның да кыз чагы булмаган дисеңме әллә?
— Юк, юк, булмаган, булмаган, мин генә яшь, мин генә бер генә.
— Анысы хак — бер генә, дөньяда бер.
Дөньяда бер генә булган кыз ак яулыгы астыннан кабарып торган чәчләре өстенә кечкенә кара калфак куеп алган. Энжеләре — йолдыз жемелдәүләренең бизәккә әверелеше. Кояш нурында бигрәк тә матур елкылдый, кызның бәхетле карашы белән бергәләп, дәртле көн, якты көн аклыгын арттыра. Кызның бу матурлыгына оныгының да сокланып каравын тойган карт икеләтә бәйрәм кичерә — барысы да ул теләгәнчә бара, алла боерса, ул теләгәнчә. Картның шатлыгы авыл буйлап яңгырый:
— Жыенга рәхим итегез, туганнар, чабырга, чабыр тавына, әйдәгез, әйдә! Бөтен тирә-як жыела, бөтен нәсел-ыру килә, соңга калмагыз! Әйдә, малкай, фью!..
Сызгыруы гына рәтле чыкмый икән дә, ярый инде. Теш юклыгы сиздерә, хәерсез...
— Әйдә, Гыйльметдин, жырлап жибәр син дә, балык сыман өнсез бирма, Сөембикә, сыздыр, Гөләндәм, жырла — Тәбрикнең исләре китсен.

Һәм үзе башлап та җибәрә:

Атларыбыз пар иде лә,
Киң урамнар тар иде.
Киң урамнарны тар итеп
Йөргән чаклар бар иде, һай, һай-лай!..

Көен кем белсен, әмма сүзләре шәп ишетелә. Хәтта мокыт кучер да телгә килерлек булды:

— Бар иде бугай шул, бар иде бугай.

— Сезнең җырлар искереп-тузып беткән инде, бабай, безнекеләр бүтәнчә.

— Әйдә әле, кызым, бүтәнчәсен, яле.

Ул да түгел, Гөләндәм бу кояшлы иртәдән яктырак һәм сафрак тавыш белән җыр башлады, аңа әнисе дә иярде:

Актаныш таңнары,
Ул минем йөрәк серемне аңлармы...

Бабалары монысын да үзенчә юрамый калмады:

— Аңлар, аңлар, аңлатырбыз. Аңлата алмый калсак, изге чишмә суын эчү хәрам булыр безгә.

Коры елганы чыккач, Ямәкигә кермичә, Бәкигә борылдылар, һәм уен-көлке белән мәйданга барып җиткәне сизелми дә калды. Тукталган җир, әлеге дә баягы — изгеләр чишмәсе иде. Тик Тәбрик җыенның ерак елларда ни өчен нәкъ шушы җирдә үткәрелүен хәзер генә төшенде. Чишмәләр тау буенда. Таулар әйләндереп алган үзән исә — табигать үзе ясаган арена: бөтен Тау иле килсен дә бәйрәм итсен — көрәшсен, йөгерешсен, ат чабыштырсын, кәмит әйләнсен, җаны ни тели, шуны кылансын. Һәм кыланганнар да — гасырлар буе Тау ягы кабиләләре шушында нәсел җепләрен бәйли килгәннәр. Соңгы елларда гына гореф-гадәтләр үзгәреп, бәйрәмнәр дә бүтән төрлегә әйләнгән. Тугаш бабайча әйтсәк, ташлаганнар изгеләрне, онытылган изгелек җирдә...

Арбаны карт чак кына үргәрәк тарттырды да сыра мичкәләрен төшерергә кушты. Самавардан зуррак ике мичкәне «ә» дигәнче ямь-яшел чирәмгә куйгач, селкенеп җан кыймасын дип, бабай аларның астына ике яклап печән тутырды һәм, вак-төяк шөгыль беткәч, җиргә аяк бөкләп утырды да хозурланып бер кычкырып җибәрде:

— Һай, дөньялар, бу көннәрне дә күрергә насыйп булган икән! Узган бәхетләр тагын кайта икән ул. Я, кызым, Сөембикә, бир әле чынаякларны.

Сөембикә гөлҗимеш сурәте төшкән дүрт пар чынаяк алып тезгәч, карт аларның барысын да тутырып, берсен үзе эчте дә бүтәннәрне кыстарга кереште:

— Өй сырасының нәрсә икәнен белеп калыгыз, үзегез дә ясарга өйрәнегез. Мәгез әле.

Мактый-мактый ике-өч йомры бушаткач, кучер агай, эш бар дип, вакыты җиткәч килеп алырга вәгъдә биреп, үз юлына китте. Ә бәйрәм калды. Барыннан бигрәк Тугаш карт үзе сайрады, үзе кинәнде. Көенең ниндилеген кем белсен, әмма сүзләре аермачык:

Борын-борында, иген кырында
Җырлый өздереп кыз белән егет
Бәхет турында.

Җырлыйлар алар — аерылмас ярлар,
Шул чак ук атып, гөрзи уйнатып,
Килгән ят яулар.

Җыр гөнаһ икән... Яңгырамас бүтән:
Атлы явызлар егетнең, кызның
Телләрен кискән.

Тик иртә-кичтә тынмый җыр һич тә:
Әверелгән шунда егет былбылга,
Кыз — гөлҗимешкә.

Сандугач-егет җырлый өзелеп,
Гөләп-чәчәккәй сөюен әйтә
Хуш исләр сибеп,
Хуш исләр сибеп.

Гөләндәм белән Сөембикә җырны тыңлаганда моңаеп кала, ә Тәбриккә барыбер...

— Бабай, син ни укынасың алай? — дип сорый ул, бер дә исе китмичә генә.

— Мин ни... дога кылдым, балам, синең бәхетең-тәүфыйгың өчен. Теләкләр теләдем, ходайдан ялвардым — рәхәт яшә, дөньяның барлык матурлыгын күр, алыплар туган җир намусына тап төшермә.

— Слушаюсь, товарищ бабай... шулай эшләрбез.

— Рәхмәт яхшы сүзеңә, — дип, бабасы тау буендагы беленер-беленмәс калган курганнарга күрсәтте.— Әнә теге урларны күрәсеңме?

— Юк.

— Ул чокырлар — борынгы бабайларыбыз авылы, шуның эзләре.

Авыл дигәне — кола ялан, ә җыен дигәне? Анысы кайда? Әллә инде бабасы Тәбрикне юк нәрсә белән чынлап ук мавыктырмакчы?

Әһә! Чабыр дигәне Тугаш бабайның хәтерендә шаулый һәм ул аны бүтәннәр өчен дә шулай ишетелә дип белә, узган хатирәләр аның күзләрендә очкыннар булып уйный, йөзендә шатлык булып балкый — нәкъ аяз күктәге июль кояшы шикелле. Хәтта кояштан да алдарак күтәрелеп, күк түбәсендә зәңгәр төс булып җемелди.

Кытайский әфлисуннар
Килә икән яшниктә.
Картайгачтын үкенерсең,
Әйттереп кал яшьлектә, һай!..

Сыралы чынаягын чиратлап Гөләндәмгә, Сөембикәгә һәм Тәбриккә бирә дә, тегеләре ялындырмый гына чөмергәндә, карт тантана итә:

— Кыланып калыгыз әйдә, чабыр елына бер генә килә ул.

Сыра ләззәтенә чыдый алмыйча мәзәк ымлыклар чыгарып, телләрен шартлатып куя, мичкәләренә шап-шоп суккалый, сакал-мыегын сыпыра. Сакал-мыегын сыпыра да күз кыса — запас, янәсе, биниһая. Ихлас шаянлык, ихлас чаялык, ихлас бәхет. Шушы кадәр дә бәхетле була ала икән кеше! Әйтерсең аңа житмеш сигез яшенә җиткәнче югала килгән барлык бәхет-шатлыкларын берьюлы кайтарып биргәннәр дә, ул шуларны сыра рәвешендә чөмерә.

— Менә күрерсез әле туганнарыгызны, якташларыгызны — прәме бөркетләр алар, бөркетләр!

Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы...

Әмма, хикмәт, җыен дигәне һаман дүрт кешедән артмый шул, бөркет түгел, ябалаклар да күренми хәтта. Шуны сизенеп, мөгаен, кояш кызуы арткан саен бабайның чырае әкрен-әкрен сүрелә, төссезләнә, ә соңынтын караңгылана ук башлады. Шук сүзләре сирәгәя, тора-бара бөтенләй тына куйды. Хәтта үзенә сүз кушканга ук үртәлә һәм авыз эченнән мәгънәсез сүзләр мыгырдана башлады:

— Егылып үлгерләре!.. Сезнең белән шул буласы билгеле иде инде аның... сезгә ышанган мин тиле...— Кемне тиргидер — әйтүе кыен.

Балалары елмая гына. Аларга нәрсә! Аларга барыбер — күптән онытылган, ерак заманнарда калган бәйрәмне кайтармакчы булып тырышкан картның өметләре зәңгәр рәшә төсле күккә очканны сизә

торып, карт күңелнең сары балчык рәвешле кибеп яргаланганын күрми дә, күрергә дә тырышмыйлар.

Гөләндәм бигрәк тә авызын ера:

— Кала кешеләре гел шушылай табигать арасына чыгып ял итә. Менә дигән ял булды, бер дә хафаланасы түгел, — дип, бабасын тынычландыра, янәсе. Ә фактысын китереп әйтсәк, мыскыл итә.

Ике-өч сәгать түзем белән генә көтте карт, әмма офыкта беркем күренмәде, дүрт, биш сәгать түземсезләнеп көткәч тә, кара нокта да күзгә чалынмады. Карт, аптырагач, чал башын ашъяулык астына тыгып ятты. Беркемне көтми, ял гына итә, имеш... Ә шулай да, бермәлне ерактан машина гөрелтесе ишетелә башлаган иде, дерт итеп сикереп тә торды һәм баягы саф көлүе белән балкып, кеткелдәргә дә тотынды:

— Әйттем бит мин сезгә киләләр дип. Бөтен тирә авылларга үзем барып игълан кылдым ич. Бармаганнарына кешеләр аркылы хәбәр иттердем. Нишләп килмәсеннәр, киләләр. Уракка төшү мәшәкатеннән соңга гына калганнар безнең туганнар. Әнә, Алып батыр ыруы корымаган әле — әнә ничек җырлап килә, күрәсезме? Изге чишмәләр дә чылтыр-чылтыр каршылый. Аларның беркайчан да корыйсы юк, алла боерса, гомер бакый.

Бабай артыннан ияреп, балалары да машинаны каршыларга юл буена ук чыктылар. Җыр һаман көчәя, машина гөрелтесе һаман сөенечлерәк була барып, кешеләрнең инде төс-битләре дә ачык күренә башлады. Машинада яше-карты җыр сузмакта:

Ак калфакның табылган чагы,  
Туганнарның сагынган чагы...

— Ишетәсезме, балалар, безнең җыр, безнең туганнар...

Бабай сабыйларча самими сөенә, хәтта бүтәннәргә кызганыч булып китә... Тик әнә бәйрәм килә, мәйданга шаулап җыен килә — Тугаш карт эссе кояш нурында түгел, шул шатлыкта коена. Ниһаять, бәйрәм белән ара — күп дигәндә илле, кырык метр, юк, аннан да кыскарак — ун, биш... өч метр калгач... узды да китте машина. Узды да китте бәйрәм, узды да китте җыен. Аңламый, абайламый да калдылар. Ни булды? Үзәнбай авыл клубы мөдиренең шул машинадан:

— Бәйрәм клубта була, шунда барыгыз — концертка! — дигән сәер сүзләре генә акылга керә алмыйча үзән өстендә чайкалып юкка чыкты. Клубта нинди чабыр инде ул?

Бабай һушыннан язгандай үзалдына лебер-лебер сөйләнергә керешге:

— Әртист булып чыктылармыни? Безнекеләр түгелмени? Ә безнең кунаклар кайда? — Еламый гына.

— Ул хәтле кайгырма әле, бабай, кайда булса да барыбер түгелмени? — дип юаткан була Сөембикә.

Юк инде, баягы шатлык-сөенечләр җилләр булып очкан — иреннәре үк калтырый картның. Аңардан да кайгылы, аңардан да хәсрәтле, аңардан да бәхетсез кешене дөньяда табу да кыендыр бу мизгелдә. Мичкәләрен кочаклады да исерек кеше төсле бер хәрәкәтсез, ким дигәндә, ярты сәгать ятты.

Басуларда бытбылдыклар, тургайлар бәйрәм итә, кояш баягыдан да яман кыздыра, тирә-якта мотор тавышлары... Машиналарга төялеп, күрше авыллардан да концерт карарга киләләр, ахрысы.

Шуны төшенеп диярсең, бабай башын күтәрде:

— Ичмасам, Гыйльметдин олакты. Гөләндәм, бар булмаса фермага, тизрәк килеп алсын, юньсез.

— Хәзер, бабай, алып киләм. Курыкма, кырда кундырмабыз.

— Миңа кырда калсам ни... Менә мичкәләр җәл.

Сәгать чамасы да вакыт үтмәгәндер, Гыйльметдин дигәне шалтыр-

шолтыр килеп тә житте. Артыннан ияртә килгән эте әлсерәп телләрен чыгарган.

— Бер дә бушамаган әле мичкәгез. Әллә гүпчи дә сата алмагансыз инде? — дип. Гыйльметдин мичкәне кәчкә күтәреп салды.

Икенчесен Тәбрик илтеп куйды.

— Сату дисең. Бушлай әчүче дә табылмады. Адәм рәтле кеше калмаган икән инде бу дөньяда, беткән Алып бөркетләре, югалган. Берәве генә дә килеп чыкмады. — Шунда карт үзенә гажәпләнгәндәй карап торган маэмайга күз төшерде.— Мин дә синең кебек үк телемне асылындырып идем дә, оялам гына, — дип куйды.

Әмма кыстасалар да, арбага утырмады.

Кайта торыгыз, минем изгеләр белән сөйләшәсем бар әле...— диде.— Олы урамнан кайтмагыз, шыпырт кына тыкрыктан төшегез...

Шулай да кич Гөләндәм белән Тәбрик клубтан кайтып керә-керүгә концертны мактарга тотынгач, колхоз председателенең агитбригаданы Тугаш бабай үтенечен искә алып чакыруын да сөйләгәч, картның кәефе чак кына күтәрелде дә шикелле.

— Ярый, улым, үзегезгә ошагач бик әйбәт. Тик мин тагын да күңелләрегезне күрсәтмәкче идем шул.

— Бабай, «Идел сюитасы» дигән биюләре нәкъ син әйткән дуслык бәйрәме инде. Чабырыгыз сәнгатькә күчкән — болай булгач, мәңгелеккә әйләнгән, бигрәк тә шәп бит инде ул, бабакай, ә?

— Эһе-эһе...

*

* *

Ай чамасы вакыт үткәч, скважинадан ике чакрымга сузылган торбалар, су колонкалары авыл кешеләренең капка төпләренә үк килеп туктады, ферма каралтыларына таралды — барлык терлекләр якын киләчәктә су белән өзлексез тәэмин ителеп торачак дигән сүздер бу. Шулай итеп, Тугаш бабай гомер буе хыялланган изге чишмәгә табынасы калмады бугай — ул авылга үзе килде дә инде, үзе кеше акылына мәдхия төслерәк чылтырдый башлады. Һәрхәлдә, Тәбриккә шулай тоела иде.

Ә мәче төшеп интектергән хәерсез коены инде мәңгелеккә күмәр чак житте...

Билгеле, Тәбрик тыныч җан белән китә ала инде хәзер. Һәм китәчәк тә. Әмма юлга җыенып бетте дигәндә, тагын бер җитди эше барлыгын төшенде: әнисе кабере шушы көнгә чаклы чардугансыз икән.

Иртәнге ашны ашагач, Тәбрик дәү әтисенә зиратка барырга тәкъдим итте. Гөләндәм, «мин дә барыйм әле», дигән иде, бабалары этәчкә кычкырганнан да катырак итеп кырт кисте:

— Йөрмә каберлеккә шайтан җыеп! — диде.

— Дәү әти, я инде, әллә ниләр сөйләмә.

— Бер дә әллә ни түгел — бер кыз-хатын артыннан йөз шайтан ияртә ул.

Бабай белән бәхәсләшүнең файдасызлыгын аңлаган яшьләр көлештеләр дә — шуның белән бетте. Дүрт баганалык агачны бәләкәй арбага салып бәйләгәч, икәүләп зиратка киттеләр.

Зиратка җитү белән карт гадәтенчә нәрсәдер укына-укына озак кына басып торды, аннары монда кемнәр ятуы, аларның нинди кешеләр булуы хакында сөйләп китте. Барысы да яхшы адәмнәр, урыннары оҗмахта булсын. Яман кешеләр исәннәр арасында гына була икән...

Чардуган кору ярты көнгә сузылды. Эш арасында Тугаш карт Тәбриккә таныш булмаган чит сүзләр кушып сөйләнә-сөйләнә, әллә нинди сәер тавышлар белән көйли-көйли, һаман моңайды. Ә соңынтын авыл тормышының, җир кешесенең бер яктан искиткеч гади, икенче яктан

карасаң, баш җитмәслек хикмәтле, фаҗигале икәнен, озак кына тавыштынсыз калып, тагын да тирәнрәк аңлата төште. Бу гадилек — җирдән башланган тереклектер инде, бу катлаулылык — җирдән яралган шул тереклекнең бүген яшәп ятуы һәм киләчәктә дә яшәп ятачагыдыр. Баш җитмәслеге — менә кемнендер синең баш очыңа килеп, тагын кемнендер моңаеп утырачагыдыр. Картка хәтта шул көн үзе үк ирешә алмаслык хыял төсле тоеладыр. Аның ыруыннан исән калган бердәнбер егет тә читкә китеп барса, кем килеп моңаер аның баш өстендә, кем килеп чардуган корыр? Гөләндәм балаларымы? Юк, әйтә алмыйм. Ай хода, үзең сакла, үзең ярлыка!

— Вакыт җиткән икән инде, дөнья белән бәхилләшер чак җиткән икән. Сиксән сигез ел ничек гамьсез яшәлгән!

Шулай да карт үз акылы белән килешеп үк бетми әле — изгелек бөтенләй үк юкка чыкмас, аталар догасыз калмас, баш очыбызга, ничек кенә дисәң дә, бер килеп егылыр әле балалар, дип өметләнә. Аның өчен аталар һәм бабалар үзләре исән чагында кайгыртып калырга тиеш икән. Тәбриккә ул шуңа күрә олы түземлелек белән аңлатырга тырыша да бит инде. Тырышлыкның файдасы тидеме, юкмы, әллә үз башы белән генә шундый да кешелекле фикергә килдеме — менә бала анасы каберенә чардуган корырга килде бит, беркем кушмыйча гына агач утыртырга да кайтыр әле бәлки, ходa боерган булса. Хәзер булмаса, соңыннан төшенер. Менә Тугаш карт, дөнья бетереп, дөнья иңләп йөргәндә, үзе дә этисенә рәшәткә тотарга уйламаган — бүтән вак-төяк мәшәкатьләр артыннан куып, гомер кичкәнен сизми дә калган. Ә хәзер... соң булса да уң булсын. Иншалла, Тәбрик тә бер килер әле авылына. Килергә насыйп итсен, рәхмәтеннән ташламасын тәңресе.

Ана кабере өстенә өр-яңа чардуган торып басты. Инде китәргә вакыт. Көрәкне, чиләккә салып, балта-чүкечне Тәбрик күтәрде, бәләкәй арбаны бабасы өстерәде. Кайтышлый, юк-бар сүз арасына кыстырып, карт янә үзен борчыган сорауны кузгатты:

— Улым дим, шулай да ник китәсең әле син бездән?

— Эшләргә вакыт. Гел кунаклы уйнау килешмәс.

— Юк, улым, бер дә уйнамадың син. Муен нык булгач, камыт табылды — әнә нинди могҗиза эшләп ташладың.

— Институтка бармый ярамас, ахрысы, председатель дә бик каты димли.

— Авыл инженерлары әзерли торганынамы, әллә һаман нифтенеке дисеңме?

— Шушы көннәрдә хәл итәм инде, бабай.

— Безнең янга кайтара торганы шәбрәк булыр, балам, ныграк уйла, яме.

*

* *

Кич.

Авыл өендә — электр уты, кызык, күңелле. Бүгенге шул яктылыкта карт белән оныгы ерак үткәннәргә сәяхәткә китә. Ник? Бүгенге матур тормыш кына нишләп җитми әле кешегә? Нигә кирәк аңа үзе яшәмәгән борынгы заман, нигә хаҗәт аңа үзе яшәмәячәк килер заман? Адәм баласына өч заман бирелгән кирәк шул, бирелгән.

Сәяхәт дигәннәре — өстәлдәге кечкенә китап, китаптагы кәкре-бөкре сүзләр, рәсемнәр.

— Улым, шушы инде атаклы шәһре Болгар. Шушы ташпулат — кемнәр өчендер салынган маузали. Тегесе — кече манара.

Аннары, чиркәү сымanрак зур гына корылма очрап, Тәбрик анысы белән дә кызыксынгач, карт экскурсоводның көймәсе комга терәлде дә куйды:

— Нәрсә икәнен үзем дә белеп бетермим шул, улым, берәүләр әйтә: анысы да маузали, ди, икенчеләре хөкем пулаты диләр. Ә дөресе аның — ханәкә, ягъни әйтик, хаҗга, табынырга килүче безнең ише дәрвишләргә җәйге торлау — икенче төрле әйткәндә — дөрбә. Картлар гына түгел, соң заманда яшьләр дә килеп карый башлады. Алар өчен гади ташлар, безнең өчен — изге.

Карт экскурсовод сүзләре сонга таба ниндидер моң белән кушылып ишетелә башлый. Моң, сүз, сурәт — өчесе бергә... Бабай әйткәнчә, бу сихерле моңнар да борын заманнан, ыруг коесының төбеннән үк килә икән. Тәбрик әнисенең сандыгында, бик күп истәлекләр белән бергә, егерме буынны буйлаган шәҗәрә дәфтәрләрендә әллә ничаклы кызык һәм чын хикәятләр саклана, аларны укыгач, искиткеч матур җырлар ишетәчәк икән Тәбрик. Ә менә монысы таныш та бугай, шулай ук ерак заманнардан килә.

Сандугач-егет җырлый өзелеп,
Гөләп-чәчәккәй сөюен әйтә
Хуш исләр сибеп, хуш исләр сибеп.

Тукта әле, бу тавыш бик якыннан, бүгенге көннән яңгырый түгелме соң? Якын дигәннән дә якынрак — үзебезнең ишегалдыннан. Таныш та, якын да. Нигә дисәң — Гөләндәм тавышы. Бабай, шатлан, синең җыр да дәвам итә. Тәбрик отып калырга тиеш дигән җырыңны Гөләндәм җырлый. Гөләндәм. Әй, Гөләндәм, гөл сабагы, җыр геройларының берсе син үзең түгелмени соң? Син бит ул, син! Ә сандугач-егет? Бәлки анысы... Бәлки... Юк, тел әйләнми. Һәммм... Тәбрик болай матур итеп җырлый белми һәм, мөгаен, белмәс тә! Мондый көйләрне бөтен нечкәлекләре белән аңлап та җиткермидер әле ул — ничектер томанлы матур сурәтләр итеп кенә күз алдына китерә. Шулай булгач, егет — бүтән, сандугач — бүтән. Сандугач һәм Гөлҗимеш телендә бүтәннәр сөйләшә. Гөләндәм, мөгаен, бүтән берәүгә җырлыйдыр... Кем икән ул, ни атлы икән сандугач булып сайрар егет? Ләкин Тәбрик түгел. Тәбриккә андый бәхетләр турында уйланырга, уйланырга гына кала. Хәтта уйлардан да ниндидер яман тавыш аерырга азаплана бит әле менә.

Тукта, чынлап, баягы җырга һич тә туры килми торган ниндидер ямьсез аваз...

— Бабай, ишетәсеңме, кемнәрдер «дөрбә яна» дип кычкыра.

Кыйссалар сөйләргә көйләнгән карт сабыр гына тезеп китә тагы:

— Нишләп янсын инде таш сарай, ишекләре, тәрәзәләре дә калмаган бит аның. Янмас, улым, янмас, гасырлар буе ул нинди генә утлар кичмәгән, нинди генә яулар күрмәгән. Барыбер янмаган, җимерелмәгән. Хәзерге гадел заманга килеп җиткәч, мәңге торачак инде ул — дәүләт үз чутына алган ди бит аны.

— Шулай шул, бабай, мин дә шулай уйлыйм, янмас ул.

Әмма тавыш яңадан кабатланды да бу юлы инде аермачык булып, колакларны ярырдай булып ишетелде. Торып тәрәзәдән баксалар, урамда кешеләр йөгерешә:

— Фәрхетдиннең өе яна, яна, тизрәк!

Тәбрик сикереп торды да солдаттагыча тизлек белән киенеп, урамга ташланды. Тугаш карт белән Сөембикә апасы аның артыннан йөгерә килделәр.

Ерактан ук өйнең инде тоташ утка әверелгәнлеге күренеп тора. Кешеләр өй хәтле тоташ ут тирәсендә кайнашалар — ут яктысында әллә нинди кыяфәтләргә кергән сәер кешеләр... Әллә монысы төш кенәме? Юк шул, чын бусы... Ялкын янына барып булмый — пешерә, төштәге хәл генә булса, алай итмәс иде.

Янгын сүндерүчеләр сипкән судан чыж иткән тавыш та чыкмый. Шуңа күрә күпчелек кеше, йортлар тирәсендә сакка басып, очкыннарны гына сүндерә тора инде.

Бабай да, Сөембикә апа да ах-ух килә: «Нәрсә булды икән, төртеп яндырдыларммы икән? Ялгышмы?» — диләр.

Тәбрикнең башына килгән беренче уй шул булды: «Миннән күрмәсеннәр тагы!»

Елар чиккә җиткән Тугаш бабай су сибүдән туктаган насослар янында аптырап калган янгынчылар арасына үтте.

— Өйдәге җиһазларны чыгардыгызмы? — диде ул, утка ташланырга әзерләнгәндәй.

Тегеләргә бу сорау ошап җитмәде, ахрысы, карт соравын кабатлагач, җикереп үк җибәрделәр:

— Әйттек ич, соңга калганбыз. Кинәт кабынган. Җәйге чолладә копкоры бүрәнә — күкерт кебек икәнен белмисеңмени, картлач?

— Әчтә әллә ни юктыр инде Фәрхетдиннең, өе җәл, өе шәп ие,— дип сүзгә кушылды икенче бер карт.

— Нишләп булмасын, нишләп булмасын ди ул? Егерме буыннан килгән шәҗәрәне кая куясың? Хатирәләрне? Тәбриккә дигән мирас? Кайда ул? Бүтән каян табыйк аны? Каян? Ник алып чыкмадыгыз, ник коткармадыгыз?!

Ачыргалануга да җавап бирүче булмады.

— Менә бит, ә... Ничәмә буыннан килгән затлы нәрсәләр, киемнәр, таңкәләр... Әй, Фәрхетдин, Фәрхетдин, юньсез, үзе дә саклый алмады, безгә дә бирмәде.

— Борчылма, бабакай, бүтәне табылыр.

— Табыла торган әйбермени, Тәбрик улым. Узган гомер, калган хәтер дигәндәй...

Йорт һаман яна.

Бермәлне өй эченнән әллә нинди сәер тавыш ишетелгәндәй тоелды. Әллә кеше инде... Юк, бер караганда, юаныч, икенче яктан, фаҗига — тавык икән! Югарыдан, өйалды белән өй арасындагы ачык тәрәзәдән кытаклап һәм черләп тавык чыкты. Кая барырга белми мескенен. Җиргә очып төшмәкче иде, тирә-якта халык, шау-шудан куркып, өй түбәсенә үк менеп китте. Ә анда — тәмуг, вулкан... төтен һәм ут бер бөтен булып ургыла. Ул да түгел, бер әби үрсәләнә:

— Ай алла, минем чуар тавыгым. Шул бит, шул, карагыз, минем тавыгым, харап була бит! Кет-кет-кет-кет, ти-ти-ти-ти...

— Җиргә оч, тавык баш, җиргә! — дигән тавышлар да ишетелде.

Әмма тавыкның инде аларны ишетерлек әмәле калмаган — ялкынга камалган, канатлары үк көя... Тавыктан бигрәк карчык үрсәләнә:

— Әй, чуар тавыгым, хараплар гына буласың лабаса. Югалган идең лә аны, атна буе күзгә чалынмый торгач, сасы көзән буган дип йөрсәм, яшертен күкәй салып, чебеш чыгарырга утыргансың икән.

— Утырсын иде үз өендә генә, чит өйләргә ияләшсәң, шулай була ул, — дип кинаяле усаллашты Тугаш карт.

Дөресе шул, нишләсен әби — җавабы юк. Ә тавык... Тавык өй түбәсеннән бакча ягына очмакчы иде... Канатлары чытырдап, утның нәкъ уртасында җилпенде-җилпенде дә... утка әверелеп, күккә төтен һәм ут булып очты... очты теге дөньяга...

— Үз дөньяңнан бизеп, читтә күкәй салып йөрсәң, шулай була ул.

— Ах...— Өй эченнән, ахрысы, тагын сәер тавыш.

— Сез ишеттегезме? — дип сорады Тәбрик Сөембикә белән Гөләндәмнән.

— Әллә тагы. Ишетелгәндәй тоелды шул.

— Тоелгандыр гына ла, Фәрхетдин Кыртапада бит.

Тугаш картның шул сүзләрне әйтүе булды, өй «гөрс» итеп ишелеп тә төште.

— Карап торып яндырдык өйне. Ай-яй!

— Кеше тора торган өй түгел әле, кайгырма.

— Сирәк булса да кайтып тора иде бит. Кыш көннәрендә бигрәк тә.
— Хәзер кайда торыр икән инде?
— Үзе өй салучы... Әтмәлләр әле — акчасы күптер...
— Туктагыз әле, җәмәгать, кешесез өй нишләп янды соң әле ул, ә?
Тәбрик бабасының тавышын ишетте:
— Җәмәгать! Берәрсе төртеп яндырмагае! Милициягә хәбәр итик — эзләсеннәр.
— Ярый, бабай, кайгырма ул хәтле.
— Ә шәҗәрә? Ыруг коесы? Аның да суы киптеме инде? Изге иде бит ул, изге!
— Кайгырма, бабай, бәлки әле ул хәтле үк изге дә булмагандыр, ныклабрак карый төшсәң... анда да мәче төшкәндер.
Шушы сүзләрне ишетүгә, карт телсез калды. Телсез калды да баскан төшендә җиргә утырды.
— Я раббым, күрәселәр бар икән! — дип көч-хәл белән генә мыгырданды ул. — Анда да мәче! Кайда, нинди мәче?
Карт белән бәхәсләшүнең уңайсыз икәнен тойган Тәбрик аны култыклап торгызырга азаплана иде, бабайның икенче ягыннан ниндидер ят адәм култыклавын күреп алды. Аңа ул бәлки игътибар да итмәс, шул килеш янадан өенә кайтып китәр иде, ләкин ят кеше болар янынан никтер китәргә җыенмады. Әллә таныш та инде?
Күзгә-күз карашып байтак торгач, ут яктысында карачкы төсле күренгән кара киемле ят адәм телгә үк килде:
— Танымыйсыңмыни?
— Юк, танымыйм.
— Келәнчегә эзләп килгән идең ич, мин шул кеше.— Мескен, мин синең этиең дип, интекми генә әйтәсе сүзне ничек аңлата алмый газаплануын кара!
Һәм Тәбрик карый, ләкин инде мәсхәрәле итеп өстән карый:
— Мин сезне танымыйм.
— Таныйсың ла... Менә сиңа акча китердем, сиксән сум. Ал, ал, курыкма, хәләл акча... Пальто алырсың. Шинельдән озак йөрү килешмәс бит.
— Шинельдән сез дә ояласызмыни? Гафу итегез, мин аның белән бик горурланам.
Көтелмәгән бу сүзләрдән чүгеп куйды бәндәң. Җир яныл табанын пешергәндәй тыпырчына ук башлады.
— Кеше арасында кешечә булсын дигән идем... Нәкәнис, син ятим бала түгел ләса. — Көчләп диярлек акчаны тоттыруы булды, Тәбрик дары шикелле дөрләп тә кабынды, әйтерсең инде күмергә үк әйләнә барган өй белән бергә ул да яна иде. Бәлки... Тик уйларга вакыт юк, Тәбрик эчтән һәм тыштан бәреп янган нәфрәтенә чыдый алмыйча, акча дигәннәрен чытырдатып йомарлады да дөрләп торган өйгә ыргытты... юк, ыргыта алмый калды, өлгермәде.
— Улым!..
Нинди сүз! «Улым!» Йа ходай, ишетер көн бар икән бу сүзне дә. Ишетте бит Тәбрик, тәки ишетте... Аның да этисе бар, бар, ул ятим түгел... Һәм ул сүзне ишетүгә йодрык төсле күтәрелгән кул һавада хәрәкәтсез калды. Ә атасының ике кулы да күккә, тәңресенә сузылган кебек сузылган, Тәбрик йолдызларга үрелгән төсле... Ут яктысында шәүлә булып өч кул күтәрелгән. Ник? Яратырга, сөяргә? Ата куллары — улы кулындагы акчага талпына, калтыранган куллар каушаган йөзгә күләгә булып төшә, аны кызганмау мөмкин түгел бугай. Ничек кенә булмасын, шунысы хак — Тәбрик акчаны кире кайтармый булдыра алмады. Мирсәет исә кирәксез нәрсәдәй йомарланган кадерле акчаларын баягыча каушый-каушый күкрәк кесәсенә салып куйгач, Тәбриккә янгын яктысында атасының бөтен дөньясы — барлык яшерен почмакларына ка-

дәр! — ап-ачык күренде. Көлке һәм кызганыч, кызганыч һәм рәнжешле... Ике көн элек кенә бу адәм «улым» дигән изге сүзне әйткән булса, Тәбрик һич икеләнмичә аның кочагына ташланган булыр иде һәм кысып-кысып кочар иде, яратыр, сөяр иде, шатланыр, шатландырыр иде. Ә бүген... бүген күңелдә тагын бозлы тау куышы барлыкка килде. Бая гына пешереп интектергән эсселек, икенче минутта, өй дигән күмерләр һаман дөрләп янып торуга карамастан, чыдый алмаслык салкынга әверелде. Салкынлык, бозлык һәм... боз сөңгеләр.

Тик эшнең ни белән бетәсен сизгән ата, янда аптырап торган кешеләр ишетмәсен дигәндәй, ялагайланып пышылдады:

— Мин — синең этиең, этиең мин синең.

— Минем этием юк,— дип, Тәбрик читкә борылды.— Әйдә, бабай, өйгә.

— Хәзер инде кайтып нишлисең... — Бабайның кузгалырга нияте булмаса да, Тәбрикнең көчле кулларына буйсынмыйча булдыра алмады. Тик ике-өч адым киткәч тә, баягы кеше боларның каршысына төште:

— Мин бит синең янга махсус килдем.

— Вакытын тапкансыз...

— Минем бәхет шулай инде ул, нишләтәсең.

— Ә нишләп төнлә? Көндез кешеләрдән куркасызмыни? Безне икәү бергә кешеләр күрмәскә тиешме? Шулаймы?

— Ярамый, үзең беләсең...

Улының тагын авырткан төшенә кагылды кеше. Бабасын ычкындырып, Тәбрик Мирсәеткә текәлде:

— Шулай, шулай — көндез кеше күрә! Кеше алдында законсыз булып калган малай белән сөйләшү сезнең саф вөҗданыгызга куләгә булып төшә! Сез акыллы! Тик акыллы булсагыз да, мин сезнең белән сөйләшергә теләмим.

— Улым, Тәбрик!

— Сезнең улыгыз юк, сез бит үзегез эти дип эндәшмәскә куштыгыз,— диде ул тыныч кына итеп.

— Гафу ит, Тәбрик, мин ялгышканмын!

— Шулаймыни? Ялгыш кынамыни? Ишетәсеңме, бабай, ул бит ялгышып кына мине ятим иткән.

— Мин ул кешене белмим, балакай, белергә дә тырышмыйм. Мин адәм рәтле кешеләрне генә беләм. Ә бу... — Карт кулын селтәде.

Янып беткән өй урынындагы утлы күмерләр чүмәләсе янында торган кешеләр, бәхәсне ишетептер инде, акрынлап болар янына җыела башласа да, ата белән бала, артык ярсыганлыктан, аларны бар дип тә белмичә, һаман үзләренә кирәкне (күренүенчә — соңгы кабат!) әйтеп калырга тырыша. Көйрәп торган күмер яктысында, әйтерсең, инде кешеләр яна, ике кеше яна...

Ата:

— Мин сине китә дип ишеткән идем. Саубуллашырга килдем.

Бала:

— Ялгышыпмы?

Ата:

— Син миңа бүгеннән соң эти дип эндәшә дә, яза да аласың.

Бала:

— Хәзер инде минем андый теләк бетте.

Ата:

— Ни сөйлисең син?!

Бала:

— Әнисен үтергән кеше — бала өчен ата түгел.

Ата:

— Тәбрик, акылыңа кил!

Бала:

— Әйе, син — үтерүче, син минем әниемне үтергән. Син һәм Фәрхетдин икәүләп.

Ата:

— Яман кешеләр сүзенә ышанма.

Бала:

— Минем әниемне яман телләр бозык хатын дип атарлык хәлдә калдыручы син түгелме? Мине законнан тыш бала итеп калдыручы кем? Кем? Минем документларда синең исем юк һәм булмас та.

Ата:

— Улым, кичер!

Бала:

— Сине кичерерләр, әниемне бүгенге көнгә кайтарып бирсәң.

Ата:

— Улым!

Бала:

— Син аны яклап, туган иле өчен күкрәге белән амбразурага ташланган солдат шикелле ташланырга тиеш идең. Фәрхетдин үзенең куркаклыгын яшерер өчен явыз булып кыланган кебек, син шундый ук куркаклыкны сиздермәс өчен йомшак күңелле кеше булып йөргәнсең... Ләкин сез икегез дә бер — куркаклар, дезертирлар.

Ата, баласыннан читкә тайпылып, Тугаш каршысына килде дә, ярсуын ана кучермәкче булып, ахрысы:

— Сез котырткан аны, сез! — дип кычкырып җибәрде. — Атаны балага каршы котырту! Моңардан да зур җинаять тагын кайда бар?

Карт ана мыскыллагандай карап кына торды да тыныч кына нәтиҗә ясады:

— Баладан каһәр алмыйм, дисәң, ата була белергә кирәк. Син аңа нәрсә бирдең? Илме? Бирдеңме ил? Тел бирдеңме? Бирдеңме тел? Юк, син аңа тел дә, ил дә калдыра алмадың. Шуңа күрә син ата да түгел. Сез — нәсел корытучылар, ил корытучылар, өй яндыручылар. Ил коесына төшкән мәчеләр сез!

Карт Мирсәеткә таба төкерде дә — тидеме, юкмы, караңгыда күрү читен иде — әлбәттә, оныгы янына килде.

— Мирсәетне дә, Фәрхетдинне дә гафу итмәвең — бу аларга тиешле хак җәза. Әгәр үз исемемнән генә үтенсәм, бик нык үтенсәм дә, син мине дә гафу итмә, бала. Мин дә бик каты гаепле синең каршыда. Дөньяга килгәнеңне башта белмәгән булсам да, соңыннан ишеткән идем. Барып та караган булдым не Займище дигән җиргә. Әллә нинди бер җайсыз хәлдә синең вафатыңа ышандым да куйдым. Гамьсезлектән килгән ашыгыч ышанулар бу. Ә син исән булгач, ничек кенә булса да, мин сине табарга тиеш идем, тапканчы эзләргә. Ә хәзер... үзең кайткач, хуҗа булмакчымын. Шулай, бала, кичерерлек хата түгел бу. Шуны белгәнгә күрә, үз исемемнән түгел, син яралган туфрак исеменнән сорыйм: синең алда бернинди гаебе юк аның, гафу ит син туган җиреңне. Туган җир өчен син беркайчан да артык булмаган һәм хәзер дә артык түгел. Син моны үз күзләрең белән күрдең, балакай! Гафу ит син туган туфрагыңны.

— Туган җирне гафу итмәү мөмкин түгел, бабай.

— Рәхмәт.

Шул сүз белән карт кайтыр якка атлады һәм Тәбрик тә аның артыннан кузгалган иде, шул секундта этисенең дә янда гына басып торганын абайлады. Мирсәет дигән шәүлә, инде телгә килә алмыйча, карангыга кереп югалды.

Авыл кешеләре исә, әле генә ишетелгән гыйбрәтле сүзләрнең һәм янгынның сәбәбе, мәгънәсе хакында баш вата калдылар. Ниһаять, фикерләре Мирсәет белән бер дәрәҗәдә тиргәлгән Фәрхетдингә күчте,

Күрше карчыктан Фәрхетдинне соңгы кабат кайчан күргәнлеген сорагач, тегесе бөтенләй әллә нинди сүз әйтте:
— Кичкелектә үзе дә күренгән иде ул, — диде.
— Кем ул «үзе»?
— Фәрхетдинне әйтәм. Әмма да ул лыкма исерек иде. Кайттыңмы, Фәрхетдин, дип сораганга, кайтмадым, киттем, дип мыгырданды. Кыртапага яңадан китүе булгандыр инде.
— Алайса, утны үзе төртеп киткән булып чыга.
— Үз өенә ничек ут төртсен? Сөйләмәгез юкны.
— Тәмәке тарткандыр да төпчеген сүндерми ташлагандыр.
— Фәрхетдин тәмәке тартмый иде шикелле.
— Әйе шул, эчә генә ул.
Күпме генә юрасалар да, утның сәбәбен ачыклый алмадылар. Берничә сәгатьтән соң, элекке өй урынында калган кайнар өемне сүндерделәр дә, кисәү калмаганмы дип кабат-кабат тикшергәч, таралыштылар. Шулай да авылда инде беркем дә йокларга ятмагандыр. Бу вакытта, төнге янгын төсле кабынып, офык яна, офык кына түгел, Тау ягы үзе үк яна шикелле тоелды... һәркемнең башында бер үк сорау:
«Ничек чыкты икән бу янгын?»
Иртүк юл уңаеннан Кыртапа кешесе артыннан Фәрхетдингә өенең януы хакында хәбәр җибәрделәр. Кич җитте, Фәрхетдин кайтмады. Шул кадәр дә ваемсыз булыр икән, дип зарланды кайберәүләр. Өченче көнне Кыртападан хәбәр килде: сала торган өен салып бетерергә килсен инде, дип, Фәрхетдинне чакыралар икән.
Бөтен авылның йөрәге жу итеп китте... «Әллә... Юк, юк, булмас, булмас...»
Бу көннәрдә Тәбрик үги атасы хакында менә ниләр белде.
Соңгы елларда кеше белән болай да рәтләп сөйләшми башлаган, үз кабыгына кереп бикләнгән Фәрхетдин Тәбрик белән сөйләшкәч бигрәк тә күңелсезләнә төшкән, бөтенләй сөйләшмәс булган. Аның эчендә нинди уйлар, ниятләр йөргәндер, кем белсен, боларын тик чамаларга гына мөмкиндер... Өч көн рәттән исереп йөргәч, ут чыгасы көнне әйткәннәр аңа: барыбер эшләмисең, өеңә кайтып ял ит, рәтләнгәч килерсең, дигәннәр. Шуннан соң ул өенә кайтып киткән... Караңгы төшкәч кенә өенә кайтып җиткән...
Мөгаен, кайткач, аш әзерләмәкче булып, учак яккандыр. Мич янында коры агачлар булгандыр. Исерек кеше яккан учактан шул коры агачларга кисәү төшкәндер...
Ял итеп торыйм дип кенә яткан кеше хәмер көче аркасында тиз генә уянмаслык авыр һәм соңгы йокыга чумгандыр...
Юраулар төрлечә һәм аларның барысы да дөрескә чыкты бугай: эзләмәгән өй калмады, эзләмәгән авыл калмады, тапмадылар Фәрхетдинне, югалды Фәрхетдин...
Тагын өч-дүрт көн узгач, тагын яңа хәбәр: Фәхретдин җәяүләп ниндидер калага киткән, имеш...
Бар иде Фәрхетдин, юк хәзер Фәрхетдин — хәер, гаҗәп тә түгел, Тәбрик аңа хөкем карары чыгарган һәм шул карарны җиренә дә җиткергән иде бит инде — димәк, хыял дигәне хыял гына булып чыкмады...
— Дөнья үзенекен итә, балам, дөнья зирәк хәл итә: янарга тиешлесе яна, бетә, изге әйберләр кала бирә, мәңгелеккә кала. Изге чишмәләр корымый бит, балам, үзең күрдең, авылга үзең китердең.
— Мин кызганмыйм, бабай, өйне дә, Фәрхетдинне дә...
— Шунысы җәл, төбенә төшеп җитә алмадың чишмәнең. Хәзер инде китәсең менә.
— Әгәр мин кайтмаган булсам, исән йөрер иде кеше... Мин дә гөнаһлы булып чыктым, ахрысы, бабай.

— Бәхете булмагач, яшәп ни файда инде. Берүзе торып калган иде бит, өennнән торып калган әнә теге морҗа төсле. Өе буш, дөньясы буш иде... Әниең яше тотты, изге яшь... Шул хәтле кешелексезлеккә ходай кичерәмени!

— Бабай, ничек уйлыйсың: бәлки ул аңлы рәвештә ут төрткәндер, вөҗданы кузгалып яшәргә ирек бирмәгәндер?

— Анысы да бик ихтимал, улым, бик ихтимал.

Элекке өй урынында кара янып калган морҗа нәкъ Фәрхетдиннең үзе төсле булып, тораташ сыман булып, күңелне сискәндереп һаман тора...

*

* *

Фаҗига Тәбрикнең китүен бераз тоткарлады. Авыл йөрәгендәге җәрәхәт бераз онытыла төшсен, өйне кара күмергә калдырган ут кайнарлыгы сүрелә төшсен дип тә, ә бигрәк — шунысы әһәмиятлерәк сәбәптер — халыкта үзенә карата шик калмаганга ышаныр өчен, алай-болай уйламыйлармы дип сорашыр өчен, атна-ун көннән соң гына китәргә тиеш тапты ул.

Сагаюы урынсыз иде, билгеле. Халык шикләнмәү генә түгел, гореф-гадәт буенча, өй борынча яшь солдатны тагын кунакка йөртә башлады.

Кичке якта үзара чират билгеләшеп, бөтен авыл диярлек Тәбрикне чәйгә дәшә торгач, егет инде сыйдан туя башлады. Гөләндәм белән пышын-пышын нидер сөйләшәләр дә каядыр китәләр, югалалар. Кайда, нишләп йөриләр — шайтан белсен. Шунда инде карт, күпме эндәшмәскә, ачуланмаска тырышса, да, сукранмыйча булдыра алмый.

— Ризыктан өстен булу ярый торган эш түгел ул, балам. Рәнҗешен кая куярсың? Бөтен авылны үпкәләтәсең.

Кайткан көннәрдә барлык өйләрдә кунак булгач җитмәгәнмени инде? Киткәндә дә мәҗбүриме? Бетәсе түгел — кыстыбый, диләр, өчпочмак, гөбәдия, диләр, катык, күзикмәк, коймак — тагы нәрсәләр. Бөтен авыл ризыгын ашап бетереп буламыни?

— Шушы хәтле кунак итәрлек минем нинди хезмәтләрем бар соң әле? — дип сорый Тәбрик аптырагач үзеннән дә, авылдашларыннан да.

— Син безне саклап армиядә йөргәнсең. Хезмәт түгелмени ул? — диләр картлар.

— Бөтен авыл белән изге дип табынган суыбызны капка төбенә китереп куйдың — хезмәт түгелмени ул? — диләр карчыклар. — Изгелек җирдә ятмый ул.

Аларның сүзен кызлар кабатлый.

Кызларның да, апа-әбиләрнең дә кыяфәтләрендә һәм сүзләрендә Тәбрикнең үз әнисе чалымнары һәм аһәңнәре күренеп-ишетелеп китә шикелле...

Ир егетләр исә, ничектер, Тәбрикнең үзен хәтерләтәләр:

— Шинелеңне ташласаң да солдат булуыңны ташлама, шул чакта сине илдәге бер хатын да: «Бу минем улым түгел», димәс.

Тәбрик нәрсә әйтсен аларга?

— Рәхмәт! — ди дә кызара. Кызара да,— слушаюсь,— дип өсти.

Өстәлдәге самавар күз алдында гомер буе гөжләп утырыр, сыйга куелган коймак, бәлеш, бал һәм май тәмнәре туган җир якынлыгы шикелле булып, күңелне иркәләр.

Китәр кичтә бөтен авыл хатын-кызы я йомырка, я ак май, я чәкчәк, төш, я бүтән төрле күчтәнәч кертә — алмасаң, үпкәлиләр, ничек итсәң дә, ай-ваена куймыйча, күчтәнәчен калдыра торгач, Тугаш карт белән Сөембикә апа өе сый-хөрмәт складына әверелде. Теләсәң дә алар-

ның бөтенесен алып китү мөмкин түгел — калдырып киткәнгә тиргәмәсләр микән инде?

«Сезнең яхшылыгыгыз, юмартлыгыгыз шулкадәр олы ки, аларны чемоданга түгел, күңелгә генә сыйдырырга мөмкин, ачуланмагыз, апалар, үпкәләмәгез, авылдашлар».

*

* *

Соңгы тапкыр авыл белән хушлашыйм дип, Тәбрик (Гөләндәм аны урамда көтә иде инде) чыгып киткәндә, Тугаш карт аны капка төбенә хәтле озата килде. Капка баганасына сөялде дә уйлана калды: «Аз гына вакыт эчендә ничек шушы тикле нык итеп ярата алдым соң әле бу малайны? Шул кадәр иярәшенде, дөньяның кайчандыр буш торган бер почмагы тулыланды да куйды. Ә хәзер ул китеп барса? Җандагы бер олы урын тагын буш калырмы?»

Әгәр оныгы китсә, Тугаш бабагыз пристаньга хәтле озата барыр, әлбәттә. Сөембикә белән, Гөләндәм кызы белән бергә. Каратун җәһәннәм артында түгел. Әгәр кирәк булса, җәһәннәмгә дә барыр иде карт, һич курыкмас иде. Дөньяда исән калган бердәнбер улы, соңгы өмете һәм ышанычы хөрмәтенә актык сулышына кадәр атлар иде.

Әгәр оныгы китсә, яр буенда моңаеп калыр инде бабасы. Тәбрик кечкенә чемоданын тотып теплоход трабыннан узган чакта, ярда торучылардан кем дә булса: «Бигрәк тә мөлаем, бигрәк тә килеш-килбәтле, бу кем малае?» дип соравы ихтимал. Ничек җавап бирер Тугаш карт? Җавап бирер, өздереп: «Тугаш бабаң улы булыр бу чибәр егет!» дип, горурлыгын яшермичә әйтер. Анасы Көлемсәр Тәбрикнең кем улы булуы хакында документына «Тугаш улы» дип юкка гына яздырмаган, бу бөек дәрәҗә һәм олы исемне кемнең аклый алырын, әлбәттә, ана күңеле сизмичә калмаган...

Ләкин менә китеп баруы гына җайсызрак. Туган җирен — ягъни туган әнкәсен инде Тәбрик тапты шикелле, әтиләрен тапмаса, дәү әтисен тапты. Алай да җитмәсә, бөтен авыл аны үз улы төсле күрә.

Ә шулай да ни өчендер китәргә җыена бала? Укыйсы бик киләбугай шул. Укыйсы дигәннән, шунысы күңелле бит әле — Тәбрик авыл кешеләренең, бигрәк тә председатель Корбанның үтенечле соравы буенча, авыл инженерлары әзерләп чыгара торган җиргә китәргә ризалашкан. Кем белә, болай булгач, укып бетергәч, бәлки Үзәнбайга кайту нияте белән китә торгандыр әле? Шулайдыр, мөгаен, шулайдыр.

Бөтенләйгә үк китмәс. Ихтимал, китә алмас.

Бәләкәй капка аның артыннан шалт итеп ябылгач, ишегалдында шөгыль тапмыйча, бабай бакчага кереп китте.

Ә Тәбрик белән Гөләндәм бу вакытта янган өй янында басып торалар иде. Күпме кеше, күпме еллар гомер иткән нигез хәзер бөтенләй булмагандай юкка чыккан. Күмерләрен дә җыештыргач, карачкы морҗаны да сүтеп аткач һәм урынны бик тә шәпләп тигезләгәч, авылның кыяфәтен бозмый башлар, хәтерләрне дә көйдерми башлар инде ул. Тормыш үз чиратында дәвам итәр — кемнәрнеңдер юклыгы да сизелмәс, һич тә сизелмәс.

Бабай әйткәндәй, тормыш гадел, тормыш шәфкатьсез — яман җимерелгәндә, яман янып көлгә әйләнгәндә, шунда ниндидер яхшы әйберләр дә әләгә... Әнисеннән Тәбриккә күчәсе мирас һәм шәҗәрә төсле...

Анадан Тәбриккә калган бердәнбер мирас — рәсем, ягымлы, чибәр төс... улы кадерләп сакларга тиешле бердәнбер изге нәрсә... Ә бу кечкенә нәрсәме? Ана рәсеме! Җитмиме шул? Ана рәсеме бит ул! Бөтен Тау ягы табигате Тәбриккә шул мөлаем күзләр белән карап тора бит!

Гөләндәм, Тәбрик абыйсының ни уйлаганын башына китерә алмый-

ча, әллә нинди таныш та һәм серле дә елмаю белән елмаеп тик тора һәм шулай уйларны бүтән якка, бүтән матурлыкка дәшә.

Егет белән кыз Каратал авылы бакчаларын узып, Черныш дигән авыл ягына атладылар. Әлеге дә баягы, таулар тарта күңелне, нигәдер һаман җилкендереп, үзләренә чакырып тора шул таулар. Кайчандыр бүреләр йөргән, хәзер инде кемгә дә куркыныч тоелмый торган Ябалак чокыры буйлап тагын биеккә күтәрелделәр дә түбән якка — киңлекләргә, авыллар сибелеп утырган тын һәм моңсу үзәннәргә карап тын калдылар. Ай, бу киңлекләр! Ай, бу авыллар! Чиксез дөнья, Галәм кебек... Әнә инде утлар да кабынган... Күпме утлар ул авылларда — шәһәрдәге төсле үк электр утлары җемелди... Нәкъ күктәге йолдызлар санынча... Ага да ага чиксезлек, ага да ага җем-җем иткән яктылык, изге чишмә кебек, елга кебек, гомер кебек, тормышның үзе кебек.

Шулай да ник бөркетләр күренми икән бу тауларда? Кайчандыр бу тауларда алар оя кора торган булган бит. Ник рәхәтләнеп канат җилпемиләр икән алар һаман шушы чиксезлектә? Кая китеп югалдылар икән? Хәтта Ябалак чокырындагы ябалаклар да юкка чыккан.

Аерым карасаң, кемнәрдер китә бу дөньядан, әмма аларны кемнәрдер яңадан алмаштырырга тиеш...

Ниндидер өйләр искерә, туза, җимерелә һәм яна... Әмма да яңалары төзелсә, искеләренең юклыгы беленми дә... Ничәмә гасыр шулай юкка чыккан алар, ничәмә гасырлар буе алар урынына яңалары килеп баса торган. Өйләр җимерелә, гомерләр...

Ләкин бер сарай мәңгелек — менә шушы таулар, дөньядагы барлык манаралар, гөмбәзләрнең иң бөеге һәм чыдамлысы һәм иң гүзәле... Офыклар булып тоташкан гомуми зәңгәрлеккә үзләренең искиткеч манаралары, гөмбәзләре белән сузылган бу таулар — дөньяда иң чын һәм даһи художник әсәредер... Бөек йорт... Тау ягы... Ерак Болгар һәм Биләр корылмаларын да, Казан һәм Мәскәү Кремльләрен дә хәтерләтеп, алар белән бөек бер ансамбль тәшкил итә шикелле бу таулар. Һәм ул ансамбль бөтен килеш тә йөрәккә сыя икән.

Өч архитектор — Кояш, Су һәм Җил — гаҗәеп тә төрле сызыклар һәм төсләр белән бизәгән бу искиткеч зур һәм иркен сарайны. Иң сөенечлесе — мәңге җимерелмәслек итеп төзелгән бу бөек йорт. Бернинди яулар һәм янгыннар да җимерә, юкка чыгара алмаган бу әсәрне һәм алмаячак. Монда яшәгән халыкка, Тугаш бабайларга мәңгелек һәйкәл дә, торыр өй дә булып, мәңге торыр бу сәнгатьле сарай. «Әйе, җимерелмәс бу бөек өй, янмас — үзегез генә исән булыгыз, ике атамны берьюлы алмаштырган дәү әтием! Исән булыгыз!»

Егет шул сарайның бер манарасына — чирәмле тавына баскан. Янында торган гүзәл кыз балага елмаеп карый да кулларын йолдызларга суза.

Уч төпләренә тиеп, бөтен тәнне җылытып тора йолдызлар — шул кадәр якын икән алар бу төшләрдә! Учларны йомып кыссаң, ике кулда ким дигәндә ике йолдыз балкыр. Бүген булмаса, иртәгә... Әйе, йолдызларга терәлеп торган бу якты бәхетләр һәм сөенечләр ерак түгелдер, якындыр, бик якындыр, бик тә, бик тә якындыр.

Йолдызлар тоту һич тә кыен эш түгелдер бу җирләрдә.

Тау ягы дип атыйлар бу якны.

*1969—1972 еллар*

◆ ◆ ◆ ◆

## Максуд Сөндекле

### Көндәлек дәфтәреннән

●

Бу дөньядан кемнәр үтмәгән?
Утыр әле, кордаш, кил бире,
Күтәрикче яшәү хакына,
Җәннәттән ким моның кай җире?
Утырмыйкчы гомер үтә дип,
Ризык тулы җирдә уфтанып,
Вакыт нәрсә?
Вакыт үтми ул,
Без үтәбез аңа эз салып!

●

Яшәп булмый җирдә дус-ишсез,
Дуслык кайда — шатлык шул өйдә,
Ялгызлык ул боек, канатсыз,
Сәләте юк аның сөюгә.
Ялгызлыкка өйдәш булырга
Туры килсә әгәр бу башка,
Кирәк түгел миңа берни дә,
Кирәк түгел ай да, кояш та...

●

Картайганчы белем алдым мин
Тормыш дигән укытучыдан,
Бик таләпчән остаз иде бу,
Булу кирәк иде бик чыдам.
Бу остазым миңа карата
Шәфкать дигән сүзне белмәде...
Чәч агарды, әле һаман да
Исемем язып диплом бирмәде.

•

Безнең «кадим» әби, бабайлар
Бай булмаган алтын, көмешкә,
Изге мирас булып алардан
Моңнар калган безнең өлешкә.
Кемнәр әйтә безне ярлы дип?
Чирт кылларын туган моңнарның,
Мең буынга әле җитәрлек
Җан азыгы иске җырларның.

•

Бу дөньяда мин бер юлчымын,
Үтәр юлның беләм чамасын,
Мин янымда йөртәм һәр вакыт
Заманымның кыйбланамасын.

•

Фәкать бер минут эчендә
Эшләнеп куйган хата
Гомерлек кайгы китерә
Кешегә кайсы чакта.

•

Әйе, без бик бәләкәйләр,
Без тик тамчылар гына,
Ләкин тормыш диңгез булса,
Ул диңгез бездән тора!

**уфиян Сафуанов**

# КҮҢЕЛЕНДӘ — ИКЕ ХАЛЫК МОҢЫ

Күптән түгел ямьле Ык буйларында булырга туры килгән иде. Бер яры Башкортстанның урманнар белән капланган тау итәкләренә сыенган, икенчесе Татарстанның игенле яланнары буйлап сузылган һәм берчә ярсу, берчә салмак кына аккан бу елга таулардан чылтырап төшкән чишмәләрне дә, ялан ягыннан килеп кушылган инешләрне дә үзенә кабул итә-итә, торган саен киңәя, мәһабәтләнә бара. Аның сулары Татарстан туфрагын да, Башкортстан җирен дә бердәй үк сугарып, һәр ике республикага да хозурлык биреп тора.

Ике республика җиренә дә ямь биреп аккан шушы елга буенда йөргәндә, татар әдәбиятына да, башкорт әдәбиятына да өлеш керткән күренекле шагыйрь Максуд Сөндекле иҗаты хәтергә килде.



Татарстанның хәзерге Тәтеш районы Сөндек авылында туып үскән Максуд Сөндекле 1934 елда Уфага килеп, шунда төпләнеп кала, шул вакыттан башлап ул Башкортстан тормышы турында да җырлый башлый, үз иҗатын башкорт халкының моңы белән дә сугара һәм бу халык тарафыннан да үз шагыйре итеп санала башлый.

Максуд Сөндекле — әдәбиятка эшчеләр тормышын җырлап кергән, поэзиягә хезмәт темасын алып килгән һәм гомере буена шуңа турылыклы калган шагыйрь. Үз авылында беренчеләрдән булып 1924 елда Ленин комсомолы сафына баскан М. Сөндекле (Садыйк Мөбин улы Максудов) шушы ук елда Донбасска китеп, Енакиево шахтасында эшли башлый. 1925—27 елларда Артем шәһәрендә партия мәктәбендә укыганнан соң да шул шахтерлар арасында аң-белем тарату эшләре алып бара, Донбасстагы татар матбугатында хезмәт итә. 1930 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә.

Аның әдәбиятта беренче адымнары да нәкъ менә шунда, шахта эшчеләре арасында башлана. «Иң тәү башлап минем әдәбият белән кызыксынуымны уятуда Украина комсомолының иҗади оешмалары сәбәпче булдылар,— дип хәтерли шагыйрь үзе.— 1925 елда Донбассның Париж Коммунасы исемендәге партия мәктәбендә укыган чагымда рус совет язучысы Борис Горбатов белән таныштым. Ул вакытта Борис Горбатов «Забой» журналы каршында оештырылган әдәби түгәрәк белән җитәкчелек итә иде. Мин бу түгәрәккә ике кыш йөрдем. Шушы түгәрәктә катнашуым минем киләчәктәге әдәби эшемә зур файда итте, дөрес юнәлеш бирде».

М. Сөндекле татар телендә чыга торган «Донбасс эшчесе» исемле газета янында әдәби түгәрәк оештыруда актив катнаша, ул түгәрәк соңра «Молодняк» дигән Украина яшь язучылары оешмасының татар секциясенә әверелә. Секция Харьковта татар-башкорт яшьләренең әсәрләреннән торган әдәби альманах та чыгара (аңарда шагыйрь Нәби Дәүли дә катнаша).

Эшче яшьләр арасыннан күтәрелеп чыккан яшь шагыйрь үзенең беренче әсәрләрендә үк шахтерлар турында, аларның авыр эшләре һәм якты омтылышлары хакында җырлый. «Пролетар»га хат» дигән шигырендә ул:

**Минем хисләр тирән шахтадан**
**Җыр, темага баеп менәләр,—**

дип язган иде. Хезмәт өстендә туган кайнар хисләр, җир астының тирән катламнарын актарган, йөзләренә куллар карасы ягылса да, күңелләре ак һәм пакь булган хезмәт кешеләре — аның егерменче-утызынчы еллардагы күп санлы шигырьләренең һәм хикәя-очеркларының геройлары булдылар.

Егерменче елларның азакларында, утызынчы елларның башында татар поэзиясе өчен тансык булган производство эшчеләре темасын поэтик хәл итәргә омтылуы һәм күп очракта уңышка ирешүе М. Сөндекле әсәрләрен шактый популяр итте. 1930—32 елларда Казанның, Мәскәүнең, Донбассның татарча китап нәшриятлары аның «Күмер тавышы», «Сигнал», «Донбасс ударниклары», «Шахта сулый», «Соңгы хат», «Днепрострой», «Удар забой» һ. б. җыентыкларын бастырып чыгарды, әдәби тәнкыйть тә аларны хуплап каршы алды. «Хәзер Сөндекле иптәш шахта тормышын белеп, материалны турыдан-туры шахтаның эченнән алып яза»,— дип чыкты Мирсәй Әмир 1930 елда.

Баштарак кулына кәйлә тоткан, соңрак хәзерге заманның алдынгы техникасы белән коралланган эшче-шахтер шагыйрьнең бөтен иҗат гомере буена аның әсәрлә-

ренең үзәк герое булып килә. Утызынчы елларның икенче яртысында М. Сөндекле «Стаханов турында җыр» дигән поэма иҗат итте.

М. Сөндекленең Бөек Ватан сугышы чорындагы әсәрләре дә беренче чиратта эшче кешенең хисе булып, тыныч хезмәтеннән аерган өчен гитлерчы фашистларга нәфрәте булып яңгырады. Бу елларда шагыйрьнең патриотик тойгылары бигрәк тә Урал образы белән бәйләп чагылдырыла. «Улларын озата Урал», «Атла, атым, ак канатым», «Урал» һ. б. шигырьләрендә ул Салават батыр токымнарының, моннан күп еллар элек Наполеонны тукмаган атлы гаскәрнең традициясен саклаган ир-егетләрнең образын тудырды.

Шагыйрьнең бу чордагы иҗатында, бер яктан, татар язма поэзиясенә нык таянуны һәм үстерүне, икенче яктан, башкорт халык иҗаты традицияләрен уңышлы файдалануны күрәбез. 1941—43 елларда язылган «Киләчәккә хатлар» поэмасында М. Сөндекле дәһшәтле сугыш чорының героик картиналарын чагылдырганда һ. Такташның шундый ук исемдәге поэмасының алымнарын файдалана. «Акъял батыр» поэмасында исә башкорт фольклорыннан килгән элементлар аеруча нык күзгә ташлана.

Сугыштан соңгы елларда шагыйрьнең иң нык илһамланып җырлаганы — шахтерлар хезмәте, Донбасс эшчеләренең хис-тойгылары булды.

Бөек Ватан сугышы тәмамлану белән ул үзенең яшьлек еллары узган Донбасска китә һәм фашистлар белән каты бәрелешләр вакытында җимерелгән шахталарны аякка бастыру, сүнгән домналарны тергезү буенча алып барган киеренке хезмәт героикасы белән якыннан таныша. 1948 елда ул «Донбасс турында уйлар» дигән шигырьләр циклы иҗат итә.

Хезмәт героикасы белән көрәш фидакарьлегенең аерылмас берлеге М. Сөндекленең «Макар Мазай» поэмасында аеруча җанлы эшләнгән образларда, кискен ситуацияләрдә чагылды. Бөек Ватан сугышына кадәр атаклы корыч коючы булып танылган Макар Мазайның сугыш вакытында дошман тылында калып, яшерен көрәш алып баруын сурәтләгән бу поэма кеше рухының ныклыгына дан җырлый.

Илленче-алтмышынчы елларда Максуд Сөндекле, Иделдә гигант төзелешләр башлану белән, Жигулига китә һәм ГЭС төзүчеләр тормышын чагылдырган шигырьләр иҗат итә.

Максуд Сөндекле йорт төзүчеләр һәм бакыр рудасы чыгаручылар, нефтьчеләр һәм корыч коючылар, Ангараны буучылар һәм Караком каналын төзүчеләр, Уфаның киҗе-мамык комбинаты тукучылары һәм Казанның кирпеч заводы эшчеләре турында яза...

М. Сөндекленең балалар өчен язылган күп санлы шигырьләр һәм поэмаларында хезмәтнең әһәмияте, яшүсмерләрнең иҗтимагый хезмәттә катнашуы, чын хәзинәнең илһамлы эш нәтиҗәсендә генә табылуы турындагы фикерләр җанлы образлар аша, кечкенә укучының зиһененә үтеп керерлек художество алымнары ярдәмендә бирелә.

Шушы елның 15 сентябрендә күренекле шагыйрь Максуд Сөндеклегә җитмеш яшь тула. Шуның биш дистә елын ярсу хезмәттә янып үткәргән әдип үзе турында шулай дип әйтергә тулысынча хаклы:

**Сөясеңме, диләр, тормышны,**
**Бу сүз миңа сәер тоела.**
**Мин күтәреп аны җилкәмдә**
**Алып киләм гомер буена.**

Хәй Вахит

# МӘХӘББӘТЕҢ ЧЫН БУЛСА

ДРАМА 3 ПӘРДӘДӘ

КАТНАШАЛАР:

Хәят Газизовна — олы яшьтәге укытучы. Урта мәктәпнең уку-укыту эшләре мөдире.
Мөршидә — 21—22 яшьтә. Яшь укытучы.
Әнвәр Галимович — 25 яшьтә. Мәктәп директоры.
Нурислам Кадыйрович — 50—55 яшьләрдә. Укытучы.
Сажидә Шакировна — укытучы. Нурисламның хатыны.
Мәликә — 40 яшьтә. Укытучы.
Таһир Сабиров — 24 яшьтә. Хәрби училище бетергән очучы. Хәятның сеңелесенең улы.
Иршат — 8 нче класс укучысы.
Фирдәвес — 8 нче класс укучысы. Нурислам белән Сажидәнең кызы.
Закир абый — Иршатның әтисе.

Вакыйга безнең көннәрдә авылда, урта мәктәп бинасында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл мәктәбендә укытучылар бүлмәсе. Тәрәзә буенда Мөршидә тора. Өстендә плащ, янында чемодан.

Мөршидә. Ямьле икән бу яклар. Авыллары бигрәк матур. *(Бүлмәгә күз сала.)* Шушында башланамыни инде аның хезмәт юлы? Бүлмәдә ике өстәл. Берсе уку-укыту эшләре мөдиренекедер. Төрле папкалар белән тулган пыяла шкаф. Диван, урындыклар, көзге. Стенада класс журналларын куюю өчен махсус шүрлек. Шунда ук төрле зурлыктагы карталар эленгән. Каршыдагы ишеккә «Директор» дигән язу ябыштырылган. *(Мөршидә директор кабинетына шакылдатып бага, җавап булмагач, ишекне ачып карый.)*

Бүген 1 нче сентябрь. Уку елы башланган көн, тантаналы көн. Мәктәп ишегалдында линейка бара. Аның шау-шуы, җыр-музыка, быргы-барабан, команда тавышлары бирегә дә әледән-әле ишетелеп тора. Мөршидәнең күңеле шунда тартыла, әмма башта чемоданын кабинетка кертеп куя. Коридордан Иршат белән Фирдәвес керә. Иршат каяндыр туп табып ала. Шул

*чакта Мөршидә кабинетыннан чыга. Өстендәге плащын салгач, ул бөтенләй яшәреп калган, укучы балалардан әллә ни аермасы да юк диярлек.*

Фирдәвес. Абау, син кем? Укырга килдеңме?

Иршат. Унынчыга?

Фирдәвес. Исемең?

Мөршидә. Мөршидә.

Фирдәвес. Ә минеке Фирдәвес.

Иршат. Фирдәвес — дәү үс.

Фирдәвес. Сигезенчедә укыйм. Аның андый үгез төсле гәүдәсенә карама, ул да сигезенчедә. Таныш булыйк. *(Кулын суза.)*

Иршат *(ул да кулын суза)*. Иршат.

Фирдәвес. Менә күрерсең, сиңа бездә ошар. О, безнең мәктәп! Районда беренче. Тиздән безнең мәктәпкә герой исеме кушалар.

Мөршидә. Герой исеме?

Иршат. Советлар Союзы Герое Вильданов бездә укыган. Мәктәпкә шуның исемен бирергә йөрибез. *(Тубын өреп тутырмакчы.)*

Фирдәвес. Йөриләр диген. Директор абый тырыша.

Иршат. Өрә беләсеңме?

Мөршидә. Эт булып өрә беләм.

*Көлеш. Шул чакта ашыгып Мәликә керә. Өстендә ирләр костюмы, галстуктан. Бер якка авышыбрак, башкаларга күтәрелеп карамыйча гына йөрүчән.*

Мәликә *(туры шкафка бара)*. Сез нишләп линейкада түгел?

Фирдәвес. Менә...

Мәликә. Син кем, укырга килдеңме? Соңлагансың. *(Шкафтан грамоталар ала. Чыгышлый тагын Мөршидәгә күз төшерә.)* Бер класста ике ел утырмагансыңдыр? Тоткарланмагыз!

Фирдәвес. Хәзер, хәзер, Мәликә апа. *(Мәликә чыгып киткәч, кулындагы букетын Мөршидәгә суза.)* Мә! Беренче класска килгән балага тоттырырсың. Бүген унынчы класс укучылары барысы да аларга чәчәк бирә. Бездә тәртип шундый.

Иршат. Бүген бөтен мәктәп чәчәккә күмелә. Әле факел алып кайткач күрерсең!

Мөршидә. Нинди факел ул тагын?

Иршат. Мәктәпкә герой исеме кушабыз дидемме?

Мөршидә. Дидең.

Иршат. Ә ул ничек була дип сора.

Мөршидә. Сорадым.

Иршат. Митингка җыйналабыз. Шунда чашаларда ут яндырабыз. Аны ничек кабызабыз дисең?

Мөршидә. Шырпы сызып. Чыжж!..

Иршат. Түгел шул. Без аны Казаннан «Мәңгелек ут»тан факел кабызып алып кайтабыз. Мәгънәсен аңлыйсыңмы? «Мәңгелек ут!» Солдат уты! Символ! Безнең йөрәкләрдә дә мәңгелек ут янсын, ди Хәят апа.

Мөршидә. Ух, кызык икән сездә.

Иршат. Бер көнне барабыз, икенче көнне кайтабыз. Өлкән класслардан берәр отличник. Эх, шул чакта фотоаппарат та булса.

Мөршидә. Нигә булмасын, була. Миндә бар.

Иршат. Ватар дип курыкмыйсыңмы?

Мөршидә. Ә син ватма.

Иршат. Теләсәң, сине дә алабыз. Әнвәр абыйга әйтәбез дә.

Фирдәвес. Җибәрмәсә?

Мөршидә. Мин качып та бара алам.

Иршат. Җыен. Яратам поход чыгарга! Ату этиләр революциясен дә ясаганнар, колхозын да оештырганнар, фашистын да дөмектергәннәр. Безгә берни калмаган. *(Ишеккә юнәләләр.)*

Фирдәвес. Әйдә, сүз бирешәбез дус булырга. Ни генә булса да, бер-беребезнең сүзеннән чыкмаска.
Мөршидә. Әлбәттә, без дус булабыз.
Фирдәвес. Танцевать итә беләсеңме? Безнең өйдә пластинкалар тау кадәр.
Иршат. Линейка!

Мәлика керә.

Мәлика. Үтте дә инде линейка.

Иршат белән Фирдәвес Мөршидәне алып тышка ашыгалар. Анда кәчәеп килгән гөрләү тавышы ишетелеп тора. Менә Сажидә керә. Чәчәкләрен вазага утырта.

Сажидә. Белеп торасың, күпме мәшәкать көтә сине монда. Еларга җитешкән чакларың була. Ә сагынып кайтасың.
Мәлика. Бөтен авыл — аналары-балалары — мәктәпкә агыла. Сабан туе диярсең.
Сажидә. Беренче сентябрь.
Мәлика. Һәркайсының авызы ерылган.
Сажидә. Нәрсәдән бу, мин беләм.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.

Залдан музыка ишетелеп тора. Кайсыдыр гармунда марш уйный. Нурислам керә.

Нурислам. Классларыгыздан сорагыз әле, былтыргы китапларын тапшырсыннар. Дәреслексез калучылар бар.
Мәлика. Бу тотынган да инде. Минем кул күтәрелми әле. Ялны озаккарак сузасы килә.
Сажидә *(Мәликәне әйләндереп-әйләндереп карый)*. Кырым килешкән сиңа.
Мәлика. Диңгездән чыкмадым. Ә син, Нурислам, елның-елында отпускыдан йончылып кайтасың.
Сажидә. Печән әзерләп, утын артыннан йөреп җәе үтә дә китә. Кызганып та бетерәм үзен.
Мәлика. Мин быел яңа кәсепкә өйрәнеп кайттым. *(Папирос чыгара.)*
Сажидә. Хәят Газизовна күрсә!
Мәлика *(авызына капкан папиросын кире алып)*. О-о, да, малай! Ул кире кайткан бит. Быел хәлләр була икән. Пенсиягә чыкканына ничә ел иде?
Сажидә. Биш.
Мәлика. Биш елдан соң кире кайт, имеш.
Сажидә. Директор кайтартты. Ни әйтсәң дә, үз укытучысы. Пенсиясен алып, тыныч кына яшәсә ярамаган. Болай да ихтирам итәбез.
Мәлика. Хөрмәт дисәң хөрмәт, дәрәҗә дисәң дәрәҗә. Атказанган укытучы, депутат. Миңа шуның чиреге генә эләксә дә... *(Сажидәгә.)* Прическаң, ух! Прелесть!
Нурислам. Хөрмәт зур. Райком секретаре авылга килсә, иң элек аның янына кереп чыга.
Сажидә. Ярты районың анда укып чыксын да.
Нурислам. Укучылары бөтен илгә таралган. Кайсы доктор, кайсы конструктор.
Мәлика. Почтальон зарлана икән, бу Хәят апага хат ташый-ташый ничә туфли туздырдым инде, дип.
Нурислам. Мин аның кире кайтуына сөендем.
Сажидә. Сөенмәдем. Көт тә тор, үз гадәтләрен кертә башлар.
Мәлика. Почмакка бастыра инде. Кыл өстендә йөргән кебек кенә йөрерсең.
Сажидә. Үзенә дә тынгылык булмас, безгә дә.

Нурислам. Аның белән эшләве иплe.

Сажидә. Сиңа нәрсә, син аның симпатиясе.

Мәликә *(күңелле көлеп)*. Мине җене сөймәде. Шәкерте чагында да, коллегасы булгач та.

Сажидә. Әлегә кадәр мәктәптә бер начальник иде, хәзер икәү булыр инде.

Әнвәр керә. Зәвык белән киенгән.

Әнвәр. Хәят Газизовна күренмәдеме?

Мәликә. Үзсүзле булып чыктыгыз да соң, Әнвәр Галимович. Булдырам дигәнегезне булдырмый калмыйсыз.

Сажидә. Хәят Газизовнаны кире кайтарып бик дөрес эшләдегез. Шундый белемле, тәҗрибәле укытучының эшләми ятуы үзе дөрес түгел.

Нурислам башын чайкап тора, Мәликә белән карашып алалар.

Нурислам. Көндерүе дә җиңел булмагандыр.

Һәркайсы үз эше белән мәшгуль. Беренче дәрескә әзерләнәләр. Кайсы расписание янында, кайсы планын карый.

Мәликә. Әнвәр өчен риза булган инде. Ярата ул сезне. Шундый директор белән эшли алмадым дия иде.

Әнвәр. Мәликә ханым, ялагайланасыз түгелме?

Мәликә. Директорга ялагайлансаң, яшәве җиңелрәк... Бездә пепельница булырга тиешме, юкмы?

Әнвәр. Анысын Хәят Газизовнадан сорагыз инде. *(Көләләр.)* Дөресен әйткәндә, Хәят Газизовна белән эшләве җиңел булмас. Холкы. Әмма ул мәктәпкә кирәк.

Мәликә. Үзеннән бигрәк дәрәҗәсе.

Әнвәр. Анысы да исәпкә алынган.

Мәликә. Мәктәпкә бирәр әйбер кирәк булдымы, аны гына сорыйсың: «Шалтыратыгыз әле». Ә ул: «Алло, райбашкарманы бирегез. Гали Галиевичмы?» Ә тегесе: «Кем әле бу? Ах, Хәят Газизовна? Тыңлыйм. Тыңлыйм сезне. Ни йомыш? Сорагыз, нәрсә җибәртим? Машинамы? Телевизор? Ах, робот? Табам, сезнең өчен җиде кат җир астыннан табам. Мәскәүдән кайтартам. космостан китертәм». *(Көлеш.)* Бишенче «а» журналы синдәме?

Нурислам. Хәят апа — олы хакыйкать сакчысы. Кыйбласыннан тайпыла торган адәм түгел.

Мәликә. Юкка без мәктәпкә Вильданов исемен бирергә йөрибез. Мин тотар идем дә Хәят Газизовна исемен кушар идем. Ул мәктәпнең анасы. Уен эшме, ярты гасыр.

Әнвәр *(кабинетыннан чемодан алып чыга)*. Бу нинди чемодан? Кем калдырган моны?

Сажидә *(күреп алып)*. Килә! Хәят Газизовна!

Барысы да каршыларга әзерләнә.

Сажидә. Ай, музыка да булса!

Мәликә. Нигә булмасын, була ул. *(Кулына линейка ала.)* Сезнең өчен опера театры да, филармония дә булдым инде.

Нурислам. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Мәликә шаярып марш җырлап җибәрә. Хәят керә. Кечерәк гәүдәле, чәчләренә ак төшкән.

Мәликә *(шаяру катыш)*. Хөрмәтлебез Хәят ханым, сезне үз арабызда күрүебезгә бик шатбыз. Икенче яшьлегегез белән котларга рөхсәт итегез!

Көлешәләр. Исәнләшәләр.

Хәят. Мәктәпне яңа уку елына әйбәт әзерләгәнсез.
Әнвәр. Тырыштык инде.
Хәят *(өстәле янына уза)*. Нәрсәдән башлыйбыз?
Мәликә. Билгеле инде: графигың бармы, планың төзелгәнме, класс белән эшләнәме, ата-аналар белән сөйләштеңме, лекцияләр укыламы, дәфтәрләр тикшереләме, икеләләр юкмы, түгәрәк эше юлга салынганмы? *(Кул айкап.)* Тавык чүпләп бетермәс.
Саҗидә. Сез, Хәят апа, бик арып-талып эшләмәссез инде, үзегезне сакларсыз.
Хәят. Үзем әз-мәз эшләп, сездән дә шул кадәр генә сораргамы? Булмас, Саҗидә гөлкәй, өмет итмә.
Мәликә. Башланды.
Хәят. Дәвам итә. Биш ел тәнәфестән соң.
Мәликә. Туры әйткәнгә каефегез китмәсен, Хәят ханым, кан эчәргә ярата торган адәм сез.
Хәят. Мактавыгыздан эреп киттем, Мәликә әфәндем.
Нурислам *(җәелеп көлә)*. Болай башланса, без бик тыныч яшәрбез. Карагыз аны, Хәят Газизовнаны юк-бар белән алҗытмаска.
Мәликә. Ике тегермән ташы арасына салып он итәбез дә, коймак пешереп ашыйбыз әле без аннан.

Ишектә Фирдәвес күренә.

Фирдәвес. Мөмкинме? Әни, кил әле. Әни, унынчы класска бер кыз килде. Торырга урыны юк. Квартирга безгә керсен.
Саҗидә. Гомуми торак ясамакчы буласыңмы?
Фирдәвес. Әни, дим.
Саҗидә. Күрмәгән-белмәгән. Сөйләшербез әле.
Фирдәвес. Без аның белән дусланып та өлгердек инде. *(Нурисламга.)* Әти!
Саҗидә. Кем ул, нинди укучы?

Ишектә Мөршидә күренә.

Фирдәвес. Менә үзе.
Әнвәр *(Мөршидә каршына ашыга)*. Килмисең дип торам. Нигә хәбәр итмәдең, каршы алдырган булыр идем.
Мөршидә. Үз аягым белән килеп керәсем килде.
Әнвәр. Коллегалар, кабул итегез, безгә яңа укытучы!
Мөршидә. Исәнмесез!
Саҗидә. Сез кем соң, укытырга килдегезме, укыргамы?
Әнвәр *(көлә)*. Яшь булгангамы? Укытучы, укытучы. Мөршидә Хәлиловна.
Мәликә. Тагын бер итәк. *(Саҗидәгә.)* Мәликә абыегызның бәһасе арта, малай.
Фирдәвес *(аптырап кала)*. Ә... Исәнмесез... гафу итегез, Мөршидә Хәлиловна. *(Чыгып китә. Укытучылар көләләр.)*
Мәликә *(исәнләшә)*. Мин дә укырга килгән дип торам. Институттанмы?
Мөршидә. Институттан.
Мәликә. Хәзер анда сезне шулай өйрәтәләрмени? Эшкә килгәч иң элек балалар белән коридорда әүмәкләшеп алырга?
Мөршидә. Уйнап каласым килде. Соңыннан тәтемәс. Укытучы булып киткәч, без бик җитди кеше булырга тиеш бит инде.
Нурислам *(килеп исәнләшә)*. Нинди фәннән?
Мөршидә. Әдәбият.
Саҗидә. Ничек әдәбият?

Пауза.

Мөршидә. Ял йортында булганыгыз бардыр? Бер өстәл артында утырасын, барысы да ят кеше. Беренче көнне «Исәнмесез»дән узмыйсың. Икенче көнне: «Исемегез ничек?» Өченче көнне: «Кайда эшлисез?» Җиденче көнне генә телләр ачыла. Без бергә эшлисе кешеләр, әйдәгез, сразо җиденче көннән башлыйбыз.

Мәликә. Рәхим ит.

Мөршидә. Исемем Мөршидә. Пединститутның өченче курсын бетердем. Ике елы калды. Заочныйга күчтем. Кыйблам — дөреслек. Эчемдәге — тышымда. Ялган сөйләргә яратмыйм, хурланам. Иң курыкканым — үземне-үзем кызгану. Киноактриса булырга хыялланган идем — Софи Лорен. Тәтемәде. Бәлки укучыларымнан берәрсе ирешер дип юанам. Үзем укыганда сезне — укытучыларны — кызгана идем, безнең ише башкисәрләр белән җәфаланганга. Менә үзем дә сезнең хәлгә төштем. Язмыш.

Сажидә. Җиденче көн икән, алайса, мин дә әйтәм. Эшкә килдегез. Әгәр дә урын булмаса? Әдәбиятны сезгә караганда өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк кеше алып барса? Сез, сеңелкәем, кеше урынына килгәнсез.

Мәликә. На живое место.

Мөршидә. Миңа буш урын бар диделәр. Әнвәр абый?

Әнвәр. Урын бар. Нурислам Кадыйрович икенче эшкә күчә. Районга. Югарырак урынга. Райбашкарма белән сөйләшенгән.

Нурислам. Ничек? Үзем белән киңәшергә дә кирәк тапмадыгыз?

Әнвәр. Иптәшнең килүе-килмәве билгеле үк булмаганга алдан сүз кузгатырга, ничектер... Бирелдәге перспективагыз кайда?! Дипломсыз.

Сажидә. Яшь иптәш тә дипломын чыгарып салмады әле.

Нурислам. Сажидә, кирәкми.

Әнвәр *(Мөршидәгә)*. Завуч нагрузка бирер. Расписание, программа белән бүген үк таныш. Иртәгедән эшкә. Хәят Газизовна, әдәбият дәресләре. Бишенче, сигезенче классларга.

Сажидә. Ул вакытында килмәгәнгә, Нурислам гаепле микәнни?

Нурислам *(кисәтеп)*. Сажидә дим!

Сажидә. Юк икән, дөньяда дөреслек юк икән ул.

Нурислам коридорга ук чыгып китә.

Хәят. Анда балалар белән туп тибешеп йөрүче син иденме?

Мөршидә. Мин идем.

Хәят. Типтенме соң?

Мөршидә. Булмады. Мин тибәм дигәндә генә бер житезе финт ясап өлгерде. Мин һавага тибеп калдым.

Хәят. Мастерской тәрәзәсен син ватмадың, алайса?

Мөршидә. Мин түгел. Әгәр дә сезгә шулай кирәк икән, рәхим итегез, мин дип уйлагыз. Мин ваттым. *(Пырхылдап куя.)*

Хәят. Бу ни эшең?

Мөршидә. Беренче очрашкан момент. Сез мине тырпаеп каршыладыгыз.

Хәят. Ә без сине берничек тә каршыламадык. Килдең, киттең.

Мөршидә. Ничек?

Әнвәр. Хәят Газизовна, приказга кул куелган.

Хәят. Әнвәр, утыр. Утыр. Алып куй ачкычыңны. Нурислам эшләячәк.

Әнвәр идәндә аунап яткан ачкычын алып, кабинет ишегенә тыгып куя.

Мөршидә *(аңа кызык. Бер Әнвәргә, бер Хәятка карап)*. Нәрсә, сез роно приказына да, директорга да буйсынмыйсызмыни?

Сажидә *(сөенеп)*. Хәят апа хакыйкатькә генә буйсына ул. Дөрес эш түгел икән, ник шунда министрның приказы булмый.

Хәят *(кисәтеп)*. Сажидә, классыңда тәртип микән?

Мөршидә. Гаҗәп икән сездә, директордан да кодрәтлерәк кеше бар икән.

Хәят. Берәр учреждениегә килсәң, сүз дә булмас иде. Син мәктәпкә килгәнсең. Балалар тәрбияләргә. Шуңа хакым бар дип уйлыйсыңмы?

Мөршидә *(аптырап кала)*. Хакым?

Хәят. Укытучы бер ай алдан килә. Әнә, безнекеләр инде һәр баланың өендә булдылар, тикшерделәр, барладылар. Программа каралган, план төзелгән. Класслар әзерләнгән.

Мөршидә. Әнвәр абый, рәхмәт, булышырга теләдегез. Инде булмый икән, нишләмәк кирәк, сездән калмады. Олы юлга кадәр озатып куймаслармы? *(Чемоданына үрелә.)*

Әнвәр. Ашыкма. Хәят Газизовна шаярта ул. Хәят апа!

Хәят. Кайтсын, укуын дәвам иттерсен.

Әнвәр *(елмаеп кына)*. Сез беренче көннән үк минем дәрәҗәмә кизәнәсез түгелме?

Хәят. Дәрәҗәң өчен борчылырга сәбәп күрмим. Әнә яңа салдырган интернатың, мастерской, юнәткән приборларың, җиһазлар — барысы да дәрәҗәң сагында торалар. Бар, кул күтәреп кара! Дөрес әйтәмме, коллегалар?

Саҗидә. Роно мөдире конференциядә дә Әнвәрне теленнән төшермәде.

Әнвәр. Ярар, бетерик. Хәл ителгән мәсьәлә буенча конфликтка кермик.

Бу темага сүз беткәнлекне аңлатып, Хәят урыныннан ук кузгала.

Әнвәр. Хәят апа! Хәят Газизовна! *(Һаман да юмор катыш.)* Карагыз әле, Хәят ханым, кем соң бездә директор?

Хәят. Син.

Әнвәр. Шулай булгач, кем кемгә буйсына соң?

Хәят *(исе дә китмичә)*. Син миңа.

Әнвәр. Мин сезгә?

Хәят. Син минем укучым.

Әнвәр. Укучыгыз буларак, әлбәттә, буйсынам. Әмма директор буларак...

Хәят. Директор минем укучым. Укучым буйсына икән, димәк, директор да буйсыныр.

Әнвәр. Ой, үз башыма китергәнмен, ахры, мин сезне.

Мәлика. Акыллы кеше бер салган камытны икенче кияме? *(Көлә.)* Терсәгегезне тешләгез инде.

Шул чакта беренче дәрескә чакырып, озак итеп звонок шалтырый. Беренче звонок. Бөтен мәктәпнең дәррәү купканы бирегә дә ишетелә. Укытучылар кузгалалар.

Хәят *(аягүрә басып)*. Хөрмәтле иптәшләр! Яңа уку елы башлану белән тәбрик итәм! Җаваплы, авыр, шулай да яраткан эшегездә уңыш телим.

Укытучылар. Рәхмәт, рәхмәт.

Олы юл алдыннан утырып тын калалар. Аннан планнарын, класс журналларын алалар.

Мәлика. Йөрәк... Беренче күрешүгә баргандагы кебек.

Сөйләшә-сөйләшә классларга таралалар.

Әнвәр. Мөршидә, син бераз гына утырып тор. Мин хәзер. *(Чыга.)*

Хәят *(каршысына кергән Нурисламга)*. Нурислам, классыңа, классыңа!

Ул да чыга. Бирелә Мөршидә генә кала. Аптыраган. Нурислам аның янында тоткарлана.

Н у р и с л а м. Нишлибез инде? Уңайсызрак килеп чыкты.
М ө р ш и д ә. Сезгә ни... Сез барыгыз, дәрес башланды.
Н у р и с л а м. Ә син?
М ө р ш и д ә. Мин нәрсә...
Н у р и с л а м. Чыннан да, укуыңны дәвам иттерсәң соң.
М ө р ш и д ә. Эшләргә кирәк. Быел сеңелем дә укырга керде. Әнинең үзенә генә авыр.
Н у р и с л а м. Әтиең юкмыни?
М ө р ш и д ә. Нурислам абый, классыгыз кетә.
Н у р и с л а м *(ишек буенда туктала)*. Кара инде, берәр җаен табып булмас микәнни. Минем аркада килеп чыккан кебек. *(Борчылып чыгып китә.)*

Мөршидә тәрәзә буенда. Т а һ и р керә, хәрби киемнән. Гаҗәпләнеп кала.

Т а һ и р. Мөршидә?
М ө р ш и д ә *(ул да гаҗәпләнгән)*. Таһир?
Т а һ и р. Әллә күземә күренәсең инде. Синме бу? Нишләп монда син?
М ө р ш и д ә. Ә син нишләп биредә?
Т а һ и р. Минем туган авылым. Ничек килеп чыгарга булдың?
М ө р ш и д ә. Безгә исәнләшергә кирәк түгелме соң? Күрешмәгәнгә айдан артык.
Т а һ и р. Исәнмесез. Күрми китәм дип торам. Мин сине эзләдем. Институтыңа да кердем, гомуми торагыңа да... Китәм бит, Мөршидә.
М ө р ш и д ә. Нишләп алай кисәк кенә? Ике ел да эшләмәдең.
Т а һ и р. Хәрби кеше. Синнән сорап торалармыни? Күчерәләр. Көнчыгышка... Менә шәп булды, үзең килдең. Мең рәхмәт сиңа. Кил әле, туйганчы бер карап калыйм әле күзләреңә?
М ө р ш и д ә *(көлә)*. Моңарчы вакыт юк иде шул.
Т а һ и р. Әйтмә инде! Шайтан алсын, бергә чакта кадерен беләсеңмени?! Менә аерылгач үкендерер. Күпме очрашырга була иде, шундый күңелле итеп. Ә без...
М ө р ш и д ә. Үпкәләүдән бушамадык.
Т а һ и р. Башкалар белән биегән өчен дә. Ахмак! Хәзер хат аша гына сөйләшергә кала. Атна саен язачакмын. Ә син?
М ө р ш и д ә. Җавап бирермен.
Т а һ и р. Анысына да рәхмәт. Тукта, тукта... очрашу сөенеченнән... Нигә килдең әле син монда?
М ө р ш и д ә. Укытырга.
Т а һ и р. Укуыңны ташлап? Кая, аның мәктәбенә?
М ө р ш и д ә. Әүлия син. Күңелемдәгеи әллә кайдан белеп торасың.
Т а һ и р. Мин сине роман укыган кебек...
М ө р ш и д ә. Кая ул роман, кечкенә бер хикәя.
Т а һ и р. Әгәр дә мин нәтиҗә ясасам?
М ө р ш и д ә. Синең нәтиҗә ясамаган чагың бармы соң?
Т а һ и р. Аның янына килдең?
М ө р ш и д ә. Бу бит синең дә авылың. Бәлки синең белән очрашырга өметләнеп килгәнмен?
Т а һ и р. Шаяртма. Нәрсә уйладың син? Хет минем белән киңәшсәң иде. Ни дип килдең?
М ө р ш и д ә. Чакырдылар.
Т а һ и р. Шулай. Әлбәттә. Килергә теләүчесе табылгач, чакыручысы табылыр.
М ө р ш и д ә. Директор үзе чакырды.
Т а һ и р. Ә мин нәрсә турында әйтәм?!
М ө р ш и д ә. Ләкин юкка килгәнмен. Завучлары дәрес бирмәскә итә.

Таһир. Хәят апа? О, аңа эләксәң. Минем әнинең апасы.
Мөршидә. Әйтәм аны мине ошатмады.
Таһир. Ә ни өчен ул сине ошатырга тиеш? Мин ошатканы да җиткән.
Мөршидә *(көлә)*. Син чамадан чыкма, ышанып куюым бар.
Таһир. Кире кит. Бүген юк. Хәзер юк.
Мөршидә. Син дә куасың? Сездә кунакны сәер каршылыйлар.
Таһир. Мин шәһәргә җыендым. Сине үземнән калдырмыйм. Укуыңны тәмамла. Ярым-йорты булып калмассың.
Мөршидә. Миңа эшләргә кирәк. Әнинең үзенә генә авыр.
Таһир *(уйлап тормастан)*. Үзем ярдәм итәрмен.
Мөршидә *(бу кадәресен юк көтмәгән иде)*. Син? Ни дип?
Таһир *(үзенә дә уңайсыз)*. Дусларча. *(Тавышын күтәреп.)* Әҗәткә. Эшли башлагач түләрсең.
Мөршидә. Ой, көлеп үләрсең. Мин кем сиңа? Ике ел буе... бөтен эшләгәнең җитмәс. Ах, син мине сатып алмакчы.
Таһир. Дура!
Мөршидә. Рәхмәт.
Таһир. Гафу ит... Синнән нинди укытучы. Кем булам дисәң дә гаҗәпләнмәс идем, әмма укытучы...
Мөршидә *(хәтере калып)*. Кызык, techпединститутка ни өчен кердем икән соң мин?
Таһир. Анда укырга җиңелрәк булган өчен.
Мөршидә. Әгәр дә профессиямне яратканга кергән булсам? Беләсең килсә, курчак уйнаганда да укытучы булып уйнап үстем.
Таһир. Шул курчак уйнаганда гына булса инде.
Мөршидә. Синеңчә, кеше анадан туганда ук укытучы булып туамы?
Таһир. Характер булырга тиеш.
Мөршидә. Нишләгән минем характер?
Таһир. Күбәләк.
Мөршидә. Ә мин аны сындырам. Сындырам да яңадан ябыштырам. Характер! Характер минем белән тумаган, ничек кирәк, шулай әвәлим мин аны.
Таһир. Бик җиңел генә.
Мөршидә. Күпме авыр булса, ирешүе шул кадәр кызыклырак.

Хәят Газизовна керә. Мөршидә коридорга чыга.

Таһир. Дәү апа, ни эшең бу синең? Яңа укытучыны нишләп кабул итмисең?
Хәят. Нәрсә әле син мәктәп өчен бик борчылып йөри башладың?
Таһир. Кеше килгән. Бала түгел, кая килгәнен, ни өчен килгәнен белеп килгән. Димәк, шулай кирәк тапкан. Димәк, шулай сөйләшенгән, килешенгән. Директор үзе китергән. Шулай булгач, аларның планнарын җимерергә ни хакың бар?! Аңлаган кешегә аңларлык бит.
Хәят. Аңлыйм.
Таһир. Әйдә, килә бирсен. Килсен. Аны сайлаган икән. Уңыш телим. Теләгенә ирешергә язсын.
Хәят. Алмыйча да булмас. Мәктәпкә килен булып төшкәч.
Таһир *(яшен суккандай)*. Кем әйтте аны?
Хәят. Үзең әйтеп торасың лабаса.
Таһир. Мин нәрсә әйтмәм. Ә син шуңа юл куеп утырасыңмы?
Хәят. Миңа сиңа мә. Алмадык — ярамады, алабыз — тагын ярамый.
Таһир. Дәү апа, моңа юл куярга ярамый.
Хәят. Ни булды сиңа?
Таһир. Алма. Китсен. Монда калырга ярамый аңа. Калса, барысы да җимерелә.

Х ә я т. Сине аңлавы кыен.

Т а һ и р. Син көчле бит, теләсәң, эшли аласың. Юлын тап. Тап җаен. Китсен. Калмасын.

Коридордан Ә н в ә р Г а л и м о в и ч керә.

Ә н в ә р. Башлап җибәрдек. Хәерле сәгатьтә. Хәзер алда — митингка әзерләнү тора. Митинг, митинг...

Т а һ и р *(тагын кабынып)*. Кешене китергәннәр икән, кабул итмәскә синең ни хакың бар? Чакырып китерүчесе дә үзенә кәләш кирәк булган өчен китермәгәндер. Башы ике түгел! *(Үзе Әнвәрнең җилкәсенә кулын сала.)* Ә синең мәктәпкә кире кайтуыңны хупламыйм.

Х ә я т. Ишеттек.

Т а һ и р. Син кирәкме аңа? Дәрәҗәң кирәк.

Х ә я т. Алсын, кызганыч түгел.

Т а һ и р. Ул сиңа ышыкланып эшләргә тели.

Х ә я т. Ышыклансын, тик эшләсен генә.

Т а һ и р. Уңыш килсә, үзенә алыр, авырлык килсә, җаваплылыкны сиңа сылар.

Х ә я т *(кисәтеп)*. Таһир!

Т а һ и р. Бигайбә! *(Чыгып китә.)*

Ә н в ә р. Ни булган моңа, елан чакканмы әллә? *(Башын чайкап тора.)* Хәят Газизовна, мин сезгә үпкәләдем. Үзегезне остазым дип исәплим. Сезнең идеяне тормышка ашыру өчен җан-фәрман тырышып йөрим. Отряд оештырдым, факел ясаттым. Бүген-иртәгә мәңгелек уттан кабызып кайтачаклар. Ә сез...

Х ә я т. Минем өчен генә булса...

Ә н в ә р. Мәктәпкә исем сайлаганда да беренче чиратта сезнең турыда уйладым. Герой безнең мәктәптә укыган дибез икән, димәк, ул сездә укыган. Сезнең тәрбия, сезнең җимеш, сез аны олы юлга чыгаргансыз.

Х ә я т. Хәтерләмим. Утыз елдан артык вакыт узган. Барысын да кайдан хәтерләп бетерәсең. Аның мәктәбе дә ул түгел инде. Юк, хәтерләмим.

Ә н в ә р. Сездә укып чыкканнар арасында кемнәр генә юк. Бер-ике геройны кушып санасак та, хәрәм булмас.

Х ә я т. Миңа Әнвәр укытучысы дисәләр дә бик җиткән, мактаулы директор.

Ә н в ә р *(ике сөйләргә урын калдырмыйча)*. Герой сездә укыган! Мәгънәсе нинди бит, мәктәп сезнең укучы исемен йөртәчәк. Почти сезнең исемне дигән сүз.

Х ә я т. Син аллегорияләр белән сөйләргә өйрәнеп киткәнсең. Мәктәп герой исемен йөртәчәк! Аның мәгънәсе шул.

Ә н в ә р. Яраткан укытучысы белән яраткан укучысына бергә-бергә эшләве күңеллерәк булыр дигән идем. Болай булгач, гариза язарга туры килер микәнни? *(Хәятның карашын тоеп.)* Үзең бер авылда, хатының икенче авылда эшләмәс бит.

Х ә я т *(бераз көттереп)*. Тәбрик итәм. Кайчан булды әле ул?

Ә н в ә р. Әле язылышуын язылышмаган. Шулай да без инде өйләнешү алдында. Бүтән булмаса, иртәгә. Менә ич, кайтты. Институтын ташлап минем янга кайтты. Шулай, Хәят Газизовна. *(Кабинетына уза.)*

Хәят уйга кала. Аннан коридордан Мөршидәне чакырып кертә.

Х ә я т. Я, Мөршидә... Хәлиловна! Нишлибез?

М ө р ш и д ә. Бер-беребезне онытабыз. Мин килмәдем, сез мине күрмәдегез.

Х ә я т. Минемчә дә шулай хәерлерәк булмасмы?

М ө р ш и д ә. Килештек. *(Чемоданын ала.)* Хушыгыз.

Хәят. Сабыр ит. Менә расписание. Күчереп ал. Программа, планнар турында... Нурислам абыең ярдәм итәр. Сорарга оялмасаң. Оялсаң, үземә кил.

Мөршидә. Оялмам. Хәзер оялырга өйрәтмиләр. Киресенчә, кыю булырга өйрәтәләр.

Хәят. Болай сөйләшәбез. Башта син минем дәресләргә керәсең, аннан мин синекенә.

Мөршидә. Мин сезнекенә — шатланып. Сез минекенә... бер шарт белән. Гадел булырга. *(Расписаниесен күчерергә дип кәгазь әзерләгән җиреннән тукталып кала.)* Хакым бар микән соң?

Хәят. Хакны казанырга кирәк. Хезмәт белән.

Мөршидә. Мин калмам, ахры. Кеше урынына. Юк.

Хәят. Китәсең? Кая?

Мөршидә. Күзем кая карый.

Хәят. Хәзер үкмени?

Мөршидә. Хәзер үк.

Хәят. Ял итмәгән, ашамаган-эчмәгән килеш?

Мөршидә. Адәм баласы бер тәгам ризык капмыйча атналар буе түзә ала.

Хәят. Утыр!

Мөршидә. Утырдым.

Хәят. Ал кәгазь.

Мөршидә. Алдым.

Хәят. Күчер!

Мөршидә. Күчерәм.



Ут сүнә. Музыка. Без анда балаларга хас шаянлыкны, мәктәп тормышына хас гөрләшүне ишетәбез. Хәтта музыка астында укучыларның шау-шулы гүләүләре, аерым сөйләшүләре дә ишетелеп китә. Кульминациясендә исә балалар хоры — поход жыры янгырый башлый... Ут кабына. Поход жыры дәвам итә. (Әгәр дә бу сценаны мәктәп баскычында я коридорда бирергә мөмкинлек булмаса, эчке пәрдә алдында — авансценада күрсәтергә мөмкин.) Факел тотып Иршат керә. Директорны эзләве. Менә Әнвәр белән Мәликәне очрата.

Иршат. Әнвәр абый, кайда саклыйбыз?

Әнвәр. Пионерлар бүлмәсендә.

Иршат. Озаккамы?

Әнвәр. Иртәгә кадәр. Иртәгә көндез митинг.

Мәликә. Сез анда пожар чыгара күрмәгез.

Фирдәвес (*килә*). Әнвәр абый!.. Дөрес буламыни ул алай? Факелны малайлар гына сакласын, имеш. Ә без? Ә кызлар?

Иршат. Кызларны катнаштырмыйбыз. Бу — малайлар эше.

Әнвәр. Факел янында малайлар да, кызлар да сакта торачак.

Фирдәвес (*Иршатка*). Ишеттеңме?

Иршат. Синең тыгылмаган җирең булмас.

Әнвәр. Әйдәгез әле!

Каршыларына Хәят очрый. Иршат белән Фирдәвес китә. Әнвәр туктала.

Хәят. Укытучылардан дежур куярга кирәк булмасмы?

Мәликә. Мәгънәсе зур инде зурын. Яшь буынны патриотик рухта тәрбияләү өчен. Шулай да сүзегезне ишетәсе килә, Хәят ханым.

Хәят. Иртәгә, Мәликә, иртәгә. Митингта.

Мәликә. Бик зур мәшәкать куптарабыз түгелме?

Хәят. Ә син ничек уйлыйсың, кеше үстерү җиңел генә, мәшәкатьсез генә була торган эшме? Инженер йорт төзи, конструктор машина ясый. Ә безнеке катлаулырак.

Музыка шушы репликага кадәр дәвам итә. Дәрестән чыгарга бирелгән звонок кына аны бүлдерә. Звоноктан соң ук мәктәпне дер селкетеп класслардан чыккан балаларның шау-шуы ишетелә. Эчке пәрдә ачыла.

Укытучылар бүлмәсе. Х ә я т, М ә л и к ә, С ә җ и д ә керә. Журналларын шүрлеккә куялар. Сәҗидәнең култык астында бер кочак дәфтәр.

С ә җ и д ә *(дәфтәрләрен өстәлгә салып)*. Кузгалмыйча утырсаң да таң атканчы җитәрлек. Сукыраям инде бу дәфтәр тикшереп.

М ә л и к ә. Дөньяда иң күп эшләүче кеше — укытучы.

Ә н в ә р керә, кабинетына юнәлә.

Ә н в ә р. Хәят апа, сезне тәбрик итәргә кирәк икән. Таһир өйләнгән ди ич.

Х ә я т *(теләр-теләмәс)*. Йөри шунда.

С ә җ и д ә. Таһир? Өйләнгән дәме? Ни ара?

М ә л и к ә. Күптән вакыт иде.

Х ә я т *(каршында көзге, ә көзгедә авызына папирос капкан Мәликә)*. Борып куйчы шул көзгене. Күз алдымда чекерәеп утырмасын.

М ә л и к ә *(көзгегә карый да шаркылдап көлеп җибәрә)*. Бор, бора күр. Начальство күзенә чалынып утыруны үзем дә яратмыйм. *(Шулай да папиросын сүндерә.)*

Ә н в ә р. Сәҗидә Шакировна, түгәрәк эше ничек тора? Планы төзелгәнме?

С ә җ и д ә. Төзедем, төзедем.

Ә н в ә р. Кая, карап чыгыйм әле. *(Кабинетын ача да кереп китә. Ачкычы ишектә кала.)*

С ә җ и д ә. Хәзер, хәзер. *(Уңайсызлана. Күрәсең, планы юк.)*

М ә л и к ә *(җәелеп көлә)*. Каптыңмы? Дәресең беткәч тә кайтып китсәң соң?

Х ә я т *(кабинетка ишетелерлек итеп)*. Әнвәр Галимович, мин тикшергән идем инде.

С ә җ и д ә. Рәхмәт. Рәхмәт, Хәят апа. Оят та инде. Өлгерер хәл юк. Кайтсаң, өй тулы эш, сыеры-сарыгы. Бүген дә көтүем соңга калды. Моннан соң ничек тә... Рәхмәт.

М ә л и к ә. Киленне кайчан күрәбез? Таһир кемне бәхетле иткән?

С ә җ и д ә. Ә кемнәрне кем җылатып калдырды икән?!

М ө р ш и д ә керә. Журналын шүрлеккә куя да тәрәзә янына уза, йөзен күрсәтми.

Х ә я т. Ни булды?

М ө р ш и д ә *(елап җибәрә)*. Түзә алмадым, ычкындым.

С ә җ и д ә. Әллә инде...

М ө р ш и д ә. Алар мине кабул итмиләр. Сөйләгәнемне тыңлыйлар, яз дисәң язалар, кучер дисәң күчерәләр: янәсе, пожалуйста, сез кушканны үтибез, әмма без сезне белмибез, танымыйбыз, сез безгә чит кеше. Алар бөтенесе бер сүздә. Класслары белән. Ичмаса, шауласыннар, я тәртип бозсыннар иде, тәрәзә ватсыннар. Юк, авызларына су капканнармыни. Әйеме — әйе, шулаймы — шулай. Шуннан артык бер сүз ала алмассың.

М ә л и к ә. Купшы киенгәнне ошатып бетермиләр.

М ө р ш и д ә. Нурислам абый урынына килгәнгә. Алар аны яратканнар. Ә мине... Әнә факел алып кайттылар. Ә Иршат минем фотоаппаратка ничек кызыккан иде. Юлга әзерләнгәндә тәкъдим итеп тә карадым. Алмады. Сизеп торам: аласы бик килә, ә алмый. Протест.

С ә җ и д ә. Син нәрсә, сеңелем, мин килдем дә Нурислам абыйларын шундук онытырлар дип көткән идеңмени? Онытыла торган кеше түгел ул Нурислам. Укучылары өчен җанын ярып бирергә әзер торган кешене онытмыйлар аны. Балалар без түгел ул.

М ә л и к ә. Безнең дә онытканыбыз юк, Сәҗидә.

С ә җ и д ә. Кайда Нурислам, нишләп йөри — кайсыгызның борчылганы бар? Юаш кеше дигәч тә. Уку елы башлангач, укытучыны эшеннән алып ташларга закон釈 бармы?! Сугыш инвалидын.

Мөршидә. Сажидә апа, мин... белмәдем...
Сажидә. Кая килгәнеңне белмәскә! *(Дәфтәрләрен җыеп ала.)* Менә министерствога язсам, аннан йөрерләр! Судка китәрлек эш бу. *(Кайтып китә. Мөршидә бик уңайсыз хәлдә кала. Авыр тынлык.)*
Хәят. Син минем ярдәмемә мохтаҗмы?
Мөршидә. Бу хәлдә ярдәм итеп буламы? Миңа хәзер беркем дә ярдәм итә алмый. Хәтта сез дә.
Мәликә. Классга нишләгәнеңне әйтмәдең.
Мөршидә. Кычкырдым. Бөтенесенә. Юк, чыкмый миннән укытучы. Үземне көчкә тотып калдым.
Мәликә. Болай булгач чыга инде. Тотып калгансың ич. Беренче сынауны үттең.
Мөршидә *(яшь аралаш)*. Ә икенчесе ничек була?
Мәликә. Икенчесендә линейка гына сындырасың.
Мөршидә. Гарьлегемнән күземнән чәчрәп яшь чыкты. Бөтенесе алдында елаудан куркып, чыгып йөгердем.
Мәликә. Елаган укытучыда өмет бар. *(Кузгалалар. Иршат керә.)* Сиңа кем?
Иршат. Әнвәр абый.

Әнвәр кабинетыннан чыга.

Әнвәр. Мөршидә, онытмадыңмы, киләсе ялда клубта лекцияң.
Мөршидә. Материаллар бирермен дигән идегез.
Әнвәр *(кабинетына күрсәтеп)*. Күчереп ал. Шунда өстәлдә.

Мөршидә кабинетка керә, Мәликә белән Хәят өйләренә кайтып китәләр, биредә Әнвәр белән Иршат кына кала.

Иршат. Әнвәр абый... Ни... безнең бит... алып кайтканда ут сүнде.
Әнвәр. Нәрсә, син нәрсә сөйлисең?
Иршат. Фитиле кысылгандырмы, кинәт җил истеме, тауны күтәрелеп менүгә сүнде дә куйды.
Әнвәр. Әнә ич яна.
Иршат. Без аны шунда ук тагын кабыздык. Зажигалкадан. Мин әтинең зажигалкасын алган идем.
Әнвәр *(аптырап кала)*. Син юкны сөйләп йөрмә. Утмы — ут, янамы — яна. Бер мизгелгә генә сүнеп торган икән, аның куркынычы юк. Вак мәсьәлә. Үзең әйтеп торасың ич, шунда ук кабыздык дисең.
Иршат. Шулай да сүнде бит.
Әнвәр. Сүнмәде. Сүнә торган ут түгел ул. Мәңгелек ут. Давыл купса да, җир тетрәсә дә сүнми. Гомергә яна. Аның мәгънәсе сүнми. Ул безнең батыр солдатлар даны кебек мәңгелек. *(Иршатның чигәсенә төртеп.)* Барып җиттеме?
Иршат *(күтәрелеп карамыйча гына)*. Алдау булмасмы?
Әнвәр. Кем алдый, кемне алдый?! Нәрсә сөйләгәнеңне үзең дә аңламыйсың. Син арыгансың. Бар, булмаса кайтып ял ит.

Иршат ишеккә юнәлә.

Ә, әйе, мотоциклны чистартып куй әле. Беркөн пычратып бетергәнбез. Яңа килгән укытучы апаңны өйрәтәбез.
Иршат. Мотоциклда йөрисе килгәнмени? *(Чыгып китә.)*
Әнвәр. Балван. *(Кабинетына керә. Бераздан кабинеттан атылып Мөршидә чыга. Артыннан Әнвәр күренә. Көлә.)*
Әнвәр. Шаярырга да ярамый. Кыргый.
Мөршидә. Әнвәр Галимович!
Әнвәр. Синең өчен мин беренче чиратта Әнвәр.
Мөршидә. Минем өчен сез беренче чиратта директор, Әнвәр Галимович.

Ә н в ә р. Балалыгың чыгып бетмәгән. Кердек. Сөйләшеп кенә утырабыз.

М ө р ш и д ә. Анда кермим. Сүзегез булса биредә әйтегез.

Мөршидәгә карап тора да барып ишекне бикли. Шаярып елмая.

М ө р ш и д ә. Акылыгыздамы?

Ә н в ә р *(тагын көлә)*. Акылымны сейфка салып куйдым. Эш сәгате бетте, керәге калмады.

М ө р ш и д ә. Әллә инде...

Ә н в ә р. Әйе, исердем. Синең күз карашыңнан. Зифалыгың, нәфисләгеңнән.

М ө р ш и д ә. Ачыгыз ишекне.

Ә н в ә р. Мөршидә, безгә аңлашырга вакыт. Әнә, бөтен авыл безнең түебызны көтә. Барысының да телендә шул гына. Ә безнең әле...

М ө р ш и д ә. Иргә чыгу турында уйлаганым да юк. Ачыгыз ишекне.

Ә н в ә р. Кайчан да булса бер уйларга туры киләчәк, Мөршидә, без кичә генә очрашкан кешеләр түгел, мәктәбеңә практикага йөргән чагында ук мин сине күреп алдым. Сихерле елмаюың күңелемнән чыкмады. Мин ышанып йөрдем сиңа.

М ө р ш и д ә. Мин сезгә укытучым итеп карадым, Әнвәр абый. Сез минем укытучым.

Ә н в ә р *(елан чаккандай)*. Укытучың? Бары укытучың итеп? Түгел! Укытучың түгел мин синең!

М ө р ш и д ә *(ишекне дөбердәтә)*. Ачыгыз ишекне!

Ә н в ә р. Тилермә!

М ө р ш и д ә. Ни өчен? Ни өчен сез мине рәнҗетәсез?! Ничек җөрьәт иттегез? Минем теләгем, ихтыярым сезне бөтенләй кызыксындырмыймыни? Әнвәр хәл иткәч житкән, Мөршидәгә буйсынырга гына кала, ул йомычка, дулкын кая ыргытса, шунда ташланыр. Шулаймы?

Ә н в ә р. Бала булма. Ни өчен чакырдым мин сине. Килдең ич. Белеп килдең. Риза булып килдең.

М ө р ш и д ә. Юк! Бер нәрсә дә белмәдем, уйламадым да. Юк.

Ә н в ә р. Хәер, син унынчы класска укырга дип килгән идең бугай. Эх, син, тургай баласы. Бигрәк беркатлы. *(Ачкычны өстәлгә ыргыта. Мөршидә аны ала да ишекне ача.)* Ярар, элек белмәгән булсаң, хәзер белдең.

М ө р ш и д ә. Хәзер аңладым. Әйе, яшь кыз, институтта тагын ике елга калдырсаң ычкынуы ихтимал. Азмыни анда егетләр. Шуңа күрә кат-кат чакырдыгыз. Тау кадәр вәгъдә биреп.

Ә н в ә р. Мин икебез өчен дә кайгырттым. Синең бирегә килүең минем өчен генә түгел, үзең өчен дә кирәк иде.

М ө р ш и д ә. Ялгышасың, Әнвәр абый. Күңелем башкада. Беләм, аның миңа салкын икәнен дә беләм. Юк анда миңа карата тойгы. Күрми ул мине. Беләм, онытырга кирәк. Булдыра алмыйм. Йөрәкне йолкып алып буламыни?! Горур була алам, тәкәббер була алам. Ләкин... дәшсен генә, аның артыннан дөнья читенә китәргә әзер.

Ә н в ә р. Камчаткага? Тургаем минем. Моңлы тургаем. Ә тургай үзен таш кебек җиргә ташлап һәлак итә. Мин синең яшәвеңне телим. Коткарырга телим.

М ө р ш и д ә. Мәхәббәттән?

Ә н в ә р. Йөгәнсез мәхәббәттән.

М ө р ш и д ә. Мин котылырга теләмәсәм? Ул минем сулаган һавам, эчкән суым, җирем-күгем! Ансыз миңа тормыш юк.

Ә н в ә р. Ул өйләнгән.

Мөршидә тынып кала. Озак пауза. Музыка.

Мөршидә. Шаярмагыз... Ялганлыйсыз. Юк, булмас. Мөмкин эш түгел! Ничек инде... Өйләнгән? Ышанмыйм!

Әнвәр. Таһир өйләнгән.

Мөршидә. Юк, ышанмыйм, ышанмыйм!

Ишектә Фирдәвес башы күренә.

Фирдәвес. Әнвәр абый, Иршат мотоциклга утырып әллә кая... авылдан ук чыгып китте. *(Аңа берәү дә игътибар итми.)*

Мөршидә. Нинди хәлгә төштем! Кая килдем, нигә килдем?.. *(Тәрәзә буенда.)* Ямьсез сезнең бу яклар. Авылыгыз бигрәк шыксыз.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче көн. Класс. Биредә сугышка кадәр Советлар Союзы Герое Вильданов укыган диләр. Димәк, бу мемориаль класс булачак. Шуны әзерләү эше бара. Геройның тормыш юлын, батырлык юлын күрсәткән материалларны, истәлекләрне урнаштыру белән шөгыльләнәләр. Бу эш пәрдә буенча дәвам итәчәк. Ә хәзергә биредә Сажидә ялгызы гына. Урамнан тынлы оркестр башкаруында марш ишетелеп тора. Бераздан Нурислам килеп керә. Янгырга эләккән.

Сажидә. Менә йөр инде. Буялып беткән. Манма су. Әйтер идем инде.

Нурислам *(кәефе начар түгел)*. Әйт, әнкәсе, әйт.

Сажидә. Районга чакырып торалар, контора начальниклыгына. Окладь зур, дәрәҗәсе, машинасы. Ә ул теләми, янәсе. Кая бара диген, күрше авыл мәктәбенә. Башлангыч класска. Җиде километрга.

Нурислам. Тудый-судый, зад-перед — унбишкә җыйнала.

Сажидә. Аңла инде бу бәндәне!

Нурислам. Аңламаслык нәрсә бар, әнкәсе. Җаны теләгән — жылан ите ашаган.

Сажидә. Кеше ышанмас моңа. Менә күр дә тор, районга алмаганнар, шунлыктан башлангыч мәктәпкә кергән диярләр. Әгәр шулай булса, сүзем дә булмас иде. Мәҗбүр иттеләр, дияр идем дә тынычланыр идем. Юк бит, юк. Үзе теләп китте.

Нурислам. Хатын булып сөйлисең, Сажидә, укытучы булып түгел.

Сажидә. Ичмасам, минем белән киңәшсен иде.

Нурислам. Киңәштем, әнкәсе, бик күп тапкырлар киңәштем синең белән. Үзең белмәдең генә. Ничә мәртәбә сорасам да, гел каршы төшәсең.

Сажидә. Киңәшкән! Начальник булып, персональ машинага утырып, «зырр» иттереп авылга бер кайтып керүең үзе ни торыр иде. Йөр инде көзге пычракта, кышкы бураннарда, аксаклый-аксаклый.

Нурислам. Болай булгач йөрибез инде.

Сажидә. Сиңа нәрсә, йөрерсең. Йорттагы ул терлек, ул мәшәкать кем өстенә кала? Бер Сажидәгә?

Нурислам. Мин өлгерергә тырышырмын. Авырга китермәм.

Мөршидә керә. Кулындагы плакатын куя да Нурислам янына ашыга.

Мөршидә. Нурислам абый, исәнмесез. Күптән күренгәнегез юк.

Нурислам. Исәнме, Мөршидә. Иялэнеп буламы?

Мөршидә. Районга эшкә кергәнсез икән. Начальник булгансыз. Тәбрик итәм. Күңелегез ятамы?

Нурислам. Эшемне яратам.

Мөршидә. Күңелгә ошый торган эш булса шәп инде ул. Сезнең өчен мин бик шат, Нурислам абый. Бүген митинг, мәктәпкә герой исемен бирәләр. Калыгыз, яме?

Әнвәр керә. Кулында кнопкалар.

Әнвәр. Ә, Нурислам абый. Сәлам!

Нурислам. Саумы.

Әнвәр. Мин сезгә менә дигән эш таптым, ә сез... Мәктәпкә кендегегез ябышкан икән. Перспективага карый белергә кирәк иде.

Сажидә. Ни хаҗәтемә аңа начальник булу, машина, дәрәҗә? Ул җаны теләгән эшен сайлады. Гомер буе балалар арасында булып карагыз әле, кисәк кенә ташлап китә алырсыз микән? Нурислам абыегыз андый кеше түгел ул.

Әнвәр. Иршат кайда?

Мөршидә дәшми, аның өчен Сажидә җавап бирә.

Сажидә. Дәрескә килмәгән. Чакырырга киттеләр. Килеп җитәргә тиеш.

Әнвәр. Башкалар кайда? Митингка кадәр классны өлгертәсе иде. *(Чыгып китә.)*

Мөршидә. Нинди мәктәпкә? Кайсы авыл? Еракмы?

Сажидә. Җиде километр. Башлангычка.

Мөршидә *(уңайсызланып)*. Минем аркада. *(Карар биреп.)* Кайтыгыз кире. Үз урыныгызга кайтыгыз. Ул мәктәпкә үзем барам. Роноda хәл итәбез дә.

Нурислам. Булмый. Ул турыда сөйләргә соң инде. Класс мине үз итеп кабул итте. Аларның ышанычы белән уйнарга ярамый. Баланың ышанычын сындыру — умыртка сөяген сындыру белән бер ул.

Мөршидә *(ялынып диярлек)*. Нурислам абый!..

Нурислам. Кырык язмыш миңа тапшырылган. Бер укытучыдан икенчесенә куып йөртергә алар каз бәбкәләре түгел.

Сажидә *(кул айкап)*. Бетте инде. Аны хәзер алардан аерып алырмын димә.

Нурислам. Элекке укытучылары декретка чыккан. Болай да еш кына авырган. Былтыргы программаларын да үтеп бетерә алмаганнар. Куып җитәргә кирәк.

Мөршидә. Нишләргә инде? Мин болай эшли алмыйм. Сез анда, мин монда... Юк, болай булмый.

Нурислам. Ә син ул турыда уйлама.

Мөршидә. Уйлама! Әйтүе ансат. Сез үзегез дә инде, Нурислам абый...

Сажидә. Нурислам абыеңа ни булган?

Мөршидә. Теге чакта кулымнан тотарга иде дә җилтерәтеп чыгарып җибәрергә иде. Каяндыр, кемдер килеп сезнең урынга урнаша, ә сез... Сугышларны кичкән, ничә тапкыр яралантан солдат. Безнең буынның тынычлыгын яклагансыз, ә үзегезне яклый алмыйсыз.

Сажидә. Үзеңне яклаудан да авыр эш юк.

Мөршидә. Үзен түгел, хакыйкатьне якласын!

Сажидә. Син, сеңелем, әдәбият укытучысы, әдәбияттан чыгып хөкем йөртәсең. Тормыш әдәбият кына түгел ул. Без шушында туган, шушында төпләнгән. Семья, хуҗалык. Аларны чемоданга гына сыйдырып булмый. Алны-артны чамалабрак сөйләргә туры килә.

Нурислам *(Мөршидәгә якыная)*. Нәрсә анда класс белән? Характер күрсәтәләрме?.. Син ашыктырма, сабыр бул. Ияләнә төшсеннәр... Менә, программа буенча кайбер материаллар. Карап чык, ярап куяр. *(Мөршидә Нурисламга гаҗәпләнебрәк карап тора.)* Ал. Миңа кирәге калмады.

Мөршидә. Ой, Нурислам абый, ни дип кенә әйтим. Рәхмәт... Сезне алмаштырганмын икән, миңа хәзер сездән дә болайрак эшләргә кирәк бит инде.

Сажидә. Минем яныма кагылган дип торсам, юк икән, классы өчен кайгыртып кергән икән әле. Яшь укытучы өчен борчылып. Үзен эшеннән куган кеше өчен. Мәхлук димә инде моны. Самолюбие булмаса да булмас икән кешедә. Аның урынында, берәү булса, министрга җитәр иде инде, обкомга керер иде. Ә ул... Хуҗа Насретдин!.. Әллә күзең төште инде яшь кызга?

Нурислам. У-ха-ха... Әйтсәң дә әйтәсең. Ха-ха-ха. *(Туктала алмыйча көлә, күзләреннән яшь чыга.)*

Хәят керә. Кулында материаллар. Эшкә тотыналар.

Хәят. Сажидә, син минем кәефемне бозмакчы булдыңмы? Барып чыкмас ул ниятең. Барыбер ул яулыгыңа күз төшермим.

Сажидә. Сыер сауганда бөркәнгән идем. Онытканмын. *(Яулыгын салып портфеленә тыга.)*

Мәлика керә. Өстендә ирләр курткасы, аягында итек. Кулында камчы. Итегенә сугып куя.

Мәлика. Сәлам! Менә әйләнеп тә кайттым Наратлыдан.

Хәят *(күз кырыен гына төшереп алып)*. Рәхмәт сезгә, Мәлика ханым, бик рәхмәт.

Мәлика. Аңлашылмады, ни өчен рәхмәт алдык?

Хәят. Бирегә атка атланган килеш килеп кермәгәнең өчен.

Мәлика. Белмим, Хәят ханым, ни өчен ярата торганбыздыр сезне.

Хәят. Шушындый юкка-барга бәйләнүченеме?

Мәлика. Тырнак астыннан кер эзләүчене.

Хәят. Нигә ятратканыңны белмисенме? Менә шушылай итеп әйтә алганың өчен. Үпкәләр дип, ачуланыр дип куркып тормыйча. Мин дә аптырыйм, укучылар ни дип яратадыр үзенне?

Мәлика. Минем яратканны сизәләр, чучка танаулар.

Нурислам. Ирләр киеме боза сезне, Мәлика.

Мәлика. Үзем дә беләм. Кыска юбкалар киеп, тез-аякларымны, нечкә билләремне уйнатып йөрергә мин дә каршы түгел дә. Нишләмәк кирәк, ирексездән мәҗбүри. Детсадта баланы гел хатын-кыз тәрбияли. Мәктәптә тагын шул хәл. Менә бездә — егерме хатынга ничә генә ир. Син дә киттен. Ә балаларга ирләр тәрбиясе, ирләр йогынтысы кирәк. Шуның өчен зифа фигурамны корбан итеп йөрим. *(Хәятка.)* Ә сез тәнкыйтьлисез. Яратмыйм тәнкыйтьне. Банкетны яратам, тәнкыйтьне юк. Герой укыган классны киендерәбезме? *(Эш арасыннан җырлап җибәрә.)* Онытылмый беренче саф мәхәббәт, онытылмый...

Хәят. Кичә түгәрәккә килмәдең.

Мәлика. Белмәдем.

Хәят. Кеше җибәреп әйттердем.

Мәлика. Ул чакта соң иде инде. Сарымсак ашаган идем.

Сажидә. Нәрсә?!

Мәлика. Кеше алдында дөнья сасытып йөрмәссең. *(Көлешәләр.)*

Мәлика *(тәрәзәдән күренә)*. О, кияү кайткан ич.

Сажидә. Киленне алып кайтмаганмыни?

Хәят. Үзе дә бер көнгә генә.

Сажидә. Нишләп алай бик тиз?

Хәят. Срогы чыкты.

Мәлика. Еракками?

Хәят. Җирнең аргы башына. Камчаткага. *(Чыгарга юнәлә. Ишек буенда стенага сөялгән Мөршидә янында туктала.)*

Мөршидә *(Хәятның үзенә генә, кисәк)*. Уйламыйм мин аның турында. Бер тамчы да уйламыйм! Өйләнсен. Китсен, гомергә китсен. *(Хәят тетрәнеп куя.)*

Хәят. Мин нишләргә тиеш, арагызда ни булганын сорашыйммы? Бәлки ярдәм итә алырмын?

Мөршидә. Сез мине аңламадыгыз. Төн буе баш ваттым, һич аңлый алмыйм: ни өчен? *(Хәяткa.)* Ни өчен сез мине эшкә алдыгыз?

Хәят. Ни өчен?

Мөршидә. Алмый торганда барысы да аңлашылган иде, штат юк, нагрузка юк. Дипломы юк, җитдилеге юк. Ә шулай да кинәт алып куйдыгыз. Нагрузкасын да таптыгыз. Ни өчен? Кем нәрсә әйтте? *(Хәят дәшми.)* Әйтмәгез, кирәкми. Болай да сиздем.

Хәят. Кәләшем, диде.

Мөршидә. Әнвәр Галимович?! *(Хәят «әйе» дип башын селки дә чыгып китә.)* Һе!.. Үземнән сорап та тормый, ә. Тота да өйләнә. Йомычка. Йомычка булсаң шул инде, дулкын синнән сорап торамыни, кайсы ярга ташлыйм дип.

Малаен кулыннан житәкләп Закир керә.

Закир. Алып килдем. Ите — сезгә, сөяге — миңа.

Сажидә чыга.

Әнвәр. Табылдымы камыр батыр?

Закир. Исәнме, Әнвәр.

Әнвәр. Малаең тәртип бозган.

Закир. Кем бозмаган? Үсә-үсә утырыр әле. Бозмаска өйрәтегез. Шуның өчен акча аласыз.

Мәлика. Закир абый!

Закир. Шаярып әйтәм лә! Үзем дә үгетлим инде. Кеше буласың килсә, укы, дим. Мәктәптән кусалар, калырсың әнә этиең шикелле ат җигәргә.

Әнвәр. Дөрес әйтмәгәнсең. Хезмәт белән куркытмыйлар. Хезмәт камчы түгел. *(Иршатка.)* Мотоциклны кая куйдың?

Закир. Әйтми. Бер сүз дә алып булмый. Телен тешләгән. Үзем дә ничек кенә сорап карамадым. Каеш белән ярдым. Ята аркасын биреп. Аннан торып басты да: «Я, күңелең булдымы инде?» ди. Вәт, дуңгыз бәрәне түгел диген син аны.

Мәлика. Бишенче класста чагында шундый хәл булды. Бервакыт өйгә кайтырга җыенам. Коридорда галушымны киеп, атлап кына китим дисәм, тпруу! Аягым идәнгә ябышты да калды. Салып карасам, галушымны кемдер идәнгә кадаклап куйган. *(Үзе дә шаркылдап көлеп җибәрә.)* Ахырдан беленде, Иршат эше булган. Нинди ачуың булгандыр... *(Аласы әйберен алып чыгып китә.)*

Закир. Э-с, таш баш.

Әнвәр. Кая яшердең мотоциклны?

Закир. Инә түгел лабаса. Мөгаллимең сорый, җавап бир. *(Тузыныл.)* Муеныңны борып ташлармын!

Әнвәр. Я, кайда?

Закир. Әйтәсеңме, юкмы?!

Иршат. Юк.

Закир. Шулаймы?

Мөршидә *(куркуга калып)*. Закир абый, зинһар!

Закир. Суд аша таптырачаклар. Ахыргы сыердан колак кактырмакчы буласыңмы?

Мөршидә. Иршат, егет бул. Әйт тә сал, кайда калдырдың?

Иршат *(ирония белән).* Мотоциклга утырып йөрисегез килдемени? Анда Нурислам абый унбиш километрны җәяүләп, авырткан аягы белән... Әйтерлек булгач, яшермим дә мин аны.

Закир *(кизәнә).* Айкап торып!..

Нурислам *(туп-туры Иршат янына атлый).* А-а, герой! Син нәрсә уйлап чыгардың тагын? Баш күтәрәсең?

Әнвәр. Нурислам абыйсын кыерсытканнар ич, яклап чыга. Защитник.

Нурислам. Кем синнән сорады?! Синнән башка Нурисламны яклаучылар юк, дисеңме? Кирәк булса, ул үзен-үзе яклый алмас идеме? Бөтен классны аздырып.

Иршат. Нигә ул сезнең урынга килгән?

Нурислам. Менә нәрсә, житәр жүләр сатарга. Кайда мотоцикл? Мотоцикл кайда дим? *(Иршат җавап бирми.)* Шулмы синең үз итүең? Болай булгач, безнең арадагы дуслык сукыр бер тиен дә тормый. Я?

Иршат *(бераздан, Нурисламга гына).* Күлгә тыгып куйдым. Пар өянке янында.

Мөршидә. Су төбендә? Бәлки синең эшең түгелдер?

Иршат. Минем эшем.

Мөршидә. Ә-ә, йөрисең килеп алып чыккансың да ялгыш төшереп җибәргәнсең. Ул урында яры текә.

Закир. Шулайдыр инде. Башкача ничек булсын.

Мөршидә. Тоталмыйча калдыңмы?

Иршат. Юк.

Мөршидә. Шуып китеп авып төштеме?

Иршат. Юк.

Мөршидә. Ә-ә, караңгыда ялгыш барып кергәнсең.

Иршат. Юк. Мин аны үзем суга тыгып куйдым.

Мөршидә. Миңа ачу итеп? Нурислам абый өчен үч аласың? *(Таң калып, сокланып.)* Синең урында булсам, мин үзем дә шулай эшләр идем. Молодец! *(Иршатны кочаклап ала.)*

Әнвәр *(кычкыра).* Прекрати! Бу ни эш?!

Иршат *(Мөршидәдән ычкынырга тырыша).* Җибәрегез. Ярамыйм.

Мөршидә. Ә мин яратам.

Әнвәр. Мөршидә Хәлиловна, чыгып тор әле. Цирк түгел бу кәмит уйнарга. *(Мөршидә чыга. Әнвәр коридорга юнәлә.)* Кем бар анда, завхозга әйтсеннәр. Алып кайтсын. *(Чыгып китә.)*

Закир *(Нурисламга ишеттермичә генә).* Авыртмадымы? *(Иршатның колагын сыпырып куя.)* Үзең дә инде, мин батырдым дип әйтеп торалармыни? Батыргансың икән, урынын күрсәтәләрме? Мәгънәсез. Эзләсеннәр иде шунда. *(Кинәт көлеп җибәрә.)* Батылмаган да, югалмаган да, еракта да түгел, якында гына. Ә таба алмыйлар. Күренми, су астында. *(Аркасыннан кага.)* Ах, очлы күз, очлы күз. Закир малае шул син. *(Мөршидәнең кергәнен күреп, тагын тавышын күтәрә.)* Өйгә генә кайт, тәүбәгә китермәсәм мин сине!

Мөршидә. Закир абый, алай ук кирәкми.

Закир. Йомшаграк бул, дисеңме? Булмый. Җанын алам мин аның. *(Чыга.)*

Мөршидә. Иршат, тукта әле. Анда балалар колактан-колакка чыш-пыш. Нәрсә, факел сүнгән идемени?

Иршат. Һә, Сүнә торган ут түгел ул. Мәңгелек. Сүнә калса, без аны зажигалкадан — выжт! Өйрәнгән. *(Ишеккә атлый.)*

Мөршидә. Нәрсә? Ни сөйләдең син?

Әнвәр керә.

Әнвәр *(Иршатка).* Без синең белән икенче урында сөйләшербез. *(Иршатны чыгарып җибәрә.)* Нурислам абый, сабыр ит әле. *(Мөршидәгә.)* Бу синең нишләвең? Кемне яклыйсың? Белепме-белешмичәме? Баланың гаебен батырлык дәрәҗәсенә күтәреп кенә аның күңеленә юл табып булмый. Бала бер генә гаепнең дә җәзасыз калмавына ышанырга тиеш.

Мөршидә. Төптән уйлап карасаң, Иршат мактауга лаек. Аның акланырга да мөмкинлеге бар иде. Мотоциклны тотып кала алмадым, текә ярдан авып суга төште, кайтып әйтергә шүрләдем дип. Ә ул акланмады. Характер бар. Ул куркаклардан түгел.

Әнвәр. Мактарга? Мәктәп машинасын суга тондырсын, авыл буйлап гайбәт тарала, ә син мактарга. Күккә чөяргә түгелме? Ул мотоциклны батырмады, синең белән минем исемне батырды.

Мөршидә. Сугыш кырында нәкъ менә Иршат кебекләр геройлык күрсәткәннәр дә. Вильдановны да шундый булган диләр.

Әнвәр. Син мине бөтенләй гаҗәпкә калдырасың.

Мөршидә. Иршатка җәза бирсәң, дөрес булмас. Юк, дөрес булмый. Юк, бирдермәячәкмен.

Әнвәр. Без синең белән уртак тел таба алмабыздыр. *(Мөршидәгә кул селтәп, Нурисламга борыла.)* Нурислам Кадыйрович, митингта чыгыш ясарга кирәк булачак.

Нурислам. Мин сезнең мәктәп кешесе түгел.

Әнвәр. Хәзергә учетта бездә.

Нурислам. Төшәргә йөрим.

Әнвәр. Сез Вильданов белән бер фронтта булган. *(Яңа фикер белән кабынып.)* Чыннан да, геройның батырлыгы турында, соңгы минутлары турында тулырак сөйләсәгез. Әйе, әйе, бергә атакага ташлангансыз, бергә пулемет утына очрагансыз. Шунда Вильданов һөҗүмгә юл ачып, дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган. Аннан сезнең кулыгызда җан биргән.

Нурислам. Юк, Әнвәр Галимович, без бер фронтта булсак та, төрле частька эләктек. Аннан, мин аны бөтенләй төсмерләмим.

Әнвәр. Балаларга көчлерәк тәэсир итәр иде. Ярар, үзегез турында, ничек сугышканыгызны сөйләрсез.

Нурислам. Үзем турында? Шул гына җитмәгән иде. Нигә кирәк? *(Чыгып китә.)*

Оркестр уйнаган марш көчлерәк ишетелә башлый.

Әнвәр. Һе, кешеләр! *(Сәгатенә карап.)* Вакыт. Әйдә... Ишетәсеңме?

Мөршидә *(үзалдына).* Вильданов. Мәңгелек исем. Үзе гомергә егерме бер яшьлек булып калган. Миңа да егерме бер. Без яшьтәшләр. Бу яшьтә ул герой булган. Ә мин? Ә мин аның гомере белән яшим. Минем урында булса, ул нишләр иде? Ут ачар иде. Әйе, әйе, пулеметтан. Тра-та-та-та-та! Фальшька, һәртөрле гаделсезлеккә каршы!

Әнвәр *(көлә).* Чү! Син үзеңә-үзең ут ачасың.

Мөршидә *(әллә шаярта, әллә чын-чынлап).* Әйе, үземә-үзем! Минем аркада Нурислам абый икенче авылга йөри, Иршат мотоцикл батыра, класс протест белдерә. Тра-та-та-та!

Әнвәр. Берьюлы шунда селтән Таһирга да.

Мөршидә. Әйе, Таһирга да. Тра-та-та-та-та!

Әнвәр *(көлә).* Сип әйдә!

Мөршидә. Сакланыгыз, Әнвәр абый, мин утны сезгә төбәдем. Ни өчен мине кеше урынына китердегез? Тра-та-та-та! Ни өчен зажигалкадан кабынган факелны мәңгелек уттан кабынган дип балаларны алдарга уйлыйсыз? Тра-та-та-та!

Әнвәр. Син шаяр, әмма чамасын бел.

М ө р ш и д ә. Мөршидә шаярып сөйли башладымы, җитди мәсьәлә кузгатасын көт тә тор. Шуңа күрә сез минем җитди булуымны теләгез. Шаярырга тотынсам, куркыныч мин.

Ә н в ә р. Куркаклардан түгел. Әти коры кулы белән бүре тотучы булган. Безнең нәселнең кушаматы да «Ике йөрәклеләр». Әйдә.

М ө р ш и д ә. Сез миңа җавап бирмәдегез. Ул факелны нишләтәбез?

Ә н в ә р. Аңа ни булган? Янамы — яна!

М ө р ш и д ә. Алып кайтканда факел сүнгән. Иршат аны зажигалкадан кабызган.

Ә н в ә р. Әйдә, юк белән баш катырма әле.

М ө р ш и д ә. Үзегез дә беләсез икән. Гаҗәпләнмәдегез. Бу бит коточкыч хәл.

Ә н в ә р. Күпертмә. Бер мизгелгә генә сүнеп торган икән, аннан фаҗига ясарга кирәкми. Шундук кабызганнар.

М ө р ш и д ә. Зажигалкадан. Ул бәлки бер исерекнеке булгандыр.

Ә н в ә р. Закир абыйныкы.

М ө р ш и д ә. Шуны төн буе пионерлар саклап чыкты. Нинди хурлык!

Ә н в ә р. Кара әле, син беләсеңме, бу факел кем идеясе?

М ө р ш и д ә. Хәят Газизовнаныкы.

Ә н в ә р. Мәгънәсен аңлыйсыңмы?

М ө р ш и д ә. Мәгънәсе бик зур.

Ә н в ә р. Шулай булгач? Шул кадәр зур тәрбия чарасы турында сүз барганда, нәрсә ул синең факелыңның бер мизгелгә генә сүнеп торуы?

М ө р ш и д ә. Ялган була ич, Әнвәр абый. Болай иң изге эшне дә харап итеп ташлавың ихтимал.

Ә н в ә р. Изге ялган дигән нәрсә бар.

М ө р ш и д ә. Әйе, ялган бик күп төрле, ә дөреслек бер генә. Бу фальшьны балалар белсә?

Ә н в ә р. Балалар, балалар!

М ө р ш и д ә. Күбесе белә дә бугай инде... Мәйданда ут янар. Без аны Казаннан мәңгелек уттан факел кабызып алып кайттык диярбез. Ялкынлы сүзләр сөйләрбез. Ә балалар берсенә дә ышанмас. Тавышланмас алар, юк, башларын иеп тынлый бирерләр, ә ышанмаслар. Кемнәрне алдамакчы булабыз?!

Ә н в ә р *(кабынып)*. Һе, балалар! Балалар ни уйлар, балалар ни әйтер? Без нәрсә әйтсәк, шуны әйтерләр.

М ө р ш и д ә. Ышанмасалар дамы?

Ә н в ә р. Без әйткәч ышанырлар. Ышанмый хәлләре юк. Ышандыра белергә кирәк. Тегеләй дисәң тегесенә, болай дисәң монысына — ышанырга тиешләр. Шуның өчен укытучы син.

М ө р ш и д ә. Бала күңеле — гөлчәчәк. Аз гына кырау төштеме — шиңә.

Ә н в ә р. Әйдә, митингка вакыт.

М ө р ш и д ә. Әнвәр абый, исегездәме, мин килгәч тә Хәят Газизовна мине эшкә алырга теләмәде. Ләкин шунда ук, сез аның белән сөйләшеп чыгуга, алды да куйды. Әйтегез әле, нинди серле сүз әйттегез аңа роно приказыннан да көчлерәк? *(Әнвәр дәшми.)* Кәләшем дидегезме?

Ә н в ә р *(көлә)*. Юкса, карчыкның кирелеген ничек сындырасың. Характерын күрдең ич. Директорга да, роно приказына да буйсынмый.

М ө р ш и д ә. Моны да изге ялган дисезме? Фальшь бу. Әнә нәтиҗәсе: Таһир өйләнеп кайткан. Мәхәббәте дә фальшь, факел белән дә фальшь. Бөтенесе бер сорт — ялган. Сез моңа чирканмыйсыз да. Күнеккәнсез димме. Ә мин... Юк, күнегергә теләмим. Мәктәптә моңа урын булмаска тиеш. Балалар сулый торган һава саф булсын. Тәрбиянең нигезе гаделлек, дөреслек, хакыйкать булсын.

Ә н в ә р. Трат-та-та-та-та-та!

Мөршидә. Тра-та-та-та-та!

Әнвәр. Браво, браво! Мәктәбемдә тагын бер көрәшче артты.

Мөршидә. Ялгышлыкны төзәтик. Факелны сүндерегез.

Әнвәр. Хәзер соң инде.

Мөршидә. Митингка алып чыккач соң булачак.

Әнвәр. Хәзер дә соң. Бер нишләр хәл юк.

Мәлика, Сажидә, Хәят, алар белән берничә укучы керә. Нурислам да ияргән. Залның умарта оясы кебек кайнап гөжләгәне торган саен көчлерәк ишетелә бара. Әледән-әле класс ишегеннән баш тыгып карыйлар, кемнедер эзлиләр, кемнедер күзлиләр.

Мәлика. Җыйналып бетәбез.

Әнвәр. Районнан килеп житәселәре бар.

Мәлика. Килгәннәр бугай.

Әнвәр. Алайса, ашыгыйк.

Шул чакта Иршат керә. Кулында факел. Фирдәвес тә ияргән.

Иршат. Алдым мин факелны.

Әнвәр. Сиңа кем кушты?

Иршат. Бирәү дә. Үзем күтәреп чыгам. Ә нәрсә, ярамыймы?

Мөршидә. Сүндермәссеңме соң?

Иршат. Сүнсә...

Мөршидә. Яле, мин дә тотып карыйм әле шуны бер генә. *(Факелны Иршаттан алып баш өстенә күтәрә.)* О, хикмәтле ут, мәңге сүнмәс ут! Ян син балкып, нурларыңны чәч син безнең юлыбызга. Ой... *(Урындыкка басып югарыга күтәреләм дигән җиреннән авышып китә дә факелны төшереп җибәрә.)*

Сажидә *(тотып калырга ашыга).* Сүндерәсең бит. *(Сажидә дә өлгерә алмый, Мөршидә дә коткарып кала алмый, Әнвәрнең дә тотып калырга талпынуы уңышка китерми, факел сүнә.)*

Фирдәвес *(кычкырып җибәрә).* Ах!

Урамдагы марш көчлерәк ишетелә башлый.

Сажидә *(кабалана).* Харап иттек. Кабызыйк, кеше күргәнче кабызыйк. Нурислам, тиз бул, сыз шырпыңны.

Нурислам. Нишләмәкче буласың? Нәрсә сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы?

Мәлика. Сүнде. Яхшы бәндә иде, мәрхүм.

Әнвәр *(Мөршидәгә якын килә).* Бу синең ни эшең?!

Мөршидә. Егылып китә яздым. Гафу итә күрегез инде, Әнвәр Галимович.

Әнвәр Мөршидәгә төбәлеп карап тора, аның факелны ялгыш төшердем дигәненә ышанмый, әлбәттә. Шулай да шикләнүен башкаларга сиздерми.

Әнвәр. Митингны факелсыз гына уздырабызмыни? Хәерле булсын. Әйдәгез.

Хәят. Митинг бүген булмый, Әнвәр.

Әнвәр. Ничек булмасын?.. Барыгыз әле, бар. *(Балаларны чыгарып җибәрә. Хәяткә килә.)* Ничек булмасын? Әнә җыйналдылар. Районнан чакырылган кешеләр килде, башка мәктәпләрдән. Оркестр чакырттык. *(Ишекне ача, тышта залда шау-шу, марш авазлары көчәеп китә.)* Ишетәсезме? *(Ишекне яба.)* Шул ташкынны туктата алсагыз, барыгыз, өзегез митингны. Бер факелда ут сүнде дип. *(Кызып китеп.)* Уйлап таптыгыз дөньяда булмаган эшне. Ә мин, җүләр, сезгә ышанып, күңеле булсын инде дип... Бармы бу башка мәктәпләрдә? Кайсында? Берсендә дә юк. Без генә йөрибез җүләр сатып.

Сажидә. Мөгез чыгарырга яратабыз инде, анысы. Кешечә генә булмасын. Артыграк булсын.

Х ә я т *(кайтып төшеп)*. Бәлки, бәлки.

Ә н в ә р. Туры әйткәнгә каефегез кырылмасын, Хәят Газизовна. Хыялый кеше сез.

Х ә я т *(боегып, кечерәеп кала)*. Шулайдыр. Күрәсең, картайганмын. Бөрешеп беткән карчыктан ни көтәсең? Заман белән атларга тырышып карыйм да. Кая ул?

М ө р ш и д ә. Минем аркада гына шундый кызыклы эшнең сүнүен теләмәс идем мин.

С а җ и д ә. Сүнде инде.

Ә н в ә р. Сездә факел кайгысы. Ә минем... Әнә, кышлык утын әзерләнеп бетмәгән. Дөресен әйтәм, сезнең ул идеягезгә башта ук күңелем ятмады. Мин — практик. Минем өчен иң әһәмиятлесе — фән нигезен бирү. Минем мәктәптән чыккан һәр укучы институтка үтсен.

Урамдагы оркестр уйнаган марш көчлерәк янгырый. Һәм ул бер көчәеп, бер әкренәеп пәрдә ахырына кадәр дәвам итә.

С а җ и д ә *(тәрәзәдән күреп)*. Анда җыйналалар.

Х ә я т. Шулайдыр. Сез хаклыдыр. Электән үк мөгез чыгарырга яратa торган гадәтем бар иде. Тикмәгә генә хикмәтле Хәят дип йөртмәгәннәрдер. Берәр гаделсезлек күрдемме, хәзер чәчрәп чыгар идем. Хакыйкатькә хыянәт иткән кеше шәхси дошманыма әйләнә иде. Яшәвемнең максаты — гаделлек өчен көрәш. Һе, гаделлек сакчысы. Әйтерсең, аның миннән башка яклаучысы юк.

Ә н в ә р. Вакыт. Һәр класс җитәкчесе үз классын үзе алып чыга. Циттек. Безне көтәләр.

Кузгалалар. Хәят кына ашыкмый.

Х ә я т *(кинәт катгый һәм кискен)*. Әнвәр Галимович, митинг бүген булмый. *(Бу шул кадәр кисәк яңгырый ки, һәркем аптырап кала).*

Ә н в ә р. Ну, кире беткән кеше дә сез.

Х ә я т. Бүген булмый.

Ә н в ә р. Без аны ясамый кала алмыйбыз.

Х ә я т. Кайчан яңа факел кабызып кайтырбыз, шул чакта үткәрербез.

Ә н в ә р. Тагын? Бер хур булуыбыз гына җитмәгән. *(Сүз таба алмый, бүлмә буйлап йөренә.)* Бүген митинг буласын район җитәкчеләре генә түгел, министерствода да беләләр.

Х ә я т. Мактанырга да өлгерденмени? Алдан кычкырган күкенең башы ярыла шул.

Ә н в ә р. Замминистрның үзенең килеп чыгуы мөмкин.

Х ә я т. Шалтыратыгыз, мәшәкатьләнеп йөрмәсен.

Ә н в ә р. Юлга чыккан булса?

Х ә я т. Бик әйбәт, мәктәп белән танышып китәр.

Ә н в ә р. Сез мине нинди хәлгә куймакчы буласыз? Сез минем үзегезгә булган ихтирамымнан файдаланасыз. Һаман да укучыгызга караган кебек карыйсыз.

Х ә я т. Син минем укучым.

Ә н в ә р. Әгәр дә мин сезне тыңламасам? Мин үстем инде, парта артыннан чыктым.

Х ә я т. Митинг бүген булмый.

Ә н в ә р. Тамырга балта чабу бу. Арттан китереп сугу. *(Кискен карарга килеп.)* Конце-то концов, мин директормы? Кирәк икән, үземә бирелгән хокуктан файдалана белермен. Анархиягә юл куймам. Рәхим итеп буйсына белегез! Митингны уздырам.

Х ә я т *(аягына баса)*. Юк, Әнвәр Галимович, син ул юлга басмыйсың!

Ә н в ә р. Басам. Минем башка чарам юк.

Х ә я т. Син хәзер үк чыгып митингның кичектерелүе турында хәбәр итәчәксең!

М ә л и к ә. Техник сәбәпләр аркасында.

Ә н в ә р. Хәят Газизовна!

Х ә я т. Шулай, Әнвәр Галимович!

Ә н в ә р *(үзендә Хәятның ихтыярын җиңәрлек көч таба алмый)*. Илле ел мәктәптә эшләп, сезгә балалык сеңгән. Тормышка балалар күзе белән карыйсыз.

Х ә я т. Шулай карый алганыма горурланам.

Ә н в ә р *(шартлап)*. Саташтыгыз шул факелыгыз белән.

Х ә я т. Ә син ничек уйлыйсың? Без нигә дип мәктәпкә герой исеме куярга йөрибез? Әнвәр Галимовичны герой мәктәбе директоры дип атар өчен генә түгелдер ич. Укучыларны шул рухта тәрбияләү өчен. Без үскәндә Чапаев, Чкалов, Павка Корчагиннар бар иде. Ә хәзер? Чапаев турында анекдотлар сөйләргә генә калдымыни?! Фән нигезен бирү — беренче вазифабыз. Әмма аның белән генә чикләнергәме? Балалар батырлык белән очрашсын. Ата-бабаларының изге көрәшләрен онытмасыннар. Мәктәпкә төзүчеләр, галимнәр керсен, шагыйрьләр килсен мәктәпкә. Без кеше үстерәбез. Теләсә нинди кеше түгел, Совет кешесе. Бүген нинди кеше үстерсәк, киләчәгебез шундый булыр. Бала күңеле — ак кәгазь. Аңа нәрсә генә язарга булмый. Яманлыкны да, яхшылыкны да. Әйдәгез, без аңа гаделлек, изгелек языйк. Иленә, халкына мәхәббәт языйк. Тормышка чын кеше булып керсеннәр.

М ә л и к ә. Әйе, бала күңеле промокашка кебек. Бөтенесен сеңдерә.

Х ә я т. Бүгенге балаларыбыз шушы тормышның кадерен беләләрме соң? Минем буын тигезсезлек күрде. Шунлыктан икмәкнең кадерен яхшы беләбез. Бер сынык икмәкнең тәмен татып үстек, чөнки безнең ачыккан чакларыбыз да аз булмады. Ә алар? Ни теләсәләр, шул бар. Нәрсә ашыйм дисә, нәрсә киим дисә, нинди машинага утырыйм дисә.

С а җ и д ә. Ризыкның кадерен белсеннәр дип, ач тотып булмый шул инде.

Х ә я т. Кулакны күрмәде, фашистны күрмәде. Социализм төзелгәч кенә дөньяга килде.

Ә н в ә р. Шулай да, һәр мәктәп безнең кебек чаба башласа.

Х ә я т. Башкалар өчен җавап тотмыйм. Һәркайсы үзенчә эш алып барадыр. Үзе кирәк тапкан формада. Һәр мәктәп бертөрле эшли башласа, аның кызыгы да булмас иде. Шаблон, казенщина дияр идек.

С а җ и д ә. Үз сәгатеңне укытып чык идең дә котыл идең. Кая ул, һаман шул: тәрбия, тәрбия, тәрбия. Аннан, кырык яшьтән чәчең агарган дип гаҗәпләнәләр.

Н у р и с л а м *(кисәтеп)*. Саҗидә!

С а җ и д ә *(кызып китеп)*. Катнашмыйча гына утырчы. Син безнең мәктәп кешесе түгел! Мин трибунада түгел. Конференциядә чыгыш ясамыйм. Үз иптәшләрем арасында. Күңелемдә ни — телемдә шул.

Х ә я т. Укытучы һәр вакыт трибунада, Саҗидәкәй. Мәктәптә дә, урамда да, коллегалары арасында да. Авылда кеше бер-берсен лупа аша караса, укытучыларны микроскоп аша карый. Без үз-үзебезне тотышыбыз, шәхси тормышыбыз белән дә тәрбиялибез.

Ә н в ә р. Әй, авыр да соң бу хатын-кыз белән эшләве.

М ә л и к ә. Анысына күшылам. Үземә дә авырга килә.

М ө р ш и д ә. Сезгә нигә ул кадәр борчылырга?! Чыгыгыз да әйтегез: Мөршидә аркасында митинг өзелде дип. Әллә үзем генә чыгып кычкырыйммы?

Ә н в ә р. Мәликә апа, барыгыз: көтмәсеннәр, таралсыннар, Митинг бүген булмый.

Мәликә чыгып китә. Саҗидә белән Нурислам да чыгалар.

Хәят *(елмаеп торган Мөршидәгә)*. Син нәрсә, берәр батырлык эшләгән кеше кебек? Шушындый вакытта авыз ерган кешене яратмыйм. *(Чыга.)*

Әнвәр. Шүрләп калдыңмы?

Мөршидә. Таралсыннар.

Әнвәр. Нишләгәнеңне аңладыңмы инде? Моның өчен рәхмәт әйтерләр дисеңме?! Җавабын кем бирер? Директор? Эшли белгәнсең икән, җавабын да бирә белерсең. Әзерләнеп тор! *(Ишеккә юнәлә.)*

Мөршидә *(Әнвәр ишеккә җиткәч кенә)*. Тра-та-та-та-та! *(Әнвәр сискәнеп китә.)*

Пәрдә

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мәктәптә укытучылар бүлмәсе. Төн. Караңгы. Өстәл артында Мөршидә. Өстәл лампасы каршында укып утыра. Коридорда аяк тавышы ишетелүгә башын күтәрә, сагаеп кала. Кемдер ишекне тартып карый, дөбердәтә.

Таһир тавышы. Ач, Мөршидә, беләм бит, син монда. Ач! Ватып, каерып керәм!

Мөршидә тавыш бирми. Таһир ишекне тагын дөбердәтә, тагын тартып карый. Аннан каядыр китеп бара. Бераздан ул тәрәзәгә килә. Мөршидә куркып кала. Таһир, тәрәзәне ачып, бүлмәгә сикерә. Мөршидә ишеккә ташлана, ләкин чыгып китәргә өлгерә алмый. Таһир аны тотып ала.

Мөршидә. Онытма, бу мәктәп.

Таһир. Сине кайда тотасың, квартираңнан чыгып качкач. Калтырама. Юлбасар түгел. Безгә сөйләшергә кирәк.

Мөршидә. Хәзер түгел, биредә түгел.

Таһир. Кайда? Өеңә килдем, кертмәдең.

Мөршидә. Алып кайт та хатыныңны, парлашып килегез. Теләсәң ни вакытта ишегем ачык булыр. Ә хәзер...

Таһир. Беркая да китмим. Инде эзләп тапканмын икән, кулдан ычкындыру юк.

Мөршидә. Балаларга ишетелсә? Син әзрәк минем турыда да уйла.

Таһир. Утыр.

Мөршидә. Төнлә. Мәктәптә?

Таһир. Моннан да җайлырак урын булырмы? *(Күтәреп алып диванга утырта.)* Син шунда, мин биредә. *(Урындык алып каршына утыра.)*

Мөршидә. Шуны бел, болай миннән бер сүз дә ала алмаячаксың.

Таһир. Яхшы. Ул чакта мин китәм. Әйт, яратмыйм диген, яратканым да юк диген. Бер генә сүз. Әйт, шундук китәм. Таһирны бүтән күрә алмассың. Я?

Мөршидә. Үзең дә беләсең бит.

Таһир. Беләм.

Мөршидә *(күзендә яшь)*. Әйе, яраттым мин сине. Аерылышасы булмаса, ихтимал, гомердә дә әйтмәс идем.

Таһир. Кайчаннан? Казанда ук? Ә теге чакта, вечердан соң, озатырга теләдем, кисәк юкка чыктың. Качтың. Телефон аша очрашырга килештек, килмәдең.

Мөршидә. Кышкы пальтом иске иде, күренәсем килмәде.

Таһир.Ниләр генә уйлап бетермәдем.

Мөршидә. Синнән башка яшәү миңа авыр булыр.

Таһир. Ә миңа соң, миңа? Мин синнән башка яши аламмы? Кадерлем минем, бердәнберем!

М ө р ш и д ә *(айнып китеп)*. Җитте. Бүтән бер сүз дә! Бар, кайт.

Т а һ и р. Мөршидә, белсәң иде: мин нинди бәхетле!

М ө р ш и д ә. Зинһар, кирәкми. Ярамый. Син аңларга тиеш.

Т а һ и р. Миннән дә бәхетле кеше юк дөньяда. Өйләндем. Җирдәге иң гүзәл кызга өйләндем.

М ө р ш и д ә *(нәфрәт белән)*. Җитәр дим.

Т а һ и р. Җүләрем, мин сиңа өйләндем. Теге көнне атылып-бәрелеп чыгып киттем Казанга. Син Әнвәр янына килгәч.

М ө р ш и д ә. Мин эшкә килдем.

Т а һ и р. Ул сине өйләнергә китерде. Ярсуым сулышымны кысты, йөрәгем үч йодрыгына әверелде. Киттем ачудан кемгә булса да өйләнергә! Ышан, өйләнә идем. Әмма бер минутка икеләнеп калдым. Профессиям коткарды. Очучы — иң сабыр кеше. Самолет катастрофага очраса, бер генә нәрсә коткара: салкын канлылык. Шунда мин үземнең катастрофага барганымны аңладым. Аңладым да киттем әниең янына, ризалыгын алырга. Кердем кассага — самолетка ике билет. *(Мөршидә мондый көтелмәгән үзгәрештән айный алмый тора.)* Мөршидә, моңарчы очрашып йөрсәк тә, мин сине белмәгәнмен. Күңел күзем йомык булган. Әйтерсең, мин сине яңа гына күреп алдым. Мәктәпкә килгәч кенә. Бөтенләй мин уйламаган ягың белән ачылып киттең. Синнән башка яши алмаячагымны аңладым. Без өйләнешәбез. Мин сине алып китәм.

М ө р ш и д ә *(күз яше аша шаркылдап көлә)*. Син минем өчен дә хәл иткәнсең.

Т а һ и р. Без бер-беребезне яратабыз. Ике уйлап торасы да юк.

М ө р ш и д ә *(көлә)*. Кызык. Үземнән дә сорап тормыйлар, тоталар да өйләнәләр. Үзем белмичә дә калам.

Ут сүнә. Мәктәпкә хас гүләү ишетелеп тора. Озак та үтми, ут яңадан кабына. Көндез. Коридорда класслардан чыккан балалар тавышы. Дәресләр беткән. Бүлмәдә берәү дә юк. Ишектә Ф и р д ә в е с башы күренә.

Ф и р д ә в е с. Мөмкинме?

Берәү дә юклыгын күреп, бүлмәгә керә. Кулында газетага төрелгән такта. Аның артыннан И р ш а т атлый. Фирдәвес директор ишегенә килеп шакылдата. Аннан да җавап юк.

Ф и р д ә в е с. Ул бит аны кунарга керткән. Өйләнгән кешене.

И р ш а т. Син күрдеңме, я, күрдеңме?

Ф и р д ә в е с. Һәркем шул турыда сөйли.

И р ш а т. Ә син сөйләмә.

Ф и р д ә в е с. Нишләп әле син аны якларга керештең?! Бөтен мәктәп гаепләп торганда.

И р ш а т. Барысының да телендә Мөршидә дә Мөршидә. Әллә сезнең башка сүзегез юкмы?!

Ф и р д ә в е с. Баксаң-күрсәң, факелны да юри сүндергәндер әле.

И р ш а т. Аны башта ук сүндерергә кирәк иде.

Ф и р д ә в е с. Син ни сөйлисең?

И р ш а т. Ул сүндермәсә, мин аны үзем сүндерә идем.

Ф и р д ә в е с. Ой, Иршат, син кире типка әйләнә барасың.

И р ш а т. Аның каравы, син бик уңай тип булып киттең.

Ф и р д ә в е с. Укытучыга шулай килешәме? Ул аны тәрәзәдән керткән, ди.

И р ш а т. Ишектән ярамагач, нишләсен.

Ф и р д ә в е с. Хурлык!

И р ш а т. Әгәр дә ул мәхәббәт булса? Минем үземнең дә... Тәрәзәсеннән түгел, морҗасыннан төшәр чакларым була.

Ф и р д ә в е с *(сөенеп)*. Ә?.. Синеңме? Әй, кем янына, Иршат?

Ир ш а т. Әй, сиңа сөйләп торган мин... Иртә әле сиңа мәхәббәт турында сөйләшергә.

Ф и р д ә в е с. Булыр иртә.

И р ш а т. Синең тәрәзәңнән керсәләр, шундук директорга йөгерәсең ич. Жалоба бирергә.

Ф и р д ә в е с. Ә йөгермәсәм? Беләсең килсә, мин үзем тәрәзәдән сикерергә әзер.

И р ш а т. Кем өчен?

Ф и р д ә в е с. Башта син әйт. Гел аның турында гына уйлыйсыңмы? Очрашкан саен очрашасы гына килеп торамы? Кем соң ул?

И р ш а т. Син аны белмисең. Башка авылдан. Ә синең?

Ф и р д ә в е с. Минем дә. Мәскәүдән.

*Иршат көлә башлый. С а ж и д ә белән М ә л и к ә дәрестән чыга. Иршат чыгып китә.*

С а җ и д ә. Ниең калган монда? Нәрсә ул?

Ф и р д ә в е с. Документ, экспонат.

С а җ и д ә. Черек такта кисәге күтәреп йөрмәсәң.

Ф и р д ә в е с. Тарих бу, әни. Герой безнең мәктәптә укымаган.

С а җ и д ә. Нәрсә акырасың!

Ф и р д ә в е с. Герой утырган партаның тактасын таптык.

М ә л и к ә. Кемнәр?

Ф и р д ә в е с. Эзтабарлар. Менә ике хәреф: пәке очы белән язылган. «Г. В.» Гали Вильданов. Герой исеме. Кече авыл мәктәбенең утын сараеннан таптык. Ул Кече авылда укыган.

С а җ и д ә. Җитте сиңа. Яшер тактаңны. Директор күрсә, буран чыгарыр.

Ф и р д ә в е с. Аңа күрсәтергә дип килдек тә.

С а җ и д ә. Күрсәтермен мин! Олылар эшенә тыгылып йөрмәсәгез. Әйткәннәрме сезгә герой бездә укыган дип. Кемгә ышанасың: укытучыңамы, әллә шушы черек тактагамы?

Ф и р д ә в е с. Тактага ышанам. Ул алдамый. Ә сез безне балага саныйсыз.

С а җ и д ә. Телеңне кисәм мин синең, кызый. Бир әле. *(Тактаны ала да ыргытырга урын эзли.)*

Ф и р д ә в е с. Әни дим!

С а җ и д ә *(тактаны мичкә ташламакчы. Мәликәгә)*. Шырпы бир.

Ф и р д ә в е с. Син тактаны түгел, дөреслекне утка якмакчы буласың.

С а җ и д ә. Каян килгән дөреслек сакчысы!

Ф и р д ә в е с. Саклыйм. Ә менә син янмыйсың да, көймисең дә.

М ә л и к ә. Сине шундый итеп кем үстергән соң? Янмаган, көймәгән кеше синдәй героиняны үстерә аламы?! *(Тактаны алып бирә.)*

С а җ и д ә. Бөтенебезне харап иттерәсең.

Ф и р д ә в е с. Ха-ха-ха! Шушы черек тактадан да калтырап төшкәч!

С а җ и д ә. Бу ни эш синең, әниеңә тел озайта башладың.

М ә л и к ә. Онытма, әти-әнине сайлап алмыйлар.

Ф и р д ә в е с *(елмаеп)*. Ай, сайлап ала торган булса.

С а җ и д ә. Абау, абау, минем бала түгелдер, чегән алмаштыргандыр моны.

М ә л и к ә *(тактадагы хәрефләргә күрсәтеп)*. Кем әйтте әле аны Гали Вильданов дип? Ни өчен Госман Вафин түгел? Ә бәлки. Гөлшат Вәлиевадыр?!

Ф и р д ә в е с. Тактага гына ышанмасагыз, карагыз. *(Фотокарточка чыгара.)* Класслары белән төшкәннәр, әнә утыра!

С а җ и д ә. Сөйлиләр иде шул аны. Хәер, беренче класста ук малай нибары ярты ел гына укыган да, әтиләре шәһәргә күчеп киткән. Әллә кайчан булганны кем хәтерләп бетергән. Директоры да... юкка гына кузгатып йөрде.

Фирдәвес. Ә синә инде директор әйттеме — бетте. Закон. Каршы бер сүз әйтә алмыйсың.

Сажидә. Бар әле син, юлыңда бул!

Фирдәвес *(чыгышлый Мөршидә белән очраша)*. Ышанмыйм. Тактага ышанам, ә сезгә...

Сажидә. Югал дим! Юньсез! *(Фирдәвес чыгып киткәч.)* Синең ни эшең бу, Мөршидә?

Мөршидә. Ни булган?

Сажидә. Мәктәптә егет белән очрашырга!

Мәликә. Менә бу мәхәббәт ичмаса! Эх, шайтан алгыры, әллә үземә дә бер чамалап карарга инде. Берәр тол хатын тәрәзәсеннән...

Сажидә. Бездән оялмасаң, хатыныннан куркыр идең.

Мөршидә. Хатыныннан?! Ә нәрсә аннан куркып торырга. Мин аны бар дип тә белмим. Бик ачуымны китерсә, тотармын да Таһирын аерып алырмын!

Сажидә. Оял!

Мәликә *(гаепләп)*. Мөршидә! Күгәрченем!

Таһир керә.

Таһир. Нигә болай озак? Машина килеп калды.

Сажидә. Мөршидә дә китәргә булдымыни?

Мөршидә. Минем өчен берләнбер чара: мондагы эшләрем өчен җавап биреп торганчы китеп котылу. Артымнан елап калучы юк.

Сажидә. Качып котылыйм дисең икән.

Мәликә. Үзеннән-үзе кача алса.

Таһир. Карагыз әле, апалар, дәресләр бетте, өегезгә кайтып китмисезмени? Саубуллашырга сугылырбыз. *(Сажидә белән Мәликәне озата.)* Долой шикләнүләр, икеләнүләр — без гомергә бергә. Әйдә! *(Мөршидә уйга чумган.)* Син мине ишетәсеңме?

Мөршидә. Әйе, әйе, җыеныргa кирәк. Хәзер, хәзер. Чемоданнарны алабыз да... Кара, иптәшләр белән саубуллашырга да өлгермәдем. Бигрәк кисәк булды. Бер-ике көнгә генә дә калып булмыймы?

Таһир. Мөршидә!

Мөршидә. Әни янына кереп чыгабыздыр бит?

Таһир. Шуның өчен дә ашыгырга кирәк.

Мөршидә. Ничек көттем бу көнне, ышанырга куркып көттем. Ә хәзер мөмкинлек булгач кына үзем үк баш тартыймммы?!

Таһир. Кара әле, бу синең нишләвең?

Мөршидә. Таһир, син алай куырма әле. Уйламыйча гына хәл итә торган эшмени.

Таһир. Китәм бит. Дөнья читенә. Ай саен кайтып йөри торган ара түгел.

Мөршидә. Балалар ни дияр?

Таһир. Һе! Сайлыйсың инде, икенең берсе.

Мөршидә. Я сине, я мәктәпне? *(Уйга кала.)* Соңгы көннәрдә, ни хикмәттер, үземне сәер хис итәм. Синең турыңда уйласам гына да, аларның күз карашларын тоям. Сиксән күз миңа текәлгән. Көтәләр. Гаепләмиләр, юк, үпкәләмиләр дә. Нидер көтәләр. Алар барысын да сизеп тора.

Таһир. Кемнәр алар?

Мөршидә. Балалар.

Таһир. Бар икән!

Мөршидә. Мин аларга сүз бирдем: «Гадел булырмын, әмма таләпчән. Сезгә дә, үземә дә». Ә хәзер тотыйм да ташлап китим ди. Гаделлекме бу? Мин бит аларның Нурислам абыйларын алмаштырдым.

Таһир *(алҗып)*. Мөршидә!

Мөршидә. Яратам мин дәрес бирергә. Күзләренә карарга яратам. Аяз күк кебек саф алар. Аларның да мине яратуларын телим. Сине яратмаса, ул син укыткан фәнне дә яратмый.

Таһир. Торган саен безнең ара ерагая бара.

Мөршидә. Класска керәсең икән, күңелең керсез, ниятең изге булсын. Хәзер аларга хыянәт итсәм, бүтән бер вакытта да мәктәп бусагасыннан атлап керә алмас идем.

Таһир. Мәхәббәткә хыянәт итәргә дә ярыймы?

Мөршидә. Син очучы, әйт менә, аягы-кулы белән гарип кеше һавага күтәрелә аламы?

Таһир. Андыйларга күктә урын юк.

Мөршидә. Күңеле гарип кешегә дә мәктәптә урын юк.

Таһир. Син мине куркытасың. Көндәшләремнән курыкмыйм, синең үзгәрүеңнән куркам. Синдә укытучы вөҗданы уянса... О, бик яхшы беләм мин аның нәрсә икәнен. Әни үлгәч, Хәят апада яшәдем. Укытучы өендә. Беренче чиратта балалар, аннан соң гына үз тормышы. Намус, вөҗдан, авыл халкы ни дияр.

Мөршидә. Кызык. Укытучы була алмыйсың дигән кеше, хәзер була дип борчыла.

Таһир. Укытучы буласыз да монастырьга кереп бикләнәсез. Аннан сезне алып чыгып буламыни? Аңа хәтта мәхәббәтнең дә көче житми.

Мөршидә. Ах, Таһир, башта ук чын укытучы булсам, бу хәл килеп тә чыкмас иде.

Хәят керә. Класста тоткарланган.

Таһир. Килененне күрергә теләгән идең, рәхим ит! Ләкин тора башламады, аерылу ягын каера. Аңа да синең жиңең кагылган. Мәктәп жене. Суырып алган үзен мәктәп. Тәмам йоткан. *(Мөршидәгә борыла.)* Аяк-кулыңны бәйләп алып китәм!

Мөршидә. Сарык бәрәне кебек? Мин хәзер китә алмыйм, Таһир.

Таһир. Мин кала алмыйм.

Мөршидә. Син эшлисе жирдә татар мәктәбе юк.

Таһир. Монда аэродром юк. Шуны бел, әгәр дә хәзер аерылабыз икән, гомергә аерылабыз.

Мөршидә *(юашланып кала)*. Ташлап китә алмыйм.

Таһир. Аларны ташлый алмыйсың, мине ташлыйсың?

Мөршидә. Әгәр дә мине онытмасаң, без бер-ике елдан бергә була алабыз.

Таһир. Сине гомеремдә дә онытасым юк. Дөньямның эче-тышы синең мәхәббәтең белән агуланган. Ләкин белеп тор, быел ук өйләнергә мәҗбүр булачакмын. Яки хәзер, яки бер вакытта да!

Мөршидә. Хәят Газизовна... Сез аның яраткан апасы. Апа буларак ни әйтәсез?..

Хәят. Апасы буларак? Кавышыгыз. Бәхетле булыгыз. Күңелем тарткан киленем булырсың.

Мөршидә. Рәхмәт. Укытучы буларак?

Хәят. Сорама.

Мөршидә. Шулай да?

Хәят. Укытучы буларак мин синең турыңда уйлыйм. Ир биргән бәхет кенә житәрме сиңа? Кешенең жан азыгы — яраткан хезмәте. Чын укытучы уку елы уртасында мәктәбен ташлап китә алмас. Балаларга мәхәббәте чын булса.

Мөршидә. Ә Хәят Газизовна буларак.

Хәят. Мин — укытучы.

Мөршидә *(ишетелер-ишетелмәс)*. Мин дә.

Таһир *(кабынып китеп)*. Сез нинди телдә сөйләшәсез? Таптылар масаерга. Укытучылар имеш. Нәрсә күрәсез сез?! Сезнең өчен жир

шары — шул бер класс. Иртә дә шунда, кич тә. Кышын да, язын да. Гомер буе дүрт стена. Ә дөнья... Дөнья чиксез ул! Таулар, диңгезләр, океаннар. Берсеннән-берсе зуррак калалар. Күпме илләр, күпме халыклар! Берсен дә күрә алмыйсыз.

Хәят. Аңа каравы, син күрәсең, синең дөньяң киң.

Таһир. Бөтен күк йөзе минеке. Ул гына җитмәсә, космос. Телим биеккә, телим еракка!

Хәят *(дәвам итеп)*. Ни телим, шуны кыланам.

Таһир. Берсен дә профессиям белән бәйләмим.

Хәят. Без бәйлибез.

Таһир. Сез үзегезне чиклисез. Җирдә яшәргә килгәнсең икән, син иркенлекне, киңлекне тоеп яшә.

Хәят. Аны очучылар гына тоя дип уйлыйсыңмы?

Таһир. Кая ул сезгә!

Хәят *(өстәл тартмасыннан берничә хат чыгарып Таһир алдына сала)*. Менә! Менә! Ленинградтан. Доктор яза. Космодромнан. *(Кесәсеннән тагын бер хат чыгара.)* Монысы бүген генә килде. *(Конверттан укып.)* Литвадан. Бу киңлек түгелмени? *(Укылган хатларны кире өстәл тартмасына сала. Ә бүген килгәне өстәл өстендә ятып кала.)*

Таһир. Укучыларыңнан? Ә үзең?

Хәят. Алар — ул мин.

Таһир. Алар кешечә яши, сафа сөрә, шөһрәт казана, син шуңа аллага шөкер дип торасың инде? Аларның күкрәге тулы орден *(төртеп күрсәтеп)*, ә синдә һаман да шул бер МОПР значогы. Кара әйләнеп үткән тормышыңа. Нәрсә күрдең? Кигәнең авылча, ашаганың авылча. Һәр адымың үлчәнгән, һәр сүзең уйланылган. Булдымы хет бер генә тапкыр мәҗлесләрдә онытылып утырганың?! Иdәннәрен селкетә-селкетә җырлап биегәнең булдымы? Син бит дошманың белән дә күңелеңне басканчы талаша да алмыйсың. Кычкырып, чәчләреңне йолкый-йолкый еларга да ярамады. Шул мәктәп дип, гомереңнең иң матур елларын ирсез уздырдың. Син бит чибәр булгансың. Яраткан кешең белән аулакта очраша ала идеңме? Сөйгән ярыңны көндәшеңнән тартып алганың булдымы?.. Ах, юк! Синең булмады, укучыларыңның булды! Аларга ярый, сиңа ярамый?

Хәят. Сукыр син, Таһир. Бара укытучы урамнан, бөтен кеше — олысы-кечесе — урамның икенче ягыннан торып сәлам бирә. Керәсең клубка, шыгрым тулы. Инә төшәрлек урын юк. Кеше өстенә кеше утырган. Ә сиңа юл биреп торалар. Һәркайсы үз урынын тәкъдим итә.

Таһир. Ах, нинди бәхет.

Хәят. Әйе, бәхет! Киләчәккә хезмәт итүдән дә зуррак бәхет буламы?!

Таһир. Ышанмыйм.

Хәят. Ышанмасаң, әнә Нурисламнан сора. Районга зур урынга чакырып торганда, башлангыч класска барып керде. Дүрт стена эченә.

Таһир. Районда алмаганнардыр.

Хәят. Юньсез.

Таһир. Син Мөршидәдән дә үзеңне ясамакчы буласың. Үзеңә охшаш итеп, үзеңә алмашка. Бирмим, бирмим мин сиңа аны.

Хәят. Фамилияң Сабиров булса да, сабырлык юк синдә.

Таһир. Күралмыйм! Бу минутта күралмыйм мин сезне, иптәш укытучылар! Мораль калыбына, кагыйдәгә буйсынасыз да шуны нормаль хәл дип яши бирәсез. Шуңа күнегәсез. Күралмыйм. Алар хрусталь кебек саф булырга тиеш, имеш. Алар шәхесләре белән дә тәрбияли, имеш. Мәхәббәтләрен корбан итеп. Күралмыйм!

Хәят. Юк, гашыйк син безнең үзебезгә дә, эшебезгә дә. Сокланасың, хөрмәт итәсең. Укытучы абыеңа, укытучы апаңа дип хат саен сәлам язучы син түгел идеңме?

Таһир *(Мөршидәгә)*. Кичә синең өчен мин өйләнгән кеше идем. Җиңел булдымы?

Мөршидә башын чайкый.

Таһир. Бүген син ул газаптан азат. Ә иртәгә? Иртәгә тагын шуның кабатлануын теләмәсәң, әзерлән. Мин машина алып киләм. *(Чыгып китә. Пауза.)*

Мөршидә. Сез аны бик яратасызмы?

Хәят. Шуннан файдалана да. Белә авыр сүз әйтә алмаслыгымны.

Мөршидә *(сыгылып төшә)*. Нишлим?

Хәят *(көтмәгәндә)*. Кит. Ике дә уйлап торма, кит. Мәхәббәт, семья — зур нәрсә ул, бик зур нәрсә. Ансыз тормыш юк. Дөрес әйтә бит, калыпта, рамкада яшибез. Һәр адымың үлчәнелгән. Гомер буе — дүрт стена. Балалар, балалар дип, көн-төн... Ә үз балаң булуга ни җитә?! Карама син миңа, ай, күп нәрсә югалттым мин тормышымда. Кайтарып алып булса икән... Бәхетле кешеләр тәрбиялим дисәң, иң элек үзең бәхетле бул. Укытучының бәхетле булырга гына хакы бар, бәхетсез булырга — юк!.. Язмышка туры карый белергә кирәк.

Мөршидә нәкъ кечкенә чагындагы кебек көтмәгәндә Хәятның күкрәгенә каплана. Хәят аның җилкәсенә кулын сала. Әнвәр керә. Берсенә дә күтәрелеп карамый. Ачулы.

Хәят. Пешерделәрме?

Әнвәр. Рәхмәт әйттеләр. Бик зур эш башкаргансыз, молодцы, диделәр. Бөтен район шаулый. *(Тукталып кала. Моны аңлап, Мөршидә чыгып китә.)* Иртәгә райкомга барырга. Педсовет билгеләдем. Барысын да чакырырга куштым.

Хәят. Шулай ашыгыч?

Әнвәр. Райкомга мин буш кул белән бара алмыйм. Хәлнең укытучылар коллективында тикшерелүен, чара күрелүен әйтергә тиешмен. Беренче мәсьәлә итеп... Герой бездә укымаган... Бөтен авыл шул турыда сөйли.

Хәят. Ишеттем.

Әнвәр. Чүп өстенә чүмәлә. Шул гына җитмәгән иде.

Хәят. Күтәрелеп барганда гына осечка?

Әнвәр. Беләсегез килсә, бу катастрофа сезнең аркада. Мин сезгә ышанып, сезгә таянып эшләдем. Без, укучылар, укытучыбызны тыңларга күнеккән. Минем бер генә эшемне дә сезнең белән киңәшмичә эшләгәнем юк. Үзегез янымда булмаганда да сезнең белән киңәшә идем. Димәк, уңышлар да уртак, ялгышларымда да сезнең өлеш зур. *(Бераздан.)* Хәят Газизовна, мәктәпнең абруен саклап калырга кирәк. Коллектив өстенә тап төшерергә ярамый. Җаваплылыкны үз өстебезгә алырга тиешбез.

Хәят. Икебез?

Әнвәр. Яки мин, яки сез. Мин алыр идем, уйлап та тормас идем, ләкин миңа кем ышана. Гаепләсәләр, тәкәллефләнеп тормаячаклар. Ни дәрәҗәм, ни исемем дигәндәй. Таптап сытачаклар. Ә сез башка. Сезнең җилкәләр киң. Күтәрә аласыз.

Хәят. Кара син аны, яшь егетнең җилкәләре күтәрә алмый, ә бер аягы белән кабергә баскан карчык күтәрә, ә?..

Әнвәр. Хәят апа, зинһар, дөрес аңлагыз. Сезнең даныгыз бөтен районга, республикага таралган. Бөтен тирә-як сездә укып чыккан. Сезне тыңлыйлар, хөрмәт итәләр, ышаналар. Сезне гаепләргә кем җөрьәт итсен. Хәтере чуалган диярләр дә вәссәлам. Сезнең турыда берәү дә начар уйлый алмый.

Хәят. Булды. Бөтен җаваплылык минем өстә.

Әнвәр. Башта ук шулай килешәбез: педсоветта да, кирәк булса

райкомда да мин сезне гаепләп чыгарга мәҗбүр булачакмын. Үпкәләмәскә сүз бирегез.

Хәят. Килештек.

Әнвәр. Килештек. *(Кесәсен актара.)* Кая куйдым соң? Ә, кабинетта... *(Ишек буенда туктала.)* Педсоветта икенче мәсьәлә итеп Мөршиданең персональ эшен куям.

Хәят. Мөршидәне корбан итеп чалабызмыни?

Әнвәр. Аны болай гына калдырып булмый. Классы белән уртак тел таба алганы юк. Ул факелны сүндерүе тагын. Шуның өстенә... әйтергә оят, төнне, мәктәптә... *(Сәгатенә карап ала.)* Җыйналырга да вакыт. *(Ишегеп ача да, гадәтенчә ачкычын ишектә калдырып, кабинетына кереп китә. Хәят авыз эченнән генә сөйләнеп урыныннан кузгала.)*

Хәят. Мөршидә, Мөршидә. Эшли башламады, мә сиңа, персональ эш. *(Кабинет ишеге буенда туктала. Кырын күзе белән генә ачкычка карап тора. Аннан шалт — ачкычны бора да куя. Үзе почмактагы урындыкка барып утыра. Күзе ишектә. Эчке яктан Әнвәр ишеккә килә, этеп карый, шакылдата).*

Әнвәр тавышы. Нишләвегез? *(Дөбердәтә.)* Шаярмагыз, ачыгыз... *(Катырак дөбердәтә.)* Ачыгыз дим! *(Хәят кузгалмый да.)* Ах, сез алаймыни әле. Акылыгыздан шаштыгыз мәллә? Минем белән уйнарга? Үкенергә туры килмәсен. Мин ике сөйләмәм, ачыгыз ишекне! *(Бик каты дөбердәтә дә, аннан туктала. Тынлык урнаша.)*

Хәят *(мыгырдана)*. Берәүләрнең сөекле укучысы.

Мәлика керә.

Мәлика. Сез үзегез белән үзегез сөйләшәсез түгелме?

Хәят. Акыллы кеше белән сөйләшергә яратам.

Укытучылар җыйнала башлый.

I укытучы *(Саҗидә белән сөйләшә-сөйләшә керә)*. Эш мәктәп эчендә генә калмастыр.

Саҗидә. Калмады инде. Данлыбыз бөтен районга китте.

II укытучы. Республикага да житәр.

Саҗидә. Башларга вакыт түгелме соң?

Хәят. Җыйналып беттекме?

Мәлика. Директор үзе юк ич.

Саҗидә. Кайда йөри. Чакыртырга берәрсен йөгертик.

Нурислам керә.

Саҗидә. Бу нишләп йөри тагын?

Нурислам. Кайтып килеш.

Саҗидә. Өең монда түгел.

Нурислам. Учеттан төшәргә кирәк.

Саҗидә. Ай-һай, мине сагалап йөрмисең микән. Педсоветта артыгын ычкындырмасын дип. Аңа китсә, Нурислам бар дип тормам, бер йөрәгемне басам әле.

Хәят. Башлый торыйк. Үзе килгәнче икенче мәсьәләне — Мөршиданең персональ эшен карыйбыз.

Укытучылар. Мөршидә?

Мөршидә турында?

Нурислам. Миңа калыргамы соң?

Саҗидә. Син безнең коллектив члены түгел.

Нурислам. Саҗидәнең ире буларак.

Мәлика. Тән сакчысы.

Хәят. Мөршидә!

Мөршидә. Бастым.

Хәят. Классында эш ничек тора?

Мөршидә. Сынашабыз. Алар мине сыный, мин аларны.

Хаят. Уртак тел табарга вакыт. Факелны нигә сүндерден?

Мөршидә. Аягым таеп китте.

Хаят. Ышанмыйбыз. Кичә дә ышандыра алмадың. Бик тырышсаң да. Утыр. Белеп сүндердең. Алып кайтканда факел сүнгән булган. Зажигалкадан кабызганнар. Шуның өчен аягың таеп китте.

Мөршидә. Сезгә следователь генә буласы иде.

Хаят. Кем сөйләргә тели? Мәликә, син сүз сорадыңмы?

Мәликә *(баса)*. Мөршидә турында ни әйтим... Тырыш, өйрәнергә омтыла, белергә омтыла. Гадел.

Нурислам. Миңа мөмкинме?

Сажидә *(иренең алдына төшә)*. Мин сөйлим. Мин Мәликә фикеренә кушылам. Өметле кыз булып чыкты яшь иптәш. Эше өчен янып йөри. Киңәшем шул: үзе турында да уйласын. Авылда төрле кеше бар, телгә керергә дә күп кирәкми. *(Сажидә сөйләп бетергәч, Нурислам аңа үз янында урын күрсәтә, әмма Сажидә утырмый).*

Хаят. Бүтән сөйләүчеләр юкмы? Алайса карар кабул итик. *(Әнвәргә ишеттерергә тырышып.)* «Мөршидәнең персональ эше педсоветка куелмады дип санарга». Каршылар юкмы? Юк. Мәликә, кабинет ишеген ачып җибәр әле. *(Мәликә берни аңламыйча Хаятка карап тора.)* Ач, ач. Көн тәртибенең беренче мәсьәләсенә күчәбез.

Мәликә *(ишекне ачып җибәрә дә аптырап кала)*. Хикмәтле йозак икән бу. Эчкә керәсең, тыштан биклисең.

Әнвәр кабинетыннан килеп чыга. Кара янган. Дәшми.

Сажидә. Ба-а-а-а... Без күктән көтәбез, ә сез җирдә икән. *(Укытучылар арасында уңайсызлану. Әнвәр Хаятка текәлеп карап тора. Ә Хаят хат укый. Бөтен игътибары хатта.)*

Әнвәр. Бу ни, мәктәпкә кире кайтарганым өчен рәхмәтегезме? Директорга домашний арест салырга ни хакыгыз бар?!

Мәликә. Укытучының үз укучысын почмакка бастырырга нишләп хакы булмасын, Әнвәр Галимович.

Хаят *(нык дулкынланган, хатны Нурисламга суза)*. Нурислам, бу синең хакта.

Нурислам хатны алып укып чыгарга да өлгерми, кулыннан Сажидә тартып ала. Тикшереп кенә чыкмакчы иде, әмма игътибар белән укый башлый. Үзгәрә, Нурисламга күтәрелеп бер карап куя да кабаланып тагын укырга ябыша. Шулай да ахырына кадәр укып бетерә алмый, күз яшенә тыгылып иренең күкрәгенә каплана.

Сажидә. Нурислам! Бәгырь кисәгем!

Мөршидә. Кайдан ул хат? Нәрсә турында?

Мәликә. Литвадагы бер шәһәрдән.

Сажидә. Укы әле, укы.

Мөршидә *(хатны алып, кычкырып укый)*. «Сез безнең өч меңгә якын кешене үлемнән коткарып калган кеше... безнең шәһәрне фашистлар тырнагыннан азат итүдә күрсәткән батырлыгыгызга югары бәя биреп, партиянең шәһәр Комитеты һәм шәһәр Советы башкарма Комитеты Сезне, Ватан сугышы Герое Нурислам Кадыйрович, шәһәребезнең Почетлы гражданнары исемлегенә кертү турында карар кабул итте...» *(Мөршидә хатны укуын дәвам иттерә алмый, күзен яшь томалаган, иреннәре дерелди.)* Нурислам абый!..

Әнвәр *(килеп кулын кыса)*. Герой!..

Мәликә. Шушы көнгә кадәр шуны сөйләмәскә, күпме бергә эшлибез.

Әнвәр. Шундый геройлык күрсәтә торып.

Нурислам. Күпертмәгез лә зинһар өчен. Исән кайткан, шунысына мең шөкер. Күпме кеше ятып калды.

Ә н в ә р. Шулай да, нинди батырлык иде ул?

Н у р и с л а м. Хәтерләмим дә инде. Сугышта ни булмас. Ярый, ташлагызчы. *(Чыкмакчы.)*

Ә н в ә р. Юк, юк, сөйлисең.

М ә л и к ә. Нурислам!

Н у р и с л а м. Соң инде... Мин командовать иткән взвод шәһәргә беренчеләрдән булып бәреп керде. Плен төшкән немец офицеры шәһәр халкының костелга куып кертелүен, костелны шартлатырга, андагы халыкны һәлак итәргә җыенуларын әйтте. Без шундук костелга ташландык. Фашистлар өерен кырып салырга, халыкны коткарырга өлгердек, ә мине ярты үлек хәлендә госпитальгә озатканнар.

Ә н в ә р. Без, без дисең дә, монда сине язганнар, почетлы гражданин!

Н у р и с л а м. Исән калганнардан мин генәдер.

Х ә я т *(Нурислам янына килеп)*. Рәхмәт. Рәхмәт, Нурислам.

Ә н в ә р. Сөйләгән булсаң соң. Мин сезне мәктәптән җибәрә идемме.

С а җ и д ә. Сөйләп йөргәч, Нурислам буламыни ул.

М ө р ш и д ә *(сөенгән, дулкынланган)*. Нурислам абый, сөйлисез. Сөйләтәбез. Митингта, факел яндырып. Үзем отряд оештырам. Факелны мәңгелек уттан үзем яндырып алып кайтам. Нурислам абый, чыгыш ясарга әзерләнегез.

М ә л и к ә. Әй, Нурислам абыйлары өчен балалар сөенәчәк тә соң. Менә кайда аларга бәйрәм.

Н у р и с л а м. Арттырасың.

М ә л и к ә. Әйтә килдемме мин сезгә, мәктәптә ирләр тәрбиясе кирәк дип.

Ә н в ә р. Нурислам Кадыйрович, сез мине коткардыгыз. Кем әйтә герой бездә укымаган дип? Бездә укыган. Менә ул! Үз арабызда. Иртәгә райкомда күтәрәчәкмен. Бөтен конфликт берьюлы хәл ителә. Барысы да үз урынына утыра. Кая әле, хат кайда? Аны да райкомга!

Н у р и с л а м *(ачуы чыга)*. Ташлагыз! Мин сезнең карьерагызны коткару өчен сугышмадым, Әнвәр Галимович. Дан өчен дә түгел. Без ил сакладык. *(Чыгып китә.)*

С а җ и д ә *(ире артыннан)*. Атасы, сиңа борчылырга ярамый. *(Хәяткә карый.)*

Х ә я т. Педсовет бетте, иптәшләр.

Укытучылар таралышалар.

Х ә я т. Иртәгә райкомга үзем барам, Әнвәр.

Әнвәр кабинетына юнәлә. Ачкычны табып алып кесәсенә сала да кереп китә. Урамда машина тавышы.

Х ә я т. Таһирмы соң?

Т а һ и р керә. Туры апасына килә. Саубуллашалар. Икесенең дә күңеле тула.

Т а һ и р. Бая кызыбрак киттем. Үпкәләмә.

Х ә я т. Хәерле юл.

Т а һ и р. Мин тиз генә кайта алмам инде.

Х ә я т. Онытма. Яз.

Т а һ и р. Сәламәтлегеңне саклый күр. Минем өчен.

Х ә я т. Синең өчен булса, тырышырмын. *(Икесен генә калдыра)*. Мин сине машина янында көтәрмен. *(Чыга.)*

Т а һ и р. Карар кылдыңмы?

Мөршидә теле белән әйтергә курыккан кебек, «юк» дигәнне башын чайкап кына аңлата.

Таһир. Каласың?

Мөршидә. Ничек ташлап китим, мин бит Нурислам абый урынында. Аны алмаштырдым. Ә беләсеңме кем ул Нурислам абый? Аңлыйсыңмы?

Таһир. Бик яхшы аңладым, Мөршидә. Син мине яратасың. Әмма мин теләгән кадәр үк түгел. Болай гына. Чүт-чүт. Яраткан кебек кенә. Мәктәбең миңа караганда кадерлерәк. Кыскасы, юк синдә чын мәхәббәт. Мин теләгән якрату юк синдә. Хәерле булсын. Хуш! *(Ишеккә юнәлә.)*

Мөршидә. Таһир.

Таһир туктала.

Таһир. Син шушындый булмасаң, мин бәлки ярата да алмас идем. Ә яраттым мин сине. *(Чыгып китә.)*

Класс. Кич. Берәү дә юк. Мөршидә керә. Парталар арасында туктала. Күз алдына балаларны китерә.

Мөршидә. Минем сезгә олы хакыйкать турында сөйлисем килә. Кеше тормышта үз йолдызын таба белсен, якты идеалларыннан тайпылмасын. Нинди генә сикәлтәләргә эләксә дә, күңеленең сафлыгын саклап кала алсын, ваклыкларга яраклашмасын. Үткәнең өчен оялырлык, үкенерлек булмасын. Кеше бер вакытта да, бер генә мәртәбә дә үзенә хыянәт итмәсен... кыенлыклар алдында чигенмәсен. Чын кеше булып үсү җиңел түгел. Миңа җиңел дип уйлыйсызмы? Яратам бит мин аны. Ишетәсезме, балалар, яратам! Аның турында уйладыммы, күз алларым яктырып китә, иңнәремә канат үсә, күңелем каядыр ктыга, югарыга омтыла. Юк, мин ялгыз түгел. Ул бар. Сез бар. Мәхәббәт бар! Мәңгелек ут бар!

Музыка

Пәрдә

# А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 175 ЕЛ

## А. С. Пушкин

•

Мин үземә гаҗәп һәйкәл салдым
Ил сукмагы аңа өзелмәс.
Ул — буйсынмас биек; Александр
Баганасы аңа тиң килмәс.

Юк, бөтенләй үлмәм, гәүдәм тынса,
Җаным яшәр минем җырларда.
Даным калыр минем, ай астында
Актык шагыйрь калган чорда да.

Даным җәелер бөек Рус иленә,
Искә алыр анда һәр халык:
Мәгърур славян, фин һәм әлегә
Кыргый тунгус, дала дусты калмык.

Ил онытмас озак, чөнки анда
Дәрт кабызды минем җырларым,
Кара елларда мин ирек мактап,
Изелгәнне яклап җырладым.

Кимсетүдән курыкма, көтмә зурлау,
Тәңрең кушуың тыңла, карышма.
Исең китәрмәсен мактау, хурлау,
Тинтәк белән, ташла, ярышма.

1836

Ә. ФӘЙЗИ тәрҗемәсе

•

Рудалары астында Себернең
Горур торып, сабыр итегез,
Бушка китмәс сезнең фикерегезнең
Бөек дәрте, авыр эшегез.

Бәхетсезлекнең кардәше — өмет
Сезнең җир астына үтеп кереп,
Тагын сезгә шатлык, көч бирер,—
Көткән көннәр алар тиз килер.

Каторгада сезнең куышларга,
Җиткән кебек азат җырларым,
Мәхәббәт һәм дуслык сезнең янга
Бикләр аша салыр юлларын.

Бар төрмәләр төшәр җимерелеп,
Өзелерләр авыр богаулар,
Сезне сөеп каршы алыр ирек,
Кылыч бирер сезгә туганнар.

1827

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәсе

## Кышкы кич

Каплый күкне җил дә давыл,
Кар бурап уйнап йөри,
Бер бүре кебек улый ул,
Бер бала кебек елый.
Я кинәт кыштырдый капшап,—
Йорт саламын туздыра,
Я шакый тәрәзне, охшап
Соңга калган юлчыга.

Безнең иске өйдә төнлә
Моңсу да, караңгы да.
Әбкәем, тәрәз төбендә
Калгыйсың ник тын гына?
Әллә җилләр улавыннан
Оедың-ардыңмы син,
Әллә орчык җырлавыннан
Йокыга талдыңмы син?

И эчикче, ичмасам,
Яшьлек дусым, гамь онтылыр,
Бир әле, кайда касәң?
Җанга рәхәт, ирмәк булыр.
Җырла диңгезләр иленең
Купшы песнәк-кошларын,
Җырла син бер яшь кыленнең
Таңда суга төшкәнен.

Каплый күкне җил дә давыл,
Кар бурап уйнап йөри.
Бер бүре кебек улый ул,
Бер бала кебек елый.
И эчикче, ичмасам,
Яшьлек дусым, гамь онтылыр,
Бир әле, кайда касәң?
Җанга рәхәт, ирмәк булыр.

## Кара шәл

Шашкандай карыйм да шул кара шәленә,
Сыкрый җан сагыштан, түзалмыйм хәлемә.

Хәйләсез, мәкерсез яшь егет идем мин,
Бер юнан сылуын өзелеп сөйдем мин.

Иркәләп назлады үземне яр-кызым,
Тик кара көннәргә китерде язмышым.

Бер көнне йортыма кунаклар чакырдым.
Җиксорын бер яһүд ишекне шакыды;

Әйтте ул: «Сыйлыйсың монда дус-ишләрең,
Ә ярың тегендә хыянәт эшләде».

Нәләтләп, тәңкәләр ыргыттым алдына.
Иң тугры колымны чакырдым яныма.

Без киттек чаптырып атларда, тегендә,
Кызгану әсәре калмады күңелдә.

Сылуның капкасын күрүгә түземне,
Акылымны югалттым, кан басты күземне...

Түрдәге бүлмәгә атылып кердем мин...
Сылуны бер әрмән куенында күрдем мин.

Оныттым дөньямны, кылычым нәкъ яшен...
Үбешкән җиреннән тормады кендәшем.

Мин башсыз гәүдәне бик озак таптадым,
Ә кызга әйтерлек бер сүз дә тапмадым.

Ялварды... акты кан... Исемдә, исемдә...
Аһ, һәлак сылу да, мәхәббәт хисе дә!

Сөрттем мин кылычым кыз шәлен алдым да,
Буялды кара шәл хуҗасы канына.

Ә колым, көн батып, кич җиткән уңайга,
Аларның гәүдәсен ташлады Дунайга.

Шул көннән бирле юк беркемне үпкәнем,
Күрмәдем төннәрнең рәхәттә үткәнен.

Шашкандай карыйм да шул кара шәленә,
Сыкрый җан сагыштан, түзалмыйм хәлемә.

## Кияү

Бай кызы кинәт югалды,
Өч көн кайтмады өйгә.
Бер төндә кайтып егылды,
Аңыннан язган көйгә.
Аталары хәл сораша,
Җавап бирми бит Наташа,
Калтырый, өнсез бала,
Көчкә-көчкә тын ала.

Ата-анасы пошына,
Төшенмәк була сергә,
Ахырда алар да тына,—

Кыз сөйләми шул бер дә.
Кыз да тынычланган кебек,
Алсу йөзле, уйнап-көлеп
Ишләре белән бергә
Чыга капка төбенә.

Бер көн дус кызлары белән
Капка төбендә чакта,
Чаптырып уза шул җирдән
Берәү тройка атта.
Атларга ябылган япма,
Егет каранып як-якка,
Чанага басып бара,
Атлары ярсып чаба.

Якынлашкач, карап үтә,
Кыз да күз сала аңа.
Егет җилдәй узып китә,
Кыз бала каушап кала.
Атылып өйгә керә кызый:
«Таныдым,— ди,— ул үзе,
Тотыгыз тиз, барыгыз,
Явыздан коткарыгыз!»

Борчылып ата-анасы
Башларын чайкап тора,
Сүз куша шунда атасы:
«Әйт безгә, аңлат кына,
Кемнәр җәберләде, кызым,
Күрсәт кенә безгә эзен».
Елый гына Наташа,
Бер сүз әйтми башкача.

Иртә белән яучы килә,
Һич көтмәгән чагында.
Атасы белән сүз китә
Кыз ярәшү хакында:
«Сездә товар, бездә купец,
Егет шәп, уңган, молодец!
Буйга-сынга да килгән,
Бик булган, менә дигән.

Акыллы, бай, берәүгә дә
Бил бирми бөгеп сәлам,
Бояр кебек яши илдә,
Кичерми борчу-фәлән.
Ә бүләкне өяр егет:
Төлке тун да, алтын йөзек,
Энҗе-мәрҗән, парчасы...
Асыл затлы барчасы.

Кичә кичен калган күреп,
Бүген яучы җибәрде.
Килештекме?! Риза булып
Бирәсезме чибәрне?»
Яучы утыра ашап-эчеп,
Читләтеп кенә сүз кушып.
Ә бичара кыз бала
Нишләргә белми кала.

«Риза,— ди кызның атасы.—
Кайтып әйт, кызым тайяр,
Бирәбез,— ди,— Наташаны,
Ялгызлыкта ни ямь бар!
Гомергә кыз булып тормас,
Гел сайрап кына утырмас,
Вакыт оя корырга,
Балалар тудырырга».

Диварга сөялеп, нидер
Әйтмәк була Наташа,—
Көлә, елый, килә дер-дер,
Акылдан гүя шаша.
Яучы йөгереп янына килә,
Эчәргә салкын су бирә,
Калганын коя шунда
Наташаның башына.

Аһ да ваһ итәләр бар да,
Наташа килә телгә:
«Риза,— ди,— иргә чыгарга,
Буйсынам иркегезгә.
Кияүне дәшеп алыгыз,
Төрле сый-ашлар салыгыз,
Бал ачытыгыз туйга
Һәм чакыртыгыз судья».

«Ярый, Наташа, акыллым!
Атаң хәтта үләргә
Әзер синең өчен, кызым!» —
Туй хәстәре күреләә...
Бик күп кунаклар киләләр,
Менә кызны китерәләр,
Дуслары җырлый-елый.
Менә бубеннар чыңлый.

Чана туктый. Кияү керә.
Чәкәшеп төшерәләр.
Котлы булсын дия-дия,
Эчәләр, исерәләр.
«Ниткән эш, дуслар, бу, әй,
Ник минем кәләш болай
Ашамый-эчми икән,
Хәсрәткә төште микән?»

Кыз әйтә шунда кияүгә:
«Ниләр генә кылыйм мин?
Түзалмый җан авыр хәлгә,
Көне-төне елыйм мин.
Бер яман төш борчый һаман».
Атасы шунда: «Әйт, балам,
Төшеңдә нәрсә күрдең,
Ник безгә әйтми йөрдең?»

«Төшемдә мин күрдем болай:
Кара урманда, имеш,
Вакыт бик соң; бик тонык ай,—
Күктә болытлар көмеш;
Мин адаштым сукмагымнан,
Бер тавыш юк — тирә тынган,
Нарат та чыршы гына
Шаулашалар шым гына.

Менә кинәт, көтмәгәндә
Йорт килеп чыкты алда,
Шакыйм, шакыйм, юк берәү дә,
Ишектән кердем. Анда
Шәм янып тора бүлмәдә,
Карыйм, исем киткән хәлдә,
Алтын-көмеш идәндә,
Чиксез байлык тирәмдә».

Кияү

«Ник андый төш яман булсын?
Бай яшәрмен дип юра».

Кыз

«Төшнең башы гына бусы,
Барча байлыкка монда,
Постаулар, парчаларына,
Новгород камчыларына...
Сокланып тордым карап,
Бетәрлек түгел санап.

Кинәт тояк тавышлары,
Тышта шау-шу — кайттылар.
Ишекне яптым, аннары
Качтым тиз мич артына.
Ә ишектән, шау-гөр килеп,
Керде нәкъ унике егет
Һәм алар белән бергә
Матур кыз узды түргә.

Өере белән керде алар,
Иконаларны күрми,
Өстәлләргә утырыштылар,
Чукынып-нитеп тормый.
Иң түрдә — олы туганы,
Уң кулда — кече туганы,
Сул кулда — теге сылу,
Йөзләрендә борчылу.
Уен-ирмәк, җырлаш, көлеш,
Эчү башлана шунда».

## Кияү

«Ник яман булсын андый төш?!
Шат яшәрмен дип юра».

## Кыз

«Тукта, егет, төш бетмәде,
Эчә кияү егетләре,
Мәҗлес гел кыза бара,
Тик кыз гына уфтана.
Ул эчми, ризык та капмый,
Кайнар яшьләрен коя,
Ә егете пычак кайрый
Һәм сызгыргалап куя.
Сылуга кырын күз сала,
Аннан толымын урап ала,
Уе яман явызның,—
Уң кулын кисә кызның».

«Менә бусына,— ди егет,—
Һич түгел ышанырлык!
Чибәрем, юк-бар төш күреп
Урын юк пошынырлык».
Кыз төбәп карый егеткә:
«Кара әле бу йөзеккә!
Я, кемнеке бу йөзек?!»
Калтырап төшә егет.
Йөзек, төшеп, тәгәрәп китә,
Кияү ап-ак агара,
Халык тора, судья әйтә:
«Явызны богауларга!»
Аңа богау кидерәләр,
Үлем җәзасы бирәләр.—
Наташа бәйрәм итә,
Бәет тә шунда бетә.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## СЕНТЯБРЬ, 1973 ЕЛ

Кама буенда автогигант төзүдә һәм Чаллыда яңа шәһәр салуда Мәскәү һәм мәскәүлеләрнең өлеше зур. Лихачев исемендәге завод инженерлары һәм конструкторлары «КамАЗ» маркалы зур йөк машиналарына тормышка путевка бирергә әзерләнәләр. Мәскәү архитекторлары Кама буенда иң матур шәһәрләрнең берсе булачак Чаллы шәһәренең проектын төзиләр. Мәскәүлеләр автоградның проектын төзү белән генә чикләнмиләр. Биредә алар беренче торак йортны салдылар. Бүген автоградны төзүдә мең ярымнан артык башкала төзүчеләре эшли. Алар салган йортлар матур эшләнешләре, тышкы бизәкләре, квартираларның уңайлы урнаштырылулары белән аерылып тора. Яңа шәһәр төзелә башлаганнан бирле — 1971 елның августыннан мәскәүлеләр инде 230 мең квадрат метрдан артык торак мәйдан тапшырдылар.

**«Правда», Мәскәү.**

«Армэлектродвигатель» заводы коллективы Чаллыга «АОЛ-2» маркалы күп кенә электромоторлар җибәрде һәм шуның белән КамАЗ өчен продукция әзерләүнең тугыз айлык планын үтәде. Ереванда ясалган универсаль моторлар автогигантта күп кенә производство процессларын автоматлаштыра һәм машинага көйләү өчен файдаланылачак фирма коллективы Чаллы өчен моторлар җитештерү буенча еллык планны октябрь аенда үтәү өчен көрәшә.

**ТАСС, Ереван.**

Чаллыда Татарстан композиторлары союзы тарафыннан оештырылган КамАЗ турында иң яхшы музыкаль әсәрләргә конкурс булып үтте. Чаллы районы Культура йорты каршындагы тынлы оркестр «КамАЗчылар маршы»н башкарды.
Дәүләт премиясе лауреаты, СССР халык артисты, профессор Натан Рахлин җитәкчелегендәге Татар дәүләт симфоник оркестры башкаруында Ф. Әхмәтов, Ә. Бакиров, Х. Вәлиуллин, А. Монасыйпов әсәрләре яңгырады.

**«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».**

Горький электромонтаж җиһазлары заводы үзләренә бирелгән җаваплы заказны вакытыннан элек башкарды. Кама автогигантын төзүчеләргә йөзләрчә комплект әйберләр җибәрелде. Алар автозаводта энергетика системаларын, электр җиһазларын монтажлау эшен кыска вакыт эчендә башкарып чыгарга ярдәм итәчәк. Производствоның барлык участокларында почетлы КамАЗ заказына «яшел урам» ачылды.

**ТАСС, Горький.**

«Тугызынчы бишьеллыкның зур төзелеше — Кама автомобиль заводы бүген нинди омтылышлар белән яши?» — «Труд» хәбәрчесе КамАЗ профсоюз комитеты председателе Г. Закирҗановка шундый сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Төзүчеләр алдында,— диде ул,— беренче чиратта цех корпусларының түбәләрен ябу, производство биналарына җылылык үткәрү, җиһазлар монтажлаучыларны эш фронты белән тәэмин итү бурычы тора. ТЭЦны ходка җибәрергә әзерлек эшләре бара, ул октябрь аенда эшли башлаячак.

КамАЗның беренче заводы — ремонт-инструменталь заводта монтаж эшләре зур темп белән бара. Бер мең 800 станок монтажланды, шуларның мең ярымга якыны эксплуатациягә дә тапшырылды инде.

**«Труд», Мәскәү.**

«Сердца четырех» — Калинин шәһәрендәге иң яхшы вокаль-инструменталь ансамбльләрнең берсе шулай исемләнгән иде. Ансамбль членнары В. Забурский, С. Соколов, А. Пронин, Е. Катаев Кама буендагы бөек төзелешкә китәргә булдылар. Комсомол путевкалары алып, егетләр КамАЗга килделәр. Төзелештә эшләүчеләргә бүләк итеп алар җыр алып килделәр. Хәзер ансамбльнең исеме яңа — «Кама таңнары». Коллективның репертуары киң. Анда татар халык җырлары да, классик әсәрләр дә бар. «Татарстан буйлап сәяхәт» җыры аеруча шатлыклы яңгырый.

Культура йорты ачылышка коллектив яңа программа әзерли.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Воронеж авыр механик пресс заводы эшләп чыгарган махсус прессларның беренче партиясе графиктан ике айга элегрәк Чаллыга җибәрелде.

КамАЗ өчен бу прессларны җыю эшен И. Панов һәм В. Шерстюков җитәкчелегендәге алдынгы бригадалар башкара.

**ТАСС, Воронеж.**

Наманган «Электротерм» производство берләшмәсе Чаллыга электр җылыткычлар җибәрде. Бу приборларны берәмләп тә, һәртөрле зурлыкта һәм формада батареялар ясап та урнаштырып була. Алар һаваны да, суны да һәйбәт җылыталар, җылылык бирүнең югары коэффициенты белән аерылып торалар. Бу җылыткычларны КамАЗ өчен заводның иң яхшы бригадалары эшли. Автогигант цехларына салкыннар башланганчы куелырга тиешле приборларны эшләүне завод графиктан элегрәк башкарды.

**ТАСС, Наманган шәһәре,**
**Үзбәкстан ССР.**

Озакламый башкалада яшәүчеләр һәм кунаклар Революция музее залларының берсендә тугызынчы бишьеллыкның зур төзелеше — КамАЗ турындагы экспозицияләр белән таныша алачаклар.

Музейның фәнни хезмәткәрләре күптән түгел Чаллыда булып, төзелеш барышы, андагы кешеләр, аларның хезмәте, тормышы, көнкүреше, ял итүләре турында материал туплап кайттылар.

**«Социалистическая индустрия»**
**на строительстве Камского автозавода».**

Чаллыда СССР халык артисты, Ленин премиясе лауреаты Людмила Зыкина концертлары зур уңыш белән барды. Концертлардан соң популяр җырчы газета хәбәрчеләре белән очрашты.

«КамАЗ төзүчеләргә сез нәрсә теләр идегез?» — дигән сорауга Л. Зыкина:

— Күңел көрлеге, хезмәттә яңа уңышлар телим,— дип җавап бирде.— Монда башкарыла торган эшләр барыбызның да киләчәге өчен эшләнә. Бу төзелештән озак вакытлар дәвамында киләчәк төзелешләр үрнәк алачак. Мин дә, барлык башка кешеләр кебек үк, завод һәм шәһәребез матур, уңай булсын дип телим. Эштән шатлык бөркелсен, күңелләр бәхет белән тулсын! Ә без биргә ешрак килергә тырышырбыз...

**«Социалистическая индустрия»**
**на строительстве Камского автозавода».**

Диңгез пароходчылыгы суднолары Мурманскидан АКШ портларына даими йөреп тора. «Шура Кобер», «Вася Шишковский», «Валя Котик» теплоходлары Америкадан КамАЗ өчен җиһазлар алып кайттылар...

ВЛКСМ Үзәк Комитеты карары нигезендә оештырылган «СССРның 50 еллыгы» исемендәге удар отрядның икенче группасы 500 егет һәм кызлардан тора. Алар күптән түгел КамАЗның яшь төзүчеләре сафына бастылар.

Бөтенсоюз удар комсомол төзелешенә килеп җиту уңае белән үткәрелгән тантаналы митингта Россия Федерациясенең 37 автономияле республикасы, крае һәм өлкәләреннән килгән яшь төзүчеләр производство планнарын вакытыннан элек үтәргә, комсомол экономия фондына 32 мең сум акча кертергә, «КамАЗ төзелеше ударнигы» исеме өчен ярышка кушылырга, профессиональ осталыкны, гомуми белем, идея-политик дәрәҗәне үстерергә сүз бирделәр.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**



Сентябрь башында КамАЗда халык кинофестивале булып үтте. «Чулпан», «Гренада» кинотеатрларында, якындагы поселок клубларында, цехлардагы һәм монтаж идарәләрендәге клубларда, еш кына турыдан-туры төзелеш мәйданнарында эшчеләр кино сәнгате осталары белән очраштылар.

— Сәнгатьнең көче,— диде фестивальне ачканда партиянең шәһәр комитеты секретаре И. С. Донская,— халык белән даими бәйләнештә булуда.— КамАЗчылар халык кинофестивале оештырган кинематографистлар союзына рәхмәт белдерделәр. Бу — кино хезмәткәрләре белән автомобиль комплексы төзүчеләре арасындагы иҗади дуслыкның башлангычы.

СССР кинематографистлары союзы делегациясе: идарә секретаре А. Караганов, кинодраматург Б. Метельников, киноактерлар М. Володина, Л. Шагалова, Е. Градова, Д. Фирсова, В. Этушлар Чаллыда һәм Түбән Камада 38 очрашу үткәрделәр, аларга 25 мең тамашачы катнашты. Шул ук вакытта «Ирек — тәмле сүз», «Иван Васильевич һөнәрен үзгәртә», «Монолог», «Язның 17 мизгеле» фильмнарының премьералары булды.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Каунас шәһәренең «Нерис» заводыннан Кама автогиганты төзелешенә микрошлифлар әзерли торган махсус станокларның беренче партиясе озатылды. Алар ярдәмендә автомашинаның иң мөһим детальләр ясауга китә торган металлның микроструктурасы билгеләнәчәк.

КамАЗ заказы бер айга вакытыннан элек башкарылды. Завод коллективы предприятие коммунистларының удар төзелеш заказларын иң кыска срокта һәм югары сыйфатлы итеп башкарырга чакыруларына бертавыштан кушылды.

Шәһәрдәге барлык станок төзү заводлары КамАЗга үз продукцияләрен озаталар. «Прекалас» махсус станоклар заводы камилләштерелгән ярым автоматлар җибәрде, Дзержинский исемендәге станок төзү заводы да якын көннәрдә удар төзелешкә үз продукциясен озатачак.

**ТАСС, Каунас, Литва ССР.**

Кама автомобиль комплексы төзелеше Чаллы районының экономик структурасын тамырдан үзгәртә. Шәһәр тирәсендә куәтле авыл хуҗалыгы зонасы үсеп чыга. Анда барлык эшләр промышленность нигезендә башкарылачак. Шуңа бәйләнештә шәһәр тибындагы поселоклар салына.

Авыллардагы төзелеш эшләрен рациональ оештыру өчен проект төзүчеләр реконструкция алымнарының иң эффектлыларын эзлиләр.

**«Жилищное строительство», Мәскәү.**

Чаллы музеенда «Сезгә, КамАЗ төзүчеләр» дигән исем астында үткәрелгән күргәзмә-конкурста Г. Симбирин, В. Куделькин, И. Әхмәдиев әсәрләренә югары бәя бирелде — алар конкурс лауреатлары исеменә лаеклы дип табылды.

Чаллы кешеләре Татарстан художниклары союзы һәм Казан сынлы сәнгать музее оештырган сатирик рәсем күргәзмәсен дә яратып карадылар.

Казандагы А. М. Горький музее фәнни хезмәткәрләре дә КамАЗда еш булалар. Алар — тулай торакларда, төзелеш мәйданнарында эшчеләр өчен кадерле кунак. Чаллы музеенда алар ярдәмендә «Пушкин Казанда», «Рус әдәбияты классиклары Татарстанда» дигән күргәзмәләр оештырылды.

«Советская культура», Мәскәү.

Петров исемендәге Баку машина төзү заводыннан КамАЗ төзүчеләр адресына эре суыткаргеч металл конструкцияләр җибәрелде.

Аерым өлешләре 2,8 метр диаметрлы бу трубалар буйлап КамАЗдагы ТЭЦның турбиналары конденсаторларын суыту өчен су кудырылачак.

Хәзер трубаларның яңа партиясе озатылырга әзерләнә. Сентябрь аенда автозавод төзүчеләр тагын 150 тонна труба алачак.

Бу трубаларны әзерләү тәҗрибәле мастер П. М. Спичак җитәкчелегендәге иң яхшы бригадага тапшырылды.

ТАСС, Баку.

Чаллыда Чехословакия яшьләре арасында зур популярлык казанган «Контакт» эстрада ансамбле (Братислава) кунак булды.

Алар концертларда словак һәм рус халык җырларын, эстрада әсәрләрен башкардылар.

КамАЗ төзүчеләр Дунай буеннан килгән кунакларны җылы каршылады.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

СССР Монтаж һәм төзү эшләре министрлыгының Свердловск механика заводы коллективы КамАЗ заказын вакытыннан бер айга элек үтәде.

Урал эшчеләре «МСК» кранын монтажладылар. Бу кран гадәти типтагы краннардан төзүчеләргә киңрәк мөмкинлекләр бирә.

Быел Свердловск механика заводы КамАЗ өчен озайтылган уклы тагын бер зур кран әзерләячәк. Әлегесе кебек үк, монысы да төзүчеләргә срогыннан элек тапшырылачак.

ТАСС, Свердловск.

Шушы елның 22 июнендә «Советская культура» газетасында КамАЗда культура тормышы проблемаларына багышланган материаллар басылып чыккан иде. Газетаның бу чыгышы укучыларның, шулай ук төзүчеләргә культура хезмәте күрсәтүне яхшыртуга бәйле учреждениеләрнең, оешмаларның игътибарын җәлеп итте.

Газетаның 21 сентябрьдә чыккан санында моңа ВЦСПС секретаре Л. Земляникованың, СССР Художниклары союзы идарәсенең, Бөтенсоюз театр җәмгыятенең, Үзәк актерлар йорты директоры СССР халык артисты М. Жаровның җаваплары басылып чыкты. Аларда КамАЗ төзүчеләр белән иҗади контакт программасы билгеләнә.

РСФСР Министрлар Советының нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре Дәүләт комитеты председателе Н. Свердлов Чаллы укучыларын әдәбият белән тәэмин итү буенча конкрет чаралар турында яза.

«Советская культура», Мәскәү.

Марсель Зарипов

# ТАВЫК КОШМЫ, ТҮГЕЛМЕ?..



Аңлап кара инде бу Чигвинцев дигән кешене? Вакыты белән бик сак, саран, сумын гына түгел, тиененә кадәр санап бара. Ә кай чакта меңәре белән очканда да исе китми... Бик каршылыклы натура ул. Бер караганда, эшендә төгәл дә, принципиаль дә. Шул ук вакытта кирәгеннән артык йомшак та үзе. Ә аннары шуңа үкенеп, нервлана: үзе дә сизмәстән фильтрлы сигаретын алып каба, иң каты сүзләр белән үзен-үзе орышырга тотына, әмма аннан гына кешенең холкы үзгәрми бит.

Чигвинцевның характерындагы каршылыкларны телгә алганда, мин иң элек шуны күз алдында тотам. Уйлап карагыз: тавыкларга азыкны Чигвинцев Чаллы элеваторыннан ала. Өсте ябык зур-зур әрҗәләр белән махсус җиһазландырылган машиналарын һәр көн кырык чакрымга куа. Элеваторда катнаш азыкның сыйфатын тикшерә торган махсус лаборатория дә бар. Димәк, җимне алып кайт та, бер дә шикләнмичә тавык-чебешкә сип, чүпли бирсеннәр, тик йомыркаларын гына салсыннар. Ә юк, Чигвинцев алай итми. Азыкка анализ ясап барырга үз лаборантларын утырта, әзер җимне, кабат эшкәртү өчен тагын бер цех ачып җибәрә. Җәһәннәм астыннан, Кара диңгездән, диңгез кабырчыклары алып кайта, үзләре яныннан, Камадан, вак чуер таш ташыта, ит комбинатларыннан техник май эзләп таба, күп төрле поливитаминнар юллап Белгородка, Мари республикасына бара...

Шуларның барысын да исәпләп-хисаплап баксаң, мондый саннар килеп чыга. Узган ел гына да Чигвинцев 120 центнер балык мае, 1558 центнер техник май, 958 центнер балык оны, 252 центнер сөяк оны, 319 центнер тоз алып кайткан. Шуларны эшкәрттергән һәм элеватордан алган катнаш азыкка кушып, тавыкларына ашаткан. Шуларның барысына 230 мең сум акча киткән. Шактый капитал! Шунысы да бар: ул тамаша эшне башкарып чыгар өчен күпме көч түгелгән, күпме нерв туздырылган бит әле!

Барысын исәпләп карагач, бу Чигвинцев нигә кычытмаган җирен кашып интегә икән, дигән уй килде минем башка. Нигә дәүләт стандарты буенча әзерләнгән, димәк, сыйфаты әйбәт булган элеватор эшләп биргән җимнән генә канәгать түгел икән ул? Нигә артык хәсрәт алып, үзен дә, башкаларны да бимазалап йөри икән? Әлеге йөзләрчә

тонна витаминнар, майлар зур авырлык һәм очраклы юллар белән генә табыла бит. Күп вакытта эшнең язмышы кыл өстендә генә кала, чак кына «җил исеп» куйды исә, ул кылның шундук өзелеп китәрдәй чаклары еш була.

Түзмәдем, күңелемә килгән бу уйларымны Чигвинцевның үзенә дә әйттем.

Аның ни дип җавап биргәнен язганга кадәр бер нәрсәне искәртеп китәсем килә. Шуннан бер көн элек кенә элеватор директоры Галимҗан Закиров белән очрашкан идем. Сүз уңаенда Чигвинцев филиалын да телгә алып, сезнең элеватор ярымфабрикат кына эшләп чыгарамыни, сездән алган җимне соңыннан кат-кат эшкәртергә туры килә икән бит, нигә алай брак эшлисез, дигән идем мин аңа. Закиров кулын гына селекте дә:

— Модалар ательесында гына һәр көязнең теләген канәгатьләндерәләр. Ә безнең элеватор модалар ательесы түгел бит! — диде.

— Чигвинцев бәлки фокусниктыр ул, кем белә аны. Кем белә аны: иртәгә тотар да тавыкларына килосы алты сум тора торган чөгә балыгы яки кара икра ашата башлар! Без тагын, рәхим итеп, аның кубызына бии башларга тиеш булабызмы?..

Шулай итеп, элеватор директоры минем авызны бик тиз томалап куйды.

Менә шуңа күрә дә теге сорауларны Чигвинцевка бер дә икеләнмичә бирдем мин. Дөресен әйтим, ул аптырап калыр дип көткән идем. Әмма Чигвинцевның чәнти бармагы да селкенмәде.

— Закировка аңа нәрсә? — диде ул һәм иплән кенә сигаретын кабызды. — Ул бит үз каланчасыннан гына карый. Әйе, элеватор үз продукциясенең сыйфатын гарантияли, җимгә анализ ясап, язуын да җибәрә. Ә миңа ни пычагыма аның язуы. Миңа чебешләрем тиз үссен, тавыкларым йомырканы күп салсын, итләре тәмле булсын, каурый-мамыкларыннан менә дигән йомшак ястык чыксын! Әлбәттә, азыкны элеватордан алып кайтып, шундук кошларның алларына сибәргә дә була. Моңа зур акыл кирәк түгел. Анысын теләсә кем булдыра аның. Бәлки дуңгызлар гына асрасам, мин дә шулай эшләр идем. Ләкин бит чебеш чучка түгел. Әгәр тавык-чебешкә җимне шул элеватордан алып кайткан хәлендә генә ашата башлап, эшләрнең көе китсә — хәзер Чигвинцевка төртеп күрсәтә башлаячаклар. Менә, имеш, дәүләттән дөнья кадәр акча алды, нинди зур фабрика салды, тегеләй итәм дә болай итәм, дип алтын таулары вәгъдә иткән булды, диячәкләр. Әгәр шундый хәлгә калсаң, җир тишегенә кер дә кит инде аннары!..

Тукта, мин сезгә Чигвинцевның кем икәнен әйтмәгәнмен бит әле. Григорий Никифорович Чигвинцев «Красный ключ» совхозы директоры. Ә совхозда тавык үрчетәләр, йомырка һәм тавык ите җитештерәләр. Совхозның кайбер экономик күрсәткечләренә күз салып үтик. Узган ел совхоз дәүләткә кырык миллионнан артык йомырка, биш мең центнерга якын тавык ите тапшырды. Бишьеллыкның өч елында планнан тыш унөч миллион йомырка (зур бер кош фабрикасы җитештергән кадәр) җитештерде, ә тагын ике елдан соң елына 70—80 миллион данә йомырка җитештерергә ниятли. Күпме бу, азмы? Бу — узган бишьеллыкта бөтен Татарстан җитештергән йомырканың яртысы дигән сүз!

Дөрес, хәзер нәтиҗәләр белән генә мактана торган заман түгел. Ул нәтиҗәләргә ничек, нинди юллар белән ирешелгән — хәзер иң мөһиме әнә шул. Бу хакта озаклап сөйләп укучыларны ялыктырмас өчен, тик шуны гына әйтеп китәм: «Красный ключ» совхозында бер кеше биш сәгать эш вакытында мең йомырка җитештерә, тавыклар саны тик бер ел эчендә генә дә ике йөз меңгә арткан. Гыйбрәтле сан-

нар болар. Болар белән кайда да мактанырга да, горурланырга да була.

Диңгезчеләр корабны мактыйм дигәндә, иң элек аның тизлеген телгә алалар. Монда мактаныйм дисәң, иң башта ит, сөт, йомырка алу өчен күпме азык тотканыңны әйт. Менә кайда хикмәт! Азыкны исәпсез-хисапсыз, тау кадәр итеп мал алдына салу өчен зур баш кирәк түгел. Аны теләсә кем булдыра, ә син менә аз азык белән күп ит, күп йомырка алып кара! Моңа ирешү өчен эшнең рәтен белүдән тыш зирәклек тә, хәйләкәрлек тә, тырышлык та кирәк...

Чигвинцев мең йомырка алу өчен 1,8 центнер азык берәмлеге сарыф итә. Бер азык берәмлеге бер кило солыны алыштыра. Моны хәтергә салып куйыйк — кирәге булыр.

Бу сан белән, ягъни 180 килограмм солы сарыф итү белән мактанырга да була, шуның өчен орышырга да мөмкин. Монда хикмәт мәсьәләгә кайсы яктан килеп карауга бәйле. Әйтик, Россия «Птицепром» фабрикаларында мең йомырка алу өчен ике йөз егерме килограмм азык берәмлеге тотыла, ди. Бу Чигвинцевныкыннан кырык килограммага артык дигән сүз. Димәк, кырык миллион данә җитештергәндә Чигвинцев елына 16 мең центнер икмәкне янга калдыра булып чыга. Әгәр дә «Красный ключ» күрсәткечләрен эталон итеп алсак, бүтән совхозлар экономия ясамый, бәлки икмәкне кирәгеннән артык әрәм-шәрәм итә булып чыга.

Исәп-хисапны тагы дәвам итик. Россия «Птицепром»ы 1973 елда барлыгы унике миллиард данәдән артык йомырка җитештерде. Димәк, илле мең тонна ашлык кирәгеннән артык сарыф ителгән. Образлы итеп әйтсәк, крестьян халкы төн йокыларын калдырып, тир түгеп үстергән унбиш мең тонна икмәкне тотканнар да елгага аударганнар. Хәер, алай гына түгел. Ярый әле, берьюлы- аударып кына эш бетсә. Ә бит бу «артык» икмәктән җим ясау өчен төрле балык, сөяк оннары, әллә нинди поливитаминнар, төрле майлар, минераль азыклар өстәп эшкәртергә кирәк... Шул «артык» икмәктән эшләнгән җим «Красный ключ» тавыкларына алты ел ашатырга җитәр иде. Димәк, совхоз алты ел буена шушы «артык» азыкны ашатып, кырыгар миллион данә йомырка, дүртәр йөз тоннадан артык тавык ите җитештерә алган булыр иде.

Тагын бер мисал китермәкче булам. Алда ул безгә кирәк булачак. Чигвинцевка узган ел бер йомырка 4,3 тиенгә төшкән. Ә аны дәүләт 9 тиен түләп сатып ала. Шулай итеп, совхозга һәр йомыркадан биш тиенгә якын акча килә барган. Саф табышы ике миллион өч йөз дә туксан меңгә җиткән. Я, шушыннан соң тавык кош түгел, дип әйтеп карагыз инде менә!

Алай дип әйтмиләр әйтүен Чигвинцевка. Ләкин сүз җае чыкканда төрттереп куялар. Янәсе, аңа һәр эштә гел җай чыгып кына тора. Эше ничек шәп бармасын ди аның...

Анысы да дөрес. Җае килгән яклары да юк түгел. Совхоз утырган урыннан да яхшыракны табып булмас иде. «Красный ключ» искиткеч матур җирдә — Кама буена ук урнашкан. «Бруски» романының авторы Панферов ыгы-зыгылы башкала тормышыннан качып, заманында шушында килеп торырга җыенган булган. Төз һәм юан нарат-лар арасында аңа дип салдырылган йорт хәзер дә тора әле. Җирле халык аны һаман да «Панферов йорты» дип йөри. Ул йорт янынннан Кама бик яхшы күренеп тора. Җәен иртән иртүк торып чыгып, яр буендагы тау өстенә бассаң, сулышлар иркенәеп, җаннар рәхәтләнеп китә. Тирә-як тып-тын. Ара-тирә сузып кычкыртып куйган теплоход тавышыннан башка шылт иткән аваз да юк. Теплоходларның әле сүндереп өлгермәгән яшел, кызыл, сары һәм ак утлары су өстендә җемелдәп, экияттәгедәй матур булып күренә...

Монда җире дә бик уңдырышлы. Узган ел, барыбызга да мәгълүм, Кама буйларында, Чаллы тәбәгендә бик нык корылык булды. Игеннәр кәеп бетә язды. Түбән Кама районы буенча гектарыннан нибары 11,9 центнер гына уңыш җыеп алынды. Ә менә Чигвинцев тагын «бәхетлерәк» булып чыкты: аның совхозы уңышны ике тапкыр диярлек артыграк алды.

Аның тавыклары да республикабызда йомырканы иң күп сала торган тавыклар. Читлектә утырып орлык чүплиләр, сусасалар чиста су эчәләр һәм, әйтерсең, сүз берләшкәннәр, һәркайсы елына 230 ар йомырка сала.

Тавыклары гына түгел, хәтта бал кортлары да бүтәннәрнекенә караганда акыллырак, эшчәнрәк. Андый акыллы, тырыш кортларны кайдан тапкандыр, шайтан! Совхозда дүрт умарталык бар. Шул умарталыклардагы һәр корт семьясы икешәр пот бал җыеп биргәннәр. Чигвинцевка тагын дан, тагын премия, тагын аның авторитеты күтәрелә!

Ниһаять, Чигвинцевның эше гел җай гына, гел уңышлы гына бара диючеләргә тагын бер дәлил: фабрикасында эшнең ничек баруын белер өчен тегендә-монда чабып йөрисе түгел аңа. Кабинетына киләсе дә телевизорын кабызып, тәмәкесен тартып, карап кына утырасы! Ә телевизоры фабрикада эшнең ничек барышын, тавыкларның ни кылануларын барысын да бик ачык итеп күрсәтеп тора.

Белмим, бәлки чыннан да, Чигвинцев эше гел җай гына бара торган, халык әйтмешли, туганда ук күлмәк киеп туган бәхетле кешедер. Ләкин бу хакта сүз озайтып тормастан, игътибарны бүтән мөһимрәк нәрсәгә — Чигвинцевның менә шушы зур уңышларга ничек ирешүенә юнәлтмәк булам.

Чигвинцевка нәкъ илле яшь. Җитлеккән, шактый тәҗрибә туплаган кеше инде ул. Тормыш тәҗрибәсе аңа җиңеләеп, дуамалланып китәргә ирек бирмәс. Ә төптән уйлап тотынган эшләрне эшләргә аның әле көче дә бар, дәрте дә сүнмәгән. Кызыклы экспериментлар ясап карарга, кирәк чагында тәвәккәллек күрсәтергә дә хәленнән килә.

Беренче экспериментын, хәзергечә итеп әйтсәк, концентрациягә омтылышын Григорий Никифорович үз белдеге белән, үз тәвәккәллеге белән гамәлгә ашырган...

Ул үзе авылда туып үскән. Авыл мәктәбендә укыган, аннары техникум тәмамлап, зоотехник булып чыккан. Бераз колхозда эшләгәч, институтка укырга киткән. Фәнне җиңел үзләштергән: яхшы укуы белән беррәттән, җәмәгать эшләренә дә якыннан торып катнашкан, студентлар җәмгыятендә фәнни-тикшерену эшләре белән дә шөгыльләнгән.

Дөрес, ул тикшеренүләр әле зур фәннән ерак була, ләкин студент Чигвинцевның тырышлыгын, фәнни эшкә сәләте барлыгын остазлары сизенеп ала. Чигвинцев институтны гел бишлегә генә тәмамлагач, аны беркая да эшкә билгеләмичә, ярты ел буена кафедрада тоталар, аспирантурада калдырмакчы итәләр. Ләкин ул риза булмый, берәр гадәти совхозга эшкә китүне артыграк күрә. Гадәти дип мин шул мәгънәдә әйтәм, ул елларда барлык хуҗалыкларда да, һәр төрле терлектән берәр пар дигәндәй, тавыгын да, үрдәген дә, сарыгын да, дуңгызын да, сыерын да бергә асрыйлар иде бит.

Чигвинцев та шундый совхозга барып урнаша. Андагы хәлләрне яхшылап өйрәнгәннән соң, ул совхозның төрле җирдә урнашкан фермаларындагы барлык тавыкларны бергә туплау уе белән яна башлый. Ул чорларда комплекслар, фабрикалар, телевизор аша идарә итүләр турында Чигвинцев авыз да ачмый. Аның «концентрацияләү» дигән нәрсәсе дә җитештерү характерын һич тә үзгәртмичә генә «җыйнау»дан гыйбарәт була. Ләкин совхоз директоры аның бу

фикере белән килешми, искечә эш итүне яхшырак саный: «Кирәкми, без генә артык акыллы булмыйк. Ничек эшләгән, шулай эшләсеннәр — кешеләрне дә борчымыйк. Аннары тагын ике мең тавык сыйдырышлы кетәклекне ничек итеп салмак кирәк», — ди.

Чигвинцев — үзсүзле кеше. Әгәр ниятләгән эше барып чыгарына һәм файдасы булырына ныклап ышанса — син аны тоткарлап калырмын димә. Барыбер эшләп караячак ул аны! Совхоз директорының берничә көнгә командировкага киткәнен генә көтеп тора да төрле авыллардагы тавыкларны сарыклардан бушаган бер абзарга җыя да куя.

Иярәшенгән иске гадәт буенча гына барып, әллә ни уңышка ирешеп булмаячагын, җитештерүне үстерү, хуҗалыкны алга җибәрү өчен шул җитештерү нигезләрен, идарә итү принципларын һәм гомумән крестьян хезмәтенең характерын яңача үзгәртеп корырга кирәк икәнлеген сизенеп, шуңа инанып эшли моны Чигвинцев...

Шушыңа охшаш нәрсәне дуңгызлар белән дә башкара Григорий Никифорович. Әлеге зоотехник булып эшләгән совхозда соңыннан үзе директор булып эшли башлагач, вак дуңгыз фермаларын бетереп, бер зур ферма оештыра. Районда «үз белдеге белән фермаларны бетергәне өчен» аны каты гына шелтәлиләр, әмма Чигвинцев үзенең хаклыгын исбатлый. Ферманы эреләндергәннән соң дәүләткә итне элеккегә караганда биш тапкыр артыграк тапшыра...

Ә өченче тапкыр шундый «үз белдеге белән эшләгән эксперимент» өчен «Красный ключ» совхозы директоры Григорий Никифоровичка берьюлы бер мең сум премия бирәләр.

Хәер, ашыкмыйк, тәртибе белән генә сөйлик.

Григорий Никифорович дуңгызлар һәм тавыклар белән эксперимент ясаган совхозда директор булып дүрт ел эшли. Совхоз алдынгылар рәтенә чыга. Аның тагын шундый сынап, эштә тикшереп карыйсы килгән кызыклы фикерләре була әле. Ләкин өлгерә алмый кала — аны дуңгыз асрау тармагыннан кошчылыкка күчерәләр. Ул, мин кошчылык өлкәсендә бер нәрсә дә белмим, ә монда минем дүрт еллык практикам бар, нигә мине белгән эшемнән аерасыз, монда эшләсәм, мин дәүләткә күбрәк файда китерәм бит, ә яңа эштә барысын да яңабаштан башларга кирәк булачак, аңа әллә никадәр вакыт әрәм китәчәк, тимәгез миңа, калдырыгыз шушы урынымда, дип күпме генә тыпырчынып караса да, тыңламыйлар, кошчылык совхозына — «Красный ключ»ка директор итеп куялар.

Соңгы дүрт ел эчендә «Красный ключ»ка ул инде бишенче директор булып килә. Мондый шартларда эшнең нинди рәте булсын ди?.. Бөтен нәрсә кнопка-автоматлар белән генә эшләнә торган хәзерге зур, якты корпусларны ул чакта төштә дә күрүче булмый әле. Тавыклар ничек җаен тапса, шулай казынып йөри, аларга азыкны чиләк-көянтәләр белән ташып тараталар. Табыш алу турында әйткән дә юк инде, ел ахыры җиттеме — күпме зыян күрелгәнен исәпләүдән башлары чыкмый.

Моннан унбер ел элек Чигвинцев эшне әнә шундый шартларда башлап җибәрә. Ләкин шулай да аңа инде бераз җиңелрәк була башлый: тулысынча автоматлаштырылган комплекслар төзү мәсьәләсе көн тәртибенә куела, терлекчелекне специальләштерү, индустрияләштерү гомумдәүләт программасына әверелдерелә, Чигвинцев фикерләрен тормышка ашыру мөмкинлеге туа. Күп тә үтми, Россия Федерациясендә «Птицепром» главкасы, Татарстанда шуның бер тресты оештырыла. Лениногорскида, Питрәчтә, Юдинода һәм «Красный ключ»та зур-зур кош фабрикалары төзелә башлый. Автоматлаштырылган конвейерлы линияләр, читлекләр булмый әле. Дөрес, безнең илдә алар инде эшләнә, ләкин җитәрлек түгел. Шуңа күрә

Казанның утыз җиде предприятиесе үзара берләшеп, үзләрендә әлеге конвейерлы линияләр өчен аерым детальләрне эшләү мөмкинлеген табалар, эшләп чыгарылган детальләрен «Сельхозтехника»га тапшыралар. Ә «Сельхозтехника»да ул детальләрдән автомат линияләр эшләп, төзелеп ята торган кош фабрикаларына озаталар. Шулай итеп, үткән бишьеллыкта сиксән, бу бишьеллыкның өч елында тагын илле шундый линия корып куялар. Замана үзгәрә, яше олыгая барса да, Чигвинцев экспериментка хисреслеген югалтмый. Тик ул хәзер, тәҗрибә туплаган кеше буларак, мәсьәләне тагын да тирәнрәк, төрле яктан уйлап, кабаланмыйча эшли. Тавык үрчетү һәм тәрбияләү мәсьәләсенең серенә яхшылап төшенеп алгач, Григорий Никифорович сынауның тагын да зуррагын ясап карарга — ике йөз илле мең баш тавыкны бер түбә астына урнаштырырга ниятли.

Монда шунысын әйтеп китик, тулысынча автоматлаштырылган хәзерге заман кош фабрикасы бипаларының гомуми стандарты егерме мең тавыкка исәпләнеп төзелә. Димәк, йөз мең тавыкка унике данә шундый биналар корырга кирәк. Шуларның һәркайсында үзенең мөстәкыйль технологик системасы, складлары, азык бирү, йомырка җыйнау, читлекләрне чистарту конвейерлары, инженер коммуникацияләре булырга, һәркайсына юл салынырга тиеш.

Ә менә шул унике бина урынына бер зур корпус салганда ничек булыр? Беренчедән, җир аз китәчәк. Аннары унике урында калын стеналар корып торуның хаҗәте калмый: залларны җиңел коймалар белән генә бүлеп куясың да — эшең бетте. Унике юл урынына бер юл гына салырга туры киләчәк. Унике бина урынына бер бинаны гына җылытырга кирәк булачак. Димәк, никадәр кирпеч, никадәр цемент, никадәр су трубалары, җылыткыч трубалар янга кала дигән сүз. Гамәлдәге стандарт нигезендә эш иткәндә бу эшләрне башкарып чыгар өчен ике миллион сигез йөз алтмыш мең сум акча тотарга кирәк булыр иде. Ә менә болай эшләгәндә исә шул акчаны янга калдырырга мөмкин булачак. Уйлый белгән кешегә уйланырлык нәрсә бар бит!

Анысы шулай. Ләкин кемнең башына нинди фикер килмәс? Үзенең зурлыгы белән шаккатыргыч нининдер бер фабрика салып кую безнең заманда әллә ни катлаулы эш түгел. Әнә КамАЗдагы һәр корпусның түбәсендә чын мәгънәсендәге аэродром ясап, иң зур самолетларны да шунда утыртырга һәм очырып җибәрергә була. Эшнең асылы шунда: ике йөз илле мең тавык сыйдырышлы бер бина салуның экономик ягы ничек булыр икән? Тавыклар үзләре моңа ничек «карар» икән? Андый коточкыч зур кетәктә йомырка салырга теләрләрме алар? Тавык — нәзберек кош. Бәлки аларга зур бинаның һавасы килешмәс, бәлки тагын нининдер бүтән төрле берәр уңышсызлык килеп чыгар да бөтен тырышлыгың җилгә очар?..

Әнә шундый нәрсәләр килеп чыкмасын өчен, бу кызыклы фикерне башта трестта, аннары республикабызның Министрлар Советында, КПСС өлкә комитетында, аннары Россия Федерациясенең авыл хуҗалыгы министрлыгы коллегиясендә, СССРның Дәүләт төзелеше коллегиясендә бик ныклап тикшерәләр. Ниһаять, бу тәкъдим белән килешәләр. Төзелешне планга кертәләр, акча һәм материаллар бирәләр. Бирүен бирәләр, әмма Чигвинцевны бик каты кисәтеп куялар: кара син аны, бу эшең барып чыкмаса, файда урынына зыян китерә башласа — башың белән җавап бирәчәксең!..

Минемчә, «Красный ключ» совхозы директоры Чигвинцевның эшләре гел көйле баруы аның холкына бәйләнгән. Намуслы, тәртипле кеше ул. Уйлаган уен җиренә җиткермичә туктамый торган, биргән вәгъдәсен үтәмичә калмый торган җитәкчесе, коммунист авторитетының кадерен белеп эш итә торган кеше. Әгәр син биргән

вагъдәңне үтәмисең икән, әгәр синең җитәкче буларак авторитетың юк икән, ул чакта синең бәяң бер тиенгә дә тормый. Шуңа да ул һәр вакыт уйлана, эзләнә, көннән-көн яхшырак эшләргә тырыша. Югыйсә, үзенә шул тикле мәшәкать арттырып, комплекслар төзеп йөрмәс тә иде. Совхоз сиксән миллион йомырка бирсә ни, кырык миллион йомырка бирсә ни, директорның хезмәт хакы артмый да, кимеми дә бит. Фабрикасы табыш китерсә дә, зыянга эшләсә дә, аңа барыбер шул ук өч йөз сумын түләп барачаклар. Ә ул, күрәсез, һаман нидер уйлап таба, һаман борчылып, эш шәбрәк барсын өчен янып яши.

Ни өчен Чигвинцевны әрәм-шәрәм итүче дип атаганымны соңрак әйтермен. Ә хәзер игътибарыгызны менә мондый бер детальгә юнәлтмәкче булам. Мин совхозның бик күпләргә үрнәк булырлык эш нәтиҗәләрен блокнотыма язып барганда, Григорий Никифорович миңа артык шапыртмаска, тавык башына ничә йомырка алулары һәм аның өчен күпме азык тотылуы турында әллә ни җәелеп китмәскә кушып, кисәтеп куйды.

Мин бу хәлгә аптырап калдым, «Красный ключ»тагы нәтиҗәләр бүтәннәрнең әле төшенә дә керми торгандыр, ә бу миңа, имеш, артык җәелеп китмә!?

Чигвинцев минем гаҗәпләнеп калуымны сизде булса кирәк: кесәсеннән сигарет алып кабызды да иплән кенә аңлата башлады:

— Әлбәттә,— диде ул, кайберәүләр өчен бу саннар бәлки, чыннан да, һавадагы торна гынадыр. Ә безнең өчен алар инде уч төбенә кунган сыерчык кына. Безнең мөмкинлекләребездән чыгып караганда, мине бәлки мактарга түгел, ә орышырга кирәктер. Безнең фабриканы күргәнегез бармы соң сезнең?

— Юк әле.

— Кит аннан!

Чигвинцев урыныннан торды да экраны «Рубин» яки «Темп»ныкы кадәрле булган зур телевизор янына барып, аның тоткаларын боргалый башлады. Һәм без, аның кабинетында утырган килеш кенә, «Красный ключ»ның кош фабрикасына киносәяхәт ясадык.

Дөрес, совхозның телевидениесен Мәскәүдәге үзәк телевидение кадәр үк дип булмый. Шулай да уникe каналы бар аның, һәм барысы да эшләп тора. Бер каналда конвейер белән азык ничек бирелгәне, икенчесендә йомыркаларның, сортларга аерылып, бер урыннан икенче урынга иплән кенә тәгәри барулары, өченчесендә йомыркаларның складка озатылуы бик ачык күренеп тора.

Үзе миңа телевизордан хуҗалыгын күрсәтә Григорий Никифорович, үзе шунда ук совхоз кешеләре турында сөйли:

— Безнең операторлар, — ди ул, — барысы да эш өчен янып тора. Тамара Андриянова, Нюра Зотина, Валя Сочкова, Мария Прохоровалар һәр тавыктан ике йөз иллешәр йомырка алалар. Бүтәннәр дә алардан калышмаска тырыша. Барысы да булдыра алганча яхшырак эшләргә, һәр эшне башкарганда төгәл, җитез булырга омтыла. Алардан башка бу комплексны үзләштерә алыр идеммени мин?.. Менә шулай, иң яхшы кошчылар һәр тавыктан ике йөз иллешәр йомырка ала, ә совхоз буенча әлегә тавык башына ике йөз утызар йомырка гына туры килә. Әгәр яхшырак азык ашатсам, мин бәлки һәр тавыктан өчәр йөз йомырка алыр идем, ә көн саен ашатыла торган утыз биш тонна җимнең бәлки яртысы да җитәр иде. Ә бөтен ил буенча алганда күпме икмәк янга калыр иде. Менә кайда ул резерв, файдаланып бетмәгән мөмкинлек! Әнә авыл апайлары чебешләрне йомыркадан чыгу белән иң чиста тары ярмасы белән, эремчек белән тикмәгә генә туйдыра башлый дип беләсезме? Тикмәгә генә кычыт-

кан чабып, аны он белән болгатып ашата дисезме? Бик белеп эшли ул аны. Чөнки кычытканда витамин, каротин бик күп...

Мин Чигвинцевта өч көн тордым. Без бер-беребезгә яхшы ук күнектек һәм үзара «син» дип сөйләшүгә барып җиттек. Аның акыллы эш итүе белән килешсәм дә, бер нәрсәгә һич тә төшенеп җитә алмадым. Ярый, үз совхозында катнаш азык филиалы төзеп, ул үзенә әллә никадәр мәшәкать тудырсын һәм чамасыз күп акча (мең данә йомырка җитештерүгә киткән кырык өч сум акчаның тугыз сумы азыкны филиалда кабат эшкәртүгә китә) чыгарсын да ди инде. Ләкин, әйдәгез, әйберләрне үз исемнәре белән атыйк; кеше эшен башкара бит ул. Әгәр әле кибеттән генә алган ботинкага һәркайсыбыз яңа үкчә кага башласа, официант урынына һәркем кашык һәм сәнәкне савыт-саба юа торган җиргә кереп ала башласа, заводтан яңа кайткан генераторның роторын алыштыра башласа — нәрсә килеп чыгар?

Мондый хәл бер Чигвинцевта гына булган булса, ихтимал, бу турыда сүз озайтып торырга да кирәк булмас иде. Гадәти хәл түгел бу, дияр идек тә шуның белән — вәссәләм. Ләкин республикабызның азыкны элеваторлардан ала торган бүтән кош фабрикаларының хәле дә шушыңа охшаш бит. Алгарак китеп булса да, Татарстан буенча кайбер саннарга игътибар итик. «Птицепром»ның Татарстандагы фабрикалары 1973 елда кошларга ашату өчен 1202 тонна балык, 1054 тонна фарш, 164 тонна сөяк оны, 82 тонна балык мае, 667 тонна техник май, 19 тонна чүпрә, 28 тонна киптерелгән сөт, 92 тонна акбур табып алып кайтканнар. Шушыларның барысына бер миллион алты йөз кырык өч мең сум акча тотылган.

Акча да бик мөһим нәрсә, әлбәттә. Ләкин монда эш акчада гына да түгел әле. Хикмәт шунда, әлеге кош фабрикаларының үзләре оештырган азык цехларында барлык эш кул көче белән башкарыла. Эш коралы чиләк тә көянтә, соскы да көрәк. Ә элеваторларда һәм махсус заводларда үзләре эшләп чыгарган азык белән кош фабрикалары әнә шулай чиләнгәнне бер дә пошынмыйча гына карап торалар. Һәм күңелдә алар берни дә эшләмиләр дигән фикер туа. Бәлки эшлиләрдер дә. Ләкин мөмкин булганның барысын да түгел, киресенчә, тиеш булганның да бик азын гына эшлиләр булса кирәк. Ә бит Чигвинцев фабрикасында һәм бүтән шуның ише фабрикаларда бик зур кыенлыклар белән генә башкарыла торган шул ук эшне элеваторда ансатрак юл белән һәм арзангарак төшереп тә эшләргә булыр иде. Чөнки анда эшне машинага көйләргә һәм автоматлаштырырга мөмкинлекләр зуррак. Поливитаминнар табу мәсьәләсе бик катлаулы. Аның өчен Чигвинцев кебек үткен, аның кебек өлгер һәм хәйләкәр, зирәк булырга кирәк. Монысын мин бик яхшы аңлыйм. Ләкин тоз, кабырчык һәм чуер ташны табарга була торгандыр лабаса! Идел бар, ул гына җитмәсә, Кара диңгез, башка диңгезләр бар. Күпме кирәк — шул кадәр алып кайтырга мөмкин. Шулай булгач, Чигвинцев нигә бүтәннәр эшләргә тиешле эшне үз өстенә алып, мәшәкать арттырып йөри икән соң?

Бу уйларымны мин Чигвинцевның үзенә дә әйттем.

— Ә мин ул чакта кая барып бәрелергә тиеш соң? — диде Григорий Никифорович, минем соравыма каршы сорау биреп. Һәм шундук бу фикерен ачыкларга тотынды: — Инкубатор көн саен дөнья кадәр чеби чыгарып тора. Ул чебиләр күкәй кабыгыннан килеп чыгуга, пи-пи-пи килеп, ашарларына сорый, үзләре турында кайгыртуны, үзләрен кадер-хөрмәт итүне таләп итә башлыйлар. Бар, кул селтәп кенә котылып кара син алардан! Һәр чебешкә көн саен егерме бер грамм азык кирәк. Тегенди-мондый азык кына да түгел, ә витаминнары ягыннан да, протеины буенча да яхшы, югары сыйфатлы

азык. Югыйсә, ул тиешенчә үсә алмаячак, йомыркасын йөз сиксәненче көнендә түгел, бер ел тулгач та сала башламас. Шулай булгач, мин аңа күпме артык җим бирергә тиеш булам? Менә бит исәпләп карагач ничек килеп чыга ул!..

Ә болай, яхшы сыйфатлы азык ашатканда, эшләр бөтенләй башкача. Әйтик, әлеге азыкны яхшырту өчен мин ике йөз утыз мең акча тоткан булсам, ике миллион саф табыш алдым. Кайсы яхшырак?

Әлбәттә, ике йөз утыз меңгә караганда ике миллион яхшырак! Бу хакта берәү дә бәхәсләшеп тормас. Ләкин мәсьәлә шунда, Чигвинцев теге ике йөз утыз меңне дә янга калдыра ала иде бит. Азыкны тиешле дәрәҗәдә югары сыйфатлы итеп эшләмәвен дәлилләп һәм «Красный ключ»ка әлеге артык чыгымнарын кире кайтаруларын таләп итеп, кирәкле документларын туплап, элеватор өстеннән арбитражга гына мөрәҗәгать итәсе бит. Моның бернинди дә ояты юк, чөнки ул акча Чигвинцев үзе генә тапкан мал түгел, бар коллектив көче белән табылган байлык лабаса! Телиме Чигвинцев, юкмы, ләкин табышның ике йөз утыз меңгә кимүе үзеннән-үзе совхоз производствосын совхоз эшчеләренең көнкүреш шартларын яхшыртуга тотыласы акча фондын киметүгә китергән: узган ел торак йортны төзеп бетерә алмаганнар, материаль кызыксындыру фондыннан һәр эшчегә тиешле булган премия кырык алтышар сумга ким чыккан...

Менә шушы дәлилләремнән соң минем әле тагын бер, үземә калса, бик җитди дәлилем бар шикелле иде. Элеватор директоры Закиров белән Чигвинцев күптәнге дуслар. Заманында алар бер мәктәптә укыганнар, бергә уйнап үскәннәр. Хәзер дә бәйрәмнәрдә телефон аша гына булса да үзара котлашып, бер-берենә тормышларында сәламәтлек, эшләрендә уңыш теләшеп торалар. Шулай булгач, ничек инде Чигвинцев арбитражларга барып, дусты белән дәгъвалашып йөрсен?

— Григорий Никифорович, — дидем мин Чигвинцевка туптуры, — Закиров эшләргә тиешле эшләрне син әнә шул дуслык хакына үз өстеңә аласыңмы әллә?

— О-о-о, кайда табасыңны, кайда югалтасыңны алдан белеп торып булса икән ул! — диде Чигвинцев, уйлап та тормыйча. — Ә миңа кирәк булган витаминлы өстәмәләрне Закиров кайдан алсын соң?

— Ә син кайдан аласың соң? Айдан алып төшәсеңмени?

— Мин — башка мәсьәлә. Мин табарга мәҗбүрмен, минем бүтән чарам юк. Элеваторга нәрсә аңа? Ул азыгын озатып җибәрә, минем исәптән тиешле акчасын ала да — эше бетте. Ә мин табыш аламмы, зыян күрәмме — аның анда бөтенләй эше юк. Мине азык мәшәкатьләреннән коткару өчен Закиров нигә баш ватып утырсын ди әле? Минем чебешләр өчен ник кайгырсын ди ул? Кичер, гафу ит, минем үз хәсрәтем дә муеннан, диячәк ул. Эгоизм, үз мәнфәгатең өчен тырышу дигән нәрсә көчле бит адәм баласында. «Рәхмәт, Чигвинцев, безнең эшне эшләп йөрисең бит, молодец. Мә, үзеңнең чыгымнарыңны кире ал», дип үк әйтер дәрәҗәгә җителмәгән шул әле. Аның өчен эштә идеаль тәртип, югары культурага, интеллектка ирешү кирәк...

— Ә нигә арбитражга мөрәҗәгать итмисең соң? — дидем мин, һаман әле үземнекен куәтләп.

Рас эшлекле бәйләнешләр шул тикле йомшак икән, рас берсенең продукциясен икенчесе ни эшләткәне белән кызыксынмыйлар, үзара бәйләнешләрнең экономик нормалары эшләнмәгән икән — ул чакта юридик һәм әхлакый каналлардан файдаланырга кирәк. Эшлекле тәртиплелек үзеннән-үзе тумас, аңа өйрәтергә кирәк. Бу очракта ягъни элеваторлар белән кош фабрикаларының үзара бәйләнешләрендә бер-берен постфактум — кыен хәлдә калдырулары күз алдында. Мәсьәләгә «Риза булмасаң теләсәң ни эшлә, мин барыбер яхшырак эш-

ләячәк түгел», дип карауга юл куюга, җавапсызлыкка, тәртипсезлеккә урын булмаска тиеш!

Минем бу фикерләрем белән Чигвинцев та килеште, ахрысы:

— Яхшы, шулай да булсын, — дип ялгап алып китте. — Ярый, мин үземнең хокукларымнан файдаланып, Закировка арбитраж аркылы суктырып та куйдым ди. Ә ул, ялт, икенче бер җирдә мине китереп каптырачак.

— Мәсәлән?

— Әйтик, фондлар буенча.

— Нинди фондлар?

— Ә менә мондый: квартал инде башланган, ә азык нарядлары әле кайдадыр Мәскәүдә йөриләр. Госснабта, министрлыкта, главкада — анда адашып калырга урын бар. Ә бит чебешләргә чыркылдашмагыз, акыллыларым, нарядлар кайтып җиткәнче ничек тә ураза тотып торыгыз, дип булмый аларга. Мин Закировка килеп ялынырга тиеш булам: «Зинһар, коткар, дус кеше?» Ә ул минем белән сөйләшергә дә теләмәсә. «Хакым юк, агай-эне. Дәүләт милкен рөхсәтсез бер грамм да бирә алмыйм», дисә? Ул чакта мин нишләргә тиеш? Ә чебешләр безнең үзара низаглашуыбызны бар дип тә белмиләр. Аларның җим савытлары гел тулы булып торырга тиеш. Шулай булмаса аларның талканы бик коры: йомырка күрсәтәчәк түгел алар. Ә ул чакта минем автомат кондиционерлар, телевизорлар, тагын әллә нинди катлаулы машиналар белән җиһазландырылган бу иләмсез зур комплексымнан ни файда кала? Ул чакта инде табыш турында уйлама да. Һәм миңа да меңәр сум премия тәтемәс, бәлки син, агай-эне, бу урында ялгыш утырмыйсың микән, диярләр иде. Аңладыңмы инде чикләвекнең юкәдә икәнен? Сизденме минем ни өчен арбитражга барырга ашыкмаганны? Син мине анда кума. Син миңа менә шуны әйт: цистин, аргенин, метионин кебек витаминнарны кайдан юнәтим мин? Әгәр шуларны күбрәк таба алсам, менә эшләр җайланыр иде, ичмаса: азыкны тагын да кимрәк тота, ә продукцияне тагын да күбрәк ала башлар идем... Һәм ул чакта йомырканың бер данәсе хәзерге шикелле дүрт тиен ярымга түгел, ә нибары өч тиенгә генә төшәр иде!..

Бар, аңлап кара инде син бу Чигвинцевны... Хәер, кем белә, бәлки ул хаклыдыр. Ни әйтсәң дә, тормыш катлаулы нәрсә бит. Анда көн саен килеп чыга торган яңадан-яңа хәлләрнең барысын да алдан әзерләнгән аерым кысаларга гына сыйдырып бетереп буламыни?

Белмим, белмим. Уйларга кирәк әле...

**Ислам Беляев**

# СОЛДАТ ТӨЙМӘСЕ

## Сугышчан яшьлек

Болытлар, буранлы даладагы кар дулкыннары кебек сыртларын кабартып, әкрен генә көйриләр, Самолет вакыт-вакыт аларның төтен сыман куелыгына кереп китә дә, аннары, кабат өскә калкып, көмеш канатлары белән кояшта ялтырый. Җир хәзер кайдадыр бик аста, зәңгәр һава океаны төбендә ята. Тоташ болыт пәрдәсенең ертыклары арасыннан ул җыерчыклы йөзен бер генә күрсәтеп ала да кабат күздән югала.

Биеклек тугыз мең метр. Мин самолетта гына түгел, күңел канатларында да очам. Хыялларым, үземне узып, еракка, Керулин далаларына омтыла. Күңелем белән күптән инде кылганнар, комнар арасында йөрим, андагы сукмакларны эзләп табып, таныш окоплар, землянкалар өстенә килеп чыгам. Ничек шулай ашкынмассың да ничек канатланмассың! Моннан утыз еллар элек узган юлымнан сугышчан яшьлегемә кайтып барам түгелме соң?!

Әнә иксез-чиксез сахраның чит-читләрендә, диңгез ярларын хәтерләтеп, күксел сопкалар басканнар. Аларның түбәсенә кыр казлары кебек тезелеп дөяләр — чүл кораблары менеп бара. Ә үзәндә сизелерсизелмәс кебек булып күккә зәңгәр төтен бөдрәсе үрелә. Анда ак киез тирмәләрдә кичке ашлар пешә. Яшел хәтфә өстенә бихисап мал көтүләре сибелгән. Озын ялларын туздырып, дала юргалары чабыша. Күккә, мәгърур канатларын җилпеп, бөркет ыргыла...

Сагындым, бик сагындым мин шушы даланы — үземнең сугышчан яшьлегем канат ярган, тозлы тирем тамган, туңган, өшегән, сусаган җиремне. Менә ничә еллар инде аны оныта алмыйм. Җилләр тавышын ишетеп уянам да йокым кача. Аны юксынуым бу. Тиктомалдан сусыйм, иреннәрем көя. Димәк, хәтерем кайнар. Ә буыннарымның сызлавы — кайтаваз, миңа очсыз-карыйсыз дала юлларыннан килгән исәнлек хәбәре...

Тиздән, тиздән... Инде күп калмады. Көмеш канатлы һава лайнеры иртәгә иртә белән безне дала иленә китереп төшерәчәк.

...Болытларга охшап, күңелдә әкрен генә истәлекләр агыла. Самолет моторларының тавышына каяндыр әллә җирдән, әллә еллар томаны

эченнән вагон тәгәрмәчләренең җыры килеп кушыла. Себер урманнары өстенә корылган ак болыт җәймәсе аркылы мин кайчандыр үзебезне төяп чапкан эшелонны күргәндәй булам. Гүя самолет канатлары астында ак болыт даласы түгел, 1943 ел декабренең салкын карлары җәелеп ята. Ә офыктагы алсу шәфәкъ нуры ни өчендер шомлы янгын шәүләсен хәтерләтә.

Унҗиде яшьлек егетләрне хәвефле утлардан еракkарак, еракkарак алып китәргә тырышкандай, эшелон көнчыгышка карап көне-төне алга чапты. Һәм менә Себердәге нәни бер станция. Перрон. Күктән тирбәлә-тирбәлә күбәләк карлар төшә. Һава искиткеч тын. Безнең эшелон фронтка китеп баручы бер состав янына килеп туктый. Вагоннарыбызны шунда ук солдатлар сырып ала. Төрле яктан сораулар яудыралар:

— Егетләр, кайдан киләсез?

— Арагызда москвичлар юкмы?

— Әйтегез тизрәк, кайсыгыз Харьковтан?

— Казаннар, кулларыгызны күтәрегез!

Шау-шу, уен-көлке. Товар вагонының киң итеп ачылган ишеге төбенә өелешеп басканбыз да перрондагы солдатлар белән гәп корабыз. Күрше эшелон аларныкы булып чыкты. Безнең белән борынны чөебрәк сөйләшәләр, фронтка чакыралар, «әй, болар шомармаган котелоклар бит әле», дип чеметтереп тә алалар. Аеруча үткен телле бер егетнең тавышы безгә ничектер таныш тоела. Үзен күрергә теләп, классташлар барыбыз да, аяк очларыбызга баскан килеш, үрелеп ишектән карыйбыз.

— Адаш, шайтан, синме бу?! — Кисәк арабыздан Хәмиз шулай дип кычкырып җибәрмәсенме.

— Әнәс... Ләбит... Хатип... Тфү, тфү, егетләр, әллә күземә күренәсезме?!

Алтыбыз бергә перронга сибелдек. Бүреген кыңгыр салып гимастеркадан гына чыккан, биленә киң каеш буган шадра егет, чыннан да, безнең классташыбыз Хәмиз иде. Ул бер яшькә олырак булганлыктан, бездән алдарак алынды. Менә хәзер нинди гаҗәеп очрашу! Классыбыз белән Себер күге астында басып торабыз лабаса.

— Солдат икмәге килешкән сиңа.

— Килешмәскә, безгә икмәкне тозлап ашаталар, агай-эне.

— Тоз дигәнең тир буламы инде ул?

— Баргач күрерсез. Барысын берьюлы белү — зарарлы...

Хәмиз чак кына көлемсерәп, безнең солдат тормышы турындагы сорауларыбыздан читкә тайпылырга тырыша. Дулкынлана, күрәсең. Бит алмаларындагы сөйкемле шадралары чекерәеп тора. Күбәләк кебек очып, аларга кар бөртекләре килеп куна да, шунда ук эреп, юкка чыга. Егет ут кебек яна. Үзе моны сиздермәскә, тыныч күренергә тырыша. Ыспай гәүдәсен кысып торган киң каеш астыннан җәһәт кенә баш бармагын шудырып ала да гимнастеркасын төзәткәләп куя. Әйтерсең аның шушы кыланышы, бөтен күз карашы: «Менә нинди солдат мин хәзер!» — дип кычкырып тора. Кинәт ул һавалануга охшаш бер ышаныч белән әйтеп куйды:

— Безнең урынга барасыз, так что сынатмагыз, егетләр. — Һәм мутланып адашына күз кысты: — Син минем винтовканы сора, яме. Номеры...

— Майлап калдырган идеңме соң?

— А как же! Барысы да тәртиптә, агай-эне. Нәкъ устав кушканча.

— Алайса, ярый. Тик безнең юл башка яккарак шул, туган.

— Ә кая?

— Анысы хәрби сер. Син инде моны гына аңларга тиеш, солдат иптәш.

— Кара, кара, син бик яман кешегә әйләнгәнсең әле!

Алар көлешә-көлешә бер-берсенә төрткәләшеп алдылар. Шулай да солдат Хәмизнең бирешәсе килми иде.

— Барыбер көнчыгышка барасыз, — диде ул әүвәлге тантана белән үк. — Самурайларны сезгә калдырып китәбез. Ну, сез көтегез, Гитлерны тончыктыргач, һичшиксез ярдәмгә килербез.

Кисәк «вагоннарга!» дигән көчле тавыш яңгырады. Хәмиз тиз-тиз генә кул биреп, һәрберебез белән саубуллашып чыкты да, бүреген басыбрак киеп, йөгерә-йөгерә китеп барды.

Алар көнбатышка, без көнчыгышка кузгалып киттек.

1943 елның декабре... Алдымда киң, тигез елга үзәнен күрәм. Кырыс тынлык хөкем сөрә. Минем өчен әле монда барысы да яңа, һәрнәрсә кызыклы. Әнә, канатлары белән кылганнарга тиеп-тиеп, үзән өстеннән түбәнтен генә бөркет очып бара. Ерактa, үзәннең аргы кырыенда, Керулин ялтырап ята. Ул хәзер тоташ боз астында. Ә кар юк. Җир шәпшәрә. Кайрак шикелле такыр яр буенда атлар, дөяләр чемченеп йөри. Бераз арырак акшарланган балчык өйләр, киез тирмәләр күренә. Бу — Баян-Төмән, дөресрәге, аның бер чите. Ә бирге якта, — уентыклаunion сопкаларга кереп торган иңкүлектә, — без, безнең дотлар, дзотлар...

Кисәк аргы яктагы сопка түбәсендә җанлылык күреп, мин шунда төбәләм. Кечкенә генә булып калкып чыккан кара нокталарның анда, түбән таба хәрәкәт итеп, арта, зурая баруын, ниһаять үзәнгә төшеп җиткәч, озын тезмәгә әйләнеп, кылганнар арасына кереп китүен күзәтеп торам. Бу — кәрван. Ул хәзер үзәк юлы белән китте. Аннан ерак түгел туган абыем хезмәт итә. Без — икебез дә дала солдатлары. Биш ел буе безне өметсез сагынуларга дучар иткән коточкыч ераклык кинәт көтмәгәндә юкка чыкты. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән далада ике туган бер-беребезгә күрше булып калдык.

Өндерхан ягыннан кисәк коры салкын җил исеп китә. Ул, кылганнарны уята-уята, Керулин үзәненнән йөгереп үтә дә без яшәгән иңкүлеккә килеп керә. Биредә, салам эскертләренә охшап, рәт-рәт солдат землянкалары тезелгән. Җил, аларга бәрелә-бәрелә, шәрә туң җирдән ком баганасы күтәрә. Аннары туп чөеп уйнаган шук малай төсле, бөтерчекләнеп, аны ары алып китә, бире китерә, землянкалар арасында бер югалып, бер калкып борыла-сарыла чабып йөри-йөри дә сафта басып торучы солдатларның шинель итәкләре белән шаярырга керешә. Ком безнең сулыш юлларыбызга каплана, күзләребезгә керә. Аңардан сакланырга тырышып читкә борылабыз, калын бияләйләр кигән куллрыбыз белән битне ышкыйбыз. Үзебез инде күп-күмгәк. Дер-дер калтырыйбыз. Җил сөякләребезгә үтеп керә. Шул ук вакытта аптырашта калып үзебезнең взвод командирына карыйбыз. Әйтерсең аңа эссе. Утыз градуслы салкын исендә дә юк. Аягында хром итекләр. Шинеле дә юка гына. Бүрек колакчыннары да безнеке кебек төшереп бәйләнмәгән. Колаклары ут капкандай кып-кызыл. Болары әле бер хәл, ә менә кулларының ялангач булуы безне тәмам акылдан шаштыра. Ничек түзә ул?! Тимердән чүкеп ясалган диярсең үзен. Гомумән, бөтен кыяфәте белән ул сынга охшаган. Җыйнак кына гәүдә. Какча яңаклар. Эчкә батып торган үткен күзләр. Яргаланып беткән иреннәр.... Ничектер шулар абыйның армиядән җибәргән фоторәсемен хәтерләтә.

Без землянкабыз алдындагы ачык мәйданчыкта штык сугышына өйрәнәбез. Җилне теткәләргә, юк итәргә теләгәндәй, штыкларыбызны бер алга омтылдырабыз, бер кире тартып алабыз.

— Раз, два!.. Раз, два!.. Коли!.. Коротким!.. Длинным!.. Акимов, сез шинель эченнән тун кимәгәнсез бит?

— Һич юк, иптәш кече лейтенант. Телогрейка...

— Ни өчен, алайса, кулларыгыз бөгелми?

— Күшектеләр, иптәш кече лейтенант. Салкын.

— Салкын?! — Командирыбызның тавышында чын ихластан аптырау, риясыз гаҗәпсенү. — Сердюк, я әйтегез әле, солдат тунса нишли? — дип сорый ул уң флангта басып торган украин егетеннән.

— Иөгерә, иптәш кече лейтенант.

— Бик дөрес! Молодец, Сердюк!.. Взвод, на-прав-во!.. Шагом марш!.. Бегом!..

Штыклар ялтырап алга сөрлекте. Шәрә туң җирдән зыңлап аяк тавышлары сибелеп киттеләр дә сөзәк калкулык битеннән югары үрләделәр, сопка өстенә менеп җиткәч, алар аска коелды, аннары кабат кире әйләнеп кайттылар.

— Взвод, стой!.. На-пра-во! — Командирның да сулышы капкан. Ләкин ул моны сиздермәскә тырышып күңелле генә итеп сорап куя: — Я ничек, егетләр?

— Җылы, иптәш кече лейтенант. Хәтта эссе дә.

— Ә сезгә, иптәш Акимов, җылымы?

— Так точно, иптәш кече лейтенант! Мунчада чабынган кебек булдым.

Шау килеп көлешеп алдык. Командир да канәгать. Шаян сүзләр әйтеп куя. Әмма йөгәнне тәмам кулдан ычкындырып бетерми. Бер минутка гына аны бушатып тора да кабат эшлекле, җитди тонга күчә.

— Смиррр-но!.. На-пле-чо!.. Отставить!.. Акимов, сез тагын... Я бирегез әле...

Взвод командиры винтовканы кулына алып аяк катына куя да:

— На-пле-чо! — дип, аны шунда ук ялт-йолт иткән җитез бер хәрәкәт белән иңенә күтәрә.

Менә хәзер ул винтовканың тимерле түтәсеннән ялан кул тоткан килеш кымшанмыйча басып тора. Бияләй аркылы да өшетә торган металлның салкынын гүя үз кулыбызда сизеп, тәннәр чымырдап, калтыранып китә.

— К но-о-ге! — Командирыбыз, ниһаять, винтовканы аягы катына төшереп куйды да: — Тот! — дип, аны шунда ук Акимов кулына очырды.

— Күз буды, күз буды, егетләр! Күрдегезме, винтовканы очырган арада кулын кулга ышкып җибәрде, — дип, Акимов шул чакта кычкырып әйтеп салмасынмы.

Аның күзләре бу вакыт шундый зур шатлык, эчкерсез гаҗәпсенү белән ачылганнар иде ки, бөтен взвод, шул исәптән командир үзе дә, тыела алмыйча күтәрелеп көләргә тотынды.

— Ну, бераз күңелегез ачылдымы? — диде шуннан соң командир, сәгатенә карап.— Ә хәзер — казармага! Обед җитте.— Һәм, кинәт исенә төшкәндәй, көлемсерәп Акимовка төбәлде: — Миңа да салкын бит. Ләкин алай ук түгел. Чөнки сибиряк мин. Шуның өстенә Монголиядә алтынчы елым. Сез дә күнегерсез, чыныгырсыз әле. Безгә башкача мөмкин түгел. Юкка гына безне дала солдатлары дип атамыйлар бит... Эсселәр... Салкыннар... Сусау... Боларның барысына да түзәргә өйрәнергә кирәк. Бирелә иң беренче чиратта шул таләп ителә.

Әйе, табигать тә монда әйтерсең дошман белән бер сүздә, ул да безгә каршы баскан. Җәен эсселәр 48 әр градуска җитә, диләр. Анысын әле күргәнебез юк. Ә менә 40 градуслы салкыннарны татыдык инде. Өстеңә шинель, шинель астыннан телогрейка киясең — барыбер суык җилеккә үтә. Ә төннәрен уянып китәсең дә сискәнеп куясың: гөрес-гөрес җир ярыла. Әйтерсең сугыш бара, әйтерсең кемдер синең тәнеңә землянка стенасы аша салкын хәнҗәрен батырырга ниятләнә.

Коточкыч ком бураны купты. Табигать көчләренең шул кадәр аяусызлык, җимергеч дәһшәт белән котырганын әле бервакытта да күргәнем юк иде. Йодрык-йодрык ташлар, чүп-чар кебек бөтерелеп, очып

кына йөриләр. Казарма дер селкенә, тәрәзәләр зыңлый — менә-менә бөтенесе җирдән кубып очып китәр төсле. Колакка кайдандыр буш мичкә тәгәрәп үткәне, нәрсәнеңдер гөрселдәп ауганы килеп керә, өзек-өзек яңгыраган чаң тавышлары ишетелә. Доң-доң-диң... Доң-доң-дин... Адашмасыннар өчен давыл чагында һәр вакыт шулай чаң сугалар икән. Ләкин иң хәерлесе чыгып йөрмәвең. Юлда ком буранына очраган кәрван гадәттә туктый, җиргә ятып, давыл тынганны көтә, ди. Без дә ком туфаны эчендә калган ярым караңгы землянкада тик утыра бирдек. Төш вакыты житкәч, кухняга аш алырга да тарттырылган бау буенча гына барып кайттылар.

Көнозын котырды давыл. Кичен ул басылды, ишекне көчкә ачып һавага чыктык. Күз алдыбызга гаҗәеп күренеш килеп басты. Тып-тын. Һич селкенгән, кыймылдаган нәрсә күренми. Тирә-якта өем-өем комнар, барханнар сузылып ята. Офицерлар торган вак-вак землянкаларны бөтенләй шәйләрлек тә түгел. Ком астыннан тик морҗалары гына чыгып тора. Керү-чыгу юлларына, тәрәз амбразураларына тыгызлап, түбәләмә итеп, ком утырган. Иң башта, көрәкләр алып, шунда киттек. Чыга алмый яткан командирларыбызны ком әсирлегеннән коткарырга туры килде. Аннары радиокласс, склад землянкаларына тотындык. Коткару эшләре беткәндә чалт аяз күктә тулган ай йөзә һәм безгә йокларга ятарга да вакыт җиткән иде инде.

...Һавага соры тузан болыты эленгән. Ул очмый да, таралмый да. Без барсак бара, без туктасак туктый, колонна алга киткән саен зурая, куера гына төшә. Әйтерсең сине пар казанына бикләп куйганнар. Вакыт-вакыт тын бетә, атлап булмый башлый. Алдан да, арттан да солдатлар атлый. Сулышка иркенрәк булсын өчен бераз арткарак калам. Шунда ук взвод командирының:

— Тартылырга! — дигән тавышы яңгырый.

— Мөмкин түгел, иптәш кече лейтенант, — дим.

— Ни өчен бүтәннәргә мөмкин, сезгә — юк?

— Иптәш кече лейтенант, минем алдан домна миче бара лабаса!..

Үзем шаяртам, үзем, шикләнеп, алдымдагы зур гәүдәле егеткә сыңар күз белән генә карап алам. Аның куна тактасыдай киң, матур аркасы хәзер миндә нәфрәт уята диярлек. Әмма егетнең ачуланганы, хәтере калганы сизелми. Шаяртып әйткән сүземә аның да, башкалар белән берррәттән, хахылдап куйганы ишетелә.

Мин үзем кәрләләрдән түгел, шулай да Кусковның янәшәсенә килеп баскач, багана янындагы бүкәнгә охшап калам. Әле Новиков дигәне бар. Анысы моңардан да озынрак. Гадәттә, безнең телефонистлар взводы килгәнне әллә каян күреп, туктап көтеп торалар һәм, елмаюларын яшерә алмыйча, артыбыздан карап озатып калалар. Иң җитди командирларның да, безне күргәч, авызлары ерыла. Дөрес булса, бервакыт телеграф линиясе ремонтларга тырнаклар сорап баргач:

— Нәрсәгә сезгә алар, баганага менәргәме? Аяк очларына басып үрелсәләр, баһадирларыгызның болай да буе җитә, — дип, буш кул белән борып кайтарганнар, имеш.

Гомуми тезелүләр вакытында хәтта дивизия командиры үзе, яныбызга килеп, баһадирлар белән кул биреп исәнләшеп китә, хәл-әхвәл сораша. Боларга ашны да аның приказы буенча икеләтә порция бирә башладылар.

Кышын, каршыдан җил искәндә, Кусков артыннан баруы бик рәхәт. Ә менә хәзер эсседә, рәхимсез кояш баш өстендә басып торган вакытта, мондый ышыкланунның бөтенләй кирәге юк. Киресенчә, җил иссен, бераз сулыш иркенәйсен иде дисең. Тик кая ул! Өч сәгать буе инде ут кебек кызган күк астында җансыз, үле дала буйлап барабыз. Җил

урынына, сулышны каплап, Кусковның аркасыннан кайнар пар бөркелә.

Мин аның гимнастеркасындагы тир табына карамаска, күңелсез кичерешләремне онытырга тырышып, тирә-ягыма күз йөртәм. Әнә уйга чумып, аска карап, җыр башлаучыбыз Степанов бара. Әнә изүен чишеп җибәргән дә, төкердем дөньясына дигән кыяфәттә, җилләнеп, озын буйлы, нечкә муенлы Соколов атлый. Әнә киң җилкәле, төп кебек нык, үткен, чая егет Громов. Әнә җор сүзле Орлов, үтә тыныч табигатьле Тарасов, авыр, салмак адымлы Парфенов...

Бер җан, бер тән без. Моннан сигез ай элек шинель кигән без төклетуралар нәрсәбез беләндер бер-беребезгә охшап та калдык. Дала безне үз калыбына тартты. Әнә ничек кара янып чуен китекләренә әйләнгәнбез. Яңаклар какча. Иреннәр яргаланган. Гимнастеркалар уңып, тәмам агарып беткән. Әйе, походлар шәп суырган безне. Җәйге өйрәнүләр дә үтеп бара. Менә бүген дә иртән чыккан идек, әле һаман юлда. Флягалардагы соңгы су тамчылары белән иреннәрне чылатканга да инде байтактан. Ә туктарлык чик әле күренми. Көнчыгышка, Тамцак-Булак ягына карап атлыйбыз да атлыйбыз.

Бара торгач, киң, тирән ермак очрады. Аны адәм ышанмаслык зурлыктадыр дип башыбызга китермәгән идек. Әле һаман чокыр кырыеннан барабыз. Егетләр тып-тын гына атлыйлар. Күрәсең, тел кыймылдатырлык та рәтләре юк. Сусау, әлсерәү өстенә, билгесезлек җанны кыйный. Шулай да солдатның көлке капчыгы һәр вакыт үзе белән. Әнә кемдер ялгыш кына шаяртып куйды:

— Егетләр, танк чокырына дөя кереп баткан, шуны чыгарырга барабыз, — диде.

Һәм шул җитә калды. Гөр килеп көлешеп алдык. Атлавы да рәхәт булып китте. Җилкәләр күтәрелә, адымнар тизләнә төште. Яныбыздан выжлап узып киткән «виллис» һәм анда утырган хәрбинең тузан болыты эченнән күренеп калган ялтыравыклы погоннары янә бер җанлылык уятты, телләрне чишеп җибәрде.

— Генерал!

— Армия штабыннан...

— Зур начальник килә, тикмәгә генә түгел бу, туганнар, — дип, солдат төрлечә фараз кылды.

Кисәк туктарга команда бирелде. Каршыбызда — лагерь: машиналар, штаб палаткалары, поход кухнялары. Морҗаларыннан хәтта төтен дә чыга. Димәк, төшке аш пешә. Солдат халкы шунда ук эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алды.

— Я, егетләр,— диде Вася Орлов, учларына төкергәләп.— Килеп җиттек. Кулларыгызга ломнар, көрәкләр алыгыз.

Аның сүзен раслагандай, колонна каршына сапер инструментлары төялгән машина килеп туктады. Безгә палаткалар корырга боерылды.

— Оһо, бередә байтакка төпләнербез, ахры!

— Шулай да күпмегә дип уйлыйсың?

— Хет бер айга, хет бер елга булсын. Шушында калырга да риза. Тик бүген генә казытмасыннар, — диде Орлов, палатка эченә үрмәләп.

Без дә аңа иярдек. Палаткага кереп, кайнар ком өстенә сузылып яткач, гаҗәеп рәхәт булып китте. Әмма бу озак дәвам итмәде.

— Обедка! — дип белдерде кинәт старшина.

Дежурныйлар, кухняга барып, чиләкләр белән төшке аш алып кайттылар. Ашагач, мөгаен, ял бирерләр, гомумән, бүген эшләтмәсләр, шул чаклы юл килгәннән соң борчып тормаслар инде дип уйлаган идек. Әмма юк, алай килеп чыкмады. Котелок һәм кашыкларыбызны комда «юып» капчыкларга кире тыгарга да өлгермәдек, тезелергә дигән команда яңгырады. Приказ укыдылар. Анда оборона эшләрен тиз көндә бетерергә диелгән иде. Шунда ук участоклар бүлеп бирелде.

— Һи, бу ике көнлек эш ич! — дип, дәртләнеп, мин көрәгемә ябыштым һәм... көтелмәгән хәлдән чак кына егылып китмәдем. Көрәк жиргә бер сантиметр чамасы керде дә бөгелеп килде. Аста таш, чат таш иде. Башкаларда да шундый ук хәл, күрәсең. Әнә берсе көрәген атып ук бәрде.

— Шартлатырга динамит кирәк монда, — дип, үзалдына сүгенеп куйды ул.

— Иң яхшысы — кәйлә! — аңа кайсысыдыр шулай дип киңәш бирде. Мин дә кулыма кәйлә алдым. Чокыйм. Жир чак-чок итә, очкыннар чәчри. Ярты сәгать, бер сәгать азапландым, шабыр тиргә баттым, ә эшләгән эшем чыпчык тезеннән. Кәйләмне ачу белән читкә ыргыттым да жиргә сузылып яттым.

Кояш рәхимсез кыздыра. Тирә-якта ни куак, ни агач. Эссе. Авыз чатнап кипкән. Сулыш тамак төбен пешерә... Штаб палаткасы янына туктаган цистерна янына барып, чиратка бастым. Су бирделәр. Һәр солдатка бер фляга — кечке ашка кадәр шуны житкер. Уйлап-нитеп тормадым, бер эчүдә флягамны бушатып та куйдым. Шундук тәнемнән шабырдап тир бәреп чыкты. Утлы плитәгә төшкән су тамчысы кебек кенә булды бу, эчәсе килгәнне басмады. Кәефсезләнеп, кабат урыныма барып яттым.

Кусков Николай гайрәт белән кәйләсен уйната. Ташка китереп суккан саен мускуллары зыңлап китәдер төсле. Шул тойгыдан күңелгә тагын да авыррак була. Үземне бөтенләй егәрсез, хәлсез итеп сизә башлыйм. Менә бит ходай бирсә биргән кешегә көчне дә, буйны да, дип уйлап алам. Абыйсының Кара диңгез матросы, Советлар Союзы Герое икәне исемә килеп төшә. Ул Коля кебек үк зур буйлы, киң җилкәле пәһлеван булып күз алдыма баса. Яраланган командирын яна торган корабльдән алып чыгып, аны күтәргән килеш, тоташтан өч сәгать суда йөзгән. Искиткеч батырлык бит бу... Хәзер исә мин шуның киресен уйларга, үзем табынган каһарманнар рәтеннән Кусковның абыйсын сызып ташларга әзер. «Көчле кеше — һәр вакыт батыр. Физик көче булмаса, Герой була алыр идемени», — дип үземә аклану эзлим. Шул ук вакытта янәшәмдә эшләгән Орловның, кешедән калышмаска тырышып, җан тартышканын күрәм. Бичараның бүртәеп чыккан кабыргаларын берәмләп санарга мөмкин. Куллары — сөяк тә сеңер генә. Ә буен инде әйтеп тә торасы юк. Андыйлар турында гадәттә «чебен талагы», «чәбәш» дип сүз каталар.

Тордым. Кабат кәйләгә ябыштым. Тиздән лом да ходка китте. Маңгайдан, аркамнан шабырдап тир ага. Гимнастерканы күптән инде салып ташладым. Казыйм. Телләр аңкауга ябышкан. Күзләрне, иреннәрне тоз ашый. Тез буыннарым бөгелеп-бөгелеп китә. Артык бер минут та түзәрлегем калмаган кебек. Әмма бирешмим, тырышам, «үлсәм үләрмен, барыбер хур булмам, башкалар рәтеннән ерып чыгармын», — дип үземә көч бирәм...

...Шулай бер көн үтте, икенчесе килде. Без күнектек. Сулышыбыз иркенәйгән төсле булды. Ләкин кыенлыклар әле бетмәгән иде. Бер метр тирәнлегендә казыгач, мәңгелек туң башланды. Монысы инде таштан да яманрак иде. Ватып та, китеп тә алырлык түгел. Лом белән бар көчеңә китереп бәрәсең — уймак кадәрле чокыр кала. Аптырагач, учаклар ягып эретә башладык. Әле ярый, якын тирәдә өермә үләннәре күп иде...

Мич авызыннан бәргәндәй, Гоби чүленнән кайнар җил исә. Җир кызган плитәгә әйләнгән, хәтта ботинка табаны аркылы аякны пешерә. Тирә-якта елап эзләсәң бер үлән, яшеллек әсәре күрмәссең. Үзәннәр, сопкалар инде көеп ком төсенә кергәннәр. Әйтерсең һәлакәтле кояш

бөтен тереклекне кырып бетергән. Дала үле. Хәер, гарнизонда да артык зур җанлылык сизелми. Соңгы вакытта походлар, өйрәнүләр бетте. Солдатлар ничектер тынып, басынкыланып калдылар. Бөтен дивизиядә киеренке тынлык урнашты.

Калинин егете Парфенов белән икәү куна-төнә далада ятабыз. Гарнизонның көньяк өлешендәге сопка өстендә — безнең «штаб-квартира». Иелеп кенә басып торырлык чокыр казылган. Җир өстәле, җир сәкесе бар. Плащ-палатка түбә хезмәтен үти. Өстәл өстендә төне-көне рация эшләп тора. Дивизиябез тирәсендәге барлык сопкаларда хәзер әнә шундый радионокталар барлыкка килде. Июль башында безнең радистларның һәммәсе далада торып эшләүгә күчтеләр. Үзара радиограммалар алмашабыз, тизлектә ярышабыз, кыскасы, кыр шартларында эшләүгә күнегәбез.

Без Парфенов белән алмаш-тилмәш дежур торабыз, алмаш-тилмәш аска төшеп, гарнизоннан су һәм азык алып киләбез. Тирә-як тып-тын. Ара-тирә генә саргылт йонлы дала тычканнары яисә калын, итләч тарпаганнар йөгереп үтә. Көн урталарында, вакыт-вакыт, күккә җырлап тургай менә. Төннәрен исә тормыш тәмам сүнә. Тик кайдадыр шакаллар гына, нәни балалар кебек үксеп, үзләренең барлыкларын сиздереп куялар. Ә бер төнне алар землянкабыз янына ук килделәр...

Парфенов дежур иде. Мин дә әле уяу ятам. Кичен, кояш баеганда, туган якларны искә алып, землянка кырыенда озак кына сөйләшеп утырган идек. Шул күңелне кузгаткан, ахрысы, йокыга китеп булмый. Кинәт аяк очында нәрсәдер кыштырдап куйды. Аннары баш турысында ук мышнаган тавыш ишетелде. Ул да түгел, Парфенов:

— Шакаллар! — дип пышылдап, аягыма төртте.

Мәхлукларны капчыкларыбыздагы коры паек исе ымсындыра иде, күрәсең. Безне алардан нибары юка плащ-палатка гына аерып тора. Ә ишек авызы бөтенләй ачык. Җир баскыч турыдан-туры землянкага алып керә. Шуннан күренгән йолдызлы күк фонында берничә тапкыр елгыр шәүләләр узып-узып китте. Менә берсе баскыч өстендә тукталып, башын калкыткан килеш, озак кына эчкә карап торды. Мин янымда яткан СВТ винтовкасын капшап куям. Парфеновның куллары исә билендәге штыкка үрелә. Чүл этe борыннарын йөртеп иснәде дә үскегән тавыш чыгарып куйды, аның янына тагын берсе килде. Ләкин эшләп торган рациянең яшел уты һәм гөжләгән тавышы аларны өркетә иде булса кирәк, эчкә керергә кыюлык итмәделәр, колакларын уйнаткалап, таптанып тордылар да киттеләр, тагын әйләнеп килделәр. Бу юлы инде алар өчәү-дүртәү иде. Ләкин без үзебездә курку сизмәдек. Ни әйтсәң дә янибызда винтовкалар бар. Ә корал кешегә батырлык бирә.

Чакырылмаган төнге кунакларның әрсезлеге безгә ошамый башлаган иде инде. Алдыма алып, әзерләп куйган винтовкамның затворын кисәк кенә үземә таба тарттым. Металл шыкылдаганны ишетү белән мәхлуклар шундук читкә атылдылар. Затворны ябып, курокны җибәргәндә алар инде табан ялтыратырга да өлгерделәр. Буш көпшәдән чыккан коры шартлау тавышы качучы күләгәләр артыннан төнге далага очты...

Ә гомумән көннәр бернинди мажарасыз үтәләр. Билгеле бер тәртип, график буенча өйрәнүләр бара. Әле микрофон, әле телеграф ярдәмендә эшлибез. Тыныч, рәхәт. Ашыктырган, арттан куалаган кеше юк. Тик баш станция генә, көтмәгәндә эфирга кереп, бу күнегелгән гадәти тормышка бераз төрлелек һәм киеренкелек өстәп куя. Бигрәк тә төнлә яисә көндезге ял вакытларында дәшеп, безнең уяулыкны тикшерергә ярата ул. Әмма аның бу мәкерле гадәте күптән инде исәпкә алынган. Солдат уйлап чыгарган төрле эреле-ваклы хәйләләр, әмәлләргә гади котелокның акустик сыйфатларын ачуны да өстәргә мөмкин. Анардан

безнең радист халкы бик оста файдалана. Котелок эченә асып куелган колакчалар сигналларны бер дә динамиктан ким яңгыратмыйлар.

Шулай да бу көнне барысы да ничектер көтелмәгәндә булды. Төшке аштан соң землянка кырыена чыгып иркенләп сузылып ятарга да өлгермәдек, котелок кинәт каты гына шытырдап куйды. Шундук сикереп урыныбыздан тордык. Морзе сигналларын чәчрәтә-чәчрәтә, безне баш станция чакыра иде. Колакчаның бер җәбен Парфенов, икенчесен мин эләктердем. Безне тагын да каушата, гаҗәпләндерә төшеп, баш станция микрофон белән эшләүгә күчте:

— «Лачын», «Лачын», мин — «Карчыга»... Егерме дүрт... Егерме дүрт... Ничек аңладыгыз? Кабул итүгә күчәм...

— «Карчыга», «Карчыга», мин — «Лачын»... Сезне аңладым... Сезне аңладым...

Әйе, барысы да ап-ачык: «Егерме дүрт» — сугышчан тревога! Җыенып кайтырга дигән сүз. Күңелдә тик бер генә сизенү: «Димәк, димәк»... Әйе, моның хәзер башкача булуы да мөмкин түгел. Әнә югарыдан гарнизонда күренгән хәрәкәт, гадәттәгегә охшамаган җанлылык үзе үк шуны әйтеп тора. Анда иңкүлектә солдатлар инде колоннага тезелә, орудиеләр маскировка чокырларыннан чыгарылып машиналарга тагыла. Әйе, димәк, ул көн килеп җитте: димәк, кузгалабыз...

...Гарнизонда безне дөрләп янган учаклар каршылады. Бар артык-портык нәрсә утка ташлана. Иске чолгаулар яна, матрас, мендәрләргә тутырылган өермә үләннәре яна, кирәксез документлар, укылган солдат хатлары һәммәсе утка очалар.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, без инде тулы сугышчан хәзерлек хәлендә үзебезнең элемтә батальоны колоннасында басып тора идек. Аркада капчык һәм рация, иңнәрдә скатка, винтовка, противогаз; билдә көрәк, котелок һәм патронташлар. Һәммәсе дә өйрәнүләргә чыккандагы кебек. Тик башыбызга кигән каскалар һәм капчыклардагы чын патроннар, гранаталар гына, иңнәргә авырлык өстәп, күңелне әлегә хәтле татылмаган хисләр белән дулкынландыралар иде...

Өч ай дәвам итте безнең поход. Утлы Гоби чүле... Түбәләре болытларга тигән шыксыз Хинган таулары... Ниһаять, Кытай кырлары... Маньчжурия... Чиләклән койган яңгырлар... Сазлы юллар... Утлы атакалар... 1945 елның 3 сентябрендә нәкъ җырдагыча, «Тын океанда тәмамланды безнең поход». Бөтен Үзәк Азияне диярлек җәяү йөреп чыгып, мең ярым чакрым юл үттек. Мең ярым чакрым бар да мең ярым чакрым кире кайт. Барлыгы өч мең дигән сүз. Менә кайчан кирәк булды ул безнең чыныгулар, кырыс дала шартларындагы күнегүләр!

...Түбәләрендә мәңгелек кар яткан биек таулар һәм уттай янган кызган комнар. Кеше үтеп йөри алмаслык урманнар һәм кысыр дала. Көмеш чишмәләр һәм тозлы күлләр... Монголия әнә шундый.

Каяндыр илнең урта бер җиреннән Бөек дала башлана. Аның өстеннән сәгатьләр буе очарга һәм бер генә җан иясе, бер генә яшеллек тә очратмаска мөмкин. Тик яз ахырында һәм җәй башларында гына дала кыска бер вакытка хәтфәгә төренеп ала. Бу — аның иң матур, иң тыныч чагы. Куйлар кышкы калын туннарын салалар. Бияләр янында яшь колыннар уйнап йөри. Монгол хатыннары кымыз ясый, тирмә түбәләренә җәеп бислаг[1], хурут[2], ит киптерә. Кыскасы, далада тормыш кайный. Монголияне яшел ил дип атаулары да, күрәсең, җәйнең нәкъ әнә шул чагы белән бәйләнгәндер.

---

[1], [2] Бислаг, хурут — сыр төреннән булган милли ризыклар.

Әмма эссе кояш бик тиз яшеллекнең башына җитә, җәй урталарында инде дала тәмам көеп, эштән чыга. Бөтен тирә-як шыксызлана, ком төсенә керә. Көтүләр, корып җиргә ауган кыска, сирәк дала үләнен чүпли-чүпли, акрынлап көнбатышка хәрәкәт итәләр, яисә елга үзәннәренә тупланалар.

Тулы тынлык урнаша. Күк тә, дала да җансыз. Бөтен җиһанда тик бер хаким — ул да булса кояш. Сәгатьләр буе баш өстендә шул утлы шар асылынып тора. Аңардан качар да, яшеренер дә урын юк: тирәюнь шыр ялангач.

Мичтәй кызган дала буйлап, йомгаклана-йомгаклана, ара-тирә өермә үләннәре тәгәрәп үтә. Кайнар җил аларны, зур-зур чүмәләләргә төреп, офыкның бер читеннән икенче читенә куа. Дала коры кыштырдау тавышына күмелә. Төннәрен, кояш үзенең тәхетеннән төшеп ялга киткәч тә, бу хәрәкәт тукталмый. Җил өф итеп өреп куйдымы — өермә үләне маҗаралы сәфәргә чыга.

...Кинәт күрше посттагы часовойның кисәтүле тавышын ишетәсең:

— Тукта, кем килә!

Җавап юк. Тынлык. Тагын да катырак тавыш белән часовой кабатлап эндәшә:

— Тукта, кем килә!

Монысыннан да дәһшәтлерәк булып өченче кисәтү яңгырый:

— Тукта, атачакмын!!!

Шарт-шорт затвор ачылып ябыла. Барысын да ишетеп торасың. Тик мылтык шартлыйсы гына кала. Көтәсең. Нервлар кыл кебек тартыла. Менә... Менә... Чү, нәрсә бу?! Йөрәгең кинәт кысылып куя. Эсселесуыклы булып китәсең. Җиңел генә йөгереп, кемдер үзеңә таба килә түгелме соң?! Кисәтергә, ныклап торып күрергә дә өлгерми каласың — яныңнан куркыттым бит, куркыттым дигәндәй, лерт-лерт сикергәләп, өермә үләне үтеп китә. Әйе, шул үзе! Шул каһәр төшкере! Күләргә дә, ачуланырга да белмисең. Чын аяк тавышлары чыгарып, эштер-өштер йөгерә бит, иблис җан!

Кышын походларда бу — алла биргән ягулык, ә казармада — түшәк. Шул чәнечкеле коры үлән тутырылган матраслардагы татлы йокылар әле дә булса төшкә керә.

Ә инде бәхетсез очракка туры килеп, төнлә даланың янганын күрсәң — анысы үзенә бер табышмак. Менә караңгы офыкны иңләп неп-нечкә бер кызыл елан үрмәли. Әкрен генә шуыша, шуыша да, кинәт бөтерелеп, һавага сикерә. Аннары хәлсезләнеп кабат җиргә килеп төшә. Кабат үрмәли, кабат ыргытыла... Димәк, ялкын юлында өермә үләннәре очрый. Йомгаклана-йомгаклана дала буйлап йөри торгач, алар шулай гөлт итеп кабына торган кибәннәргә әйләнәләр, ермакларга, чокырларга кереп тулалар.

Тукта, нишләп соң әле болай күңел һаман юлдан читкә тайпыла, өермә үләне кебек бөтерелеп гел далага очарга гына тора. Нинди гүзәл урыннар өстеннән үтәбез ләбаса! Таулар арасындагы кояшлы яшел үзәннәр ничек күзне иркәли! Әнә җәйләү дә килеп чыкты. Кояшка җәеп салынган ак киндер кисәкләре — куй көтүләре болар. Ә югарыдан аспирин таблеткалары булып күренгән ак таплар — тирмәләр, әлбәттә. Һәммәсе дә төсле кинодагы кебек ачык, матур. Күршеләребез — Америка туристлары да хәзер иллюминаторларга һаман саен ешрак иеләләр, җирдән күзләрен ала алмыйлар.

...Кинәт каршыбыздагы таблода искәртүле сүзләр белән чекерәеп кызыл ут кабынды: «Каешларны элэктерергә...» Шуның артыннан күп көттермәде, йөзеп барган су кошыдай, стюардесса да килеп чыкты. Кулындагы кечкенә подностан пассажирларга леденецлар тәкъдим итә-итә, ул креслолар яныннан узды. Колакларымда ят бер чымырдау, авырту сизеп, мин аның «күчтәнәчен» авызыма салып та куйдым. Һәр

вакыттагыча самолет җиргә төшәр алдыннан була торган гадәти хәстәрлек, биеклек кимегәндәге гадәти күренешләр болар. Тик ни өчендер миңа хәзер алар гадәттәгедән үзгәрәк, сиздергечрәк, хәтта нәрсәләре беләндер газиз дә булып тоелалар. Әнә динамиктагы тавыш та күп өлеш мөлаемрак, тантаналырак яңгырый төсле.

— Улан-Батор... Монголия Халык Республикасы башкаласы...

Ике яклап таулар кысып торган елга үзәнендә Европа тибындагы биек таш йортлар калкып чыкты. Самолет гүя шуңа куанып, канатларын уйнатып алгандай итте. Җир, бер уңга, бер сулга янтаеп, башта ташлы-түмгәкле елга тугаен, аннары текә яр битен күрсәтеп алды да искиткеч зур тизлек белән иллюминаторлар яныннан очты. Бераздан бөтен тирә-як капылт ачылып, иркенәеп китте, бөтен нәрсә хәрәкәтсез калды.

Мин үземне креслога бәйләп токкан каешлардан ычкынырга ашыктым. Шул арада ишек тә ачылып китте һәм кемнеңдер җылы, җинел тыны булып битемә йомшак дала җиле килеп бөркелде. «Исәнме!» дип аңа шыпырт кына хәбәр салдым...

Көләч нурда йөзгән дала аэродромында, «тәпиләрен» бетонга терәп, көмеш кош утырып калды. Чем-кара «ЗИМ»нар безне яр өсте буйлатып Улан-Баторга алып китеп баралар. Асфальт юл тасмасы бер түбән оча, бер югары чөелә. Алгы утыргычта шофер белән янәшә урнашкан калку буйлы, якутчарак кыяфәтле монгол егете Җигмит әледән-әле безнең якка борылып елмайгалап ала, я саф рус телендә ни дә булса әйтеп куя. Форсаттан файдаланып, ул безне визитыбыз планы белән дә таныштырып чыкты. Болгария, Венгрия, ГДР һәм Чехословакиядән дә журналистлар бар икән. Безнең алар белән бергә Убур-Хангай аймагында, яңа төзелә торган индустриаль шәһәр — Дарханда, аннары Селенгада булуыбыз күздә тотыла. Улан-Батор белән дә ныклап танышачакбыз. Җигмит болар турында әйткәндә, мин тын да алмыйча дулкынланып көтеп утырдым. «Керулин», я булмаса «Баян Төмән» дигән сүз дә чыкмасмы дип өмет иттем. Әмма юк. Колагыма бер дә үзем белгән урыннарның исемнәре чалынмады. Җигмит исә:

— Прошу любить и жаловать, тәрҗемәчегез сыйфатында мин сезне озатып йөриячәкмен, — диде дә тынып калды.

Аэродромда алар икәү иде: ул һәм Монголия Журналистлар союзы секретаре Уржинбадам. Анысы бездән бераз арттарак калып, икенче машинада кайта. Мин хәзер 30—35 яшьләрдәге бу монгол егетләренең икесе турында да уйлыйм, алар үткән тормыш баскычларын күз алдыма китерергә тырышам. Моннан 26 ел элек мин солдат төймәсе бүләк иткән малай да инде хәзер зур булгандыр, болар кебек укып белем алгандыр, ә кем белә, шушы егетләрнең берсе бәлкем үзе үктер.

— Җигмит, әйт әле, син кайсы яктан, Керулиннан түгелме?

— Юк. Нигә?

— Тәк, болай гына... Ә Уржинбадам кайдан?

— Ул Улан-Баторда туган.

Җигмит дикъкать белән минем күзләремә карый. Мөгаен, әллә Керулинда булган идегезме дип кызыксына ук башлар. Ә мин бу сүзнең һич тә болай ашыгыч арада гына кузгатылуын теләмим. Вакыт килер, һәммәсе ачыкланыр. Монголиядә ике атна булачакбыз. Бу — шактый гомер. Күп нәрсәне эшләп өлгерергә, хәтта Керулин буйларына да барып кайтырга мөмкин. Әлбәттә, минем Убур-Хангай җирендә дә, Дарханда да, Селенгада да буласым килә, әмма үзем хезмәт иткән урыннарны күрми китсәм, бу гомерлек бер үкенеч булып калыр төсле...

— Җигмит, әнә теге тау ничек дип атала ул?

— Зайсан-Толгой.

— Әйе, әйе, ишеткәнем бар...

Менә нинди икән син, гүзәл Зайсан! Як-ягың урман. Итәгеңдә ша-

һәр җәелеп ята. Ә хәтфәдәй яшел түбән өстендәге әнә теге биек ак фигура — һәйкәл... Совет солдаты хөрмәтенә калкытылган монумент шул инде. Улан-Батор аннан уч төбендәге кебек ачык, матур күренәдер. Шуны бит инде кимсетеп, кайчандыр «Кнез шәһәр» дип атаганнар. Ә хәзер әнә ничек күкрәп үскән ул Кызыл Баһадир! [1] Һәркайда, күкне терәп, биек-биек йортлар, төзелеш краннары басканнар. Әйтерсең эчендәге якты куанычы ташып, шәһәр тагын да биеккәрәк сикерергә әзерләнгән. Борынгы Толу үзәне хәзер тар шул инде аңа. Көньяк-көнбатышта башкала тауга күтәрелгән дә, зур якты тәрәзәләрен балкытып, бире карап тора. Гүя ул:

— Рәхим итегез! — дип, Улан-Баторга килүчеләрне каршылый.

Очып барып аның кочагына атылырга теләгәндәй, машина зур тизлек белән түбән таба чаба. Тау астын сырган таллык каерып ачылган капка булып артка чигә һәм без шул ук секундта шәһәргә килеп керәбез. Менә Толу аркылы салынган зур бетон күпер. Күземә чуер ташлар белән капланган коры елга төбе чалынып кала. «Су юк...» «Суы кипкән...» Төкерек йоткан хәрәкәт ясыйм. Мин чын-чыннан сусау сизәм...

Ниһаять, машина киң гранит баскычлар каршысына килеп туктый. Биш катлы зур матур бинаның өстендә язу: «Улан-Батор гостиницасы». Өченче каттагы люкс — безнең номер. Керү белән графинага ябышам. Буш! Стаканны алып, ванна бүлмәсенә юнәләм. Кранны ачам — шаулап су ага. Эчәм. Көмеш кебек саф, салкын су. Тагын агызам, тагын эчәм. Ванна кранын да борып карыйм. Аттырып су ага. Әнә инде юлдашларым да бу сәер кыланышларыма игътибар иттеләр.

— Нәрсә син анда һаман су белән шаярасың? — диләр.

Бу — көлке, билгеле. Ләкин нәрсә дим, ничек итеп аларга аңлатыйм. Кайчандыр Монголиядә яшәгәндә бик сусаган идем, бу сусау ике елга сузылды. Казармада сусадым, постта сусадым, Гобины кичкәндә сусадым, Хинганда сусадым, менә хәзер яңадан монгол җиренә аяк баскач, кабат тамагым кипкәнне сиздем димме? Юк, дәшмәвең хәерлерәк. Барыбер:

— Эч рәхәтләнеп. Монголиядә хәзер ел саен меңнәрчә кое казыла, меңнәрчә скважиналар бораулана, геологлар яңадан-яңа җир асты диңгезләрен, җир асты күлләрен табалар. Су җитәрлек, — диярләр дә сүземне көлкегә алырлар.

## Юлда

Анатолий ашап утырган җирдән чәнечкесен өстәлгә куйды да озак дәвам иткән бәхәсне яңадан кузгатырга азапланган кыяфәт белән сорау бирде.

— Димәк, барасың?

— Барам.

Мәсьәлә бу вакытта тәмам ачыкланып беткән иде инде. Дарханга без бергә барабыз, аннары Анатолий белән Иллеш Селенгага китә, ә мин кире Улан-Баторга кайтып, Керулин ярларына юл тотам.

— Син бер тапкыр анда булган бит инде, — дип, Анатолий үзенекен сукаларга тырышты. — Ә Селенганы әле күргәнең юк. Әйдә, безнең белән.

— Бу мөмкин түгел.

— Гаҗәп! Нәрсә тарта сине анда шул кадәр?

— Кошны туган оясына нәрсә тарта?

— Керулин — синең туган оян түгел.

— Дөрес. Ләкин без анда канат чыныктырдык, егет булып җиттек. Тормыш юлыбыз шунда башланды.

[1] Улан-Батор — монголча Кызыл Баһадир дигән сүз.

— Син романтик, дускай! — Анатолий чәнечкесенә тозлы кыяр әләктереп алып авызына капты.
— Романтиканың монда катнашы юк, — диде Иллеш, сүзгә кушылып. — Белмичә сөйләнәсең, Анатолий. Яшьрәк шул әле син. Солдат тозы ашамагансың. Романтикадамыни хикмәт? Их, җиңел дә кулланабыз соң бу сүзне хәзер! Аркасына рюкзак аскан теләсә кайсы туристны романтик дип исәпләргә әзер торабыз хәтта.
— Монысы белән килешәм. Тик мин аңламыйм, бер булган җиргә яңадан барудан ни файда?
— Ә яшьлеккә кире кайту? — Бу начармы? Моның зур мәгънәсе бар, агай-эне.
— Яшьлеккә кире кайтуныңмы?
— Гомумән, үткәнеңне хәтерләүнең, истәлекләр яңартуның. — Иллеш тирән итеп, ләззәтләнеп тәмәке суырды. Һәм, авызыннан төтен алкалары очыра-очыра, каядыр югары караган килеш, уйга талып, бермәл тын гына утырды да көлеп җибәрде: — Бер кызык вакыйга искә килеп төште әле. Сөйлиммe? — диде ул.
— Сөйлә, — дип, без тыңларга әзерләндек.
— Малай чакта булды бу. Бервакыт шулай Мәскәүдә урам буйлап барам. Ифрат эссе. Үлеп морожный ашыйсы килә. Ә кесәдә җилләр уйный. Их, мин әйтәм, ятсын иде хәзер шушында акча аунап. Күп түгел, бер морожныйлык кына... Үзем шулай уйлыйм, үзем аяк астына карап барам. Һәм, ышанасызмы, үзебезнең чатка җиткәч...
— Акча таптың?
— Ихлас менә! Яңгыр трубасы астында түгәл бер тәңкә...
— Oho! Алайса, бер морожныйлык кына булмаган инде бу.
— Тукта, бүлдермә... Шуннан соң бик күп еллар үтте. Фронттан кайткач, үземнең бала чактагы бер дустымны очраттым. Ул да сугышта булган, бер аягын, бер кулын югалткан. Сөйләшеп әкрен генә барабыз. Үзебезнең урамга җиткәч, әлеге вакыйганы искә алдым да: «Менә шушында бөгәрләнгән килеш ята иде ул бер тәңкә», — дип, урынын да күрсәттем. Бу да көлде башта. «Могҗиза», диде. Ә берничә көн үткәч, телефоннан шалтырата: «Беләсеңме, мин могҗизага ышанам, әйдә, тикшереп карыйк әле», — ди. «Нәрсәне?» мәйтәм. «Бүген гаҗәп төш күрдем: имеш, теге урында бер тәңкә акча ята. Киттекме?» — ди.
— Һәм киттегезме?
— Әйе, киттек.
Иллеш, сүзен өзеп, ашыкмыйча гына трубкасын суырды, сыра эчте.
Анатолий түземсезләнеп кабат сорау бирде:
— Һәм акча таптыгызмы? — диде ул, чак кына көлемсерәп.
— Әлбәттә. Нәкъ шул ук урында. Түгәл бер тәңкә.
— Алайса, бөгәрләнгән дә инде?
— Хәтта бөгәрләнгән дә... Кыскасы, сез үзегез дә сиздегез бугай инде...
— Ягъни дустыгыз акчаны махсус ташлаган булган?
— Әйе, бу аның фокусы иде. Тик мин моңа шундук түгел, бераз соңрак төшендем. Башта көлешә-көлешә акчаны эшкә җиктек. Морожныйлар сатып алдык та, бик әйбәтләп кенә сыптырып куйдык. Нәкъ малай чактагыча килеп чыкты. Шуннан соң гына күңелгә шик төште: акча бөгәрләнгән дә иде бит. Монысы инде ни өчендер артык тоелды. Ясалмалылык сизелә иде. Шуннан әйттем дустыма:
— Молодец, могҗизаны шәп укмаштыргансың, ләкин нәрсәгә кирәк иде бу — шунысын гына аңламадым, — дидем.
Көлде дә бу:
— Тәк кенә, сине сынар өчен генә, — дип җавап кайтарды. Соңыннан исә, байтак вакытлар узгач, үзенең мәзәген түбәндәгечә аңлатты:

— Беләсеңме, — диде ул, — без сугышта тормыш өчен кирәк булган бик күп кадерле нәрсәләрне югалттык. Шул исәптән балаларча шатлана, ышана белү сәләтен дә. Синең дә бәгырең корышып каткандыр дип уйлаган идем. Ялгышканмын икән. Бактың исә, син әле балалыкка да кайта беләсең икән, — диде.

Иллеш сөйләп бетерде дә өстәл өстендә яткан трубкасын кесәсенә алып тыкты. Без тын гына урыннарыбыздан тордык...

Анатолий бәлкем хаклыдыр. Бәлкем, чыннан да, мин төпсез хыялга бирелгән бер затмын һәм үткәннәремне артык идеаллаштыра торганмын. Яшьлегем даласына ашкынуым да бәлкем гел шуннан гына киләдер. Бактың исә, утыз ел үткән. Дивизиябезнең эзе генә түгел, урыны да инде калмагандыр. Шулай булгач, баруымда ни мәгънә? Ник барам?...

Яшьлекне сагынумы бу, нәрсә?

Әллә, чыннан да, хыялга, романтикага бирелүме? Ә бәлкем без үзебез хыял чишмәседер?.. Ихтимал... Бик ихтимал... Тик беренче тапкыр далага килгәндә, 1943 елның теге салкын декабрендә, без романтика турында уйламадык. Бурыч үтәү тойгысы көчлерәк иде, күрәсең. Безгә: «Туңсагыз, өшесәгез дә, үләр дәрәҗәгә җитеп сусасагыз да, түзегез, шушы урыннан кузгалмагыз», — диделәр. Һәм без түздек, кузгалмадык. Без батырлыкның секундлар белән дә, минутлар белән дә түгел, бәлки атналар, айлар, еллар белән, ә аннары километрлар белән дә үлчәнгәнен аңладык. Менә шул бәлкем романтика булгандыр. Әгәр без күпмедер дәрәҗәдә романтик икән, моңа безне фәкать авырлыклар өйрәттеләр. Даланың үзәккә үткән салкыннарына, чамасыз эсселәренә түзүебез, соңыннан сусыз чүлләр, текә таулар аша кичүебез, җәяүләп меңнәрчә чакрым юл үтүебез безгә үзе бер легенда булып тоелды һәм без авырлыкларны сабыр гына күтәрергә өйрәндек.

Бу бер. Икенчедән... Ә икенчедән, нәрсә дияргә соң? Сугыш елларыннан исемнәре хәтергә сеңеп калган шәһәрләр, авыллар, станцияләр яныннан үткәндә юлдашыңның кинәт вагон тәрәзәсенә капланып тын калганын күрәсең дә тетрәнеп китәсең. Аның йөзенә тирән моң, сагыш билгесе чыга, ләкин моның сәбәбен сорамыйсың. Үлән баскан, җир белән тигезләнеп килгән окоплар өстендә берүзе каңгырап йөргән билгесез кешене очратканда да дәшми узасың. Кем ул? Кайдан? Ни өчен йөри? Сорашып, кызыксынып торуның кирәге юк. Димәк, ул йөри сугышкан. Ерактагы туган җиреннән аны монда, җимерек окоплар арасына нәрсә китергәнен бәлкем ул үзе дә рәтләп аңлатып бирә алмас иде. Ишелгән крепость стенасы, я булмаса иске блиндаж янында йөзе белән ташка капланып үксегән чал агайны күрсәң дә — эндәшмә, тын гына узып кит: ул — ветеран, ул сугышта булган... Шул барысын да әйтеп бирә.

Җир буйлап ветераннар йөри. Алар белән бергә җирдә зур бер юксыну хисе йөри. Шагыйрь Сибгат Хәкимнең Курск дугасы турында язган шигырьләрендә, поэмаларында да мин шул ук юксынуны сизәм. Үзенең сугышчан иптәшләрен, полкташ дусларын сагына шагыйрь. Ләкин алар инде юк... Бөтенләйгә юк... Шагыйрь икенче тапкыр Курск дугасында булып кайтты. Соңгы баруы турында язган чәчмә әсәрен йотылып укыдым. Менә бу юллар тетрәндерде мине: «...Дуга, серле, дәһшәтле Дуга... Сыртларда, иске траншеяларның өстендәге тынлыкта сагышым тирбәлә. Сагыну хисе күңелне шундый кисә, теләә, талый, тәгәрәп-тәгәрәп үксисе килә»...

Мин күршемдә утырган базык гәүдәле, киң битле монголга карыйм. Ифрат сөйкемле, матур күренә ул миңа. Әле ярты сәгать элек кенә аның дөньяда барлыгын да белми идем. Иртән аэропортка килгәч, Уржинбадам, кемнедер эзләп, ашыга-ашыга пассажирлар арасына кереп югалды да бераздан шушы ир уртасы кеше белән янадан күренде.

— Менә танышыгыз, — диде ул, аңа ишарәләп. — Намхай да Чойбалсанга кайта. Ул сезне дивизиягез торган урынга алып барыр.

Самолетка кереп утыргач та без иркенләп, яңабаштан танышып алдык. Намхай аймак газетасы редакторы икән. Хәзер СССРдан кайтып килеше. Журналистлар делегациясе составында Кыргызстанда булган.

— Димәк, тарихи урынга барасыз? — диде ул, сүзне мин теләгән темага күчереп.

— Ә сез ул урынны яхшы беләсезме? — дип, мин дә сорау бирергә ашыктым.

Сезнең дивизияне хәтерлим... Яхшы хәтерлим. Далада куйлар көтеп йөргәндә андагы зур-зур тәрәзәле биек йортка ерактан еш кына соклanып карап торганнарым истә.

— Мөгаен, безнең клуб булгандыр ул.

— Әйе... Ә мин, беркатлы, аны хан сарае дип уйлый идем. Бала гына идем шул әле.

— Менә әкият!.. Ә хәзер ничек ул, торамы?

Әллә соравымны ишетмәде, әллә юри ишетмәмешкә салышты, Намхай, ни сәбәптәндер, дәшмәде. Бераз тын калып утырды да ул үзенең ничек бервакыт безнең дивизия солдатлары янына тәмәке эзләп баруы турында сөйләп китте.

— Кайда икән хәзер алар, исән микән? — дип көрсенеп, тирән сулап куйды ул. — Бәлкем сугыштан кире кайтмаганнардыр. Шәп егетләр иде... Мин аларның занятиедә чакларына туры килдем. Керулин үзәнендә утыралар. Алларында — сүтеп салынган пулемет. Курка-курка гына якынлаштым да ун-унбиш адым кала туктадым. Торам басып. Ул вакытта әле русча бер авыз сүз белмим. Болар миңа игътибар иттеләр. Нәрсәдер әйтәләр, үз яннарына чакыралар. Мин исә башымны чайкыйм, «тамих, тамих»[1] дип, һаман үземнекен суктырам. Бармагымны суырып күрсәтәм, төтен чыгарган булып кыланам. Болар төшенеп алдылар да торып яныма килделәр. Һәрберсе кесәмә тәмәке тутыра. Кайттым да этинең итәгенә бушаттым. Картның күзләреннән яшь килде...

Хәзер иң эссе зона өстеннән очабыз. Ераграк киткән саен Гобиның якынлыгы үзен ныграк сиздерә. Күктә бер болыт әсәре күрмәссең. Дала буш, җансыз. Фәкать, таш булып каткан дулкыннарны хәтерләтеп, шәрә сопкалар гына басып торалар. Кинәт анда, очлы хәнҗәр кебек ялтырап, көчле нур чаткысы уйнап алды. Каяндыр сопкалар тезмәсе арасыннан нindидер тар көмеш тасма килеп чыкты да, сулга ыргытылып, төньякка таба сүтелеп китте. Һаваны карлыгачтай кыеп, самолет та шунда борылды.

— Керулин! — дип әйтеп ташладым мин искәрмәстән. Кисәк телемә килгән шул сүз шактый каты ишетелде булса кирәк. Намхай көлемсерәп:

— Әйе, ул, — дип башын селекте.

Саумы, саумы, данлы елга!

Әле син һаман шул ук икәнсең. Әйтче, зинһар, Үзәк Азиянең иң үзәгендә, һәлакәтле кояш көйдереп, яндырып бетергән үле далада нинди тылсымлы көч сине уятты да, нинди кодрәт иясе синә дәрман бирде. Буш сахралар буйлап, ярты илне дип әйтерлек иңләп, көне-төне агасың да агасың. Үзең, югыйсә, Нил да, Амазонка да, Идел дә түгел. Тирәнлектә, киңлектә булсын, син аларның берсе белән дә ярыша алмыйсың. Суың билдән, аркылыга да ун-унбиш метр гына. Шулай да никадәр көч, дәрт бар синдә.

Керулин!..

---

[1] Тамих — тәмәке.

Дәһшәтле ханнар... Кара аләмнәр... Берөзлексез гөрләгән тояк тавышлары... Котырып чапкан атлар... Яшенле кара болыт булып яуга күтәрелгән баскыннар өере...

1945 елның җәендә, ярларына көмеш канатлы эскадрильяләр төшеп тезелделәр, танклар, бронетранспортерлар ташкыны җәелде. Чал киңлекләрнең тынлыгын моторлар гөрелтесе ертты. Үзләренең сугышчан байракларын Дунайда, Эльба ярларында данга күмгән азатлык гаскәрләре иде болар. Шушында ук синең данлы цэриглар — Сухэ-Батор солдатлары, кылычларын ялтыратып, тимер ташкынга кушылды. Истә, бик истә алар. Далада өйрәнүләрдә йөргәндә дә, соңыннан сугышчан походка чыккач та үткен күзле, киң күңелле ул бөркетләрең белән ничә тапкыр очрашырга туры килде. Аеруча Керулин буенда төнлә булган бер очрашу хәтердә нык саклана.

...Көнозын икәүләп Баян-Төмәндә йөргәннән соң абыйны Керулинга кадәр озата киттем. Чөнки аерылышу минутының бераз гына булса да кичегеп торуын тели идек. Әмма тиздән моның өчен үкенергә туры килде. Кечкенә балчык өйләр, киез тирмәләр янынннан үтеп, шәһәрне чыгарга да өлгермәдек, машинабызның двигателе төчкерергә, көйсезләнергә тотынды, аннары бөтенлләй үк сүнде. Сәбәп бензин багында булып чыкты. Аңа ком эләккән икән. Яңадан шәһәргә кайтып, аны чистартып килгәнче байтак вакыт узды. Абый әледән-әле сәгатенә карап ала. Үземнең дә эчемдә мәчеләр тырнаша, чөнки кичке тикшерүгә кайтып өлгермәвем, соңга калуым бик ихтимал иде.

Ниһаять, барысы да җайланды. Кабат юлга чыктык. Бу вакытта инде утлар алынган, төн җирне кара пәрдәгә төргән иде. Күзләребездәге аерылышу моңын да ул бер-беребездән яшерә иде төсле. Керулин үзәненә төшеп җиткәч, ике туган кочаклашып машина әрҗәсендә тын гына саубуллаштык та мин түбән сикердем. Һәм еракта янган утларга карап, кылганнар арасыннан туп-туры дивизиябезгә юл тоттым. Биш-ун минут бардым микән, кинәт йөрәгем жу итеп китте: мин үземнең түбән очканымны сиздем. Ул да түгел, шапылдап суга да килеп төштем. «Керулин!..»

Куәтле агым шунда ук аягымнан екты. Беләм, су киң дә, тирән дә түгел. Шулай да ятьмәгә эләккән балык кебек чәбәләнәм. Ни йөзеп, ни атлап китеп булмый. Су бөтерчегенә эләккәнмен, күрәсең. Кисәк кемнеңдер эндәшкәнен ишетәм. Шул секундта ук кулыма бау тагылган корык башы да килеп керә. Күп уйлап тормастан, мин аңа ябышам...

Менә, күзгә-күз карашып, без икәүдән-икәү Керулин буенда басып торабыз. Ул да, мин дә солдат. Тик аерма шунда гына: коткаручым монголча сөйләшә, ерактагы җемелдәп күренгән утларга күрсәтеп, мин үземнең шунда кайтып баруымны аңлатырга тырышам, вакытның күпме икәнен сорыйм. Цэриг исә:

— Мэдэху, Мэдэху! — дип башын селкә.

Якында гына атларның пошкырганы, кыштыр-кыштыр үлән ашап йөргәне ишетелә. Димәк, коткаручым атлар көтә. Кулындагы озын корык нәкъ шул турыда сөйли. Менә цэриг сузып, йомшак кына итеп кая табадыр аваз бирде. Шундук кемдер караңгыдан аңа җавап кайтарды. Болар үзара сөйләшеп алдылар. Тиздән мин сүзнең үзем турында, дөресрәге, мине дивизиябезгә илтеп кую турында баруын аңладым. Караңгыдан атка атланып килеп чыккан цэриг үзе белән тагын иярле бер ат та иярткән иде. Аның тезгенен ул миңа сузды.

Ерактагы утларга табан без, атларыбызны кушаяклатып, икәү бергә чабып киттек, уңда-сулда палаткалар, маскировка чокырларына яшерелгән машиналар, туплар күренеп калды. Ләм-мим сөйләшмичә, шул ук вакытта күңелдә ниндидер сугышчан теләктәшлек, дуслык хисе тоеп, кылганнар арасыннан без озак чаптык. Ара байтак иде шул. Әле ярый, болар очрады дип, мин эчтән генә куанып барам. Ниһаять, килеп

життек. Үзән инде артта калды, без гарнизон янында. Икәү берьюлы иярләрдән сикереп төшәбез дә сүзсез генә кул кысышабыз.

Тагын биш-ун минуттан мин инде землянкабызда идем. Нәкъ вакытында кайтып өлгердем. Киемнәремне сыгып үземне тәртипкә китерүем булды, «Тезелергә!» дигән команда яңгырады. Мин тиз генә сафка барып бастым.

...Аста һаман бер үк күренеш: безне аксыл кылганнар каплаган киң, тигез үзән озатып бара. Аның буеннан-буена тоташ коридор булып сопкалар баскан. Үзәнне урталай ярып үткән тар зәңгәр тасманың да игечиге юк төсле. Көтмәгәндә ул сулга ыргытылды. Кисәк килеп чыккан елга борылышы хәтер өчен уелган киртек кебек сискәндереп җибәрде дә күптәннән хыялымда йөргән таныш күренешне бөтен тулылыгы белән күз алдыма китереп бастырдым. «Менә хәзер Баян-Төмән күренергә тиеш... Тәбәнәк өйләр, ак киез тирмәләр... Ә теге якта...» Ләкин боларны уйлап бетермәдем, йөзеп дип әйтерлек, каршыбызга шәһәр килеп чыкты. Тик мин бернәрсә дә күрергә өлгермәдем, ул дулкыннар арасындагы салны хәтерләтеп кисәк кенә югары чөелде дә шунда ук түбән шуышып күздән югалды. Без аның көнбатыш өлешендәге сопка өстенә килеп төштек.

Шәрык стилендә салынган ике катлы кечерәк кенә гостиницада юынып, өс-башымны алыштырырга да өлгермәдем, номерым шау-гөр килеп күрешкән-исәнләшкән авазлар белән тулды. Җаны түзмәгән Намхай өенә кереп кенә чыккан да ничек урнашканымны белү өчен килеп тә җиткән. Өстәвенә, редакциянең бөтен хезмәткәрләрен дип әйтерлек үзе белән иярткән. Бераздан алар чыгып китте.

Ниһаять, мин ялгызым гына хәзер. Кич. Гостиницаның палубадай яссы, тигез түбәсендә өстенә тент корылган бер нәни мәйданчык бар. Өстәл һәм камыш креслолар куелган. Арып-талып шәһәрдән әйләнеп кайткач, күңелемдәге мөлдерәгән уйлар, тәэсирләр белән шунда менеп кунакладым. Ял итәм. Шәһәр һәм аның әйләнә-тирәсе әкрен генә сыек караңгылыкка төренә.

Асылда мин белгән теге элекке Баян-Төмән юк инде. Исеме дә, үзе дә яңа хәзер: Чойбалсан!.. Шәһәр өстенә калкып, биектә басып һәйкәл тора. Шәп-шәрә сопканы бизәп, анда яшь агачлар үсә. Гөлләр утыртылган. Туганнар каберлеге ул. Монгол җирен яклап һәлак булган совет батырлары ята анда.

Ә түбәндә, яр астында, үзенең мәңгелек җырларын җырлап, бөтерелә-бөтерелә, Керулин ага. Кылган үскән елга үзәне, ерак-еракларга җәелеп киткән дә аръяктагы зәңгәр сопкаларга барып терәлгән. Күзләрем арып, әлҗе-мөлҗе килеп беткәнче шунда карыйм. Кичке эңгер төшкән иңкүлекләргә озак-озак карап утырам. Кайчандыр анда без идек... Без дотлар, дзотлар корып, танк чокырлары казып ныгыткан җир ул... Һәм шул яктагы киң, иркен җәйләүләрнең берсендә алма битле чая малай яши... Монгол малае... Мин истәлеккә биргән солдат төймәсен кысып тоткан да ул җибәрми. Юк, кулыннан ычкындырмый... Монгол җире дә йөрәгемне шулай ныгытып тотып тора.

## Дала хәтере

Өй алдында чыпчыклар чыркылдаша. Төркемнәре белән комга килеп төштеләр. Торып тәрәзәмне ачып җибәрдем. Канатлы эшкуарлар шундук, пырылдап, кая табадыр очып китте. Мәйданнан сөт бидоны тоткан

монгол хатыны үтте. Буш автобус күренеп узды. Агачлар, йортлар, рәшәткәләр, каршыдагы мәйдан — һәр нәрсә алсу саф нурга төренгән.

Киенеп урамга чыктым. Рәшәткәләр артында, яшь топольләрнең яфракларын лепердәтә-лепердәтә, иртәнге йомшак җил шаяра. Ашыкмыйча гына мәйдан уртасындагы яшь парк кырыеннан атлыйм. Каршымда, бераз үрдәрәк, таныш бина — элек безнең унҗиденче армия штабы урнашкан йорт. Хәзер анда партком — Көнчыгыш аймагының партия штабы. Бирерәк — редакция, музей, аймак театры. Һәркайсын тукталып карап уздым.

Мәйдан тып-тын. Вакыт әле бик иртә. Шәһәр уянмаган. Мин түземсезлек белән минутларны саныйм...

Сәгать сигез. Намхай килде. Ишектән керә-керә үк шат, күтәренке тавыш белән эндәшеп:

— Димәк, бүген тарихи урынга!.. Син әзерме? — дип сорады.

— Әллә кайчан!

— Алайса, бераз гына сабыр ит инде, яме. Мин бер җиргә шалтыратып кына алыйм да китәбез.

Номерымдагы телефоннан ул озак кына кемнедер чакырды, кемнедер көтте, аннары тын торды, тагын шалтыратты, тагын сөйләште, шул арада исенә төшереп, «хәзер, хәзер!» дип мине дә тынычландырып алды.

Түземлеге бетеп, күрәсең, шофер машинаны тәрәзә төбенә үк китереп туктатты да, үзе турында искәртеп, каты гына сигнал бирде. Намхай аны гүя ишетми иде.

— Безне машина көтә бугай,— дип, мин сак кына әйтеп куйдым. Бераздан сәгатемә дә карап алдым.

— Хәзер! Хәзер! — диде Намхай, телефоннан аерылмыйча гына. Аннары кинәт туп-туры итеп күзләремә карады:

— Беләсеңме, мин синең танышыңны таптым ахрысы...

— Таптыңмы?! Тукта, син кем турында әйтәсең?

— Соң теге ни... Син төймә бүләк иткән малай инде. Хәзер малай түгел, әлбәттә. Худунда ул... Далада кайдадыр атлар көтә. Алло!.. Алло!..

Кабат, кызып-кызып, телефоннан сөйләшергә кереште. Мин беркавым шаккатып өнсез калып тордым. Исемә килергә дә өлгермәдем, Намхай тагын миңа мөрәҗәгать итте:

— Кайдалыгын ачык кына әйтә алмыйлар,— диде ул.— Дала бик киң бит. Якын-тирәдәге сурларга атлар җибәрелгән.

Бу шул хәтле көтелмәгән нәрсә иде, беренче шапкә хәтта зиһенем таралып китте. Әлеге малай турында Намхайга кайчан сөйләгәнемне дә хәтерли алмый тордым. Мөгаен, самолеттадыр. Моның өчен хәзер шатланыргамы яки үкенергәме икәнен дә белмим. Уйламыйча никадәр мәшәкать тудырганмын бит. Никадәр кеше эштән аерылган. Кемдер атта чаба. Кемдер телефонда утыра... Далада эзләү бара. Барысы да минем аркада. Мин Намхайга:

— Ә син аның чыннан да ул икәнлегенә нык ышанасыңмы соң? — дия генә алдым.

Ул җилкәләрен җыерып куйды да:

— Без күп түгел бит. Үзләренең тирә-як җәйләүләрдәге күршеләрен монголлар яхшы беләләр, — дип читләтеп җавап бирде. Аннары фикерен ачыклый төшеп: — Кичә өйгә кайткач, бөтен сомоннарга, сурларга шалтыратып чыктым, — диде.

Ниһаять, юлга кузгалдык. Намхай өметләндерерлек бер хәбәр дә ала алмады булса кирәк.

— Киттек! — дип кул гына селтәде дә машинага чыгып утырды.

Бөтен барлыгым белән мин бу вакыт еракта, Керулин артындагы күксел сопкалар арасында идем инде. Бормалы тигез юл буйлап «га-

зик» шунда чапты. Ниндидер бермәлдә миңа дәрес бармыйбыздыр кебек булып китте.

— Үземә ышан, — диде Намхай, икеләнергә урын калдырмыйча. — Юлны яхшы беләм. Күтү көткән җирләрем бу...

Ул тагын нәрсәдер әйтте. Мин баш кагып куйдым. Ә күңел дивизиябез турындагы сүзнең чыкканын көтте. Менә-менә Намхай землянкаларыбызны искә алыр, клуб турында тагын нәрсә дә булса әйтер төсле иде. Ни хәлдә икән хәзер алар? Ихтимал, землянкалар ишелгәндер. Ә клуб?.. Күз алдыма таштан салынган калку, нык бина килеп баса. Клуб бинасын салуга бөтен дивизия катнашкан иде. Иртәләрен физзарядка урынына һәр көнне ике култык астына кыстырып таш китерәбез. Ә ял вакытларында — өмә. Соңыннан кырыс солдат тормышын бизәп, ул клуб безгә күпме куанычлы минутлар бүләк итте! Сугыштан кайткач, «Батырлык өчен» медален дә шунда алдым.

Кылган арасыннан сузылган озын, тар юл тасмасы, көпчәкләр астына кереп, кыскарганнан-кыскара барды да кинәт, бездән качарга теләгәндәй, комлы яр өстенә сикерде. Мотор үкереп югары тартылды. Ә көпчәкләр, аңа карышып комны актара-актара, зырылдап бер урында әйләнергә тотындылар. Гоби чүле исемә төшеп, мин машинадан чыктым. Намхай артымнан иярде.

— Әйдә,— дидем мин аңа,— икебез бер ат көченә торабыздыр әле.

Дөрестән дә, әллә ни күп көч кирәк булмады: җилкәләребез эшкә керешкәч, машина иркен генә югары менеп китте.

Таш сопка итәгеннән чабабыз. Юл-мазар күренми. Мин сопканың калын, киң күкрәгенә карап барам. Кисәк ниндидер эчке бер сиземләү мине икенче якка борылырга мәҗбүр итә. Нәкъ шул вакыт күземә киң, тирән ермак чагыла.

— Я, ничек, таныдыңмы? — дигән тавышын ишетәм Намхайның.

— Нәрсәне?

— Әле генә үтеп киттек ич...

— Ермакны әйтәсеңме?

— Ул сез казыган...

Аңа сүзен тәмамларга туры килмәде.

— Танк чокыры! — дип әйтеп салдым искәрмәстән.

Ничектер колагыма бу чак-чок иткән, таш ярган тавыш булып яңгырады. Үз сүземә үзем гаҗәпсенгәндәй, машинадан башым тыгып, каранып алдым.

— Без казыган өлеше әнә тегендә аның, — дидем мин, яртылаш ком күмгән ермакның офыкка китеп югалган очына төбәлеп.

...Күргәч тә таныдым бу урынны. Элеккечә анда акшарланган кечкенә таш йорт тора. Ә калганнарын инде хәтер китереп өстәде.

...Караңгы салкын төн... Сибәләп яңгыр ява... Без Мухин белән бәрешеп ачык әрҗәле машинада утырабыз... Каршыбыздан бер-бер артлы хәрби составлар чабып үтә... Әйе, бу шул урын. Соңгы тапкыр өйрәнүләргә барганда монда төнге сәгать икегә кадәр тукталып торган идек. Хәзер инде разъезд юк. Солдатлар салган тар колеялы тимер юл да алынган.

...Нәкъ теге вакыттагыча, көтеп машинада утырам. Өйнең ачык тәрәзәсеннән Намхайның кабат шалтыратканы, кем беләндер телефоннан сөйләшкәне ишетелә. Якында ачык утар һәм берничә тирмә күренә. Монголлар сарыклар кыркыйлар. Бирелә хәзер сур икән. Тормыш үзенә яңа магистраль салган.

Без тагын юлда. Каршыбызда сопка. Соңгы сопка... Менәсе дә төшәсе... Теге якта — иңкүлек... Менә томан эченнән калыккан серле көймәләрдәй окоплар килеп чыкты. Яр күкрәгендәге йөзләгән тәкрарлек оялаpын хәтерләтеп, алар тау битенә сырганнар. Эчләренә инде кылган

үскән, ком тулган... Авыр өйрәнүләрдә узган көннәребезнең телсез шаһитләре...

Кисәк аста, уң канатта, Керулин җемелдәп китә. Шул, онытылган сәхифәне ачып җибәргәндәй, 1945 елның 31 маенда шушы юлдан кайтып абыйны күргәнемне исемә төшерә. Алда хәзер дә бит очрашу тора. Менә-менә сопканың түбәсенә менеп җитәрбез дә аста мине күреп алырлар:

— Нихәл, кайттыңмы? — диярләр...

Юк, әкият түгел бу. Хыял таралды, әкренләп ул юкка чыкты. Кешене саңгыраулата торган коточкыч тынлык мине рәхимсез чынлыкка кайтарды.

...Машина туктаган иде. Намхай ишекне ачты. Беренче аяк баскан урынымда — буйга киселгән өйрәнчек граната һәм зур гына снаряд гильзасы... Гранатаны кесәмә алып тыктым. Никтер гильзага да үрелдем. Нәкъ шул вакыт сагышлы, ачы бер хис бәгырьне телеп үтте дә, башымны күтәреп, игътибар белән тирә-юньгә күз салдым. Иңкүлек буш, бөтенләй буш иде. Мин кабер каршындагы кеше кебек тын калып, беравык хәрәкәтсез басып тордым. Аннары тиз-тиз атлап түбән таба төшеп киттем. Каршыма кылган арасыннан бер-бер артлы җимерек саман стеналар, убылып төшкән землянкалар килеп чыктылар.

Ташлар, хәрабәләр, җирдә аунап яткан төрле кирәксез әйберләр... Алар бер тавыштан ни турындадыр сөйлиләр, мине үз яннарына чакыралар иде. Әнә солдатлар үзләре коеп эшләгән алюмин кашык. Әнә ишелгән бер землянка катында кайсыдыр офицерның тимер койкасы чыгарып ташланган килеш ята. Әнә юынгыч итеп җайлаштырылган озын торба. Краннары хәзер, кәкрәеп, төрлесе төрле якка караган...

Мине акрынлап ялгызлык тойгысы били барды. Тирә-якта үз землянкабызның урынын чамаларлык бер генә таныш нәрсә дә күренми иде. Маңгаемнан бөрчек-бөрчек тир бәреп чыга. Аларны кул аркасы белән генә сыпырып алам да туктаусыз каранам, эзлим. Бер уңга, бер сулга китәм, я ары, я бире сугылам. Һаман бер үк күренеш: иске кирпеч базларын хәтерләтеп, як-якта ишелгән, җиргә иңгән землянкалар таралышып ята. Тәмам аптырап, гаҗиз булып хәрабәләр уртасында басып торам. Шул вакыт күзләрем иңкүлекнең аргы кырыена, көньяктагы сопка өстенә төбәләләр. Кайчандыр анда Парфенов белән куна-төнә радиоэлемтә тотып яткан идек бит. Безне соңгы тапкыр аннан алып төшкән сукмак зур тарихи юлның башы булды.

Уйга чумып, күрәсең, байтак вакыт узганын да сизмәгәнмен. Намхай йомшак кына итеп җилкәмә кагылды. Әлегә кадәр ул, кайдадыр еракта-рак калып, машинада артымнан ияреп килә иде. Комачауларга теләмәгәндер, әлбәттә. Менә хәзер, сак кына эндәшеп, уйларымнан аерды.

— Бәлкем машинага утырырсың. Эссе, — диде ул, башы белән кояшка күрсәтеп.

— Кайтабыз!

Ниндидер шатлыклы, үтә җинел бер тойгы белән мин шул сүзне әйтеп ташладым да урынымнан кузгалдым. Намхай гаҗәпсенеп сорап куйды:

— Ә землянкагыз? Аны...

— Юк инде, эзләп тормыйбыз.

— Ни өчен?

— Ничек табасың аны хәзер... Үткәнгә юл юк, дускай. Яшьлек эзләремне кылган каплаган. Комнар күмгән...

Мин шаярып шулай сөйләндем. Машинага кереп утыргач, Намхай җилкәмә кабат орынып алды.

— Әнә! — диде ул, ниндидер зур гына бер таш өеменә игътибар

итеп.— Клуб хәрабәсе түгел микән ул? Син бит землянкагызны шуннан ерак түгел дигән идең.
— Кайчан әйткән идем?
— Әйткән идең инде...
— Гаҗәп! Ә син шуны исеңдә тоттыңмы?
— Хәтерне бит ком басмаган.
— Рәхмәт, Намхай!.. Тик хәрабәләр, таш өемнәре монда аз түгел бит.
— Шулай да киттек! — Намхай шоферга әлеге таш өеменә борылырга кушты.

Эзләремне комнар, кылганнар күмгән диюем ялгыш булган икән шул. Юк, алар онытылмаган... Алар бүгенгедәй хәтердә сакланган.

Мин барган көе үк машинадан сикердем. Иң әүвәле хыял пәрдәсе артында биек, матур таш бинаны күрдем. Ул хәрабәләрдән торып басканнан соң, тирә-яктагы һәр нәрсә, үзенеке-үзенә урнашып, үз хәленә килде. Убылган землянкалар калку таучыкларга әйләнделәр. Җимерек саман стеналар штаб биналары булып рәткә тезелде. Кылганнар каядыр юкка чыкты. Кеше аягы басмаган ком өстеннән юллар, сукмаклар салындылар.

Сугыштан кайткач безгә орденнар, медальләр тапшырганда яңгыраган алкышлар, котлау сүзләре белән гөр килеп клуб артта калды. Бераз сулгарак тотып, мин түбән таба атладым. Ачык ишекләрен канатлар кебек җәеп, артымнан машина килә. Аннан Намхайның әледәнәле:

— Әйдә утыр, утырып бар,— дип эндәшкәне ишетелә.

Мин исә тулысынча инстинкт иркендә. Нindидер илаһи бер эчке көч жилтерәтеп алды да туп-туры землянкабызга таба алып китте. Юк, мин аны эзләмәдем, юнәлешне югалтып буталып та йөрмәдем, ә үзем күргән кебек ышаныч белән атладым да атладым... Һәм кинәт заманнар алмашынып, башым әйләнеп киткәндәй булды. Күзләремә килеп капланган томан пәрдәсеннән котылырга тырышып, мин башымны югары күтәрдем. Күктә, бик биектә, көмеш чыңнар сибеп нәни генә бер кош сайрый иде...

Җирдә старшинаның эмальле яшел чәйнеге ята. Өстеннән кайчандыр машина көпчәге үтеп киткән. Бөтен әйләнәдә хәзер узган-үткән юл күренмәсә дә, аны бер кырыйга алып куйдым. Янымa «газик» килеп туктады. Намхай машинадан төшү белән читкә борылды. Әйе, мондый чакта ир-атның күзләре бик сирәк очраша. Мин әкрен генә землянкабызның ишегенә юнәлдем. Ишек дигәнем сай гына ермак иде. Шуннан аска төштем. Ком... Ком да таш... Үлән үскән... Кайчандыр пирамидабыз торган почмакта күземә ялтыравыклы бер әйбер чалынды. Аяк очым белән төртеп, аны комнан чыгардым. Тимер кружка, тимер котелоклар арасында, капчыкта, үзебез белән бергә Кытайдан йөреп кайткан бердәнбер затлы әйберебез — без җиңү шәрабы эчкән стакан иде ул. Ватылган булса да, искиткеч кыйммәт.

Алып аны кесәмә салдым да кире чыктым.

Әнә кечкенә-кечкенә ком өемнәре. Аякларым шунда алып киттеләр. Һәр өем катында тукталып узам: «Монысы старшина землянкасы». «Монысы безнең элемтә батальонының хуҗалык склады...» «...Монысы радиостанция...» Чү, тукта! Менә нәни казык!

...Соңгы тапкыр таныш инкүлеккә карыйм. Тирә-як тып-тын. Сугышчан дусларымны күз алдыма китерәм. Сопка артындагы окоплар казылган өйрәнү кырыннан бер командир чатанлап кайтып килә. Башында папаха. Погоннарында өч зур йолдыз. Бер аягы калын итеп марля белән уралган, ә икенче аягында шпорлы хром итек. Әйе, бу — полковник Сальников. Фронтовик. Кавалерист. Сугышта яралангач, бирегә укчы

дивизиягә җибәргәннәр үзен. Занятиеләрнең берсен дә калдырмый, һәрберсен тикшереп, энә күзеннән үткәрә.

Әнә икенче бер фронтовик. Анысы — безнең элемтә батальоныннан. Сержант Косолапов. Ул — взвод командиры ярдәмчесе. Күкрәгендә орденнары, медальләре күренми, ләкин йөрәк турысына тегелгән кызыл тасманы зур горурлык белән йөртә. Бу — аның сугышта яра алганын белдерә торган билге. Ә икенче билге — гимнастерка астында. Кайвакыт анысын да күрәбез. Умырылган калак сөягендәге йодрык сыярлык җөй безгә бу кешенең нинди ихтыяр көченә ия булуы турында сөйли. Ул да безне өйрәтергә көнбатыштан килде. Менә хәзер взводны занятиедән алып кайтып килә. Ә аңардан чак кына арткарак калып, үзалдына нидер уйланып, көлемсерәп, взвод командиры, кече лейтенант Бочаров атлый. Ни өчендер мин аны гел бәсләнеп каткан керфекләре белән күрәм... Ифрат салкын. Коры ачы җил битне кисә. Ә бу юри, шуңа үч иткәндәй, бүрек колакчыннарын күтәреп үк куйган. Куллары ялангач. Шәрә колакларын бер генә тапкыр ышкып ала да, винтовканы кулында уйната-уйната, безгә штык сугышы алымнарын күрсәтә... Чойбалсанга кайткач, Намхай белән бергә Керулин буена киттек. Инде бу вакытта кара төн иде. Шыпырт кына дулкыннар сөйләшә. Җылы җил исеп киткәли. Яныбыздан, лерт-лерт сикергәләп, өермә үләннәре йөгереп үтә. Нәкъ теге чаклардагы кебек. Күктәге йолдызлар, даладагы кыштырдау тавышлары, кылганнар һәммәсе яшьлекне хәтерләтә.

Елгадан кемнәрнеңдер тыелып кына көлгәне, суда чапырдашканы ишетелә. Аяк астында ук дулкыннар чайкала. Намхай киң итеп кулларын җәеп җибәрә дә:

— Тын, рәхәт хәзер... Мең ел яшисе килә,— дип әйтеп куя.

Ә мин күккә карыйм. Даланы, Керулинны тыңлыйм. Дулкыннар ритмына ялганып күңелгә шигырь юллары килә:

Ил гражданы булып өлгергәнче
Солдат булып үлгән үсмерне
Полкташым, дустым, юлдашым, дим —
Бер ант бәйли безнең гомерне.
Без елларның утлы өермәсен
Айкап кердек яшьлек чорына.
Кузналардан гранатка күчтек,
Мәктәпләрдән — сугыш кырына.

Төнге далада Намхай белән без байтак йөрдек. Керулин буйлап атлый-атлый, шактый ерак киткәнбез. һәркайсыбыз үз уйларына чумган иде. Тын гына кире борылдык. Гостиницага кайтып җиткәнче сөйләшмичә бардык. Аннары каты итеп кул кысыштык та бер-беребезгә тыныч йокы теләдек.

...Каты итеп ишек шакыган тавышка уянып киттем. Әле таң атаратмас вакыт иде. Бернәрсә аңламыйча, урынымнан тордым. Күнегелгән гадәт буенча тәрәзәгә күз төшереп алдым. Парк рәшәткәсенә иярле ат бәйләп куелган... Сыртыннан пар күтәрелә... Шуып-шуып җиргә ак күбек кисәкләре төшә... Сәерсенеп мин ишекне ачтым. Битен җил кискән, урта яшьләрдәге бер монгол бусага аша сәлам бирде. Аннары янында басып торган дежур администраторга борылды да, башын чайкап, нидер әйтеп куйды. Номерыма чакырып, мин аңа урын тәкъдим иттем. Ул шунда ук, гафу үтенгәндәй, ашыга-ашыга саф рус телендә сөйләп китте:

— Мин еракта, бик еракта идем. Далада атлар көткән чакта килеп әйттеләр: СССРдан синең дустың килгән, диделәр. Көтүдәге иң яхшы аргамакка атландым да чаптым. Бер көн, бер төн чаптым. Юл бик ерак иде. Китеп барырсың дип курыктым.

Ул графинадан су агызып эчте дә йөземә игътибар белән карап алды:

— Юк, Жеребцов син түгел. Аның ирен кырыенда ат типкән эз бар иде, — диде.

— Жеребцов кем соң ул? — дип сорау бирдем.

Ул кабат йотлыга-йотлыга сөйләргә тотынды.

— О, бик яхшы кеше! СССР цэригы. Сезнең дивизиядән иде ул. Безнең тирмәбезгә килеп йөрде. Атларны, куйларны җыеп кайтырга булыша, безгә тәмәке алып килә иде. Хәзинәдә булганы белән без дә аны хөрмәт иттек. Аннары Керулин үзәненнән күчеп китәргә туры килде. Ерак киттек, 20 чакрымга. Жеребцов барыбер эзләп тапты. Кыш иде бу. Салкын. Тирмәдә ягарга утын юк. Дустыбыз бераз сөйләшеп утырды да китеп барды. Ә бер көннән ике иптәшен ияртеп янадан килеп керде. Кечкенә чаналарга төяп безгә утын китергәннәр иде. Егерме чакрым тартып килгәннәр. Менә нинди кеше иде ул! Аннары сугышка китте. Кайткач күрешербез, мин сезне барыбер эзләп табармын дигән иде... Ләкин шуннан соң без аны күрмәдек.

Монгол тирән итеп тын алды. Кулындагы эшләпәсен яньчештергәләп байтак вакыт дәшми утырды да:

— Юк, һәлак булмагандыр, исәндер ул! Монголиядән киткәндә саубуллашырга гына өлгермәгәндер, — дип, урыныннан кузгалды. Аның ышаныч белән әйтелгән бу сүзләре никтер моңсу яңгырады. — Шул кешене тапсагыз, мин сезгә зур бурычлы булыр идем, — дип дәвам итте ул. — Тик менә исемен, адресын гына белмим. Сорарга башыма килмәгән. Әйе, ул чакта малай гына идем шул әле. Ә фамилиясе Жеребцов... Тәгаен Жеребцов. — Моны, басым ясап, ул кабатлап әйтте.

Без аның белән урамда, «Дуслык» паркы янында саубуллаштык. Ул әле суынырга да өлгермәгән атына менеп атланды да чаптырып китте. Күперне чыгып, Керулин үзәнендә күздән югалганчы, мин аның артыннан карап калдым.

Һәммәсе моның гаҗәеп бер төш кебек иде.

...Самолет зәңгәр биеклеккә ыргылды. Яшел дала аэродромы уртасында артыбыздан кул болгап калган Намхай кечерәйгәннән-кечерәя барды. Күңелемнән аңа соңгы тапкыр саубуллашу сәламе җибәрдем дә кабат таныш үзәнгә карадым. Мин диңгез ярларына охшап баскан сопкаларны, кыр казларыдай тезелеп югары менеп барган дөя кәрваннарын күрдем. Күземә үзән уртасындагы ак киез тирмәләр, сизелер-сизелмәс кенә күккә үрелгән зәңгәр төтен бөдрәләре чалынды. Димәк, учакларда иртәнге ашлар пешә. Ә яшел хәтфә өстенә бихисап мал көтүләре сибелгән, җитез юргалар чабышып уйнап йөриләр. Шуннан бераз сулдарак, уентыкланып сопкаларга кереп торган иңкүлектә — җимерек дотлар, дзотлар... Хәрабәләр. Орудиеләр үткән юлларны нечкә, нәфис дала үләне каплаган. Аларны тибрәндереп моңсу җылы җил исә... Җил... Дала солдатларының истәлеген озак елларга сакларга тырышкандай, ул окопларны, землянкаларны акрынлык белән комга күмә....

Һавадагы җилпенеп-җилпенеп киткән бер шәүлә кул изәү булып хәтеремә сеңә. Беләм, сайрар кош ул. Җимерек саман стена янында аның оясы бар. Анда, кабык ярып, яңа тормыш борынлый...

Әбрар Кәримуллин

# ТАТАР ТИПОГРАФИЯЛӘРЕ ТАРИХЫННАН

*«Матбагаи Шәрәф», «Үрнәк», «В. Е. Казаков», «Мәгариф» типографияләре*

Татарда басма китап тарихы шактый озын һәм гыйбрәтле. Әлеге мәкаләдә без бу тарихның кечкенә бер сәхифәсенә — 1905 елгы рус революциясеннән соң Казанда ачылган «Матбагаи Шәрәф» һәм аның дәвамнары — «Үрнәк», «В. Е. Казаков», «Мәгариф» басмаханәләре тарихына гына күз салып үтәргә уйлыйбыз.

Мәгълүм булганча, патша хөкүмәтенең 1905 ел, 17 октябрь Манифесты Россиядә яшәүче барлык милләтләргә «матбугат иреге» «бүләк» итә: һәрбер милләт үз телендә газета-журнал чыгару, типографияләр ачу, нәширлек ширкәтләре төзү, китап тарату буенча махсус китапханәләр оештыру хокукын ала. Ләкин гамәлдә «матбугат иреге»ннән файдалану алай җиңел генә булмый. Патша цензурасы, жандармнар идарәсе һәм урындагы властьлар һәр очракта бу эшкә аяк чалырга тырышалар. Рустан кала милләтләргә карата бу аяк чалу политикасы аерата бер эзлеклелек белән алып барыла. Моны без татарлар өчен газета-журналлар чыгару, типографияләр ачу мисалында бигрәк тә ачык күрәбез.

Манифест игълан ителгәннән соң күп тә үтми, 1905 елның 4 ноябренда, Гыйльми Шәрәф (Гыйльметдин Шәрәфетдин улы Шәрәфетдинов), типография ачуга рәсми рөхсәт сорап, Казан губернаторы исеменә прошение белән мөрәҗәгать итә [1]. Бер уйлаганда, рөхсәт бик тиз алынырга тиеш иде кебек. Ләкин бу рөхсәтне бер елга якын көтәргә туры килә. Иң элек Казан жандармнар идарәсе Гыйльми Шәрәф турында яшерен мәгълүматлар җыярга керешә. Моның өчен Г. Шәрәф кайчандыр яшәгән яки эшләгән урыннардагы властьлар белән яшерен хәбәрләшү башлана. Мәсәлән, Тәтеш өяз исправнигыннан [2] (Г. Шәрәф шул өязнең Кыр Аксуы дигән авылында туган), Санкт-Петербург градоначальнигыннан, Оренбург жандармнар идарәсеннән Г. Шәрәфкә характеристикалар соратып алына. Хәтта Казандагы рус газетасы «Волжский вестник» редакциясе дә аңа язма характеристика бирергә мәҗбүр була. (1906 елның җәендә Г. Шәрәф бу газета редакциясендә аз гына вакыт эшләп чыккан була.)

Айлар буе көтеп-көтеп тә нәтиҗә чыкмагач, Г. Шәрәф 1906 елның 26 апрелендә, үзенең бертуган энесе Борһан Шәрәф белән берлектә, Казан губернаторы исеменә кабат прошение язып җибәрә [3]. Ниһаять, 1906 елның августында гына алар типографияне ачу турында рәсми рөхсәт кәгазе алалар.

Типография 1906 елның 1 ноябрендә В. Е. Казаков йортындагы «Болгар» номерларында ачыла [4]. Аның рәсми хуҗасы итеп Гыйльми Шәрәф билгеләнә, ә Борһан

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, фонд 1, дело 1688, лист I (Алда ЦГА ТАССР дип күрсәтелгән),
[2] ЦГА ТАССР, фонд 1, опись 4, д. 1688, л. 11.
[3] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 1997, л. 1.
[4] Шунда ук, ф. 1, оп. 4, д. 1688, л. 18.

белән Шәһәретдин Шәрәфләр пайчылар сыйфатында идарә составына кертеләләр. Типографиянең оешу тарихын һәм эшчәнлеген якыннан белгән кайбер замандашларның, аерым алганда, татар басмаханәләре тарихчысы Ш. Әхмәрнең раславына карагында[1], бертуган Шәрәфләрдән тыш, бу типографияне оештыруда башка кешеләрнең дә азмы-күпме ярдәме булган булырга тиеш.

Әйткәнебезчә, типография Г. Шәрәф исеменә ачылып, аның эше өчен бөтен җаваплылык та, беренче чиратта, аның өстенә төшкән.

Типография 1906 елның ике ае эчендә генә дә 37 280 данә гомуми тираж белән 13 исемдә китап чыгарып өлгерә. Анда басылып чыккан беренче китап — Мәҗит Гафуриның «Яшь гомерем» дигән шигырьләр җыентыгы (тиражы — 2300 данә). Шунысы игътибарга лаек: бу җыентыкның 1908 елда чыккан икенче басмасына 1914 елда Матбугат идарәсе тарафыннан арест салына[2].

Г. Шәрәф типографиясендә басылып чыккан икенче китап «Франция революциясе» дип атала (тиражы — 2000 данә). Бу — тәрҗемә әйбер. Хәзергә кадәр китапның бер генә нөсхәсе дә табылмаганлыктан, аның авторы һәм тәрҗемәчесе турында әлегә берниндн дә мәгълүмат биреп булмый, әмма китапның басылып чыкканлыгында һичбер шик булуы мөмкин түгел, чөнки ул архив материалларында ачыктан-ачык телгә алына[3], шулай ук «1906 елда Россиядә басылып чыккан китаплар исемлеге»ндә дә китерелә (СПБ. 1908. Теркәлү номеры 18 244).

«Матбагаи Шәрәф»тә басылып чыккан беренче китаплар арасында шулай ук «Мөселман сайлаучыларына хитаб», «Авыл халкына хитаб» кебек мөрәҗәгать тибындагы брошюралар да бар. Болары, күрәсең, урындагы социал-демократлар оешмасының турыдан-туры катнашы белән дөнья күргәннәрдер дигән фикер кала. Һәрхәлдә, Г. Шәрәф типографиясендә революцион эчтәлектәге шундый китапларның күпләп басылып чыгуы игътибарга лаек факт.

1907 елда инде бу типографиядә 52 китап, 1908 елның беренче яртысында 41 татар китабы дөнья күрә.

1908 елның урталарында Казан губернаторының махсус карары белән типографияне ябалар. Сәбәбе — казакъ телендә басылып чыккан «Фәрьядлар» дигән шигырьләр җыентыгы. Казандагы матбугат эшләре буенча вакытлы комитет председателе М. Пинегин бу китапны, «патша хәзрәтләре шәхесеннән көлә, халыкны рус хакимлегенә каршы котырта, баш күтәрергә өнди»[4], дип бәяли.

Бу, әлбәттә, Шәрәфләр типографиясен яптыру өчен бер сылтау гына була. Ул еллардагы матбугат турындагы закон буенча, революцион эчтәлекле яки самодержавиене тәнкыйтьләгән китаплар бастырып чыгарган өчен типография үзе түгел, ә бу китапны үз хисабына басарга әзерләүче нашир яки нашир белән автор икесе җавап бирергә тиеш иде. «Фәрьядлар» җыентыгы «Пржевальский исемендәге татар-кыргыз җәмгыяте» акчасы исәбенә Сабир Фәхретдин улы Габделмәнов дигән кеше заказы белән басыла; моның өчен аны җавапка тартып, бер айга төрмәгә ябылуга хөкем итәләр, ә җыентык үзе властьлар тарафыннан юкка чыгарыла[5]. «Матбагаи Шәрәф»не ябу исә Казан губернаторының үз ирке белән, законнан тыш эшләнә. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, әлбәттә, татар матбугаты XIX гасырның буеннан-буена законнан тыш саналып килгән,— әлеге фактны да шуның бер чагылышы гына диярге мөмкин. Гомумән, патша хөкүмәтенең татар матбугатына карашы XIX йөздә ничек булса, ул XX йөз башында һәм 1905 елгы буржуаз революциядән соң да үзгәрмичә шул килеш кала.

Дөрес, Казан губернаторы типографияне ябу өчен үзенчә «дәлил» дә эзләп маташкан. «Типография хуҗасы Гыйльметдин Шәрәфнең ышанычсызлыгы хакында соңгы вакытларда миңа еш кына хәбәрләр ишетелә башлады»,— дип «дәлилли» ул үзенең карарын һәм типографиянең яшәве «дәүләт тәртипләренә һәм җәмгыятьтәге иминлеккә һичшиксез зарар китерә»[6] дигән нәтиҗә чыгара. Монда шулай ук типо-

---

[1] Ш. Әхмәр. Матбагачылык тарихы. Казан, 1909, 67 бит.
[2] СССР Үзәк дәүләт тарих архивы (Ленинградта), ф. 776, оп. 27, 1912 ел, д. 248, л. 6. (Алда ЦГИАЛ дип кенә күрсәтеләчәк.)
[3] ЦГИАЛ, ф. 777, оп. 27, д. 537.
[4] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 3764, л. 1.
[5] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 124, л. 5.
[6] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 1688, лл. 41—46.

графиянең татар социал-демократлары белән тыгыз элемтәсе һәм шушы ук типографиядә «Казан мөхбире» газетасының басылып килүе дә күпмедер дәрәҗәдә үз ролен уйнаган дип уйларга мөмкин. Һәрхәлдә, боларның берсе дә жандармерия күзеннән читтә калмаган, билгеле.

Г. Шәрәф үзе дә типография өстенә күтәрелгән болытларны алдан ук сизеп алган булса кирәк. 1908 елның 7 маенда ул, типографиянең мөдире вазифасына вакытлыча Владимир Емельянович Казаковны раслауны сорап, губернаторга үтенеч белән керә. Губернатор аның үтенечен кире кага. 23 майда Г. Шәрәф тагын шундый ук үтенеч белән мөрәҗәгать итә: монысында мөдирлеккә Ибраһим Мөхәммәтшакир улы Шакировны тәкъдим итә. Губернатор бу соңгы тәкъдимгә рөхсәтен бирә, ләкин шуның артыннан ук, 25 июньдә, типографияне бөтенләй ябу турындагы карарга үзенең имзасын куя. 30 июньдә инде полицейскийлар килеп, типографиягә арест салалар.

Бер ай чамасы вакыт үткәч, Гыйльми Шәрәф типографияне яңадан ачарга рөхсәт бирүләрен үтенеп тагын гаризалар яза башлый [1]. Типография җиһазлары өчен кредиторлар алдында бурычлары күплеген, ул бурычларны каплау өчен типографиянең эшләве кирәклеген дәлил итеп куя. Ләкин губернаторга бу дәлилләрнең берсе дә тәэсир итми. Шуннан соң Шәрәф икенче төрле юллар эзләргә керешә: Галимирза Саинов дигән бер кеше белән сөйләшеп, аңа типографияне «сатуы» турында 1908 елның 30 октябрь числосы белән губернаторга язма хәбәрен ирештерә [2].

Шунысы кызык: бу вакытта инде Г. Ю. Саиновның кулында типография ачу турында губернатордан алынган рөхсәт кәгазе була (1908 ел, 28 октябрь числосы белән). Г. Шәрәф хәбәре эзеннән үк ул да губернаторга типография ачу өчен үзенең Г. Шәрәфтән җиһазлар сатып алуы турындагы гаризасын җибәрә. Шулай итеп, типографиядән арест алынып, ул Г. Саинов кулына күчә.

Типографиянең Г. Ю. Саинов кул астында һәм яңа шартлардагы эшен тикшерүгә керешкәнче, кире кайтып, аның Г. Шәрәф җитәкчелек иткән чорындагы эше рәсми органнарда ни өчен шундый ачу уятуының сәбәпләрен анығрак билгеләргә тырышып карыйк. Типографиядә 1907—1908 елларда басылып чыккан китап продукциясе бу мәсьәләгә шактый зур ачыклык кертә дип уйлыйбыз.

Мәсәлән, 1907 елда монда, «Мәгариф» китапханәсе заказы белән, «Авыл халкына җирне ничек итеп үз кулларына алырга» дигән брошюра басылып чыга (авторның псевдонимы — «М-лов», тәрҗемәчеләре А. Газакаев һәм Б. Юскаев). Брошюра пролетариатның буржуазиягә һәм помещикларга каршы көрәшен аңлатуга багышланган, бу көрәштә пролетариат белән крестьян сыйныфының үзара дуслыгы, союзы хакында сүз бара, шул союздан тыш крестьяннарга җир элекмәячәге әйтелә. Дүрт елдан соң бу китапка арест салына [3].

Шул ук елны «Матбагаи Шәрәф»тә Г. Тукайның «Шигырьләр», М. Гафуриның «Милләт мәхәббәте» дигән җыентыклары дөнья күрә; бу җыентыклар да цензура эзәрлекләвенә дучар булалар [4]. Шундый ук язмышка бу типографиядә басылган башка китаплар да очрый: «Төрле-төрле шәп җырлар» дигән халык җырлары җыентыгы (1902 елгы басма) [5]; шәкертләр поэзиясен һәм җырларын үз эченә алган «Шәкертләр садасы» (1907 елгы басма) [6]; Т. Богдановның «Германиядә сайлау көне» (тәрҗемәчесе күрсәтелмәгән); казакъ авторы Йосыф Куфаевның «Сары-Арка әүвәл кем кулында булган?» дигән китабы; З. Бәширинең «Милләт кайгысы»; Н. Думавиның «Шигырьләр» исемле шигъри җыентыклары һ. б. [7]. Гыйльми Шәрәф типографиясендә барлыгы 106 китап нәшер ителә, шуларның егермегә якыны патша цензурасы тарафыннан эзәрлекләүгә яки конфискациягә эләгә. Бу хәл губерна властьларын борчымый калмаган, билгеле.

Моның өстенә, «Матбагаи Шәрәф»тә бу елларда «Казан мөхбире» газетасы да даими басыла килә. Мәгълүм ки, бу газетаның рәсми редакторы булып шәһәр думасы

---

[1] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 1688, лл. 41—46

[2] Шунда ук.

[3] ЦГИАЛ, ф. 776, оп. 21, ч. 2, д. 210, 1911, лл. 2—8; ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 172, л. 3; д. 192, лл. 14—15.

[4] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань, 1964. Х. Х. Хасанов. Габдулла Тукай и царская цензура. В кн.: Габдулла Тукай (Сборник статей о поэте). Казань, 1968, стр. 209—215; Қ. Нәҗми, Мәҗит Гафури һәм патша цензурасы.— «Совет әдәбияты», 1934, № 11, 78—80 битләр.

[5] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 107, л. 2. ЦГИАЛ, ф. 776, оп. 21, ч. 2, д. 1, ч, 2, 1911 ел, л, 14,

[6] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 91, л. 59—61.

[7] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 91, л. 58; д. 92, лл. 59—61,

гласные, Казан учительская школасы попечителе юрист Сәетгәрәй Алкин саналса да[1], асылда аны чыгару эше тулысы белән диярлек Гыйльми Шәрәфнең энесе Борһан Шәрәфкә йөкләнгән була. Вакыт-вакыт аның бу газетада рәсми редактор вазифасын үтәве дә билгеле[2]. Кагыйдә буларак, С. Алкин катнашы белән газетада бары либераль буржуазия карашын чагылдырган мәкаләләр генә дөнья күргән, ә революцион-демократик идеяләрне пропагандалаган материаллар һәм эшче-хәбәрчеләрнең корреспонденцияләре[3] күп очракта Борһан Шәрәф кулы аша үткән. Шундый революцион эчтәлектәге мәкаләләр өчен газетаның рәсми редакторы С. Алкинны берничә мәртәбә җавапка тартып, редакторлыгыннан да мәхрүм итеп карыйлар. Ләкин Алкинның авторитеты һәм җәмгыятьтәге югары урыны властьларны һәр очракта чигенергә мәҗбүр итә. Шуның өстенә ул, юрист буларак, газетаны тыюның законга сыймаганлыгын суд аша да исбатлый алган, билгеле[4].

Әлбәттә, цензура, жандармерия С. Алкинның номиналь, ә Б. Шәрәфнең фактик редактор булуын яхшы белгәннәр, шуңа күрә алар типографияне эзәрлекләү белән бергә, анда басылып таратылган «Казан мөхбире» газетасын да эзәрлекләүгә юл эзләгәннәр.

«Матбагаи Шәрәф»не ябу шулай ук бу типографиядә 1907 елның 10 декабреннан басыла башлаган «Әхбәр»[5] газетасы (наширләре — Борһан Шәрәф белән Харис Фәйзи) һәм «Тәрбия»[6] журналының (нашире — революционер Мулланур Вахитовның абзасы Исхак Казаков) чыгудан туктавына сәбәп була. «Тәрбия» журналының, мәсәлән, нибары дүрт саны чыгып кала.

Күренгәнчә, Казан губернаторының типографияне ябтыру өчен бик җитди «сәбәпләре» булган икән.

«Матбагаи Шәрәф»нең эшчәнлегендә игътибарга лаек тагын бер нәрсәне күрсәтеп үтәргә кирәк: бөтен яшәве дәверендә монда нибары биш исемдә генә дини китап басыла (алар арасында бер генә Коръән дә, һәфтияк тә юк). Типографиянең төп китап продукциясен матур әдәбият һәм фәнни-популяр әсәрләр тәшкил иткән. Югарыда әйтелгәннәрдән тыш, монда Закир Һадиның «Яңа әсхабе кәһаф» повесте, Г. Чыгтайның «Мәче һәм төлке» исемендә хикәяләр җыентыгы, «Шигырьләр мәҗмугасы» сериясендә рус шагыйрьләренең «XX гасыр кояшы» дигән җыентыгы (Мирсаяф Кәримбаев тәрҗемәсе) һ. б. дөнья күрә. Тукай белән Гафуриның гына да җиде китабы шушы типографиядә басылып чыга (беренчесенеке — өч, икенчесенеке дүрт тапкыр). Типографиянең даими заказчылары булып «Мәгариф», «Сабах», «Хезмәт» (Троицк шәһәреннән) һәм башка шундый күренекле нәшриятлар һәм китапханәләр саналган. Китап продукциясенең яртысына якыны нәкъ менә шул нәшрият һәм китапханәләрнең заказы белән басылган. Алар арасында Закир Һади, Ф. Кәрими, Акмулла кебек татар язучыларының әдәби әсәрләре, тәрҗемәләр (мәсәлән, Конан Дойльнең Шерлок Холмс турындагы хикәяләре, төрек язучысы Әхмәт Мидхәт әсәрләре), сәяхәтнамәләр, библиографик белешмәләр, фольклор җыентыклары, тел белеменә, медицинага караган фәнни-популяр китаплар һәм башкалар бар.

Ш. Әхмәр әле 1909 елда ук бу типография турында болай дип язып китә: «Яшь борадәран Шәрәфләр вә иптәшләре тарафыннан ачылган бу матбага татар матбагалары арасында узене тиз күрсәтергә муафыйк булды. Матбагаларымызның иң кирәкле вакытында эшкә башлап, кыска гына вакытта узләренең матбагасында басылып чыккан нәрсәләрене һәр йирдә күрергә мөмкин, һәр йирдә исемене ишетдерү дәрәҗәсенә китерделәр. Матбагаларында басылган нәрсәләр гомум халыкның соңгы теләвенә муафыйк яңа әдәбият улып, яңа китаплар күбрәк алар матбагасында басылып чыга башлады»[7].

Шулай итеп, 1908 елның көзендә «Матбагаи Шәрәф» рәсми «яшәүдән» туктап, Саинов кулына күчә. Яңа хуҗада ул башта «Саинов матбагасы» дип йөртелеп, тиздән

---

[1] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 217, лл. 19—20.
[2] Шунда ук, л. 15.
[3] М. Гайнуллин, Татарская литература и публицистика начала XX века, Казань, 1966, стр. 24—31.
[4] ЦГА ТАССР, ф. 420, д. 4, лл. 17—19.
[5] ЦГА ТАССР, ф. 420, л. 11.
[6] Шунда ук, л. 67.
[7] Ш. Әхмәр, Матбагачылык тарихы, Казан, 1909, 67—68 битләр.

«Үрнәк» дигән исем ала. 1908 елның ноябреннән 1911 елның январь аена кадәр, ягъни ике ел эчендә, «Үрнәк» типографиясендә 480 мең 665 нөсхә гомуми тираж белән барлыгы 152 исемдә китап басылып чыга. Шуларның 79 исемдәгесе — матур әдәбият (оригинал һәм тәрҗемә әсәрләр, фольклор җыентыклары), уникесе — дин китаплары (Ш. Хөсәеновның китап ширкәте заказы буенча басылганнар), калганнары — төрле уку әсбаплары, дәреслекләр, фәнни-популяр китаплар, календарьлар һ. б. Матур әдәбият әсәрләреннән монда Г. Тукайның тугыз җыентыгы, Фатих Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык», «Фәтхулла хәзрәт», «Татар кызы» кебек хикәя, повестьлары, «Яшьләр» исемле драмасы, Г. Камалның «Бүләк өчен», «Күгәргән алтыннар» дигән комедияләре, М. Гафури, Н. Думави, М. Укмасыйларның яңа шигырь җыентыклары дөнья күрә. Тәрҗемә китаплар да шактый күп. Мәсәлән, шундыйлардан: А. Пушкинның «Таш кунак» («Каменный гость»), «Алеко, яки чегәннәр» («Цыгане») поэмаларын, Л. Толстойның «Өч сәаль» (Три вопроса»), «Җиләкләр», «Асурия падишаһы Асархадун» («Ассирийский царь Асархадун»), М. Горькийның «Ике сукбай» («Два мужика»), Н. Гогольнең «Борын» («Нос»), Л. Андреевның «Асылган җиде кеше хикәяте» («Повесть о семи повешенных») дигән хикәяләрен күрсәтергә мөмкин. Чит ил язучыларыннан да тәрҗемәләр бар (Д. Дефоның «Робинзон Крузо»сы, мәсәлән, берничә тапкыр кабат басылып чыга). Фәнни-популяр әсәрләргә мисал итеп рус мәгърифәтчесе Н. Рубакинны «Мәхлукатта зур вә куркынычлы хикмәтләрнең заһир булу вакыйгалары» («Грозные силы природы») дигән китабын алырга мөмкин.

«Үрнәк» типографиясендә басылып чыккан китапларның да яртысына якыны «Үрнәк»нең үз хисабына нәшер ителгән. Калганы — чит заказлар. Чит заказлардан «Мәгариф» китапханәсе 17 китап, «Сабах» — 5, «Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм ширакәсе» — 11 китап бастыра; «Хезмәт», «Шәрык», «Уку», «Гаилә», «Милләт» кебек нәшриятлар һәрберсе 2—3 әр исемдә китап нәшер итеп чыгаралар. Болардан башка аерым наширләрнең (Гатаулла Курсави, Габделхаликъ Курсави, Мәрфуга Чокрый, Х. Әбүзәрев, Әхмәт Исхаков һ. б.) заказлары буенча да китаплар басылып чыга.

Күренгәнчә, иҗтимагый шартларның үзгәрүе (революцион хәрәкәтнең бастырылуы, реакциянең баш күтәрә башлавы, надзорның көчәюе) аркасында, ачыктан-ачык революцион, социаль-демократик эчтәлекле әдәбиятны бастырып чыгару бөтенләй кыенлаша. Ләкин шулай булса да «Үрнәк» басмаханәсе үзенең элеккеге демократик юнәлешеннән читкә тайпылмый, легаль мөмкинлекләрдән файдаланып, укучыларны татар, рус һәм чит ил әдәбиятларының иң яхшы үрнәкләре белән даими таныштыра бара, фәнни-популяр әсәрләр бастырып чыгаруга зур әһәмият бирә. Арада, әлбәттә, революцион рухтагы әсәрләр дә булмый калмый. Бу чорда «Үрнәк» типографиясе бастырып чыгарган кайбер китапларның соңыннан патша властьлары тарафыннан эзәрлекләнүе нәкъ менә шул турыда сөйли. Мәсәлән, «Төрле-төрле шәп җырлар» исемле фольклор җыентыгы өчен Гыйльми Шәрәф белән «Үрнәк» типографиясенең рәсми хуҗасы Саиновны 1911 елда хөкем җаваплылыгына тартмакчы булалар. Матбугат эшләре буенча вакытлы комитет Казан хөкем палатасы прокурорына җибәргән шикаять хатында ифрат зарарлы җырлар сыйфатында әлеге җыентыктан түбәндәге юлларны мисалга китерә:

**Уян, шәкерт, йокламагыл,**
**Йер өстенә тырмамагыл.**
**Чәчәк, орлык — ул яшәсен,**
**Карда, җирдә аунамагыл.**

**...Кирәк безгә яңа фөнүн,**
**Яхшы тәртип, тугры канун.**
**Бетсен иске шаламалар,**
**Корыйк гүзәл яңа тормыш.**

**Шәкерт йөрер безнең гыйнуан,**
**Һәр беремез бер арыслан.**
**Корал кулда, телдә һаман,**
**Хәзер тора, килсә дошман...**

Комитетның шикаять хатында язылганча, бу җырлар «дошман белән сүз (тел коралы) ярдәмендә генә түгел, туры мәгънәсендә корал тотып көрәшергә өндиләр...»[1].

Нәтиҗәдә, әлеге җыентыкка Казан округ суды тарафыннан арест салына, ә Г. Шәрәф белән Г. Саиновны «Уголовное уложение»нең 129 статьясы, 6 нчы пункты нигезендә хөкем җаваплылыгына тартырга ниятлиләр[2].

Дөрес, бу эш шулай кәгазьдә генә торып кала (бу вакытта инде «Үрнәк» типографиясен япкан булалар). Ләкин губернатор һәм жандарм властьлары, хөкем белән куркытып, икенче бер максатка да ирешмәкче булалар: Г. Шәрәф белән Г. Саинов шушы хәлләрдән соң яңадан типография ачу турында сүз кузгатып маташмаслар яки сүз кузгатсалар да, аларның үтенечен кире кагу җиңелрәк булыр дип уйлыйлар. Чыннан да, озак та үтми, губернатор типографиядән арестны кире алуны сорап язган Г. Саинов үтенечен бөтенләй җавапсыз калдыра[3].

Монда игътибарга лаек тагы бер нәрсә бар: властьлар «Үрнәк» типографиясенең чын хуҗасы Г. Саинов түгел, Г. Шәрәф икәнлеген алдан ук сизенәләр. Казан губернаторы боерыгы буенча «Үрнәк» типографиясенең эшен тикшергән чиновник Якимов 1911 елның 13 январенда губернаторга биргән җавап рапортында Саиновны турыдан-туры «ялган хуҗа» дип атый һәм типографиянең чын хуҗасы Г. Шәрәф икәнлеген күрсәтә[4]. Г. Шәрәфнең әүвәлге «зарарлы эшләрен» искәртеп үткәннән соң (сүз «Фәрьядлар» җыентыгын бастырып чыгару турында бара), И. Якимов болай дип дәвам итә: «Бу документ нигезендә, ди, крестьянин Шәрәф типография эшенә бөтенләй катнашмыйдыр дип уйларга мөмкин иде. Әмма чынлыкта Шәрәф типографиянең тулы хокуклы идарәчесе булып тора»[5]. Аннары чиновник губернаторның бу хәлдән нинди нәтиҗәләр чыгарырга тиешлеген күрсәтеп үтә: «Типографияләр турындагы закон һәм кагыйдәләрне күрәләтә бозганы өчен бу очракта Шәрәф белән Саиновны җавапка тарту зарур булыр иде»[6],— ди. Әгәр монда законны чыннан да бозу булса, властьлар моңардан файдаланмый калмаган булырлар иде, билгеле. Ләкин хикмәт шунда, властьлар кулында Г. Шәрәф белән Г. Саиновка каршы хөкем эше кузгатырлык бернинди дә ачык дәлил булмый. Шулай да алар типографияне ябу өчен «сәбәп» уйлап табалар. 1911 елның 18 январенда губернатор имзасы белән карар игълан ителә. «Типографиянең эшен дәвам итүе җәмгыять иминлегенә һәм дәүләт тәртипләренә зарарлы»,— диелә бу карарда, һәм шуның нигезендә 1911 елның 5 февралендә типографиягә арест салына[7]. Төп «сәбәп» итеп әлеге дә баягы фольклор җыентыгы алына.

Шулай итеп, Г. Шәрәф алдына тагын типографияне «коткару» бурычы килеп баса. Рәсми хуҗа Г. Саинов үзе, типографиягә арест салынганнан соң, аны яңадан ачу турында артык кайгыртып маташмый, тора-бара бу эшләрдән бөтенләй читләшә. Г. Шәрәф тә үз исеменнән бу мәсьәләне күтәрергә базмый, чөнки тәҗрибә нигезендә моңардан берни чыкмаслыгын алдан ук сизенә. Монда тагы нинди дә булса хәйлә табарга кирәк була. Ниһаять, ул моның юлын таба!

1911 елның 21 мартында Владимир Емельянович Казаков (типография шушы кешенең йортында урнашкан була) губернатордан типография ачу турында таныклама алып[8], шул ук елның 26 апрелендә губернатордан раслату өчен типографиядә эшләргә тиешле эшчеләрнең исемлеген тәкъдим итә[9].

---

[1] ЦГИАЛ, ф. 776, оп. 21, ч. 2, д. 259, 1912 ел, л. 2.
[2] Шунда ук, лл. 5—10.
[3] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 3771, лл. 19—21.
[4] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 3771, л. 10.
[5] Шунда ук, л. 10.
[6] Шунда ук, лл. 10—11.
[7] Шунда ук, л. 12.
[8] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, лл. 2, 9.
[9] Бу исемлеккә түбәндәге кешеләр кертелгән.
1) Ибраһим Мөхәммәтшакиров — хәреф җыючы, типографиядә эшләү хокукы булуы турында рәсми билеты бар (1906 елның 22/XI да бирелгән),
2) Исхак Ибраһимов — печатник, билетсыз.
3) Йосыф Шакир улы Серебряков — хәреф җыючы, билетлы (29/II-1908 дә бирелгән).
4) Сабир Мөхәммәтҗан улы Моратов — хәреф җыючы, билетсыз.
5) Абдулла Галиулла улы Миндубаев — хәреф җыючы, билетсыз,
6) Абдулла Гыйләҗетдинов — хәреф җыючы өйрәнчеге.
7) Галиулла Вәлиулла улы Гобәйдуллин — печатник, билетсыз.
8) Константин Васильевич Суворов — печатник, билетсыз, (Кара: ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, л. 10.)

Губернатор, күрәсең, рус кешесенең татар наширләре белән элемтәсе булыр дип һич башына китермәгәндер, һәрхәлдә, ул Казаковның «Үрнәк» типографиясен үзенә сатып алуына ризалыгын биргән [1].

Ләкин типография яңа хуҗа кулы астында бер ай да эшләп өлгерми, Казан жандармнар идарәсеннән губернатор исеменә тагын яшерен хат килеп төшә. 1911 елның 26 май числосы, 456 нчы номер белән теркәлгән бу хатта шундый юллар бар: «Минем карамактагы Идарә исеменә мәгълүматлар керде; формаль рәвештә тикшерелмәгән бу мәгълүматлар буенча, яңа ачылган һәм «Мәгариф» кетепханәсенә хезмәт күрсәтә торган «Үрнәк» типографиясе, гәрчә бүтән кешегә, рус кешесенә сатылган булып исәпләнсә дә, чынлыкта Гыйметдин (?) Шәрәфов кулы астында эшләвен дәвам итә...» [2]. Бер атнадан соң, 3 июньдә, жандармнар идарәсе начальнигы әлеге хатка «өстәмә» итеп тагы бер донесение җибәрә һәм анда «Үрнәк» типографиясенең Казаков тарафыннан сатып алынуы фиктив нәрсә генә булганлыгын искәртеп [3], аның чын хуҗасы Г. Шәрәф икәнлеген янә кабатлый һәм аны, типографияне, тизрәк ябу кирәклеге турында сүз кузгата. Хәлбуки, типографияне сату-алу закон куйган таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән була (бу хакта властьлар тарафыннан расланган рәсми договор бар [4]). Моны губернаторның кушуы буенча тикшерү үткәргән чиновник Якимов та раслый. Ләкин бу чиновник шул ук вакытта типографиянең чын хуҗасы Г. Шәрәф икәнлеген тагын бер мәртәбә искә төшереп уза [5].

Шулай итеп, губернатор, кулында бернинди фактик мәгълүматлар булмавына карамастан, жандармнар идарәсенең таләбенә буйсынып һәм тикшерүче Якимовның әлеге рапортына нигезләнеп, типографияне ябарга кирәк дигән нәтиҗәгә килә һәм 1911 елның 26 июнендә шушы хакта язма боерык бирә.

Типографияне шулай өч тапкыр ябуының һәркайсында да губернатор законнар җыелмасының 1890 елгы XIV томында теркәлгән мәгълүм положениегә нигезләнеп эш итә. Ә чынлыкта бу положение 1905 елгы 17 октябрь Манифесты белән бөтенләй гамәлдән чыккан саналырга тиеш була.

Ай-ай ярым эшләү дәверендә В. Е. Казаков типографиясе татар телендә 14 исемдә китап бастырып чыгара (гомуми тиражы — 49 500 данә). Алар арасында С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә Байронның «Мәхбүс» («Шильон тоткыны») поэмасын, З. Бәшири, Н. Хәлфин һәм башка татар язучыларының әсәрләрен күрергә мөмкин.

Гомумән, Шәрәфләр типографиясенең бөтен яшәве дәверендә анда 868 мең 210 данә гомуми тираж белән 272 исемдә татар китабы басылып чыга (бу исәпкә рус телендә басылган китаплар керми; алары турында махсус тикшерү кирәк). Бу яктан Г. Шәрәфләр типографиясе, Кәримовлар типографиясеннән кала, ул заманда иң зур татар басмаханәсе саналырга хаклы.

Бу типографиянең төп фигурасы, оештыручысы, эшен юлга салучысы Гыйльми Шәрәф икәнлеген әйтеп киткән идек инде. 1906 елда, ягъни типография ачарга рөхсәт алганда, аңа нибары егерме бер яшь кенә була әле. Ләкин, шундый яшь булуына карамастан, ул типография эшендә инде ярыйсы ук тәҗрибә туплаган, китап басу машиналарын яхшы белгән кеше була. Китап басу эшенә ул 1903—1904 елларда Петербургта, шәрык типографияләренең иң күренеклеләреннән булган Ильяс Бороганский типографиясендә өйрәнә. 1905 елгы рус революциясен дә шунда, Петербургта каршылый. Революция аның карашларына зур йогынты ясаган булса кирәк. Һәрхәлдә, озак та үтми, ул, туган якларына кайтып, үзенең көч-энергиясен татарлар арасында китап бастырып тарату эшенә багышлый. Башта Оренбургтагы Мөхәммәт-Фатих Кәримовның типографиясенә эшкә урнашып, анда хәреф җыючы, корректор һәм конторщик булып хезмәт итә, аннары, Казандагы либераль рус газетасы «Волжский вестник» редакциясендә кыска гына вакыт эшләп алганнан соң, 1906 елда, ниһаять, үзе типография ачып җибәрә. Үз профессиясен яхшы белүче һәм сәләтле оештыручы буларак, ул бу типографиянең эшен бик тиз юлга сала һәм озак та үтми, аны Казанның иң күренекле басмаханәләре дәрәҗәсенә күтәрә.

---

[1] Казаков губернаторга типографиянең җиһазы турында да тулы исемлек бирә; анда 163 исемдә төрле җиһазлар санап үтелә. (Кара: ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, лл. 11—15.)
[2] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, л. 13.
[3] Шунда ук, л. 14.
[4] Шунда ук, л. 17.
[5] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, л. 20.

Әлбәттә, бу эштә Г. Шәрәф ялгыз булмаган. Аңа күпмедер дәрәҗәдә туганнарыннан Шәһәретдин белән Борһан Шәрәфләр һәм кайбер башка кешеләр дә булышкан. Кемнәр соң ул башка кешеләр дигәне? Билгеле булганча, Борһан Шәрәф бервакыт «Мәгариф» китапханәсенең идарә составына керә, ә «Мәгариф» китапханәсе, үз нәүбәтендә, Галиәсгар Камал оештырган китап нәшриятының дәвамы булып, большевик Х. Ямашев һәм башка социал-демократлар[1] белән тыгыз элемтәдә тора. Беренче рус революциясе башлану белән «Мәгариф» китапханәсе киң күләмдә революцион һәм социал-демократик әдәбият тарату эшенә керешә[2], һәм, кагыйдә буларак, бу әдәбиятның күпчелек өлеше «Матбагаи Шәрәф»тә басылып чыга. Безнең уйлавыбызча, «Матбагаи Шәрәф» алдан ук нәкъ менә шул «Мәгариф» китапханәсенең база типографиясе буларак ачылган булырга тиеш. «Мәгариф» китапханәсенең заказы белән монда, мәсәлән, «Франция революциясе», «Авыл халкына җирне ничек итеп үз кулларына алырга» кебек революцион эчтәлекле китаплар нәшер ителә. Шундый әсәрләр өчен «Мәгариф» китапханәсе идарә членнарыннан Г. Камал, К. Мөхетдиновлар жандармнар идарәсендә аңлатма бирергә мәҗбүр булалар. «Авыл халкына...» брошюрасының тәрҗемәчеләреннән берсе — А. В. Газакаев исә (Г. Камалның кардәше) ниндидер билгесез кешеләр тарафыннан (янәсе, талау нияте белән) ерткычларча үтерелә[3].

Беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев һәм әдип-революционер Гафур Коләхметовның марксистик мәкаләләре урнаштырылган «Казан мөхбире» газетасының Г. Шәрәфләр типографиясендә басылуы да бу типографиянең, аерым алганда, аның идарә членнарыннан берсе булган Борһан Шәрәфнең Казандагы татар социал-демократлары белән элемтәсе турында сөйли. Шул ук вакытта Борһан Шәрәф, «Мәгариф» китапханәсенең идарәсенең члены буларак, типография белән китапханәнең бердәй юнәлештә эшләүләрен дә тәэмин иткән булса кирәк. Бу фактлар барысы да Г. Шәрәфләр типографиясенең «Мәгариф» китапханәсе инициативасы белән ачылган икәнлегенә ышанычлы дәлил була ала. Аның соңында, бораддәран Шәрәфләр үзләре исеменнән бастырып чыгарган китапларны сату эше белән шөгыльләнмәгәннәр, бу эшне дә шул ук «Мәгариф» китапханәсе башкарган[4]. Бу факт та безнең фикеребезне раслый.

Дөрес, «Мәгариф» китапханәсе үзенең барлык заказларын, шул исәптән социал-демократик юнәлештәге әдәбиятны да, бер «Матбагаи Шәрәф»тә генә бастырмаган, башка типографияләргә дә урнаштыргалаган. Моның, күрәсең, үз сәбәпләре бар. Шул рәвешчә, бәлкем «Мәгариф» китапханәсе үзенең «Матбагаи Шәрәф» белән турыдан-туры бәйләнешен властьлардан яшереп сакларга теләгәндер. Ләкин асылда бу Казан жандармнар идарәсе өчен сер булмый, билгеле[5].

Үз вакытында безнең әдәбиятта, бигрәк тә Г. Тукай иҗатына кагылышлы мәкалә, китапларда, Гыйльми Шәрәф Тукайны бик нык эксплуатацияләгән, аның иҗатын баю өчен файдаланган дигән бер караш яшәп килде. Бу караш, башлыча, Г. Кариевның шактый ук буталчык һәм дөреслеге бернинди факт белән дә расланмаган язма истәлекләренә нигезләнеп туган иде. Соңгы вакытларда табылган фактлар бу карашның ялгышлыгын күрсәтә. Китап белгече — библиограф Э. К. Сәгыйдова, шагыйрьнең үз хатлары һәм бүтән материаллар нигезендә, Тукай белән Г. Шәрәф арасындагы мөнәсәбәтләрнең бөтенләй икенче төрле булганлыгын исбатлый[6]. Сәгыйдованың нәтиҗәләре, күрүебезчә, «Матбагаи Шәрәф» һәм «Мәгариф» китапханәсе эшчәнлеге белән дә раслана.

Гыйльми Шәрәф һәм аның типографиясе халыкка аң-белем бирүдә, татарлар арасында алдынгы иҗтимагый-политик һәм революцион фикерләр таратуда күренекле роль уйнадылар. Аларның эшчәнлеге революциягә кадәрге татар басма китабы тарихының гүзәл бер сәхифәсен тәшкил итә.

---

[1] Р. И. Нафигов, Формирование и развитие передовой общественно-политической мысли, Казань, 1964, стр. 245.
[2] Шунда ук, 245—250 битләр.
[3] Шунда ук, 248—250 битләр.
[4] «Мәгариф» көтепханәсенең әсами көтебе, Казан, 1911, 8 бит; «Мәгариф» көтепханәсенең әсами көтебе, Казан, 1911, 16 бит; «Мәгариф» көтепханәсенең әсами көтебе, Казан, 1911, 26 бит.
[5] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 4, д. 4932, лл. 13—14.
[6] Э. Сәгыйдова, Тукай и «Магариф», «Дружба народов», 1967, № 8, стр. 245—246.

Шуны да әйтергә кирәк: Шәрәфләр типографиясенең властьлар тарафыннан бөтенләй ябылуы ул башлап һәм җәелдереп җибәргән китап басу эшен туктата алмаган. 1913 елда «Мәгариф» китапханәсе җитәкчеләреннән берсе Мөхәммәтәмин Мостафин ачкан «Мәгариф» типографиясен без В. Е. Казаков типографиясенең (ягъни «Матбагаи Шәрәфнең) турыдан-туры дәвамы итеп карый алабыз. Гыйльми Шәрәф үзе дә бу типографиянең эшендә якыннан торып катнашкан. М. Мостафин 1914 елның 3 маенда, Г. Шәрәфне «Мәгариф» типографиясенә рәсми җитәкче итеп куюны сорап, хәтта губернаторга үтенеч белән керә. Ләкин аның үтенечен, әлбәттә, кире кагалар.

«Мәгариф» типографиясендә 1913—1917 елларда барлыгы 147 исемдә татар китабы басылып чыга. Аларның гомуми тиражы 530 350 экз. 147 китапның 106 сы — «Мәгариф» китапханәсенең үз заказы белән басылган китаплар. Әлбәттә, Г. Шәрәф типографиясенең элекке чорлары белән чагыштырганда, «Мәгариф»тә басылып чыккан китаплар саны алай күп түгел. Моны беренче империалистик сугыш һәм Россиядә башланган реакция чоры белән аңлатырга кирәк. Бу чорда цензура тагы да көчәя, революцион эчтәлекле әдәбият бастыру мөмкинлеге бөтенләй бетерелә. Шулай да «Мәгариф» матбагасы үзенең демократик юнәлешеннән читкә тайпылмый, элгәрләре башлаган прогрессив традицияне дәвам итеп, төп игътибарны халыкка кирәкле әдәби һәм фәнни китаплар бастыруга юнәлтә. Бу яктан без «Мәгариф»не революциягә кадәрге башка татар типографияләре арасында иң демократик юнәлештәге типографияләрнең берсе итеп саный алабыз.

Бөек Октябрь революциясеннән соң да «Мәгариф» типографиясе берничә ел эшен дәвам итә әле. Анда Совет властеның беренче декретлары, документлары басылып чыга, дәреслекләр, уку әсбаплары нәшер ителә. Бары Казанда дәүләт типографияләре барлыкка килеп, китап басу эше дәүләт карамагына алынгач кына, ул яшәүдән туктый.

Нурмөхәммәт Хисамов

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНЫҢ ХАЛЫКТА ЯШӘЕШЕ

Тикшеренүчеләр Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен татар халкының «яраткан китабы» дип атыйлар. Без, махсус оештырылган экспедиция материалларына таянып, бу тәгъбиргә «иң» кисәкчесен өсти алабыз. Матур әдәбият сөючеләр арасында «Йосыф китабы» дип йөртелгән бу поэма — бездә иң күп таралган һәм халык күңеленә иң тирән үтеп кергән борынгы әдәбият әсәрләренең берсе.

Татарстанның Апас, Алексеев, Кама тамагы, Чүпрәле, Октябрь районнарына, Шәһри Болгарга һәм Пермь өлкәсенең Барда районына оештырылган экспедицияләр бу әсәр белән халыкның барлык катлаулары да таныш икәнлекне күрсәтте.

«Йосыф китабы» мәдрәсәләрдә даими укылып килгәнгә, өлкән буынның укый-яза белгән өлеше турында сөйләп тә торасы юк. Урта буын вәкилләре арасында да поэманың аерым өзекләрен яттан белгән яки аның эчтәлегеннән хәбәрдар кешеләр байтак очрый. Әсәрне мәктәп программаларына кертү яшь буынга да поэма белән танышу мөмкинлеген бирде, аның белән кызыксынуны җанландырып җибәрде. Шуңа күрә Кол Гали әсәренең бүгенге көндә ничек яшәешен күзәтү халыктагы җанлы бер рухани күренешне өйрәнү булып каралырга тиеш.

Махсус оештырылган экспедицияләр нәтиҗәсендә «Йосыф китабы»ның башкарылышына, халыкта яшәешенә караган шактый материал тупланды. Бу эш киләчәктә дә дәвам иттереләчәк. Хәзергә исә, тупланган кадәр материалга таянып, әсәрне башкаруга кагылышлы кайбер мәсьәләләрне күздән кичерергә уйлыйбыз.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының башкарылышында һәм халык иҗатына үтеп керүендә мөһим өч момент күзгә ташлана: 1) китаптан уку; 2) әсәрнең сюжетын телдән сөйләү; 3) халык иҗатында әсәргә таяну, ияру яки пародияләр.

## Поэманы китаптан уку

Кол Гали үз әсәрен язганда ук башкаручыларны һәм тыңлаучыларны күздә тоткан. Әсәрнең үзендә моңа ишарәләр күп. Менә керештән бер өзек:

**Йосыф үзрә әхүәл нәтә кәлдикини...**
**Назым берлә әйтәен, аңлаң имди.**

Шагыйрь, шул заманның әдәби традициясенә ияреп, илаһияттән илһам сорый:

**Тәүфыйк үиргел хикмәт таба кайтмага,**
**. . . . . . . . . . . . . . . .**
**Йосыф сәүчи әхүәлени айтмага...**

«Хәтимә»дә исә мондый юлларны укыйбыз:

**Бу зәгыйфең ошбу назмы азумады,—**
**Робагыйы вәзен эчрә дорсын имди.**

Китерелгән мисалларда ике момент игътибарга лаек. Беренчедән, әсәрнең көйләп укуга исәпләнгәнлеге сизелә. «Назым берлә әйтү» дигәндә дастан әйтү традициясе төсмерләнә. Төркмән туйларында хәзер дә «Көр-оглы» дастанын башкаручыга: «Көр-оглы айт»!» — дип тәкъдим ясыйлар икән. Мәгълүм ки, бездә бәетләр күбесенчә көй белән башкарылган. Халык «бәет әйтү» ди. Һәр вакыт көйләп башкарылган «Нәүрүз бәете»ннән дә «шадибат әйтү» дигән фразеологик әйләнмә калган. Хәзер ул бушка вакыт уздырып йөрүче кешеләргә карата кулланыла. Татар мәҗлесләрендә, кемнең дә булса җырлап бирүен үтенгәндә: «Әллә берне әйтәсеңме», «Әйтеп бир булмаса», диләр яки җырлаучыны «Әйт шуны!» дип хуплап куялар. Бу тәгъбирләрнең һәр кайсы бик борынгыдан, дастаннар чорыннан ук килә булса кирәк. Кыскасы, поэмадагы «назым берлә әйтү»нең көйләп башкаруга ишарә булуына шикләнмәскә мөмкин. Бу — мәсьәләнең бер ягы.

Икенчедән, әсәрдән китерелгән өзекләр башкаруның аудиториясенә дә ишарә ясый. Ягъни башкаручы һәм тыңлаучылар күз алдына килә. Күмәк аудиториядә башкарылуга тагын да ачыграк дәлил поэманың үзендә үк бар. Шагыйрь әсәренең яңа бүлеген башлаганда, тыңлаучыларның (укучыларның түгел!) игътибарын тарту өчен, аларга махсус мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, Зөләйха турындагы бүлекне:

«Колак лотыб дыңлаңыз ошбу сүзи...— дип башлый.

Шундыйрак юлларны әсәрнең «Хәтимә» өлешендә дә очратабыз. Көйләп укыла торган әсәрнең эпик колачы үзеннән-үзе зур аудитория сораган.

Башкаручының тыңлаучылар белән актив бәйләнышы нәтиҗәсендә аудиториядә әсәрне башкаруның үзенә аерым традицияләре эшләнгән. Мәсәлән, башкаручының юл уңаенда сүзләргә аңлатма биреп, төрле эпизодларны шәрехләп баруы, аерым гыйбрәтле вакыйгаларны тормыштагы күренешләр белән чагыштыра килүе һ. б.

1972 елгы экспедиция вакытында Кама тамагы районының Олы Кариле авылында Нәфисә Гарифулла кызы Вәлиева (1896 елда туган, хәзер пенсиядәге колхозчы) сөйләгән истәлек әсәрне башкаруның күп кенә кызыклы якларын ачыкларга ярдәм итә. Менә ул истәлек:

«Сабакта остабикәләребез: «Йосыф»ның көе шушы көй, дип көйләп укыйлар иде. «Йосыф китабы»ннан өлешләп сабак биреп җибәрәләр иде. Икенче көнне абыстай тыңлап тора, без укып күрсәтәбез. Алдагы көнгә тагын биреп җибәрә.

Элеккеге кешеләрнең барысы да («Йосыф китабы»н — Н. Х.) укый белми иде. Менә безнең шикелле укый белүчеләрдән тыңлыйлар иде. Хәзер дә шулай тыңлыйлар.

Кайсы әйтә: «Йосыф» китабын укы әле,— ди.— Минем ишеткәнем юк»,— ди. Җыелалар да укып бирәм. Кайсының, укыгач, җылыйсы килеп куя. Җыларга да кирәк бит, күңелләргә дә кирәк бер нәстә. Аңламаган кешегә аңлатып барасың.

Күбрәк кич утырганда укыла иде. Кайсы иптәшләр укый белми иде. Белсә дә, кеше укыганны тыңлавы кызыграк. Кайбер кеше көйлерәк, аңлатыбрак укый. Менә шул аңлатып, көйлерәк укучы янына җыелалар».

Бүтән башкаручылардан язып алган мәгълүматлар да шундый характердарак. Әмма бу истәлек тулылыгы һәм мәсьәләне күп яклап ачыклавы белән аерылып тора.

Беренчедән, әсәр халыкның барлык катлауларында да күмәк төстә башкарылган. Яшь буынга ул мәдрәсә аша тапшырылган. Өлкән буын вәкилләре арасында «Йосыф китабы»н белмәгән кешеләр юк диярлек. Әсәрнең үзенә беркетелгән махсус көе дә буыннан-буынга тапшырыла килгән.

Икенчедән, поэманы башкаручылар арасында үзенә күрә хезмәт бүленеше барлыкка килгән. Аеруча эрудицияле (аңлатма биреп бару өчен шул таләп ителә) һәм моңлы тавышлы башкаручылар гомуми хөрмәт белән файдаланган һәм әсәрне тыңлаучылар күбрәк шундый кешеләр тирәсендә тупланган.

Өченчедән, «аудиториягә тартылу» әсәр белән таныш булмаганлыктан гына түгел, бәлки таныш әсәрне кат-кат тыңлау ихтыяҗыннан да килеп чыккан. Алай гына да

түгел, аудитория, аерым осталар тырышлыгыннан тыш, тыңлаучылар үтенече белән оешкан. Әсәр махсус пропагандалауга мохтаҗ булмаган, халык үзе аңа тартылган.

Дүртенчедән, башкару методикасында үзенә күрә дифференциация яшәп килгән. Аудиториянең әсәр белән танышлык дәрәҗәсенә карап, тәфсилле яки кыска аңлатма бирелгән, яисә бөтенләй аңлатмасыз укылган.

Һәм, ниһаять, әле китереп узган мәгълүмат халыкта булган эстетик ихтыяҗның кайбер психологик мотивларына да яктылык сибә («җыларга да кирәк бит, көләргә дә кирәк бер нәстә»).

Экспедиция вакытында безгә әсәрне кат-кат укырга этәргән кайбер үтә шәхси, психологик сәбәпләрне дә һәм гомуми социаль әһәмияткә ия булган мотивларны да теркәргә туры килде. Менә аларның берничәсе:

«Яшь чагымда мин тормыштан аерылып кайттым. Бик кайгылы йөрдем. Шул вакыт аппак (туган апасы — Н. Х.), күңелем булсын дип, мине юатыр өчен укып йөрде. Үзе эшләп йөри, үзе «Йосыф китабы»н укый».

**[Мәликә Галләмова. Шәһри Болгар. 1901 елда туган. Хәзер пенсиядәге колхозчы.]**

Өстәп шуны әйтергә кирәк, М. Галләмова әсәрнең апасыннан отып алган өлешләрен әле дә бик яратып укый. Көе исә, үзенең оригиналь яңгырашы белән, моңарчы язып алынган вариантларның барысыннан да аерылып тора.

Нәфисә Вәлиева, югарыда китерелгән өзеккә өстәп, болай диде:

«Үзем дә укып-укып елыйм — улларымның кайсылары сугыштан кайтмады...»

Халык күңелендә нинди гаҗәеп ассоциацияләр туа: Ягкубның улы Йосыфтан аерылу тарихы анага сугышта җуйган улларын исенә төшерә. Кыскасы, кешеләр шушы поэмада үзләренең күп төрле рухи халәтләренә аваздаш хисләр табалар. Әхлакый-хисси дөньяның күп төрле халәтләренә аваздаш булу, халыкның рухи ихтыяҗларына һәр заманда җавап бирә алу «халык китапларының» (Ф. Энгельс термины) чын кыйммәтен билгели дә.

Шулай итеп, поэманың халыкта яшәешен өйрәнүнең күп төрле аспектлары ачыла Аларның һәрберсе аерым игътибарга лаек булса да, алда әйтеп үткәнебезчә, әсәрнең яшәешенә бәйле берничә мәсьәлә белән чикләнергә уйлыйбыз.

Халык әсәрне эстетик бер бөтен итеп карый. Башкаручы китаптан нинди дә булса өзекне укып биргәндә, ул эпизодның әсәр сюжетында нинди урын тотуын да искәртергә онытмый. Гадәттә өзекне башкарганчы, бу турыда киң генә мәгълүмат биреп уза. Әгәр инде аңлатма башкарылган өзектән соң килсә, аның роле эпизодка өстәмә яктылык сибүгә кайтып кала. Һәр ике төрнең әһәмияте — асылда бер.

Мәликә Галләмова укыган өзектә Йосыфның гүзәллегенә сокланып бармакларын кискән хатыннар турында сөйләнә. Өзек Зөләйханың кисәтү характерындагы сүзләре белән тәмамлана:

**Зөләйха әйдер: йә әмримә мотыйг ула,**

**. . . . . . . . . . . . . . . .**

**Йаки мәхбүс кылам, зиндан эчрә кала,**
**Төкәл гомри зиндан ичрә калсун имди.**

Өзекне укып бетергәч, М. Галләмова Зөләйха белән Йосыф арасындагы мөнәсәбәтләрнең тулы тарихын сөйләп чыга. Аңлатманың характерын күз алдына китерү өчен, бер мисал китереп үтик:

«...Хәзер хатыннар моны сөйлиләр. Авыл хатыннары: И-и-и, бу патша хатыны үзенең сатып алган колына гашыйк булган икән, бик ярата икән, аны бик сөя икән. Менә бу бер көнне хатыннар җыя, мәҗлес ясый... Барысына вилкалар и пычаклар куеп чыга. (Хәзерге заман сервизы — Н. Х.). Йосыфны бик каты киендерә дә, аларга аш әзерләтеп, китертеп йөри. Хәзер бу хатыннар Йосыфны күрәләр дә кулларын кисеп бетерәләр. Карый-карый аңа гашыйк булалар... Шуннан соң Зөләйха әйтә боларга:

— Минем, ди, сабырым сезнекеннән артык икән менә,— ди.— Сез бер күрүдә кулларыгызны кистегез,— ди.— Ә мин җиде җылдан бирле шушы утта янсам да сездән сабыр икәнмен, ди».

Биредә башкаручының әсәрдә сөйләнгән вакыйгаларга карата шәхси мөнәсәбәте сизелеп тора. Ул түкми-чәчми тәмләп хикәяли. Хикәяләүдә исә интригалы башлангыч өстенлек итә. Аңлатманы эзлекле алып бару өчен, ялгам кебек стилистик чарадан файдалана. Йомгак ясап куйганда, башкарылган шигъри өзекнең үзенә кайтып төшә. Ләкин китапча кабатламый, чәчмәгә күчерә.

Тагын бер момент игътибарга лаек: башкаручының кулында китап булуга карамастан, Мисыр (шәһәр) халкы «авыл халкы» булып китә. Бу — барлык башкаручыларга хас бер үзенчәлек.

Без әлеге мисалда поэмадан кыска-кыска өзекләр башкару белән танышып үттек. Ә бит гадәттә зур-зур өзекләр укыла, яки тыңлаучылар теләге белән берничә кич дәвамында поэма тулысынча укып чыгыла. Мондый очракта шәрехләү юл уңаенда эшләнә. Аудиториянең хәзерлегенә карап, үтә сирәк һәм кыска-кыска аңлатмалардан башлап тәфсилле шәрехләргәчә төрлесен очратырга мөмкин.

Мәсәлән, Апас районының Дәүеш авылыннан Мәсрүрә Мөхәммәтҗанова (1891 елда туган), укый-укый да, текстта кыенрак саналган гарәп яки фарсы сүзенең мәгънәсен тыңлаучыдан үзе сорап куя. Тыңлаучы аңлата алмаса, үзе әйтеп бирә.

Нәфисә Вәлиева башкаруында бер өзек китерик:

«— Менә абыйларының Йосыфны атасы Якуб пәйгамбәрдән алып киткән вакытлары. Йосыф әле унбер яшендә генә булган[1].

**...Йосыфның кардәшләре эүә дүнди,**
**Берси бер углак дотыб бугазлады,**
**Канин Йосыф күңләкинә булаштурди,**
**Җөмләләри аглашу уарырлар имди.**

— Алып китеп югалткан вакытлары инде. Менә бер бәтине тотканнар да канын күлмәгенә буяганнар.

**Йул үзрә бер коба егач улур иди,**

— Бер агач үсеп тора, ди.

**Ягкуб аның дөбендә дорыр иди,**
**Һавадан иңездән бер өн кәлди,**
**Дыңладисә сәбгыйн, дәйер имди.**

— Малайларының җылашып кайтканнарын ишетә бу. Алай да корт ашамагандыр моны, бер җиргә куйганнардыр дип уйлый. «Йитмеш көн микән, йитмеш ай микән Йосыфсыз торырмын», ди.

Әле генә китерелгән өзектән күренгәнчә, һәр шигъри строфадан соң тәфсилле аңлатма биреп барыла. Дөресрәге, шигъри текст эчтәлекне чәчмә хикәяләү белән аралаштырып башкарыла. Монда төрки дастаннарның бик борынгыдан килә торган бер сыйфаты — шигъри әсәрнең чәчмә белән аралаштырылуы чагыла. Кырыс бер калыпка салынган әдәби әсәр белән эш иткәндә дә башкаручы әллә кайчаннан бирле килә торган традицияләргә буйсына. Фольклор традициясенең гаҗәеп көчен күрсәтә торган бер дәлил бу.

Әгәр дә без әнә шул тәфсилле аңлатмаларның үзләрен генә җыеп карасак та, әсәрнең сюжетын тулы гәүдәләндерерлек чәчмә хикәяләү килеп чыгар иде.

Менә икенче бер үрнәк. Бусын Апас районының Болынбалыкчы авылында яшәүче Нәбиулла Мостафа улы Мостафин (1885 елгы) сөйләде:

«Йосыф Рәхилә исемле хатынның малае, Ягкуб пәйгамбәрнең улы булган. Төш күргән. Төшен атасына сөйләгән: **«Тулган ай, унбер йолдыз төшем эчрә сәҗдә кылдый бәна дөп-дөз,**— дигән.

— «Я, әбәти, миңа тәэвил айгыл имди»,— дип төшен юрарга кушкан атасына. Атасы әйткән: **«Әя углым, ул төшеңне һич кемгә син әйтмәгел, адәмиләр кинәсеннән ки саклангыл, адәмигә шәйтан дошман улыр имди,**— ди.

Абзалары ишеткәннәр, Йосыфны алып киткәннәр кырга. Котырткannар башта: «Анда кошлар сайрый, төрле үләннәр үсә. Кайткач атаңа сөйләрсең»,— дигәннәр.

---

[1] Юл башында сызыкчалар белән башкаручының аңлатмасы бирелде.

Атасына да әйткәннәр: «Сез Йосыфны безнең белән җибәрегез. Ул төрле хикмәтләр күрер анда. Кайткач сезгә дә сөйләр. **Сез тыңларсыз, вәт ул сөйләсен,**— дигәннәр...»

Хикәяләү азаккача шушы тәртиптә бара. Поэма башкаручының хәтеренә яхшы сеңеп калган. Чәчмә белән хикәяләгәндә дә ул шигъри текстка таяна. Хикәяләү эчендә төсле пунктирлар сыман аерылып торган шигъри өзекләр сөйләүчегә сюжеттан тайпылмас өчен кирәк. Нигездә персонажларның туры сөйләмендә китерелгән шигъри фрагментлар тел ягыннан да үзгәртелми диярлек.

Тел гыйлемендә җанлы телнең үзендә үк яши торган формалар аша борынгырак катламнарны ачу яки диалектларда һәм әдәби телдә гамәлдә йөргән фонетик-морфологик фактларны билгеле бер тәртиптә карап, аларның эволюциясен, үсеш эзлеклелеген күзәтү яши. Шуның кебек, безнең әле карап үткән башкару үрнәкләрендә дә ниндидер бер тарихи эзлеклелек сыман күренеш чагылмыймы икән? Әйтик, аңлатмалар белән укудан туган тезмә һәм чәчмә текст үрелешендә аңлатманың сюжетны хикәяләүгә әверелә баруы һәм, ниһаять, шигъри текстның чәчмә хикәяләү эчендә эреп юкка чыгуы күзәтелсә кирәк.

Кызыклы хәл килеп чыга. Китаби дастаннар, халыкның рухи тормышында эпосларны кысрыклап, алар урынын биләгәч, үзләре дә фольклордагы эпос язмышын кичерәләр. «Алпамша» дастаны Казан татарларында әкияткә әверелгән сыман, «Йосыф кыйссасы» да халык телендә сюжетның әкияткә охшаш рәвешен алган. Бу әверелеш сюжетның әсәр белән китап аша танышу мөмкинлеге чикле булган киңрәк массага таралуы нәтиҗәсендә килеп чыккандыр дип уйларга нигез бар. Әмма поэма дастаннар юлын кабатласа да, алар язмышыннан котылып кала алган. Чөнки янәшә үк китап яшәгән. Ул күчереп языла торган, басыла торган. Сюжетның халык телендә яшәвенә язма һәм басма китап импульс биреп килгән. Бу — халыкның төрле катламнарында әсәрне башкаруда туган форма-алымнарның тоташ яңарып, кабатланып торуын тәэмин иткән. Ул формаларның барлык вариантларын да башкаруның җанлы процессы рәвешендә без бүген дә күзәтәбез икән, моны бары әнә шушы сәбәп белән генә аңлатырга мөмкин.



## Сюжетны телдән хикәяләү

Прозаик вариантлар, телдән-телгә сөйләнгәнлектән, тулысынча фольклор традициясенә буйсындырылган. Бу инде фольклор традицияләре болай да көчле булган әсәрнең тулысынча авыз иҗаты стихиясенә кайтуы дигән сүз. Әмма халык авыз иҗатының башка жанр һәм төрләреннән аермалы буларак, хикәяләүдә китап культурасы белән фольклор стихиясе бергә кушылган.

Башкаручы поэманың шигъри текстыннан ераклашкач кына тулы иҗат ирекенә ала. Иҗат ирекенә, сюжетны нигезеннән үк үзгәртүгә барып җитмичә, аңа төрле идея һәм сәнгатьчә яңгыраш бирүдә чагыла.

Әсәрнең халык телендәге прозаик вариантларын шартлы рәвештә «ортодоксаль» һәм «иҗади» төрләргә бүлеп карарга мөмкин. Башкаручының иҗат ирекенә аларның һәр икесенә кагыла, билгеле. Әмма «ортодоксаль» төрдә сюжетның төп линиясе, идея һәм эмоциональ яңгырашы тәүге чыганаклардан («Коръән», «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссас эл-әнбия») аерылмый. «Иҗади» төрдә кыю контаминация өстенлек итә, хикәяләү исә тылсымлы яки көнкүреш әкиятләрендәге мотивлар белән аралаша.

Сюжетта геройлар мәсьәләсен алыйк. Әдәбият фәнендә әсәрне еш кына «Йосыф вә Зөләйха» дип атасалар да, бу ике персонаж әсәрнең тигез дәрәҗәдәге геройлары түгел. Шушы хәл әсәрнең үзәк проблематикасын, сюжет нигезенә салынган кешелек мөнәсәбәтләре мәсьәләсен башкача билгеләүне таләп итә. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, «Коръән»дә булсын, Кол Гали һәм Рабгузи («Кыйссас эл-әнбия») версияләрендә булсын, сюжет Йосыф турында роман рәвешендәрәк эшкәртелә. Дөнья әдәбиятының көнчыгыш версияләре генә Йосыф-Зөләйха мәхәббәте рәвешен алган. Томас Маннның «Йосыф һәм аның туганнары» дигән романында да үзәктә Йосыф, Ягкуб һәм Йосыфның кардәшләре тора. Зөләйха образын әсәрнең героинясы иткән беренче шагыйрь — Фирдәүси. Аңарчы Зөләйха дигән исем Табарида гына билгеле.

Алексеев районының Югары Майна авылында яшәүче Нәкыя Гатауллинадан (1901 елда туган) язып алынган вариантны һич икеләнмичә «Йосыф-Зөләйха» дип атарга мөмкин. Ул шактый дәрәҗәдә әкияткә якынайтылган. Сюжет кыскартылып, җыйнакланган. Сәяхәтнең озын булуын сиздерү һәм анда килеп чыккан күп төрле вакыйгаларны сикереп узу өчен әкияткә хас стилистик алым — ялгам кулланыла. Йосыфны кол итеп Мисырга алып бару күренешен сурәтләгәндә, сөйләүче: «Баралар, баралар болар. Бара торгач...» дип китә.

Хикәяче Зөләйха образын әсәрнең чишелешенә кертеп, бу персонажны хәлиткеч каһарманнарның берсенә әйләндерә. Поэмада Йосыфның Зөләйхага никахы әсәр уртасындагы бер эпизод кына булса, монда ул «апофеоз» дәрәҗәсенә күтәрелә. Сюжет та монда Йосыфның Зөләйхага өйләнүе белән тәмамлана. Аның ахыры да әкиятләрнең типик бетемен хәтерләтә: «...Шулай итеп, Йосыф белән бергә булалар. Гомер иткәннәр аннары бергә».

Персонажларның әсәрдәге вазифасын берсеннән икенчесенә күчерү — халык вариантларындагы контаминациянең иң таралган күренеше. Менә Гайшә Сабирҗанова (Алексеев районының Югары Майна авылында 1906 елда туган) вариантыннан характерлы ике үрнәк.

Поэмада Йосыфны явыз ниятле агаларыннан миһербанлы яһүдә аралап кала. Телдән сөйләнгән вариантта моны Йосыфның бер анадан туган кардәше Ибнейәмин эшли. Гади бер оныту яки саташтырумы бу? Ул очракта нигә Шәмгун яки Равил белән алыштырылмый? Онытып калдыруда очраклылык булса да, бер уңай персонажны икенче уңай персонаж белән алыштыру очраклы түгел. Яһүдә әсәрдә аз катнашканга, онытылырга да мөмкин. Ибнейәминнең (Утыз-Имәни редакциясендәге басмада) исеме күп телгә алынса да, истә калырлык игелекле эшләре юк. Шушы ике персонажны берләштереп, хикәяче калкурак образ тудыра.

Икенче бер үрнәк. Поэмада Йосыфның атасына төш сөйләвен апасы Динә тыңлап тора һәм туганнарына җиткерә. Сөйләүче исә серне Йосыфның «бер агасыннан» тыңлаттыра. Югыйсә, сер тыңлау хатын-кызга ятышарак төшә кебек. Сөйләүче ни эшләп соң Динәне оныта һәм агасы белән алыштыра? Җыйнаклык өчен шулай эшли. Чөнки сюжетта Динәнең роле аз. Ул (Утыз-Имәни редакциясендә) бөтен очрамый да.

Бер үк вакыйганың охшаш ике моментын, вакыт ягыннан аралары шактый ерак ике очракны бергә кушу да контаминациянең характерлы бер күренеше булып тора. Поэманың үзендә Йосыфны агаларыннан Малик Догыр углы дигән сәүдәгәр сатып ала. Мисырга килгәч, Малик Догыр углыннан Кыйтфир ала. Хикәяләүче Гайшә Сабирҗанова Йосыфны турыдан-туры патшага саттыра. Югыйсә, ул сюжетны бөтен ваклыклары белән хәтерли. Ә ике сатылу актын «бутап» бер иткән. Хикмәт нәрсәдә соң? Безнеңчә, хикмәт шунда, хикәяләүче хәтерендә Малик Догыр исеме соңыннан Йосыфны зинданнан азат иткән Малик Рәйян белән ассоциацияләшә. Шуңа күрә бөтен хикәяләү дәвамында без «Малик Рәйян»ны аерым очратмыйбыз. Башкаруның психологик аспекты үзенә аерым игътибар сорый торган кызыклы мәсьәлә. Сюжетны үзләштерүдән алып башкаругача булган иҗат процессында контаминациянең күп кенә күренешләрен аңлау өчен ачкычны әнә шушы аспекттан эзләргә кирәк.

Башкару психологиясен еш кына географик тирәлек һәм социаль мохит билгели. Башкаручыларның иң зур күпчелегенә хас бер генә моментны алыйк: ул — шәһәр белән авылны «бутау». Йосыфны Мисырга илтеп сатуларын һәм Мисырның бер үк вакытта шәһәр дә булуын хикәяләүчеләр бик яхшы беләләр. Әмма Зөләйханың үз колына гашыйк булуы хакындагы гайбәтне «бөтен авыл сөйли» башлый. Зөләйха үзенең гайбәтчеләрен кызык итү өчен «бөтен авыл хатыннарын кунакка чакыра» (Мәликә Галләмова, Нәкыя Гатауллина, Гайшә Сабирҗанова һ. б. вариантлары). Йосыф янына агаларының ашлык сорап килүләре дә авылдан район үзәгенә ипи алырга килү сыман итеп тасвирлана. Кәнган белән Мисыр бер үк дәүләтнең авылына һәм шәһәренә охшатыла. Нәтиҗәдә Ягкубның балалары белән Йосыф янына күчеп килүе ата-ананың шәһәргә урнашкан улы янына күчүләренә охшаш төс ала. «Аннары инде аталарын да үзе янына алдыра»,— дип кенә уза хикәяче (Гайнетдин Госманов, Нәкыя Гатауллина һ. б.).

Шунысы кызыклы, сюжетны телдән сөйләгәндә хикәяләүче тылсымлы детальләрне шул көе сакласа да, хикәяләүне тулаем реалистик юнәлештә алып бара. Сюжетның өч чыганагы («Коръән», «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссас эл-әнбия») һәр вакыт хикәяләүче карамагында. Бер очракта деталь «Коръән» һәм «Кыйссас эл-әнбия»дагыча алынса, икенче очракта Кол Галидәгечә алына, яки башкаручы бөтенләй үзенчә алып китә. Поэмада мөһим урын тоткан **күлмәк** детален алыйк.

Йосыф атасына үзенең күлмәген бүләк итеп җибәрә. Ягкуб шуны йөзенә сөртүгә аның сукырайган күзләре ачылып китә. «Коръән»дә һәм, димәк, «Кыйссас эл-әнбия»да деталь тылсымлы мәгънәдә бирелеп, фольклорга якынрак торса, Кол Галидә көчле әдәби эшкәртелүгә дучар ителә. Кол Гали детальне эмоциональ эффект тудыру өчен файдалана, алдан берни хәбәр итми. Йосыф үзенең иң газиз кешесенә иң кадерле бүләге итеп җибәрә аны. Шул ук вакытта патша өчен бу бүләк бик кечкенә дә, әмма мәгънәле. Ягкуб исә аны кадерле булганга һәм затлы бүләк итеп йола буенча битенә сөртә. Атаның сукырайган күзләре кинәт ачылып китү эмоциональ эффект тудыра.

Телдән хикәяләнгән вариантларда нигә соң шуның образ буларак үстерелгән һәм эстетик яктан мәгънәлерәк очрагы түгел, ә садәрәк һәм архаиграк очрагы сайлап алынган? Моны соңгысының иң борынгысы белән аваздашлыгыннан, аларның фольклор факты буларак уртак стихиягә каравыннан эзләргә кирәк. Хикәяләүче өчен әдәби эшкәртү очрагы сюжетның сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр дөньясында ярым-йорты аңлатмалы бер деталь булып кала. Чөнки ул барыбер тормышчан булып китә алмаган, тылсымның бер чагылышы булып калган. Ә тегесе, борынгырагы исә тулысынча тылсым белән сугарылган. Әкият өчен соңгысы кулайрак. Булгач-булгач, аңа тылсымлы булсын!

Ә хикәяләү гомумән реалистик юнәлештә бара, дидек. Бу, барыннан да элек, геройларның гамәлләрен тирән мотивлаштырырга омтылуда күренә. Мәгълүм булганча, Ягкуб үз улларын (арада Ибнейәмин дә бар) Мисырга икенче тапкыр җибәргәндә, «телдән-күздән сакланырга» нәсихәт итә һәм икәү-икәү төрле капкадан керегез, ди. Барысы да үтә чибәр булганлыктан, халыкның күзенә артык чалынмасыннар дип шулай эшли. Бу нәсихәт, күрәсең, бик борынгы ырым-ышанулардан килеп чыккан. Шаһзадәләрнең Көнчыгышта пәрдәдән йөрүе шул ук ырым-ышанудан килә торган нәрсә. Ягкубның киңәше «Коръән» версиясендә дә шушындый. Ә менә халык вариантларында ул башкачарак итеп үзгәртелгән.

Нәкыя Гатауллина варианты.

«...Унысы бер нидән керә, бер капкадан. Моны (Ибнейәминне — Н. Х.) икенче капкадан кертәләр. «Син шул урамнан барырсың»,— диләр. Хурланалар, күрәсең, теге малайны апбарырга инде. Ничектер инде ул, ябык булганмы, нинди булгандыр, аны ияртмәгәннәр. Калдырганнар, үзең барырсың, дип. Усаллык итеп инде.

Йосыф әйтә:

— Энегезне ник алып килмәдегез?

— Ул килә хәзер,— диләр.

— Кая калды?

— Әнә шунда кыр капка төбендә калды,— диләр...»

Китерелгән өзектә дә авыл тормышы тасвирлана. Әмма безне Йосыф туганнарының ни өчен аерым-аерым керүләре кызыксындыра. Беренчедән, тегеләр унау, Ибнейәмин генә ялгыз. Чөнки бүтән анадан туган кардәшне тиң итмиләр, халык алдында бергә күренүдән хурланалар. Юкса, (поэма буенча) Ибнейәмингә үчегергә бер урыннары да юк. Әмма хикәяче Йосыф белән булган хәлләрне шул чаклы нык хәтерендә тота ки, аларның Ибнейәмингә мөнәсәбәтләрен дә шул ук схемага кора. Капкадан керүчеләрне бүтәнчә төркемләү һәм моны тиңсенмәү белән мотивлаштыру — хикәяченең оригиналь иҗаты.

Икенче бер вариант.

«...Этиләре әйтә: «Инде **өченче** кат барасыз, оят булыр,— ди.— Капка саен өчәрдүртәр керегез»,— ди.

Җәбраил килеп әйтә: «Братың кыр капка төбендә, ди. Алтын беләзек алып бар,— ди...» (Гайшә Сабирҗанова).

«Кыр капка төбе» икенче тапкыр очрый. Монда да авыл тасвирлана. Сөйләүче

кардәшләренең аерым-аерым («өчәр-дүртәр») керүен әдәп-инсаф, чама тойгысы белән мотивлаштыра.

Икенче бер детальне дә күздән кичерик. «Алтын беләзек»не Йосыф (поэма буенча) үз белдеге белән бүләк итә. Соңыннан туганнар бергә җыелгач, бар да сокланып киеп карыйлар. Әмма беләзек һәрберсеннән кире Ибнейәмин кулына кайтып төшә (фантастик трактовка!). Халык вариантында исә бик тормышчан бирелә: «...Ә беләзекне алып-алып карыйлар да, берсенә дә чак түгел, **Ибнейәмингә генә чак».**

Хикәяләүчеләрнең күпчелеге сюжеттагы ситуацияләрне яхшы күз алдына китереп сөйлиләр, аңлашылмаучылыкка урын калдырмыйлар, аерым вакыйгаларга, күренешләргә сюжет чыганакларының берсендә дә очрамый торган оригиналь аңлатмалар бирәләр.

Менә сюжеттагы үтә эмоциональ бер деталь. Коллыкка сатылгач, Йосыф юл уңаенда анасы каберенә туктала, аңа үзенең зарын сөйли.

Нәкыя Гатауллина варианты буенча, Йосыф, кәрваннан арткарак калып, «тәвә»сеннән сикереп төшә дә, анасы каберенә **тәгәрәп бара.** Аның ничек баруы язма версияләрдә әйтелми. Хикәяләүче, шулай итеп, геройның богаулы икәнен сүз уңаенда да онытмый.

Гайшә Сабирҗанова вариантында: «...Ходайның рәхмәте белән богаулары чишелә дә, йөгереп йәт кенә (җәһәт кенә — Н. Х.) бара да әнисе кабере янына. Елый бу...» Юкса, Йосыфның тирән хәсрәтен тасвирлаган бер генә борынгы шагыйрь дә үз героеның кабергә ничек баруы турында баш ватмаган. Хикәяләүче һәр детальне мотивлаштырырга омтыла, язма чыганакларда күрсәтелмәгән «бушлыкларны» үз хыялы белән тутыра.

Поэмада (шулай ук башка версияләрдә дә) Йосыфны сатканда кардәшләре сәүдәгәргә биргән таныклык-язу әһәмиятле урын тота. Йосыф аны соңыннан хозурына килгән кардәшләренә күрсәтә. Анда Йосыфның «өч төрле гаебе» язылган була: «Угры, качкын, ялганчы». Табигый ки, бу деталь телдән хикәяләүдә дә төшеп калмый, ләкин үзгәртелә.

Нәкыя Гатауллинада ул: «урлый, качкак, елак» («Кыйссас эл-әнбия»дан). Башкаручының зәвыгы да сайлап алуда роль уйнаган булса кирәк. Гатауллина — шагыйрә дә. Без язып алган шигырь-мөнәҗәтләр аның классик төрки поэзияне яхшы белүен күрсәтә. Монда да («качкак, елак») сүзләрнең рифмалашып яңгыравы роль уйнаса кирәк.

Гайшә Сабирҗановада: «...Өч төрле гаебе: берсе — **кача,** диләр, берсе — **ялганлый,** диләр, **тагын берсен оныттым...»**

«Онытучы» бер Г. Сабирҗанова гына түгел. Элегрәк тупланган язмаларда да бу очрый. Хикмәт нәрсәдә соң? Хикмәт, безнеңчә, Кол Гали поэмасының Г. Утыз-Имәни редакциясеннән узган вариантында. Гаять зәвыклы шагыйрь һәм таләпчән галим, нигезле кыскартулар белән бергә, поэмага шактый зыян да китергән.

Утыз-Имәни кулыннан узган вариантта кардәшләренең Йосыфка яккан ялалары тулы дәлилләнми калган. Басма китаплар редакцияләнгән текст нигезендә эшләнгән. Анда Йосыфның «ялганчы»лыгы аңлашыла: «күрмәгән төш»ен атасына ялганлап сөйләгән». «Качкын»лыгы да шик уятмый: коега үзенең «хуҗаларыннан качып төшкән». Ә менә «угры»лыгына әсәрдә дәлил калмаган, ул өзек кыскартылган. Бу кыскарту әле әсәрнең бүтән әһәмиятле мәсьәләләрен чишкәндә дә тикшеренүчене дәлилсез калдыра. Менә шушы «дәлилсезлек» поэмадагы детальне хәтердә калдыруны читенләштергән. Игътибарлы укучы соңыннан һәр детальне мотивлаштырырга өйрәнгән башкаручыга әверелгәч, мотивлаштырылмаган бу детальне онытырга мәҗбүр булган.

# ГОМЕРНЕҢ ИЮНЕ

Гомеренең билгеле бер борылышларында шагыйрь иҗат юлына әйләнеп карый, үз-үзенә хисап бирә, үзе өчен нәтиҗәләр ясый. Яңа шигырьләре белән бергә, элегрәк язылып вакыт сынавын үткән әсәрләрен туплый, укучы хөкеменә куя. Роберт Әхмәтҗановның «Идел-йорт» исемле шигырьләр җыентыгы әнә шундый максатны күздә тотып төзелгән.

Идел-йорт, Ватан-ана, туган җир белән шагыйрьнең биографиясе аерылгысыз. Ул халык исеменнән сөйли: «иген иктек, суктык чыпта, күрүк бастык алачыкта»... «Эленеп тора чүплəм сөлге... Ап-ак җитен читенә җыр сурәте чигелә». Халык тудырган сәнгатьнең милли бизәкләре, төсләре аша аның рухи дөньясын тоя шагыйрь.

Кеше гомеренең дә фасыллары бар: язы, җәе, көзе, кышы... Шагыйрьнең самими язы үткән. Ул — июнендә.

Инде еллар йөге\
ике иңне баса...\
Мин «А-у!» диеп дәшәм\
утыз июнь аша.

**(Июнь иле.)**

Июнь иленнән торып шагыйрь еракта калган бала чагына эндәшә. Бала чак — мәңге җуелмас матурлык, хыял иле. Хыял, гөрләвекләргә җибәрелгән кәгазь көймәләр кебек, бөялеп, я дулкынга күмелеп калмаган, ә киләчәккә, диңгезләргә юл алган. Шагыйрь бүгенге дөньясы белән үзенә соклану, гаҗәпләнү, матурлыкны тою сәләте биргән бала чак дөньясын чагыштырып карый. Шуңа күрә дә «Июнь иле», «Күренмәгән бер кешем бар бу җирдә» кебек шигырьләр бала чакны сагыну булып кына яңгырамыйлар. Үткән хатирәләргә хыял аша кайту шагыйрьне табигатькә якынайта.

Шигърияттә гражданлык пафосы үсә. Чор язмышы шагыйрь йөрәге аша уза. Шигърият колачлары киңәйгән, чыганаклары тирәнәйгән заманда эстетик принципларга таләпләр дә арта бара.

Шагыйрь һәм капитан — икесе бер язмыш,\
без менә йөзәбез шигырьдә.\
Иделләр киңәйгән заманда шагыйрьгә\
ансат дип уйлама син бер дә.

**(Яңа Иделдә сөйләшү.)**

Шагыйрь үзен раслау турында, заманга, халкына иткән хезмәте хакында уйлана.

Узды бәйрәм,\
Кояш бара төшлеккә,\
Үстердекме,\
Нәрсәбез бар урырлык?\
Ил хаҗәтен кайтарырбыз тик шунда,\
Күтәрелсә бер орлыктан мең орлык.

Р. Әхмәтҗанов дөнья әдәбияты казанышларын үзләштергән, Такташ традицияләрен үз яссылыгында үстергән, үз темасын тапкан шагыйрь.

Р. Әхмәтҗанов шигырьләрендә образлылыкның кабатланмас үрнәкләре бар. Һәр строфада диярлек — сәнгатьчә төгәллек, үзенчәлекле чагыштырулар, метафоралар. Әгәр шигырьләре бизәкле мозаикага гына корылса, Р. Әхмәтҗанов поэзиясе матурлык өчен матурлык булып калыр иде. Ләкин алай түгел. Халыкның, туган иленең үткәне, бүгенгесе өчен җаваплылык тоеп язылган фәлсәфи һәм интеллектуаль шигырьләр шул фикерне куәтли.

Тарихи фактларга таянып сюжетлы шигырь язганда, шагыйрь иң киеренке моментны сайлап ала. «Ватык гильотина», «Елъязмадан бер төн» шигырьләре әнә шундыйлар.

Утыра тормыш үлем вокзалында,\
гомер тавын сөйри сәгатьләр.

Зур дөньядан китә алмый кешеләр —
кечкенә бер
«техник сәбәптән!»

Гильотина ватылганлыктан, фашистлар әсирләрне җәзалаудан туктарга мәҗбүрләр, күпме гомер өзелмичә кала, әмма бу — вакытлыча гына.

Шагыйрь вакыйганың эчендә торып, хәтта бераз натуралистик планда яза («чират көтә сугым», «кан акмады сайрап»). Фашистлар кулындагы үлем машинасының кешеләргә китергән фаҗигасен тулырак күз алдына бастыру өчен шагыйрь әнә шундый кискен сурәтләүгә күчә.

«Елъязмадан бер төн» — киң планлы, киеренке язылган шигырь. Дөнья картасы алдында фашист түрәләре. Мәкерле сугыш планы инде әзер. Сугыш әле башланмаган. Җирдә тынлык хөкем сөрә. Кошлар чикләрнең ни икәнен белми очалар. Одердан килгән яңгыр Дунай розаларын сугара. Шигырь киносценарийны хәтерләтә, картиналар контрастлыгы, вакыйгаларны параллель кую юлы белән шагыйрь гомумиләштерүгә ирешә.

Тәрәзәгә килде рейхсфюрер,
томаладь. таңны —
тиздән, шуышып соңгы көч белән,
үлем уты сипкән дзотларны
күкрәк белән каплар
Матросовлар, Газниурлар...

Р. Әхмәтҗановның зур күләмле шигырьләрендә кызыклы бер үзенчәлек күзгә ташлана: соңгы строфаны ул ничектер тыенкы гына, психологик нюанска корылган деталь белән тәмамлый:

Төшендә елмая сабый:
баш очында
алма күрә...

(Елъязмадан бер төн.)

Алма образы патетик шигырьгә лирик нурланыш бирә.

Эленеп тора җиһан кыңгыравы:
вал өстендә —
тургай!

(Орчык җыры.)

Тургай — шагыйрьнең Болгарда туган җыры, ул җырын күккә чөя. Тарих җырда дәвамын таба.

Китапта ике поэма бар. «Таш аргамак»та лирик герой батырларга куелган һәйкәлләргә мөрәҗәгать итә. Алар язмышын йөрәгенә сыйдыра. Таш һәйкәл монологы аша шагыйрь аталар һәм уллар арасын якынайта.

Кем ананың каберен югалтса,
кем атаның каберен югалтса,
ташны түгел,
таш бәгырьле улының
таш йөрәген яшел мүк баса,

«Уйна, улым!» поэмасында сабыйлар иле:

Биш бармагы белән нурлар тотып,
баш астына салып бер кулын,
тәгәрәшеп өч йөз бәби йоклый, —
төшләр күреп йоклый
бер буын.

Сабыйлар алдында уенчык солдатлар. Ә бит кайдадыр чын сугыш бара. Ваемсыз бала чак һәм ил язмышы, дөнья даулары... Өлкән буын — сабыйлар киләчәге өчен җаваплы. Ә өлкән буынның васыяте, калдырачак эшләре — сабыйларда. Тормышчан, гади генә детальләрне автор калку итеп күрсәтә алган. Ләкин шулай да фикер җегәре, фәлсәфи тирәнлеге ягыннан караганда «Уйна, улым!» әсәре поэма жанрын күтәреп җиткерә алмый кебек.

Үзенең сокландыргыч картиналарында табигатьне психологик һәм романтик рухта чагылдырган Куинджи иҗаты белән Р. Әхмәтҗановның пейзаж лирикасы арасында ниндидер охшашлык бар. Шагыйрь табигатьне үз күңеле аша үткәрә, төсләр чагылышын бирә белә. Кеше белән табигать арасында охшаш якынлык эзли. Табигать күренешләре хис, фикер белән, шагыйрьнең эчке дөньясы белән тыгыз бәйләнештә ачыла.

...Тау артыннан ишетәм туган якта
әрекмәнгә
тамчы
тамганын!

(Авылым.)

Шагыйрь рәсемләү аша тойгы, хатирә уята. Аерым юлларны карыйк: «Камылларга тулган зәңгәр таңмы», «Киртәләргә кунган көмеш көрпә», «Яфрак арасында яшелләнә җиле». Роберт гади күз белән искәрелмәгән шагыйрәнә матурлыкны җаны белән тоя. Шагыйрьнең принцибы мондый: «ничек күренә түгел, ә мин ничек күрәм».

Дөньяның күренешләрен җанландырып тасвирлау да Р. Әхмәтҗановка хас бер сыйфат: «Сарыктай бөдрә болытлар», «Яңа туган бозау шикелле җир парлана», «Ап-ак таңның уйнак өермәсе муйнак булып каба чабудан».

Ләкин, картинасына килешсез төс белән сызып җибәргән рәссам кебек, шагыйрь кайчагында гомуми тонны бозып ташлый: «тот болытны ап-ак сакалыннан» — бусы инде шигырьгә ясалма канат кую.

Тәлгат Галиуллин үзенең бер мәкаләсендә болай дигән иде: «Р. Әхмәтҗанов үзенчәлекле шигъри ачышлары белән эзләнергә, тәҗрибәләр ясарга хакы бар икәнен раслады. Ләкин шагыйрьнең тәҗрибәләр чоры озаккарак сузылды шикелле». Моның белән килешеп бетәсе килми — һәр иҗади әсәр эзләнү, тәҗрибә түгелмени! Шулай булмаса, сәнгать әһеле бер урында таптанып, ирешелгән белән генә канәгатьләнеп калыр иде.

Традицион стильдә генә язган шагыйрьгә форма ярлылыгы турында искәртеп тә, төрле стильдә язган шагыйрьләрне (әлбәттә, сүз яшьләргә кагыла) формализмда гаепләү кайбер тәнкыйтьчеләрдә шаблонга әйләнде түгелме?

Пикассо үзен формализмда гаепләүчеләргә: «Мин формалар эзләмим, ә табам», — дигән. Бу сүзләр Роберт иҗатына карата да урынлы булыр иде.

Ритмик төзелешнең байлыгы Р. Әхмәтҗановның яңа формалар эзләү белән мавыгуыннан тумый. Тирә-юньдә бер генә хәрәкәт тә билгеле бер ритмда бармый, шул җәһәттән кеше күңеле, кичерешләре дә. Тышкы форма, ягъни сүзләр чигеше белән эчке, логик фикер агышын тәңгәлләштерә алу осталыгы Р. Әхмәтҗанов иҗатының буеннан-буена килә.

«Еллар яна» җыентыгыннан «Сабыйлар иле» шигырен алыйк. Кичке шәһәр урамы. Шагыйрьнең күзе урам ыгы-зыгысында чана тартып кайтучыларга төшә. Чаналарда — «галиҗәнаб сабыйлар».

Киемнәре төрле,
йөзләре төрле,
күзләре бер.
Сабыйлык кояшы аларда,
авазлары төрле,
адымнары төрле,
эзләре бер.

Шагыйрь урам хәрәкәтенең ритмын биргән бит. Менә көзге ритм:

Узып китте август, келтә төяп,
капчык төяп китте ындырлардан.
Камылларны чиртеп исә җилләр,
алтын гөслә зыңлый киң кырларда,

(Туган йортта сентябрь.)

Ритмның эчтәлек белән ярашуы шигырьнең үз аһәңен, музыкасын тудыра. Шагыйрь ритм нечкәлеген тою осталыгына ия, шуңа күрә Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган көйләрнең яшәеше нык. Халык арасында киң таралган җырлардан «Солдатлар», «Саумы, Кояш», «Кояшларың белән кил син миңа», «Синең эзләр» — шуның ачык мисалы.

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы кояшлы. Лирик герое инсафлы, мәхәббәткә мөнәсәбәтен ул якты образлар аша белдерә. Шигырьнең тематикасы төрле. Эзләнү, юксыну, көтү, ышану, юану. Шагыйрь һәр шигырендә яңа лирик «мин»не тудыра. «Каеннарны үт тә сугыл миңа» шигыре һәркемдә була торган изге кичерешләргә кагыла. Шигъри җанлы укучы күңелендә поэма булып дәвам итә.

Объектив дөнья белән эчке, үз дөньясы арасындагы мөнәсәбәт, бердәмлек шагыйрь иҗатында ныгый бара. Шигърият, илаһи символлардан арынып, җиргә якыная, матурлыкны әйләнә-тирәдән эзли. Шагыйрьләр көрәшче булган бу дәвердә шәхес, җәмгыять һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләр шигъриятә хис һәм фикер гармониясендә яңа яңгырашларын тапты.

Халыкларның шигърият диңгезенә үз дулкының белән кушылу өчен сәләтле шагыйрьдән киңрәк планлы, иҗтимагый фикер тирәнлегенә ия булган әсәрләр талэп итәргә хаклыбыздыр.

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

# ЯЗУЧЫНЫҢ ТЕЛ ОСТАЛЫГЫ ҺӘМ ТӘРҖЕМӘ

Татар совет әдәбиятында үзләренең кабатланмас стиль үзенчәлекләре белән нык аерылып торган тел осталарыбыз Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, И. Гази, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев һ. б. исемнәренә соңгы елларда тагын бер язучының исеме өстәлде. Телгә таләпчәнлек, халыкның тел байлыгын оста куллана белүе белән дә күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итте ул. Мин китап укучылар арасында искиткеч тиз танылып өлгергән М. Мәһдиевне күздә тотам. Аның беренче хикәяләре, «Без — кырык беренче ел балалары» повесте, «Фронтовиклар» романы яратып каршы алынды. Теленең камиллеге, табигый яңгыраш-интонацияләре белән «Без — кырык беренче ел балалары» повесте аерым бер урын алып тора. Бик җыйнак кечкенә новеллалардан торган бу повестьта яшьлекләре Бөек Ватан сугышының авыр елларына туры килгән педучилище укучыларының тормышы сурәтләнә. Повестьның җанлы сөйләм теленә нигезләнгән булуы, бигрәк тә беренче зат тарафыннан язылуы аның яңгырашын, стилен билгели. Автор телнең бөтен мөмкинлекләрен нечкә тоеп эшкә җигә белә, Бөек Ватан сугышының дәһшәтле елларын чагылдырган әсәрне дә ниндидер моңсу, җылы юмор белән үреп бара белә, анда авторның шул елларда үзе белән бергә тормыш авырлыгын җилкәләрендә күтәреп барган курсташларына да, укытучыларына карата да зур мәхәббәтен тоярга мөмкин.

Мондый әсәрнең тиз арада рус теленә тәрҗемә ителеп 50 мең тираж белән басылып чыгуын, һичшиксез, котларга кирәк [1].

Тәрҗемә итүе җиңел булган язучылар һәм шагыйрьләр бар. Әмма кайбер әдипләрнең тел байлыгын икенче телдә бирү кайчак зур каршылыкларга очрый. Татар әдәбиятында үзенең кабатланмас теле белән аерылып торган Ә. Еники, Ф. Хөсни әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү бик кыен эш исәпләнә. Күрәсең, шундыйлар рәтенә М. Мәһдиевне дә кертәсе булыр. Һәр сүзнең мәгънәви төсмерләрен, башка күчерелмә мәгънәләрен нечкә тоеп язу, гомумхалык теленең бөтен грамматик байлыгын урынлы куллану менә шушы кабатланмас стильне тудырадыр да инде.

Тәрҗемә оригинал турында мөмкин хәтле дөрес күзаллау бирергә тиеш. Оригиналны ярлы итеп күрсәтү, русча укучы күп миллионлы аудиториядә аның турында уртача фикер тудыру белән һич тә килешергә ярамый. Алда күрсәтелгән әсәрнең бизәкләргә бай булган, сугыш елларындагы авыл тормышы күренешләрен бер сүз белән дә бирә алырдай сурәтләрен саклау тәрҗемәче алдында торган гаять әһәмиятле бурыч иде. Әмма «бодай башы уып ашаган», «үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр төтенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан», аерылып килгән авыл малайларын тасвирлаучы бик күп төгәл эчтәлекле сүзләр, тәгъбирләр тәрҗемәдә чагылыш тапмаганнар. Алай гына да түгел. Повестьтагы Әркәшә Пермяковның кыска гына тормышы да, Әлтафиның авыл малайларына гына хас җорлык белән әйткән сүзләре дә, рәсем укытучысы, алтмыш биш яшьлек Иван Георгиевичның биографиясе дә, ата кара тараканның кан әйләнешен сөйләп бирә

[1] М. Магдиев. Мальчишки сорок первого. Пер. Э. Салеховой. Казань. 1974.
Бу урында шунысын да әйтеп китик. Татарча басмага керми калган бүлекләр дә өстәлгәнлектән, тәрҗемәдә әсәрнең гомуми күләме артыграк чыккан.

алмагач, завхоз-укытучының Әркәшәгә дигән ипи карточкасын алу белән янавы һәм малайның шуннан соңгы олы кешеләрчә уйлану-борчылулары да, балаларның «Игорь полкы турындагы җыр»ны укыткәндә кичергән хисләре һ. б. шундый характерлы сурәт-тасвирлар ни өчендер бөтенләй тәрҗемәдән төшеп калган. Кайбер бүлекләр бермә-бер кыскартылганнар. Мәсәлән, беренче новелланың бик матур лирик башлангычы, унынчы новеллада рус теле укытучысының «Разгром» әсәрен укыгандагы тәэсирләрен сурәтләгән дистәләрчә чын шигъри юлларның тәрҗемә ителми калуы күңелдә ризасызлык тудыра. Дөрес, кайбер дорфарак күренгән өзекләрнең төшеп калуы белән, әлбәттә, килешергә кирәк (бер солдатканың төнлә белән ире кайтып керү эпизоды һ. б.).

Әсәрнең төп үзенчәлеген без юморның тыйнаклыгында, моңсулыгында дигән идек. Автор бер дә бәйләнеше булмаган әйберләрне белдерүче сүзләрне янәшә китереп куя да, ирексездән елмаясың. Мәсәлән, оригиналында рәсем ясап харап булган Әркәшәгә автор «натуралист» дигән сүзне өсти. Тәрҗемәдә бу эпитетның төшеп калуы һич тә акланмый. Исемлек тикшергәндә бераз онытылып киткән Әркәшә урынына Әлтафиның, нәкъ Әркәшә кебек борын авазларыннан башка гына әйткән «пид» («мин») сүзе өчен, завхоз тарафыннан «шовинист» дип аталуына ничек елмаймыйсың инде? Оригиналдагы «Шулай горур кыяфәттә шовинист Әлтафи коридорга чыгып китте. Класста иң арткы партада натуралист Әркәшә генә ятып калды» дигән җөмләләрне дә тәрҗемәче никтер артык санаган.

Икенче бер очракта автор, юмор алымы итеп, персонажларның дулкынланудан иҗекләрне алыштырып сөйләвен куллана (тел белеме фәнендә аны метатеза дип атыйлар һәм ул күренеш янәшә бер төрле авазлар килгәндә күзәтелә). Борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнмәгән Әркәшәнең ата кара тараканның кан әйләнеше турындагы җавабы гына да, Гыйззәтуллинның рус теле дәресендә «Надание на дом... надано на дом... Задано на ном...» дип, география дәресендә «саф һава» урынына «хаф сава» дип интегүләре генә дә ни тора бит?! Тәрҗемәдә бу юморның әсәре дә калмаган. Сурәтләү чараларының, эпитетларның югалуын менә бу юлларны чагыштырып кына да күрергә була:

**Бәлки, күңеле белән ул да үзенең туган җире Латвиянең сагыз исе килеп торган наратлы урманы эчендә йөридер. Хыялы белән, бәлки, ул юка ботинка эчендә каткан аякларын Балтик диңгезе буендагы сары, җылы, эре комда бастырып торадыр. Ярмалы карны шәфкатьсез рәвештә биткә бәреп торган тыштагы буран, бәлки, аңа июль аендагы диңгезнең ак дулкыннарын салмак кына Рига пляжына тәгәрәтүен хәтерләтәдер.**

**Мыслями-то, наверно, она далеко отсюда, в родной Латвии. Бродит где-нибудь меж высокими соснами и греет озябшие ноги в желтом песке Балтийского побережья. И, может быть, в эту непогоду с грустью вспоминает солнечные дни на Рижском взморье...**

Автор җанлы сөйләмне колакка ишетелеп торгандай итеп бирә ала. Авыл малайларының телен ымлыклардан, күчерелмә мәгънәдә кулланылган гади сөйләм сүзләреннән, үзенчәлекле итеп төзелгән һәм яңгырашы ук ишетелеп торган җөмләләрдән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Бу үзенчәлекләр тәрҗемәдә төссезләнеп калганнар. Бер мисал:

**— Нәрсә бу; бигрәк тагын, мыскыл итәм дигәч тә!**
**— Ие! Кызлар белән түгәрәк уйнарга, бигрәк тагы! Ничә ел колхозда эшләгән башың белән оялмыйча.**
**— Һи, исегез киткән икән, уен уйнау мәҗбүри түгел. Чыкмыйм мин и в ч у. Анысына билге куя алмый ул!**

**— Что это, насмешка!**
**— Чего захотели! Водить хороводы с девчонками!**
**— Нашли дураков. За игры не ставят отметки...**

Автор геройларының һәрберсенең сөйләү үзенчәлекләре бар, тәрҗемәдә исә боларның берсе дә чагылыш тапмаган.

Авыл тормышы өчен гаҗәп табигый, үз булган реалияларны да тәрҗемәдә тану авыр: сөт салган чирек литрлы шешә «четверть с молоком» дип, кара мунча — «по-черному баня», кул сугыш уйнау — «кулачный бой», тегермән тәгәрмәче — «водяное колесо» дип бирелгәннәр. Авылдан килгән балаларның гадәт буенча Исмәгыйл абый дип эндәшүләрен сакламыйча, Исмәгыйль Идрисович дип бирү дә үзен акламый.

Әнә шулай итеп, тәрҗемәдә авторның поэтик теле, риторик эндәшләре, синтаксик кабатлаулар, нечкә чагыштырулар, портретны бер-ике штрих белән сурәтләү осталыгы, персонажның сөйләм үзенчәлекләре, урынлы кулланылган тапкыр сүзләр, гомумхалык сөйләм теленең ялтырап-ялтырап киткән сүз формалары тиешенчә чагылыш тапмаган.

Тәрҗемә итү — әсәрнең сюжетын, канвасын гына сөйләп чыгу түгел. Ул әсәрнең авторын да күз алдына китереп бастырырга тиеш. Рәсүл Гамзатовның «Минем Дагстаным» әсәрен В. Солоухин оригинал кебек укыла торган әсәрдәй тәрҗемә иткән бит! Анда Р. Гамзатовның интонациясе яңгырап тора! Татар әдәбиятының тәрҗемәләрендә дә милли үзенчәлекләрне, әсәрнең тел байлыгын тулы чагылдыру тәрҗемәченең төп максаты булырга тиеш.

**Ф. САФИУЛЛИНА,**
филология фәннәре кандидаты

## Укучылар игътибарына

Журналыбызның быелгы 2 санында басылган «Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы» исемле мәкаләдә хаталар киткән. Аларны төзәтеп укуыгызны үтенәбез.

| Бит | Юл | Басылган | Укырга |
|---|---|---|---|
| 150 | өстән 1 | тәкъдим | тәкълид |
| 150 | өстән 15 | фәнни | дини |
| 152 | өстән 7 | күп | үк |
| 153 | өстән 15 | бер | без |
| 154 | өстән 17 | тәкъдидчелеккә | тәкълидчелеккә |
| 155 | астан 27 | Шәрыкта | шәргъгә |
| 156 | астан 13 | иҗмал | иҗмаг |
| 156 | астан 11 | Коръәннәр | Коръән |
| 158 | өстән 23, 24 | мәкаль | нәкыль |

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ПУШКИН БӘЙРӘМЕ

Шушы елның июнь аенда бөек рус шагыйре, илебез халыкларының мактанычы һәм горурлыгы, совет илендәге барлык милләтләрнең уртак шагыйре Александр Сергеевич Пушкинның тууына 175 ел тулды. Шагыйрь бәйрәме гаять тантаналы шартларда, зур итеп билгеләп үтелде.

6 июньдә Кремльнең Съездлар сараенда А. С. Пушкин истәлегенә багышланган тантаналы кичә булды. Кичәне, даһи шагыйрь иҗатының дөньякүләм әһәмияте хакында кереш сүз сөйләп, СССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Г. М. Марков ачты. РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре В. Д. Федоров шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад ясады. Ахырдан сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде.

Тантаналы кичәдә партия һәм хөкүмәт житәкчеләре катнашты.

А. С. Пушкинның тормыш һәм иҗаты белән бәйле урыннарда уздырылып килгән традицион шигырь бәйрәмнәре быел аеруча зур колач алды. Ул бәйрәмнәрдә безнең республика шагыйрьләре дә якыннан катнашты. Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин Псков шәһәрендә һәм Михайловскоеда уздырылган бәйрәмнәрдә булды һәм чыгыш ясады. Зөлфәт белән Г. Паушкин Горький өлкәсенең Болдино авылында уздырылган бәйрәмдә катнаштылар.

*
* *

А. С. Пушкинның 175 еллыгын Татарстан хезмәт ияләре дә зурлап үткәрделәр. Газета-журналларда шагыйрь иҗаты, аның татар әдәбияты үсешенә ясаган уңай тәэсире хакында бик күп мәкаләләр басылды, культура сарайларында, китапханәләрдә, уку йортларында һәм музейларда юбилейга багышланган кичәләр уздырылды.

*
* *

8 июньдә Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында А. С. Пушкинга багышланган кичә булды. Аны, Татарстан язучылар союзы белән берлектә, хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма комитетының культура бүлеге үткәрде. Кичәдә татар әдипләреннән Г. Ахунов, Ә. Исхак, Ә. Баянов, Зөлфәт, рус язучылары Г. Паушкин, Г. Никитина, М. Зарецкий, Н. Морозовалар катнашты. Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары көче белән концерт бирелде.

*
* *

Татарстан дәүләт музеенда даими төстә үткәрелә торган әдәби кичәләрнең берсе бөек рус шагыйре А. С. Пушкинга багышланган иде. Анда А. С. Пушкинның Ленинградтагы Бөтенсоюз үзәк музее фәнни хезмәткәре Л. Б. Сидоровская дөнья әдәбияты даһиенең тууына 175 ел тулуга карата мавыктыргыч доклад сөйләде, шагыйрь тормышына бәйләнешле диапозитивлар күрсәтте.

Соңыннан В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры артисткасы Л. Дмитриева А. С. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» дигән поэмасын укыды.

*
* *

Татарстан дәүләт музеенда «Пушкин иҗатында Пугачев» дигән күчмә күргәзмә ачылды. Ул Пушкинның Ленинградтагы Бөтенсоюз музее тарафыннан оештырылган һәм Емельян Пугачев житәкчелегендәге крестьяннар сугышының 200 еллыгына һәм А. С. Пушкинның тууына 175 ел тулуга багышланган.

Йөздән артык экспонат арасында төрлетөрле портретлар, иске акварельләр, архив документлары һәм башка материаллар бар. Күргәзмәнең бер бүлеге Пугачев хәрәкәтен тудырган чорны сурәтли. Икенче бүлектә бөек рус язучысының крестьяннар хәрәкәте барган җирләрдә йөрүе турында сөйләнә. Өченче бүлек Пушкинның «Капитан кызы» әсәренә иллюстрацияләрдән тора. Алар Соколов, Коровин, Бенуа, шулай ук совет чоры рәссамнары Кожин, Герасимов һәм Бунин тарафыннан ясалган.

Бу күргәзмә үзенең юлын Оренбургта башлаган иде. Ярты ел эчендә ул Уральск, Ульяновск, Тольятти, Чаллы шәһәрләрендә булырга өлгерде.

## ОКТЯБРЬГА БАГЫШЛАП

Бөек Октябрь революциясе вакыйгаларын еллар бездән ераклаштырган саен, Октябрь кояшы нурлары ныграк балкый бара. Кешелек тарихында аның әһәмияте

елдан-ел калкурак булып күренә. Бөек Октябрь хәл иткән күпьяклы проблемаларны өйрәнүгә фән работниклары да һаман күбрәк тартыла. Моны тарихчыларның даһи Ленин туган шәһәр — Ульяновскида «Идел буенда Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы» дигән темага багышлап уздырылган фәнни конференциягә ачык күрсәтте. Аның эшендә Мәскәү, Волгоград, Казан, Куйбышев, Ульяновск һәм Чабаксардан килгән иллегә якын тарихчы катнашты. Алар арасында Казан вәкилләре аерата күп иде.

Конференциядә Казан дәүләт университеты профессоры И. М. Ионенко «Бөек Октябрь революциясен өйрәнүнең нәтиҗәләре һәм перспективалары», Казан галиме, доцент А. Л. Литвин «Идел буенда гражданнар сугышын өйрәнү нәтиҗәләре» дигән темага докладлар белән чыктылар.

Фикер алышуларда профессорлардан Р. И. Нәфиков, И. Д. Кузнецов, С. Г. Басин һәм башка иптәшләр катнашты.

Секция утырышларында Бөек Октябрь социалистик революциясенең ничек хәзерләнүе һәм үткәрелүе, бу революциядә милли азатлык хәрәкәтенең роле, резолюция һәм гражданнар сугышы чорында гомум демократик һәм социалистик үзгәртеп корулар хакында яшь тарихчыларыбыздан Р. Г. Хәйретдинов, И. Р. Таһиров, М. А. Мулюков, И. Г. Гыйззәтуллин, К. Ф. Фролов, В. М. Бохараев һәм башка иптәшләр кызыклы чыгышлар ясадылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

7 июньдә Татарстан язучылар союзы партия оешмасының бюро утырышы булды. Утырышта оештыру мәсьәләләре каралды. Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе итеп сайлану сәбәпле, Гариф Ахунов партия оешмасы секретаре вазифасыннан азат ителде. Татарстан язучылар союзы партия оешмасының секретаре итеп язучы Габдрахман Минский сайланды.

## КИНЕМАТОГРАФЛАР КИҢӘШӘ

Июнь башларында башкалабыз Казанда кинематографларның IV Бөтенроссия конференциясе булып үтте. Конференция эшендә Россия Федерациясенең унбер студиясеннән килгән режиссерлар, кинооператорлар катнашты. Алар бернichә көн буена экранда хезмәт кешесе образын чагылдыру мәсьәләләре турында җитди һәм эшлекле сөйләшү алып бардылар. РСФСР кинематографлары тарафыннан эшләнгән яңа фильмнарны карадылар. Конференция делегатлары КамАЗ төзелешендә һәм Чаллы шәһәрендә булдылар, тамашачылар белән очраштылар.

Конференция барган көннәрдә республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында кинодокументалистларның иң яхшы фильмнары күрсәтелде.

Конференция эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге инструкторы М. М. Доценко, РСФСР Госкино председателе урынбасары Г. И. Нифонтов, КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, шулай ук республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол һәм иҗат оешмалары вәкилләре катнашты.

## ЯШЬ ИҖАТ КӨЧЛӘРЕ СЕМИНАРЫ

Май ахырларында Идел буендагы Халыкара яшьләр лагеренда яшь иҗат көчләренең республика семинары үткәрелде. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан оештырылган өч көнлек семинарда яшь язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар катнашты. Алар социалистик реализм сәнгатенең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алыштылар, төрле темаларга караган лекцияләр тыңладылар, бер-берләренең иҗаты белән таныштылар, тәҗрибә уртаклаштылар. Семинар республиканың яшь иҗат көчләрен тагын да ныграк тупларга, аларның иҗат активлыкларын арттырырга булышты.

Семинар эшендә татар язучыларыннан бик күп кеше катнашты. Алар арасында тәнкыйтьче Р. Мостафин, драматург һәм прозаик Р. Батуллин, шагыйрьләрдән Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Ф. Шәфигуллин, З. Маликов, М. Әгъләмов, яшь һәм башлап язучылардан Ә. Гадел, М. Газизов, Х. Хөснуллин, Р. Вәлиев, Р. Гыйззәтуллин, Ә. Мортазина, Н. Гыйматдинова, Ш. Гарипова һәм башкалар бар иде. Язучылар яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Ф. Яруллинның «Әнә килә автомобиль» исемле комедиясе буенча эшләнгән яңа спектакль бара. Аны театрның баш режиссеры, Тукай премиясе лауреаты М. Сәлимҗанов куйган, художнигы — Э. Гельмс. Спектакльдә рольләрне урта һәм яшь буын артистлар башкара.

*
* *

Әлмәт татар дәүләт драма театры тамашачыларга Ш. Рәхмәтуллинның «Әҗәл якадан алгач» дигән сатирик комедиясе буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтә башлады. Әсәрне сәхнәгә театрның баш режиссеры Л. Садриев куйган. Спектакльдәге рольләрне Татарстан АССРның атказанган артистлары Диләрә Хисаметдинова, Әхмәт Галиәкбәров, Рамазан Юсуповлар һәм театрның яшь артистларыннан Гыйлемхан Камалов, Дамирә Кузаева, Идрис Мәсгутов, Иршат Зыязетдиновлар башкара.

*
* *

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә И. Кальманның «Монмартр миләүшәсе» исемле әсәре буенча эшләнгән оперетта

бара. Яңа спектакльнең режиссеры — И. Мәҗитов, дирижеры — В. Тагиев, художнигы — А. Кноблок. Биюләрне хормейстер Т. Гудкова куйган.

* * *

Татар дәүләт республика курчак театры Аяз Гыйләҗевнең «Сары чәчәк ата көнбагыш» исемле героик драмасын күрсәтә башлады. Әсәрне сәхнәгә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Тумашев куйган. Художнигы — П. Баландин.

### ЯҢА ФИЛЬМНАР

Республика тамашачылары быел Казан телестудиясе тарафыннан эшләп чыгарылган берничә фильм караганнар иде инде. Алар арасында даны бөтен илгә танылган «Академик Арбузов», табигатьне саклауга багышланган «Сосны, освещенные солнцем» исемле фильмнар һәм «Гали Ильясов җырлый» дигән фильм-концерт бар.

Быел телестудия тагын берничә яңа фильм төшерәчәк. Режиссер В. Беспалов, мәсәлән, «Кырлай» исемле музыкаль фильм өстендә эшли башлады. Исеменнән үк күренеп тора, бу фильм бөек шагыйребез Габдулла Тукай яшәгән Кырлай авылы турында булачак. Ә «Без Иделдә яшибез» дигән төсле документаль фильм Татарстан пионерлары тормышына багышлана. Аны режиссер В. Игнатюк һәм оператор Ю. Гвоздь эшләячәк.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет кинематографиясе өлкәсендәге хезмәтләре өчен ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә Казан кинохроника студиясе кинооператоры **Константин Федорович Мотковка** һәм шушы үк студия режиссеры **Харис Фәсхи улы Фәхретдиновка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе**, ТАССР Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитеты кинооператоры **Виталий Григорьевич Миронов** һәм Казан кинохроника студиясенең монтажлау участогы өлкән мастеры **Тамара Леонидовна Федоровага Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

### ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казанның Актерлар йортында опера театрының яшь җырчылары Рәхилә Мифтахова һәм Рәйсә Нуриевалар иҗатына багышланган кичә булды. Ике бүлектән торган кичәдә җырчылар рус һәм татар композиторларының, шулай ук чит ил классикларының күп кенә әсәрләрен, татар халык җырларын башкардылар. Концертта ТАССР Верховный Советы исемендәге Казан музыка училищесының Роза Әмирханова җитәкчелегендәге халык музыка кораллары оркестры катнашты.

Кичәне музыка белгече З. Мулюкова алып барды.

### ЖУРНАЛИСТЛАР УДАР ТӨЗЕЛЕШЛӘРДӘ

Чаллыда һәм Түбән Камада республика газеталары һәм журналлары редакторлары, радио һәм телевидение, китап нәшрияты җаваплы хезмәткәрләренең киңәшмәсе булды. Партия, профсоюз, комсомол работниклары, матбугат активистлары катнашкан бу киңәшмәләрдә КамАЗ һәм нефть-химия предприятиеләре комплексын төзүгә бәйләнешле мәсьәләләрнең республика матбугатында яктыртылуы тикшерелде, тугызынчы бишьеллыкның удар төзелешләрен пропагандалауны яхшырту чаралары билгеләнде.

Журналистлар һәм эшче-хәбәрчеләр алдында партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. К. Беляев, партиянең Түбән Кама шәһәр комитеты беренче секретаре И. Х. Садыйков, КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. И. Демидов чыгыш ясады.

### КИТАП КҮРГӘЗМӘСЕ

Башкалабыз Казанның Бауман урамына урнашкан политик китаплар кибете үч көн буе шаулап-гөрләп торды. Биредә «Россия Федерациясе нәшриятларында чыккан китаплар» дигән зур күргәзмә эшләде. РСФСР Министрлар Советының нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе Дәүләт комитеты карары белән оештырылган бу күргәзмә тугандаш халыкларның тату гаиләсендә чәчәк аткан милли культураларның олы бәйрәменә әверелде. Рус, татар, башкорт, чуваш һәм башка күп кенә телләрдә басылган шигъри җыентыклар, фотоальбомнар, беллетристика бирегә килүчеләр күңелен бик тиз яулап алды.

Күргәзмә экспозициясе «Бертуган россияннар гаиләсендә» «Сүз рәссамнары — халыкка», «Китап нәниләргә яңа мохитлар ача», «Гүзәллек дөньясында», «Татарстан нәшрияты китаплары» дигән бүлекләрдән төзелгән иде. Витриналарның, стендларның, киштәләрнең зәвык белән бизәлүе әллә кайдан үзенә тартып тора.

Күргәзмәнең республикабыз буйлап сәяхәте дәвам итә. Казан шәһәреннән соң ул Кама автомобиль заводын төзүчеләргә юл алды.

### ӘЛМӘТ ЯКЛАРЫНДА

#### Утыз ел юлда

Әлмәт татар дәүләт драма театрының төзелүенә 30 ел тулды. Шул вакыт эчендә, шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга йөреп, ул меңнәрчә кешегә культура хезмәте күрсәтте, совет драматургларының, татар, рус һәм чит ил классикларының 200 гә якын әсәрен сәхнәгә куйды. Моннан утыз ел элек үзешчән сәнгать түгәрәге базасында оештырылган бу театрда танылган сәхнә оста-

лары үсеп чыкты. Алар арасында Татарстан АССРның халык артистлары Ә. Галиуллин, Р. Гобәйдуллина, З. Туишева, Татарстан АССРның атказанган артистлары Б. Гатауллин, Т. Кичүбаев, Ә. Галиәкбәров, Л. Садыйкова, Л. Солтанова кебек кешеләр бар.

Иҗади уңышлары һәм хезмәт җиңләренә әйбәт культура хезмәте күрсәткәне өчен, театр коллективы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Мактау грамотасы** һәм **СССР Культура министрлыгының дипломы** белән бүләкләнде.

*
* *

Язучыларның Әлмәт бүлегендә уздырылган чираттагы семинарда яшь язучы Газиз Кашаповның хикәяләре һәм шигырьләре тикшерелде. Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, С. Сөләйманова яшь авторның әсәрләренә төпле анализ ясадылар, киңәшләр бирделәр.

*
* *

Казан телевидениесеннән «Мәхмүт Хәсәновның геройлары арасында» дигән бер сәгатьлек тапшыру оештырылды. Тапшыруда бүлек язучыларыннан Р. Төхфәтуллин һәм М. Хәсәнов катнашты.

*
* *

Тамашачыларга Зәйни Шаһиморатовның «Уеннан уймак» дигән өч пәрдәлек музыкаль комедиясен күрсәтеп, Әлмәт халык театры үзенең олы иҗат юлын башлап җибәрде. Аны сәхнәгә яшь режиссер Гөлсинә Сөләйманова куйды. Декорацияләрне һәвәскәр рәссам Марсель Зиннәтуллин ясады. Төп рольләрне үзешчән артистлар А. Ибраһимов, Н. Заһидуллина, К. Сәитова һәм М. Галәлиевләр башкарды.

Хәзер театр коллективы башкорт драматургы Нәҗип Әсәнбаевның «Рәйсә» дигән драмасын сәхнәгә куярга әзерләнә.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

«Казан утлары» журналы редакциясе бу елгы саннарның эшен тәгәлләп килә. Шул ук вакытта 1975 елның планын төзүгә дә кереште. Редакциябезгә килгән хатларга караганда, 1974 елда басылган күп кенә повесть һәм хикәяләрне, шигырьләрне, алдынгы кешеләребез турында язылган очеркларны яратып укыгансыз. Әдәбият фәненә, әдәби тәнкыйтькә караган материалларны зур кызыксыну белән күзәтеп баргансыз. Журналның соңгы битләрендә урнаштырыла торган әдәбият һәм сәнгать яңалыклары да сезгә күп мәгълүматлар биргән.

Журналны яратып укуыгыз һәм аның аерым саннары, төрле әсәрләре турында фикерләрегезне язып торуыгыз өчен редакция сезгә зур рәхмәтен белдерә.

«Казан утлары» журналының 1975 елгы саннары да сездә зур кызыксыну уятыр дип өметләнәбез.

Язучыларыбыз, тел һәм әдәбият фәне галимнәре, тарихчылар, сәнгать эшлеклеләре һәм республикабызның башка күренекле кешеләре үзләренең повесть һәм хикәяләрен, поэма һәм шигырьләрен, истәлекләрен, фәнни хезмәтләрен редакциягә тәкъдим итә башладылар инде.

1975 елда басарга тәкъдим ителгән әсәрләр арасында Хәниф Хәйруллинның «Ана улларын барлый» һәм «Картлык кемгә шатлык» дигән повестьлары бар. Моннан элек бу авторның «Канатлар талмасын» дигән уңышлы әсәре белән танышкан идегез. Х. Хәйруллин яңа повестьларында да тормыштагы катлаулы мәсьәләләргә җавап табарга омтыла.

Әхәт Гафаровның «Яра» һәм Илдар Низамовның «Өмет» дигән повестьлары кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы, яшьләрчә кыюлык белән язылган, үзенчәлекле әсәрләр.

Гөлсем Мөхәммәдованың «Яшьлек еллары» дигән повесте Галимҗан Ибраһимовның тормышына багышлана. Мәхмүт Хәсәновның «Җилләр исә дә исә» әсәре колхоз кешеләрен сурәтли.

Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Гариф Ахуновлар да зур күләмле яңа әсәрләрен тәгәлләп киләләр.

1975 елда укучыларыбыз Хәсән Туфан, Әхсән Баян поэмалары һәм төрле буын шагыйрьләренең күп санлы шигырьләре белән танышачаклар.

Тугызынчы бишьеллык батырлары, республикабыз казанышлары, фән һәм культура яңалыклары турында да күп кенә кызыклы материаллар тәкъдим итәчәкбез.


Әдәби тел мәсьәләләре, әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтькә караган материаллар, яңа китапларга рецензияләр, художникларыбызның әсәрләреннән үрнәкләр, нотасы белән яңа җырлар һ. б. бирелеп барылыр.

Һәр вакыттагыча әдәбият һәм сәнгать яңалыкларына зур урын биреләчәк.

Хөрмәтле укучыбыз!

«Казан утлары» журналына сез 1975 ел өчен дә үз вакытында язылып калырга тырышырсыз дип өметләнәбез. Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылып була. Язылган вакытта 73210 номерлы индексны әйтергә онытмагыз.

Журналга язылу бәясе бер елга 6 сум.



Язучы ГОМӘР БӘШИРОВ.
З. БӘШИРОВ фотосы.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

1975 ел өчен «Социалистик Татарстан» газетасына язылырга онытмадыгызмы! Подписка һәркайда һәм чикләүсез алына.

Газета 1 январьдан даими килеп торсын дисәгез, шушы көннәрдә язылып калырга киңәш итәбез. Татарстаннан читтә яшәүчеләр подписка бәясен (елга 6 сум) түбәндәге адрес белән җибәрә алалар:

*420066, г. Казань,*
*ул. Декабристов, 12.*
*Республиканское агенство «Союзпечати».*
*Для газеты «Социалистик Татарстан»*
*на 1975 год.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210